ӘДӘБИЯТ

7

ӘДӘБИЯТ 7

Нык безнең әдәбият.
Аның җегәрендә – Тукайлар,
Җәлилләр, Туфаннар ныклыгы.

Сибгат Хәким

Ф. М. Хатипов, Ф. Г. Галимуллин

ӘДӘБИЯТ

Татар урта гомуми белем бирү мәктәбенең
7 нче сыйныфы өчен дәреслек-хрестоматия

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән

Үзгәртелгән дүртенче басма

КАЗАН
«МӘГАРИФ» НӘШРИЯТЫ
2006

УДК 373.167.1:821.512.145*07
ББК 83.3(2Рос=Тат) я721
Х36

Профессор **Хатипов Ф. М.**— мәкальләр, бәетләр, К. Насыйри, Г. Исхакый, Дәрдемәнд, М. Әмир, Ә. Еники бүлекләрен;
профессор **Галимуллин Ф. Г.** Г. Тукай, К. Тинчурин, Һ. Такташ, С. Хәким, Ф. Хөсни, Ф. Кәрим, Н. Арсланов, Г. Ахунов, Х. Сарьян бүлекләрен язды.

Фәнни редакторы — профессор *А. Г. Әхмәдуллин*

Охраняется законом РФ «Об авторском праве и смежных правах». Воспроизведение всей книги или ее части на любых видах носителей запрещается без письменного разрешения издательства.

Хатипов Ф. М.

Х36 Әдәбият : Татар урта гомуми белем бирү мәкт. 7 нче с-фы өчен дәреслек-хрестоматия / Ф. М. Хатипов, Ф. Г. Галимуллин.— Үзгәртелгән 4 нче басма.— Казан: Мәгариф, 2006.— 287 б.: рәс. б-н.
ISBN 5-7761-1600-7

ISBN 5-7761-1600-7
© «Мәгариф» нәшрияты, 2001, үзгәрешләр белән
© «Мәгариф» нәшрияты, 2006, үзгәрешләр белән
© Бизәү. «Мәгариф» нәшрияты, 2006

ХӨРМӘТЛЕ УКУЧЫЛАР!

Моңа кадәр дә сез халык авыз иҗаты, күп кенә язучылар һәм аларның әсәрләре белән таныштыгыз. Аеруча яратып укыган әсәрләрегез дә булды. Шактыен яттан да беләсез, аларны төрле кичәләрдә, өйдәге якын кешеләрегезгә, үзегездән кечеләргә күп мәртәбәләр сөйләп күрсәткәнегез бардыр. Игътибар итми калмагансыздыр, әдәби әсәрне укыганда, кешеләр үзгәрәләр: йә җитдиләнәләр, йә моңсуланалар, йә рәхәтләнеп көләләр. Димәк, әсәрдәге вакыйгалар мавыктыра, битараф калдырмый. «Китап» сүзе әнә шундый могҗизалы тәэсир көченә ия.

Әдәби әсәр кешенең карашларын киңәйтеп, хис-тойгыларын баетып кына калмый, яшәешнең гаҗәеп күп якларын укучы алдында ачып сала. Вакыйгаларда катнашучыларның рухи дөньясына үтеп керү, катлаулы хәлләрдә аларның ничегрәк эш итүләрен күзәтү укучы өчен кызыклы да, файдалы да. Ни өчен дигәндә, ул үзе дә геройлар кичергәнне кичерә, теге яки бу хәлдән чыгу юлын алар белән бергәләп эзләшә. Шуның нәтиҗәсендә укучы яңа уйлар, мәгълүматлар белән баеганын сизми дә кала. Әллә ничә еллар үткәч тә, ул укыган әсәрләрен, андагы геройларны, шул әсәрләрне укудан туган хис-кичерешләрен кабат-кабат исенә төшерә. Әсәр геройларының аңа тормыш юлын сайлауда ярдәм итүләре дә мөмкин. Димәк, әдәби әсәрләр безнең уй-хисләребезне тирәнәйтә, тормыш серләренә төшенергә ярдәм итә.

Быел җиденче сыйныфта сез әдәби әсәрләр һәм аларның авторлары турында тагын да киңрәк мәгълүмат алырсыз. Яңа басмада Һ. Такташның «Мокамай» әсәрен бирү тиеш дип табылды. Бу әсәрләрне өйрәнүдә, кадерле укучылар, сезгә уңышлар телибез. Ләкин уңышка ирешүнең бер мөһим шарты бар: ул да булса — мөстәкыйль уйларга өйрәнү. Әсәрне укып чыккач, андагы вакыйгалар турында нык лап уйларга, үз нәтиҗәгезне чыгарырга тырышыгыз. Уйларыгызны кәгазьгә

язып куйсагыз, тагы да әйбәтрәк булыр. Бу сезнең әсәрләргә генә түгел, чынбарлыктагы күренешләргә дә шәхси бәягезне булдырырга ярдәм итәр. Аннан соң әсәр турында дәреслектә язылган бәяләмә белән танышырга, анда язылганнарны үз хөкемең белән чагыштырып карарга мөмкин. Уйларыгыз авторларның бәяләмәләре белән туры киләме, юкмы икәнен бары тик шулай гына ачыклап була. Фикерләрегез дәреслектә язылганнар белән туры килеп бетмәсә, аларны дәлилли белергә дә кирәк. Ул чагында сорауларга һәм биремнәргә җавап табу тагы да кызыклырак, мавыктыргычрак булыр. Мавыгып уку һәм эшләү — кеше өчен олы бәхет ул. Без сезгә уңышлар, бәхет телибез!

Авторлар

ХАЛЫК ЗИРӘКЛЕГЕ, ПОЭТИК ИҖАТЫ

Амбар төбендә икмәк бар,
Картлар сүзендә хикмәт бар.

Халык мәкале

Кадерле балалар! Узган елларда без сезнең белән табышмак, әкият, мәзәк, җырлар өйрәндек. Аларның һәммәсен дә халык чыгарган, күңелендә, хәтерендә саклап килгән. Быел без мәкальләр, бәетләр белән танышырбыз, алардагы зирәклек, мәгънә тирәнлеген күреп сокланырбыз, шигъри фикерләү үзгәлеген тоярбыз.

ТАТАР ХАЛЫК МӘКАЛЬЛӘРЕ

1. Хезмәт. Һөнәр. Эш рәте белү. Ялкаулык

Эш сөйгән үкенмәс.
Хезмәт төбе — хәзинә.
Агач — җимеше белән, адәм — эше белән.
Эшләгән үлмәс, эшләмәгән көн күрмәс.
Хөрмәт сөйсәң, хезмәт сөй.
Эш — кешенең көзгесе.
Һөнәрле кул үлмәс.
Егет кешегә җитмеш төрле һөнәр дә аз.
Һөнәрне күтәреп йөрисе юк.
Һөнәре бар ургә йөзәр.
Күңел курка, кул эшли.
Башлаган эшне ташлама.
Күңел биреп эшләгән эш өлге булыр,
Күңел бирми эшләгән эш көлке булыр.
Ялкауга йомыш кушсаң, ул сиңа акыл бирә.
Йокы — ялкауның бәлеше.
Мич башында җиләк пешми,
Чалкан ятып, шалкан үсми.
Иренчәк ике эшләр.

2. Бердәмлек. Туганлык. Дуслык

Татулыкка тау да кызыккан.
Аерылганны аю ашар, бүленгәнне бүре ашар.
Ил белән этәргәч, тау күчкән.
Күмәкләшкән яу кайтарган.
Йөз сум акчаң булганчы, йөз дусың булсын.
Әйбернең — яңасы, дусның искесе яхшы.
Киңәшле эш таркалмас.

3. Ил. Йорт. Азатлык

Илгә таянган — Идел кичәр.
Туган-үскән җирдән дә матур җир булмас.
Ир егет үзе өчен туа, иле өчен үлә.
Иленнән аерылган — канаты каерылган.
Үз халкыңны үз итсәң, ят халыкка кол булмассың.
Дусыннан аерылган җиде ел елар,
Иленнән аерылган гомер буе елар.
Богау — алтын булса да богау.
Атаң булса да кол, син иреккә омтыл!

4. Кешенең рухи йөзе — холкы

Таш белән атканга аш белән ат.
Сабыр төбе — сары алтын.
Күрергә матур, акылга такыр.
Иркенлек — турылыкта, күркәмлек — холыкта.
Кешене беләсең килсә, холкына кара,
Баланы беләсең килсә, уенына кара.
Кеше холкын күзәт, үзеңнекен төзәт.
Яхшы холык дошманыңны үз итә.
Ниятең кәкре булса, юлның турылыгы файда итмәс.

5. Гаделлек. Гаделсезлек

Бай кисә — котлы булсын, ярлы кисә — кайдан алдың?
Без капчыкта ятмый.
Хан кан кояр, халык дан җырлар.
Бер ялганласаң, икенче чын сүзеңә дә ышанмаслар.
Дөрес сөйләгән ялгышмый.
Йөз явызлыкны бер дөреслек җиңә.
Хаклык өчен утка кер, суга төш.

6. Тел. Җыр. Белем. Акыл

Иң татлы тел — туган тел, анаң сөйләп торган тел.
Тел — ананың теләге,
Тел — ананың баласына иң кадерле бүләге.
Ана теле бер булыр.
Бит күрке — күз, тел күрке — сүз.
Иле барның теле бар.
Җыр — кешенең юлдашы.
Җырлап эшләсәң, җырлап яшәрсең.
Ил җыр белән яши.
Тел әйтә алмаганны җыр әйтер.
Җыр булган йортта бәрәкәт бар.
Кеше җырын җырлыйм дип, үз җырыңны онытма.
Белем байлыктан кыйммәт.
Белемдә көч.
Бәхетне юлдан эзләмә, белемнән эзлә.
Дөньяда иң зур байлык — белем.
Көчле кеше берне егар, белемле кеше меңне егар.
Акыллы әйтер — юл куйдым, ахмак әйтер — җиңдем.
Акыл — дәрья, уй — диңгез.
Алтының белән мактанма,
Акылың белән мактан.
Кешенең акылы сүзеннән билгеле.
Акыл яшьтә түгел, башта.

Сораулар һәм биремнәр

1. Мәкальләрнең туры һәм күчерелмә мәгънәләрен аңлатыгыз.

2. Мәкальләрдән нинди акыл, гыйбрәт алырга була?

3. Хезмәт, һөнәр, эш рәте белү, ялкаулык турындагы мәкальләрне искә төшерегез. Бу хакта тагы нинди мәкальләр беләсез?

4. Бердәмлек, азатлык турында халык нинди мәкальләр әйткән?

5. Мәкальләрдә халык кешенең нинди сыйфатларын мактый, кайсыларыннан көлә?

6. Тел, белем, акыл хакындагы мәкальләрнең зирәклегенә игътибар итегез. Алар хакыйкатьне дөрес чагылдыралармы?

7. Мәкальләрнең шигърилеге нәрсәләрдә күренә? Алардагы иҗекләрне санап карагыз, рифмаларга игътибар итегез. Мәкальләрне матур яңгырашлы, җиңел отып калырлык итүдә боларның әһәмиятен тоясызмы? Аларны күңелдән ятлап карагыз.

8. Мәкальләрдә янәшәлек, каршы кую (антитеза), охшатутиңләштерүләргә мисаллар китерегез, аларның образлылыкны көчәйтүдәге ролен күрсәтегез.

9. Өегездә өлкәннәрдән мәкальләр язып алыгыз.

Мәкальләрне икенче төрле «картлар сүзе» дип тә йөртәләр. Чөнки алар, күп яшәгән, акыл туплаган өлкән кеше фикерләре кебек, тормышның хикмәтле якларын аңлатып бирәләр, яшәеш серләрен тирәнтенрәк төшенергә булышалар. Халык телендә «Ачу — алдан, акыл арттан йөрер» дигән мәкаль бар. Моннан кеше үзе өчен бөтен гомеренә җитәрлек җитди нәтиҗә ясый ала. Ачулы, кызган чакта карар кабул итмә, суына төш, әнә шул чакта, ягъни акыл килгәч кабул итәрсең; ул баштагы ниятеңә охшармы, юкмы, шунда үзең күрерсең дигән мәгънә килеп чыга.

Мәкальләр тирә-юньне, тормышны игътибар белән күзәтү, сынау, гомумиләштерү җирлегендә туганнар. Алар билгеле бер дәрәҗәдә конкрет күренешнең аерым якларын, сыйфатларын да чагылдыралар. Мәсәлән, «Кунак булсаң, тыйнак бул» дигән мәкаль кеше өендә әдәпле, итагатьле булуның күркәмлеген раслый. Шул ук вакытта аны киңрәк мәгънәдә, ил-көн тормышына карата да кулланырга була. Әйтик, күрше мәмләкәткә кереп, төп халкының йола-гадәтләрен, телен-моңын, мәгърифәтен, иреген кысучылар колагына әйтү өчен, бу мәкаль бик урынлы.

Бериш мәкальләрнең хикмәте туры мәгънәсендә түгел, күчерелмә мәгънәдә кулланганда гына дөрес аңлашыла. Мәсәлән, «Сыерлар су эчкәндә, бозаулар боз ялый» дигән мәкальне алыйк. Чынлыкта мондый хәл — сирәк күренеш. Ләкин аны, өлкәннәр сөйләшкәндә, яшьләр колак салып тыңлап тора, зиһененә беркетә бара, дип аңласак, киңәшнең бик акыллы булганлыгы ачыклана.

Тормышта бик күп үзгәрешләр булып тора, карашлар, мөнәсәбәтләр алмашына. Әмма мәкальләр үз кыйммәтләрен югалтмыйлар. Алар, тәҗрибә, гомумиләштерү, нәтиҗә буларак, сүз арасына абруйлы дәлил, киңәшче, сабак рәвешендә кереп китәләр. Сөйләмнең мәгънә куәтен арттыралар, аңа образлылык, җанлылык өстиләр. Шул ук вакытта алар колакка ятышлы, ягымлы яңгырыйлар. Мәкаль, энҗе бөртеге кебек, үтә җыйнак жанр. Анда бер генә артык сүз дә очрамый. Биредә сүзләр бер-берсенә тыгыз ялганып киләләр, җиңел әйтеләләр, җырлап торалар. Күбесенә шигърилек хас — ритмлы, рифмалы,

иҗекләре тигез үлчәмле була. Күренешләр күбесенчә йә янәшә, йә каршы кую юлы белән билгеләнә. Чагыштыру, тиңләштерү аркылы артыклык яки кимлек күрсәтелә. Аларда халык зирәклеген, фәлсәфи карашларын, әхлак принципларын бер-ике җөмлә белән образлы итеп әйтеп бирү куәте бар.

Мәкальләребезне җыю, тәртипкә салу, фәнни өйрәнү өлкәсендә Татарстанның халык язучысы Нәкый ага Исәнбәт фидакарь хезмәт башкарды. Ул күп халыклар әдәбиятында тиңе булмаган өч томлы мәкальләр җыентыгы туплап бастырып чыгарды. Аларда тордәшләреннән башка гына да кырык мең мәкаль тупланган. Татарстан Фәннәр академиясенең Тел, әдәбият, тарих институты төзегән бер томлык мәкальләр һәм әйтемнәр җыентыгы 1987 елда дөнья күрде.

БӘЕТЛӘР

СӨЕМБИКӘ БӘЕТЕ

(Казанны алган көйгә)

Мең биш йөз унбиштә бу дөньяга килгәнмен,
Ата-ана дәүләтен китмәс диеп белгәнмен.

Ата-ана кулында бер кайгы да күрмәдем,
Бу кайгылар күрермен дип исәпләп тә йөрмәдем.

Сөембикә атым, нугай затым, кайда минем яшь дәүләтем,
Сабый чагым, нурлы йөзем, морза кызы булган вакытым?

Унсигез яшьләрем тулган чакларымда,
Хан хатыны булдым мин ата-ана хакларында.

Кырымнан Казанга китерде тәкъдирем,
Казанның яшь ханы Җангали булды ирем.

Җангали хан мәкътул[1] бер залим кулындан,
Бәндәгә казалар очрыйдыр юлындан.

[1] Мәкътул — үтерелде.

Ханбикә булгачдин ике ел торгачдин,
Тол калдым кайгылы, хан дөнья куйгачдин.

Сөембикә атым, нугай затым, кайда минем хан
дәүләтем,
Сылу чагым, нурлы йөзем, хан бикәсе булган вакытым?

Кырымлык Сафагәрәй Казанга хан булды,
Өч хатыны булса да, дүртенчегә мине алды.

Дөньялар хафалы, замана буталды,
Казанга күрше падишаһлар күз салды.

Казан эче тынычсыз, дошман бары беленә,
Дәүләте бар кешеләр керә кеше теленә.

Сафагәрәй вакытында бик күп булды сугышлар,
Һәркайдан яу килгәчдин, авыр булды сулышлар.

Гомерем үтте ундүрт ел Сафагәрәй хан белән,
Казан шәһәре күңелсез юлда түккән кан белән.

Шәһәр тышында сугыш, эчендә тулган афәт,
Шул тынычсыз вакытта Сафагәрәем вафат.

Ике яшьлек угылым, күзем нуры, колыным,
Үтәмешгәрәем калды ятим, былбылым.

Сөембикә атым, нугай затым, кайда минем яшь
дәүләтем,
Үзем дә тол, угылым ятим, кайда минем тыныч вакытым?

Мәскәү ханы Казанны алмак була үзенә,
Казанлылар фетнә ача, карамыйлар сүзенә.

Мәскәү ханы үгетли картны, яшьне, егетне,
«Бирелегез миңа,— ди,— тотармын җәбер итми».

Морзалар сүз аңламый, көчләре аз сугышка,
Ничә кабат сүз бозып барды алар солыхка.

Солых шартын тагын да бу морзалар боздылар,
Нугай, Кырым, казанлылар төрле җиргә туздылар.

Хан урынына хан булып, таралмадым пан булып,
Гаҗизләндем морзаларга, йөрәгем, бәгърем кан булып.

Башкара алмыйм эшне, тыңлата алмыйм кешене,
Һәркайсысы белгән булып йөреттеләр эшне.

Хан кабере өстенә кордырдым таш манара,
Дидем: «Үзем үлсәм дә, исемем күп елга бара».

Манараны коргачдин көнләштеләр хәлемә,
Мәскәүгә хат яздыра шул көндәшем — залимә[1]:

«Сугыш өчен Сөембикә манараны салды»,— дип,
Тагын язган: «Кырымнан яңа гаскәр алды»,— дип.

Миндә ул ният булмады, мин сугыш теләмәдем,
Морзаларның юк фикерен күземә дә элмәдем.

Морзаларга мин әйттем: «Мәскәү белән белешик,
Һичбер җәбер итмәсә буйсыныйк та килешик.

Инде алай булмаса, көчле белән көрәшмик,
Солых бозмыйк, мал бирик, «сугыш» диеп сөйләшмик.

Тыныч торсак, күп еллар каннарыбыз түгелмәс,
Мәскәү берлән сәүдә кылсак, дәүләтебез кимемәс».

Бу сүземне морзалар һич тә кабул күрмәде,
Никадәрле әйтсәм дә, бер сүзем дә кермәде.

Мәскәү әйтә: «Сугышмагыз, мин Казанны алырмын,
Рәнҗемәгез, ахырында яхшы ук җәфа салырмын».

Шуны ишеткәч, Кырымга китәргә дә уйладым,
Күрәчәкләр булганга кабул түгел теләгем.

Карыштылар морзалар, Мәскәү сүзен алмыйлар,
Каршылыкны Мәскәүләр миннән диеп аңлыйлар.

Казан — Мәскәү арасында тагын бер сугыш булды,
Җиңелгәчтен казанлылар, солыхка киңәш кылды.

---

[1] Залимә — мәрхәмәтсез хатын.

Мәскәү соңгы солыхны башкаларга яд кыйлган,
Мине Мәскәүгә озатуны солыхка бер шарт кыйлган.

Казандагы кенәзләр үзе тыныч булырга,
Һәркаюсы кул куйганнар мине әсир кылырга.

Әмер булды китәргә, көймәләргә җитәргә,
Күзләремдин нур китте, белмим нихәл итәргә.

Мине тотып ике адәм утырттылар арбага,
Тәхет, бәхет калдырып көймә янына бармага.

Сөембикә атым, нугай затым, кайда минем хан
дәүләтем?
Күңелем моңлы, йөзем сары, күзем яшьле, әсир
вакытым.

Күзем салдым халыкка, күбе җылап озата,
Кайсылары «Мәскәү ханы рәхимле» дип юата.

Шәһәр тәмам гүлидер, җылау-сыктау тавышы,
Миңа төшкән кайгылар — морзаларның табышы.

Уйлап алдым: Кыямәт купканмы әллә бүген дип,
Тагы уйладым: җылаучылар минем кебек түгел дип.

Барып җиткәчдин дәрьяга[1] кереттеләр көймәгә,
Газиз телләрем бәйләнде, белмим ни сүз димәгә.

Кайсы әйтәдер «әлвидаг»[2], кайсы әйтәдер «әлфирак»[2],
Мин әйтәмен: «Бәхил булың, киттем инде бик ерак».

Халык калды җыгылып, һушсыз булып биректә[3],
Көчле адәмләр нишләми, булганнары иректә.

Волгига[4] чыкканда карадым мин калага,
Калды җылап Казаным, охшап үксез балага.

---

[1] Дәрьяга — елгага.
[2] Әлвидаг, әлфирак — хушлашу сүзләре.
[3] Биректә — яр буенда.
[4] Волгига — Идел елгасына.

Дидем: «Мескен Казаным, төште таҗың башыңнан,
Калдың бүген дәүләтсез, чишмә агар яшеңдән.

Кайда калды шатлыгың, кайда сәнең байлыгың?
Күрер күзгә билгеле хәзер кол, гидайлыгың.

Бушап калды сараең, нурың китте үзеңдин»,—
Дип җылап, Казанны югалттым мин күземдин.

Сөембикә атым, нугай затым, кайда минем хан
дәүләтем?
Хансарайда торган идек, бүген булдык әсир ятим.

Манарам күренде күп җирләргә җиткәнче,
Тагын да бер җыладым, хәлләрем беткәнче.

Дидем: «Ярабби, манарам, белмисең, кайда барам!
Калдырдым инде сәни, тәкъдиргә юктыр чарам.

Хан өстенә корылдың, таштандыр сәнең җисмең,
Җимерелгәнче йөрермез исемем белән һәм исмең.

Шулай сөйләп барганда, манарам да җугалды,
Җугалуга сәбәп шул: көймә бик күп юл алды.

Сөембикә атым, нугай затым, кайда минем хан
дәүләтем?
Күңелем моңлы, күзем яшьле, үзем әсир, угылым ятим.

Көймә китте кузгалып, карчыгадай кошны алып,
Миндәй гарип бичарадин[1] гакылны, һушны алып.

Бара торгач, без җиттек Зөя дигән калага,
Килде андагы бояр, морза безне күреп калмага.

Барып җиткәчдин Зөягә, анда без өч көн тордык,
Чыкмадык без бер җиргә, көймә эчендә утырдык.

Андин киттек Мәскәүгә күреп сәфәр михнәтен,
Әсир булып барабыз, күрми дөнья зиннәтен.

---

[1] Гарип бичарадин — җәберләнгән, чарасыз калган мескен.

Күп заманнар баргачдин, Мәскәүгә барып җиттек.
Бу бәхетсез башларга ни була дип, без көттек.

«Кызлар мәйданы» дигән бер урынга илттеләр,
Бераз карап торгачдин, безне йортка кертдиләр.

Кергән йортка каравыл куйдылар бер ун кеше,
Чыгармыйлар, йөртмиләр һәм кертмиләр бер кеше.

Көн дә уза, төн дә уза, хәсрәтдин тәнем сыза,
Ике бояр килгән беркөн, берсе: «Айда!» — дип, кул суза.

Әсир булгач ни чара? Кузгалдым мин, бичара,
Балам белән икебезне кая алар алып бара?

Барып кердек зур йортка, эчендә аның хансарай,
Күп кешеләр җыелган, барысы да безне карай.

Падишаһ[1] та шунда үзе, миңа әйтә бер сүзне:
«Балаң монда асралыр, иргә бирәм мин сезне»,—

Диеп, шунда баламны кулымдин да алдылар,
Әсирлектән янган идем, тагын утка салдылар.

Ишеттем мин: баламны поплар алганнар дип,
Гакылы да юк сабыйны диннән чыгарганнар дип.

Сөембикә атым, нугай затым, калды минем хан
дәүләтем,
Күңелем моңлы, күзем яшьле, калдым ялгыз, әсир,
ятим.

Мин киткәчдин, көндәшем[2], китте инде, дип, Сөембикә,
Үзенә ир кайгыртып, булмак булган ханбикә.

Халык белән киңәшеп, Астархандин хан алган,
Яшь кенә кенәз икән, исеме Ядегәр хан булган.

Көндәшем ханга барган, Казанны һәм тотам дип,
Дөнья әйткән: «Ашыкма әле, сәни дә утка атам»,— дип.

---

[1] Падишаһ — бу очракта Иван Грозный күздә тотыла.
[2] Көндәшем — Хөршид-ана булса кирәк.

Шул елны ук мине дә падишаһ бирде бер ханга,
Касыймдагы Шаһгали, Казанга дошман җанга.

Мине алгач, сугышка әмер булды барырга,
Мәскәүләр белән бергә Казанны һәм алырга.

Сөембикә атым, нугай затым, кайтса да шул хан дәүләтем,
Казаным юк, күңелем моңлы, онытылмый һич
хәсрәтем.

Шаһгалиләр баеганнар, Казанны һәм алганнар,
Мине саткан морзаларның башын җиргә салганнар.

Ядегәр белән көндәшем тагы да кулга төшкән,
Мине яндырган утта үзе дә яхшы пешкән.

Гарип[1] балам Үтәмеш тә алты яшенә җитте,
Фани дөньядан үтте, андин бер кайгым бетте.

Дөньяга килгән адәм кайгы күрмичә тормый,
Дөньяда шат йөргәннең дә тупракдыр ахыр урыны.

Сөембикә атым, нугай затым, күзем яшьле, юк рәхәтем,
Күрдем михнәт, чиктем газап, онытылмый һич
хәсрәтем.

Сораулар һәм биремнәр

1. Сөембикә кем булган? Ни өчен аның хакында бәет чыгарганнар?
2. Сөембикәнең ханбикә булып торган еллары бәеттә ничек сурәтләнә? Әсәрдән өзекләр китереп сөйләгез.
3. Казан халкы Сөембикәне ничек озата? Халык кайгысы ничек сурәтләнә? Шул юлларны табып укыгыз.
4. Сөембикә кичерешләрен сурәтләгән урыннарны табыгыз.
5. Ни өчен әсәрдә Сөембикә манарасына аерым игътибар юнәлтелә?
6. Бу әсәрнең әһәмияте нәрсәдә?

Бәет дип гарәпләр ике юллы шигырьгә әйтәләр. Бәетләр, чыннан да, күбесенчә икешәр тезмәле строфалардан тора. Бәет, башлыча, татар поэзиясенә хас күренеш. Билгеле бер дәрәҗәдә башкортларда да очрый. Әмма башка халыкларда бик күренми.

---

[1] Гарип — бу урында җәберләнгән, кимсетелгән мәгънәсендә килә.

Бәетләр, гадәттә, ил тормышындагы, кешеләр язмышындагы аяныч, фаҗигале хәлләрне хикәялиләр. Бәет чыгаручы, шундый әсәр иҗат итеп, авыр хәсрәтен тарата, бәлагә юлыгучының истәлеген мәңгеләштереп калдырырга омтыла. Тыңлаучы, укучы күңеленә кызгану хисләре сала, гыйбрәт, сабак алырга өйрәтә. Әлеге жанрның безнең көннәрдә дә очравы әнә шуның белән аңлатыла торгандыр. Бу хакта бөек шагыйрь Габдулла Тукай да: «Чү, әз генә бернәрсә шылт иттеме, хәзер бәет чыгарыла»,— дигән.

Бәет — фольклор әсәре. Шулай да ул хәзер күбесенчә язмача иҗат ителә. Аны поэзиянең лиро-эпик төре дип карарга була. Анда үкенечле хәл, вакыйгалар тасвирлана, бәет әйтүченең кичереш-тойгылары бәян ителә. Бәетләрдә тоташ сюжет сирәк күренә. Аларның тагын бер мөһим үзенчәлеге шунда: фаҗига турында һәлак булган кеше үзе сөйли, исәннәргә васыятьләрен әйтеп калдыра.

Кайчак кимчелекләрдән көлеп чыгарылган шигъри тезмәләрне дә бәетләр рәтеннән санап йөртәләр.

«СӨЕМБИКӘ БӘЕТЕ» ТУРЫНДА

Бу әсәр татар халкының гүзәл кызы Сөембикәнең фаҗигале язмышы турында сөйли. Сөембикә — нугай морзасы Йосыф кызы, Казан ханы Җангали хатыны. Җангали үтерелгәч, Сафагәрәй ханга кияүгә чыга. 1549 елда Сафагәрәй һәлак булгач, ике яшьлек улы Үтәмешгәрәй хан урынына дәүләт белән идарә итүче булып кала. Бераздан Мәскәү хакимияте аны, әсир итеп, Мәскәүгә озата, Касыйм ханы Шаһгалигә ирексезләп кияүгә бирә.

Бу язмышта бөеклек, гүзәллек, легендарлык белән фаҗига бергә үрелә. Шул ук вакытта ул татар халкы тарихы белән аерылмас рәвештә бәйләнгән.

Әсәр сәнгатьчә бик камил, җиренә җиткереп иҗат ителгән. Анда без бер генә җирдә дә сюжет үсешенә бәйләнешсез, тик рифма өчен генә китерелгән янәшәлекләрне очратмыйбыз. Иң киеренке мизгелләрнең драматик мәгънәсен рефреннар, кабатланып килүче строфалар сиздертеп бара.

Укучыларга Татарстанның халык язучысы Гомәр ага Бәширов язып алган вариант тәкъдим ителә. Кызганычка каршы, язманың бер-ике бите сакланмаган. Ул өлеше «Татар халык иҗаты. Бәетләр» китабыннан алып бирелә (Казан: Татар. кит. нәшр., 1983).

Каюм Насыйри
(1825—1902)

Каюм Насыйри (Габделкаюм Габденнасыйр улы Насыйров) 1825 елның 2 (14) февралендә элекке Казан губернасы Зөя өязе Югары Шырдан авылында укымышлы мулла гаиләсендә туа. Башлангыч белемне әтисеннән ала. 1841—1855 елларда Казанның бишенче мәхәлләсендәге мәдрәсәдә укый. Аннан соң Духовное училищеда, соңрак шул училищеның дәвамы булган Духовная семинариядә татар теле укыта. Соңыннан Казан университетына ирекле тыңлаучы булып керә.

1879 елдан башлап К. Насыйри рәсми рәвештә бер җирдә дә хезмәт итми. Бар гомерен язучылык эшенә, фәнгә багышлый. Һәр язны туган авылы Шырданга кайта, кыр эшләрендә катнаша, җәйләрен, Зөя өязе авылларына чыгып, халыкның телен, гореф-гадәтләрен өйрәнә, тарихи истәлекләр, фольклор әсәрләрен җыя. Әдип бар көчен, сәләтен китаплар, дәреслекләр язуга сарыф итә, аларны үз акчасына бастыра. 1885 елда К. Насыйри Казан университеты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте әгъзасы итеп сайлана.

К. Насыйри күбрәк Казанда яши. Берничә тапкыр агасы Габделхәй янына Мәскәүгә, Мәкәрҗә ярминкәсенә һәм имтихан тотар өчен Уфага барып кайта. 1893 елның җәендә Оренбург янындагы Каргалы авылында була.

К. Насыйри китапларын үзе төпләгән, көнкүреш әйберләре ясаган, «Һаман утырып язу ялыктыра, каннар оеша, мин һәр көн бер-ике сәгать эшләп, бу кораллар белән үземә кирәкле

әйберләр ясыйм»,— дип әйтә торган булган. Ул рәсем ясаган, географик карталар сызып, календарьларына урнаштырган.

Гомеренең соңгы елларында аны паралич суга. Электр ярдәмендә дәвалану, туктаусыз хәрәкәтләнү нәтиҗәсендә генә ул йөрерлек хәлгә килә. К. Насыйри 1902 елның 20 августында (2 сентябрендә) 77 яшендә үлә, Казанда Яңа Бистә ягындагы каберлеккә күмелә.

Бөек мәгърифәтче, галим, әдип Каюм Насыйри татар халкының рухи үсешенә ярты гасыр буена фидакарь хезмәт итеп килде. Ул фәннең барлык тармаклары буенча диярлек җиңел аңлаешлы, мисалларга, иллюстрацияләргә бай, мавыктыргыч кулланмалар язды. Татар теленең сүзлекләрен, грамматикасын төзеде. Тәрҗемә итеп, фольклор әсәрләрен кертеп һәм оригиналь әсәрләр иҗат итеп, «Кырык вәзир кыйссасы», «Фәвакиһел җөләса фил-әдәбият» («Әдәбият турындагы мәҗлесләрнең җимеше»), «Кырык бакча» җыентыкларын төзеп бастырды. Халык авыз иҗаты әсәрләрен язып алып укучыларга тәкъдим итте, халыкның күзен ачуга, аң-белемен, мәдәниятен үстерүгә зур өлеш кертте.

ӘБҮГАЛИСИНА

(Әсәр кыскартып алынды)

Гыйлем эстәп, ерак юлга

Борын-борын заманда Бохара шәһәре янындагы Шәҗегъ дигән авылда бер ир белән хатын яшиләр иде. Алар бик тату торалар, матур гына гомер итәләр иде.

Көннәрдән бер көнне боларның игезәк ир балалары булды. Ата белән ана бик шатландылар. Балаларның берсенә — Әбүгалисина, икенчесенә Әбелхарис дип исем бирделәр.

Көннәр, атналар үтте, айлар, еллар да үтеп киттеләр, балалар дүрт яшькә җиттеләр. Аларны мәктәпкә укырга бирделәр.

— Укысыннар, белем алсыннар, кеше булсыннар,— диделәр.

Әбүгалисина үзенең үткенлеге, зирәклеге белән башка балалардан аерылып тора иде. Әбелхарис, Әбүгалисина белән игезәк булса да, бер ата, бер анадан туса да, зирәклек һәм булдыклылык ягыннан туганы шикелле үк түгел иде.

Әбүгалисина бик яхшы укый, укытучы ни генә әйтсә дә, ул бик тиз төшенеп ала, белгәнен бер дә онытмый иде. Шулай ук ул, укытучы сөйләгәннәр белән генә канәгатьләнеп калмыйча, яшьтән үк китаплар укуга бирелде. Шуңа күрә бик күп нәрсәләр белде. Халык сүзе белән әйткәндә, ул «кылны кырыкка яручы» бер бала иде.

Аның зирәклеге, сизгерлеге турында бик кызык сүзләр сөйлиләр. Ул вакытларда мәктәпләрдә асларына киез салып, идәнгә тезләнеп укыйлар — парталар булмый. Әбүгалисинаның иптәшләре аның киезе астына бер бит кәгазь салып куялар, ә үзләре Әбүгалисина нишләр икән дип, кызыксынып карап торалар.

Әбүгалисина мәктәпкә килә, урынына килеп утыра, аннары бер югары, бер түбән карап тора. Аңа сорау бирәләр:

— Нишләп алай карангалыйсың?— диләр.

Әбүгалисина:

— Белмим, мәктәпнең түшәме төшкәнме, әллә идәне күтәрелгәнме? Ни булса да бар, элеккечә түгел,— ди.

Шулай ул киез астына салынган бер бит кәгазьнең калынлыгын да сизгән, имеш, дип сөйлиләр.

Унике яшенә җиткәндә, Әбүгалисина инде бик күпне белүче гыйлем иясе булып җитешә, төрле фәннәрдән үзе дә башкаларга сабак укыта башлый. Үзеннән күп зур балалар, килеп, аннан дәрес алалар.

Ул төшкә кадәр балаларга сабак укыта, төштән соң урамга чыгып, алар белән рәхәтләнеп уйнап йөри. Аның бу гадәте кайбер кешеләргә бер дә ошамый. Аңа:

— Син шундый галим, шундый акыл иясе кешесең, никадәр балаларга сабак өйрәтәсең, белем бирәсең. Ә үзең надан балалар белән уйнап йөрисең,— диләр.

Әбүгалисинаның моңа бер дә исе китми. Ул:

— Кешенең һәр яшендә үзенә күрә бер матурлыгы була, сабыйлыкның матурлыгы уен белән,— дип җавап бирә.

Тагын берничә ел үтеп китә. Әбүгалисина зур галим булып җитә. Бохара тирәсендә аңа тиң, аның белән сүз көрәштерерлек кеше калмый. Ләкин ул үзе моңа гына риза булмый, тагын да тирәнрәк белем алырга тели. Туганы Әбелхарис белән бергәләп, гыйлем эстәп, алар

туган илләреннән еракларга китәргә уйлыйлар. Ата-аналарыннан түбәнчелек белән рөхсәт сорыйлар:

— Кадерле атабыз, сөекле анабыз,— диделәр,— безнең юллар йөреп, илләр күреп, төрле җирләрдә булып, гыйлем аласыбыз, бу дөньяның серләренә төшенәсебез килә. Безгә рөхсәт бирегез, изге теләктә була күрегез...

Ата белән ана, балаларыннан аерылу бик кыен булса да, аларның яхшы теләкләренә каршы килмәделәр.

— Бездән рөхсәт, теләгән җирләрегезгә барыгыз, дөнья күрегез, белем алыгыз, шул белемнәрегез белән халыкка файдалы кешеләр булыгыз,— диделәр.

Ике туган юлга чыктылар. Ата белән ана аларга уңышлар теләп, озатып калдылар.

Көн бардылар, төн бардылар, күп юллар үттеләр, ерак җирләргә җиттеләр. Бик күп авылларда, шәһәрләрдә булдылар, төрле-төрле кешеләрне күрделәр, зур гыйлем ияләре белән күрештеләр. Шулай йөри торгач, бер шәһәргә барып керделәр. Аны карап йөри торгач, беркөнне зур гына базарга килеп чыктылар. Ни күрсеннәр: бер җирдә бик күп халык җыелган, уртада бер кеше нидер сөйли.

Әбүгалисина белән Әбелхарис халык җыелган җиргә бардылар. Теге кеше халыкка карап, болай дип кычкыра иде:

— И җәмәгать! Тыңлагыз, ишетми калмагыз! Иртәгә мәгарә[1] ишеге ачыла. Кереп карарга теләсәгез, белем алырга эстәсәгез, әзер торыгыз... Ләкин шуны аңлагыз: мәгарәдән китап алып чыгарга яки андагы белемнәрне кәгазьгә күчереп алырга рөхсәт ителми. Башка сыйдыра алган кадәр белем алып чыгу һичкемгә дә тыелмый...

Әбүгалисина да, Әбелхарис та бу хәбәр белән бик кызыксындылар. Шундагы берәүгә сорау бирделәр:

— Ул нинди мәгарә? Аның ачылуы нидән гыйбарәт? Ни өчен бу турыда болай халыкка белдерү ясыйлар?— диделәр.

Кеше җавап бирде:

— Борын заманда Фисагурис[2] дигән атаклы бер галим булган. Ул үзенең гыйлеме белән бөтен дөньяда

---

[1] Мәгарә — тау куышы.

[2] Грек галиме Пифагорны шулай атаганнар.

дан тоткан. Кимия, симия, ихфа гыйлемнәре[1] шуннан калган. Шул галим үлгәч, гыйлемнәре югалмасын, китаплары таралып бетмәсен дип, барлык китапларын җыеп, бер мәгарәгә урнаштырганнар. Ул мәгарәнең ишек төбенә сакчылар куйганнар.

Менә шул мәгарә ел саен бер вакытта өч сәгатькә генә ачыла, һәркемгә дә анда керергә, башына сыйдыра алган кадәр белем алырга рөхсәт ителә. Ләкин аннан бер китапны да алып чыгарга яки язып алырга ярамый.

Әбүгалисина бу сүзләрне ишетеп уйга калды. Әбелхариска:

— Менә без эзләгәнебезне таптык. Мәгарәгә кербез дә аннан үзебезгә кирәкле белемнәрне алып чыгарбыз. Ләкин өч сәгать эчендә генә әллә нәрсә алып булмас, шуңа күрә безгә, быел монда калып, ныклап эзләнергә, барлык кирәк-яракларыбызны әзерләп бетергәч, киләсе елда кереп, ел буенча мәгарәдә калырга кирәк булыр,— диде.

Алар шулай эшләргә карар бирделәр.

Әбүгалисина белән Әбелхарис таулар арасына чыгып киттеләр. Шунда тора башладылар.

Әбүгалисина туганына болай диде:

— Без бер елга җитәрлек азык әзерләргә тиешбез. Ләкин ул азыкларның күләме бик кечкенә булырга тиеш: безнең мәгарәгә азык алып керүебезне беркем дә сизәрлек булмасын. Шуның өстенә без үзебезне аз ашап торырга күнектерергә тиешбез.

Әбелхарис:

— Анысы алай. Аннары бит мәгарәдә су булмавы да бик мөмкин. Безгә сусыз торырга да күнегергә кирәк булыр,— диде.

— Әйе. Гыйлем алу ансат эш түгел...

Әбүгалисина һәм Әбелхарис киләсе елга мәгарәгә кереп калу өчен әзерләнә башладылар. Алар бик аз ашыйлар һәм бик аз эчәләр иде. Шулай итеп, үзләрен аз ашап торырга күнектерделәр. Көнгә егерме тиен көмеш акча авырлыгындагы зәйтүн мае белән тукланалар, айга бер мәртәбә су эчеп, сусауларын басалар иде.

---

[1] Кимия, симия, ихфа гыйлемнәре — кешеләр бик борынгы заманнардан бирле гыйлем көче белән төрле кыяфәтләргә кереп йөрү, кирәк вакытта яшеренеп йөрү, теләсәң нәрсә эшли алу турында хыялланганнар. Шундый гыйлемнәр бар дип ышанганнар.

Әбүгалисина белән Әбелхарис кече яшьтән үк җәядән атарга бик оста иделәр. Хәтта Әбүгалисина, ерактан атып, чыпчыкның күзен чыгара ала иде.

Алар җәя һәм уклар ясадылар, тау араларында йөреп, кыр кәҗәсе ауларга керештеләр: кыр кәҗәсен аталар да аның, эчен ачып, йөрәген алалар, йөрәкләрне киптереп төяләр дә он ясыйлар. Озак та үтмәде, аларның мәгарәдә ел буена ашарга җитәрлек оннары булды.

Ләкин, кеше ачлыкка никадәр чыдамлы булса да, бу — коры ризык, аның туклыгы бик аз.

— Безгә зәйтүн мае табарга, бу онны зәйтүн мае белән кушып, бавырсак ясарга кирәк,— диде Әбүгалисина.

Алар таулы урманнарда йөреп, зәйтүн җимеше җыйдылар, аннан май чыгардылар.

Мәгарәдә яндыру өчен, бер елга җитәрлек май һәм башка кирәк-яракларны да әзерләделәр.

Мәгарәнең ишеге ачылыр көн җитте. Әбүгалисина белән Әбелхарис, барлык әйберләрен алып, мәгарә ишеге төбендә көтеп торалар иде инде. Ишек ачылу белән, эчкә кереп, бер почмакка яшеренделәр...

Бу мәгарә гаять зур бер куыш икән. Анда рәттән зурзур бүлмәләр тезелеп киткән. Бүлмәләргә утыргычлар куелган. Стена буйларында зур-зур шкафлар. Алар барысы да китаплар белән тулган. Шундый гаҗәеп мәгарә бу...

Барлык бүлмәләрдә йөреп, тикшереп карап чыккач, егетләр укырга утырдылар. Ләкин бер-берсенең нәрсә укуы һәм нәрсә белүе турында сорашмаска һәм әйтмәскә сүз куештылар. Кайбер әйберләрне язып алырга да кирәк иде. Ләкин болай эшләсәләр, чыгу белән аларны тотып, язган кәгазьләрен алып калулары мөмкин. Шуңа күрә алар, моны алдан уйлап, чарасын күргәннәр, үзләре белән суган суы алып кергәннәр иде, шуның белән бик кирәкле белемнәрне язгалап та алдылар. Мондый «кара» белән язылган язу һичкемгә дә күренми, шик тудырмый, ә кирәк вакытта аны үзләре укый алалар иде.

Алар утны бервакытта да сүндермәделәр, чиратлашып йокладылар, утны сакладылар. Чөнки ут аларга, яктылык бирү өстенә, числолык булып та хезмәт итте: күпме май януга карап, елның, айның, көннең кай вакыты икәнен белеп тордылар. Шунсыз мөмкин түгел иде.

Исәп буенча инде бер ел вакыт үтеп бара. Әбүгалисина белән Әбелхарис шушы вакыт эчендә, күп тырышып, күп көч куеп, әллә никадәрле белем алдылар. Ләкин, башта сүз куешканча, нәрсәләр өйрәнүе турында берсе икенчесеннән сорамадылар.

Тиздән мәгарә ишеге ачылыр, өч сәгатькә мәгарә халык белән тулыр. Шул арада боларга беркемгә дә сиздерми чыгып китәргә кирәк. Шуңа әзерләнә башладылар: барлык әйберләрен алып, ишек төбенә килделәр дә яшеренеп тордылар.

Тышта шау-шу. Ишек төбенә халык җыелган. Ишек ачылуын түземсезлек белән көтәләр. Ә эчтә Әбүгалисина белән Әбелхарисның йөрәкләре дөп-дөп тибә иде.

Менә шалтырап ишек ачылды. Тыштан төртешә-төртешә, тыгызлана-тыгызлана мәгарәгә халык агылды. Шул ыгы-зыгы арасында Әбүгалисина белән Әбелхарис мәгарәдән чыгып киттеләр. Аларны беркем дә күрмәде.

Бу вакытларда шәһәргә Көнбатыш ягыннан ике сихерче килеп, төрле бозыклыклар эшләп йөргәннәр, шәһәр халкын интектереп бетергәннәр иде.

Әбүгалисина белән Әбелхарис, ел буе мәгарәдә ятып, кеше кыяфәтләрен югалтканнар, чәчләре һәм тырнаклары җитеп, коточкыч бер төскә кергәннәр иде. Аларны күрү белән, әлеге сихерчеләр дип белеп тотып алдылар да шәһәрнең патшасы янына алып бардылар. Патша аны-моны тикшереп тормады, шәһәр мәйданына алып барып, икесенең да башларын кисәргә боерды. Аларны мәйданга алып килделәр, җәлладлар[1] башларын чабарга әзерләнделәр.

Шулвакыт Әбүгалисина, Әбелхариска карап:

— Зур газаплар чигеп, бер ел буена мәгарәдә белем алуыбыз менә шушындый кирәк вакытта безгә ярдәм итсен, башыбызны бәладән коткарсын, мин киттем,— диде дә үзенең гыйлем көче белән җәлладлар күзеннән юк булды. Барысы да аптырап калдылар. Җәлладлар кылычларын күтәргән килеш, исләрен җуеп тордылар, аннары «һай-һу» дип, Әбүгалисинаны эзләп киттеләр. Ыгы-зыгы белән хәтта Әбелхарисны да оныттылар.

Әбүгалисина патша сарае артындагы күлгә барып төште, суга чумды һәм юк булды. Никадәр эзләсәләр

---

[1] Җәлладлар — үлем җәзасын җиренә җиткерүчеләр, палачлар.

дә таба алмадылар. Инде тегесен җәзалыйк дип, мәйданга кире кайтсалар, ни күрсеннәр: анда Әбелхаристан да җилләр искән. Тегеләр Әбүгалисинаны куып киткәч, Әбелхарис та шулай ук котылды: аның кул-аякларын бәйләгән баулар чишелделәр, сарай түбәсенә таба сузылдылар. Әбелхарис, шул бау буенча үрмәләп, сарай түбәсенә менде дә юк булды.

Бу хәлне күреп, җәлладлар чәчләрен йолыктылар, бик күп кешеләр, тагын андый-мондый хәл булмаса ярар иде дип, бик курыктылар. Ләкин Әбүгалисина үзенең гыйлеме белән халыкка зарар китерү уенда түгел иде, шәһәргә бернинди начарлык, кешеләргә бернинди усаллык эшләмәде.

Әбүгалисина Мисыр шәһәрендә

Әбүгалисина, патша сарае янындагы күлгә чумып юк булганнан соң, шәһәрдән бик еракта булган Нил дәрьясына килеп чыкты. Аннан Мисыр шәһәренә барды. Чәчсакалларын китәреп, тырнакларын кисеп, кеше кыяфәтенә керде. Шәһәрне күрү өчен, урамга чыгып китте.

Урамнарда, базарларда йөри торгач, хәлвә сатучылар рәтенә килеп чыкты. Анда да, монда да кечкенә генә хәлвә кибетләре. Аларда хәлвәфрүшләр[1] үзләренең хәлвәләрен мактый-мактый сатып торалар иде.

Әбүгалисина бер хәлвә кибетенә керде. Монда гаҗәп матур бер егет басып тора. Бу егет, һәр көн кичтән хәлвә пешереп, аны шушы базарга чыгарып сата, шуннан килгән акча белән карчык анасын тәрбияләп яши иде. Аның матурлыгы күзләрне камаштырырлык булып, бер күргән кешенең тагын күрәсе килә иде. Шуның белән бергә ул бик булдыклы һәм оялчан да иде. Әбүгалисина да бу егетне күреп, аңа сокланып карап торды. Үз-үзенә: «Бу чибәр егетне фәкыйрьлектән, хәлвәфрүшлектән коткарырга кирәк»,— дип уйлап куйды.

Хәлвәфрүш, Әбүгалисинаның үзенә болай текәлеп карап торганын күргәч, бик оялды, уңайсызланды.

«Бу дәрвиш минем хәлвәмне яратмады, ахры. Бәлки, ул үзе бик оста хәлвә пешерүчедер. Мин аны үземә чакырыйм да аннан хәлвә пешерергә өйрәним»,— дип уйлады. Кичкә үзенең өенә чакырды.

---

[1] Хәлвәфрүш — хәлвә пешереп сатучы.

...Караңгы төшкәч, Әбүгалисина хәлвәфрүшнең өенә китте. Егет аны бик хуплап каршы алды. Исәнлек-саулык сораштылар. Бераз сөйләшеп утырдылар. Ләкин егетнең иртәгә сату өчен хәлвәсе әзер түгел иде. Ул сүзне шул якка борды. Әбүгалисинадан:

— Әфәндем, сез хәлвәне нәрсәдән пешерәсез?— дип сорады.

Әбүгалисина алай бик тиз генә ачылып китмәде. Бер сүз дә әйтмичә торды.

Хәлвәфрүш тынычсызлана башлады:

— Вакыт бик аз калды, әфәндем, иртәгә сатарга хәлвәм юк. Ни боерасыз?— диде. Үзе эченнән: «Бу дәрвишнең кулыннан берни дә килмидер, ахры»,— дип уйлый, һәм ачуы килә башлаган иде.

Әбүгалисина да моны сизеп алды.

— Мин, сезне бу хезмәт һәм мәшәкатьләрдән коткарып, башка берәр һөнәр өйрәтергә уйлаган идем. Теләгегез хәлвә пешерү булгач, ярар, алайса, бер капчык кибәк китерегез, мин сезгә кибәктән хәлвә пешереп күрсәтим,— диде.

Бу сүзләрне ишеткәч, хәлвәфрүшнең ачуы килде, хәтта Әбүгалисинаны куып чыгарып, тизрәк үзе эшкә тотынырга да уйлап алды.

Ничек итеп кибәктән хәлвә булсын инде?!

Шулай да егет сабыр итте. Әбүгалисинаны мыскылламады, аңардан көлмәде. Ул Әбүгалисинаның алдына бик күп кибәк китереп өйде.

Әбүгалисина кибәкләр тирәсендә нидер эшләде — кибәкләр барысы да хәлвәгә әверелделәр. Төрле бизәкләр белән бизәлгән, төрле-төрле табакларга тутырылган хәлвә егет алдына килеп тезелде. Моңарчы мондый татлы хәлвәне беркемнең дә күргәне һәм берәүнең дә татып караганы юк иде. Әбүгалисина егеткә:

— Менә сиңа хәлвә, иртәгә базарга чыгар да сат!— диде.

Хәлвәфрүш моңа ышанырга да, ышанмаска да белмәде.

Ахырда, Әбүгалисинаның хикмәтле кеше икәнен белеп, үзенең өендә калуын үтенде.

Шул көннән алып алар бергә тора башладылар.

Хәлвәфрүш һәм патша кызы

Әбүгалисина симия гыйлеме көче белән базар уртасында хәлвәфрүш өчен күп бүлмәле зур бер кибет барлыкка китерде. Бу кибет бик зиннәтле булып, өстендә чарлагы да бар иде. Әбүгалисина белән хәлвәфрүш шул чарлакка урнаштылар.

Хәлвәфрүшнең сәүдәсе зураеп китте. Алучылары күбәйде, чөнки аның кибетендәге кебек ләззәтле хәлвә башка беркемдә дә юк иде. Шулай ук бик күп кешеләр аның кибетенең гүзәллеген карарга кереп тә хәлвә алып чыгалар иде.

Ара-тирә хәлвәфрүш хәлвәне урамда күтәреп йөреп тә сата башлады.

Көннәрдән бер көнне ул патша сарае турысыннан үтеп бара иде, аны патша кызы күрде. Бу патша кызы шулкадәр гүзәл, аның йөзе шулкадәр нурлы иде, бу нур белән чагыштырганда кояш яктысы зур кандил[1] янында ялгыз бер шәм кебек кенә булып калыр иде.

Хәлвәфрүш, баш өстенә хәлвә күтәреп, урамнан үтеп барганда, кыз сарай тәрәзәсеннән карап тора, нидер уйлана, моңлана иде. Ул хәлвәфрүшне күрде. Аның матурлыгына хәйран булды. Шаһзадәләр[2] арасында да мондый сылу егет юктыр, дип уйлады. Хезмәткәрләреннән берсе аша, хәлвә алыр өчен дигән булып, аны сарайга чакырып кертте.

Хәлвәфрүш сарайга керде. Патша кызы битен каплаган пәрдәсен күтәрде. Күзләрне камаштырырлык матур йөзен күрсәтеп, хәлвәфрүш янына килде. Хәлвә турында сораштыра башлады. Ә үзе, егетнең матурлыгына исе китеп, аннан күзен алмыйча карап торды.

Сарайда әдәпсезлек булмасын өчен, хәлвәфрүш башын түбән иеп, аска карап кына тора иде. Кыз бик җентекләп сораштыра башлагач, аз гына башын күтәреп, күз кырые белән генә кызга карап алды. Аның бөтен тәне кинәт эсселе-суыклы булып китте. Маңгаеннан ясмык-ясмык тирләр чыкты. «Бу кыз җир йөзендә булган вакытта, кичләрен тулган айның, көндезен якты кояшның кирәге юк икән»,— дип уйлады.

---

[1] К а н д и л — берничә шәм яки электр лампочкалары куела торган зур шәмдәл.

[2] Ш а һ з а д ә л ә р — патша уллары.

Әйе, матурлык бакчасының алмасы пешеп җиткән, гүзәллек бакчасының гөлләре чәчәк атканнар иде инде. Хәлвәфрүш ни эшләргә белмәде. Аның иреннәре дерелделе, куллары калтырый башлады. Ул, хәлвә сатып, шуның бәрабәренә үзенә гыйшык уты алып китте.

Хәлвәфрүш, бөтен түземен югалтып, ни эшләгәнен белмичә, кибетенә кайтты. Аның төсе киткән, агарган иде.

Әбүгалисина моны сизде. Ул хәлвәфрүшкә:

— Ни булды? Миннән яшермә, ачык сөйлә,— диде.

Хәлвәфрүш, аның аягына егылып, башыннан үткәннәрне сөйләде. Патша кызына гашыйк булуын яшермәде.

Әбүгалисина аны аталарча үгетләде: «Патшаларга эшең төшмәсен, күп газаплар чигәрсең, күп мәшәкатьләр күрерсең, юк-бар уйларны башыңнан сибереп ташла...» — диде.

Ләкин егет һич тә тынычлана, гүзәл кызны башыннан чыгара алмады.

Патша кызы да шулай ук егеткә гашыйк булган иде...

Хәлвәфрүш бик үтенеп сорагач, Әбүгалисина аның үтенечен кире кагарга батырчылык итмәде. Бик озак нидер уйлап утырды, нәрсәдер эшләгән кебек итте. Шул арада күк күкрәгәндәй, җир тетрәгәндәй булды, бүлмәнең эче салкынаеп китте. Кинәт ишек ачылды. Ишектә гүзәлләрнең гүзәле — патша кызы күренде. Әбүгалисина аны биргә гыйлем көче белән китергән иде.

Бүлмәгә керү белән, кыз берникадәр вакыт һушын җуеп торды. Күзен ачуга хәлвәфрүшне күрде, аны таныды һәм бик аптырап калды. Шуннан соң кыз:

— И егетләрнең асылы, яшь йөрәкләрдә ут кабызучы матурларның матуры! Сез минем сараема кереп хәлвә саткан хәлвәфрүш түгелме?— дип сорау бирде.

— Дөрес,— диде хәлвәфрүш,— мин нәкъ шул кеше. Ни боерасыз? Сезнең колыгыз булырга әзер торам...

Кыз, егеткә карап:

— Бу ни хәл? Сез пәри яки җенме, әллә хикмәт гыйлеме белүче акыл иясе кешеме? Мин биргә ничек килдем?— дип сорау бирде.

— И күңелләргә рәхәт бирүче назлы былбылым,— диде егет,— сез минем бәгырем парәсе, күңелем ярасы! Шиккә төшмәгез, мин дә сезнең кебек үк бер кеше. Мин бозык кеше түгел. Сезгә зарар итәргә исәбем юк. Сезнең

гаҗәп матурлыгыгызны күрдем, гашыйк булдым. Тагын бер мәртәбә күреп, сезнең нәфис тавышларыгызны ишетеп, күңелемне юатырга теләдем.

Кыз берни дә әйтә алмады. Ул үзе дә хәлвәфрүшне күргәннән бирле төн йокыларын җуйган иде. Сызылып таң атканда да, ялтырап кояш чыкканда да, моңаеп кояш батканда да, хәлвә күтәреп сарайга кергән шул егет аның күз алдына килә. Күзен йомса, йокыга талса, аны төшендә күрә иде...

Шуңа күрә мәшәкатьсез ирешелгән бу күрешү аны да бик шатландырды.

Алар, төн буе шулай сөйләшеп, җырлар алмашып, бер-берсенә булган саф мәхәббәт һәм дуслыкларын уртаклашып, бөтен кайгы һәм борчуларын оныттылар. Төннең үткәнен сизми дә калдылар!..

Сызылып таң беленде. Караңгылык пәрдәсе күтәрелеп яктыра башлады. Шул вакытта Әбүгалисина, кереп, аерылырга вакыт җиткәнен белдерде. Озак та үтмәде, патша кызы үзенең сараенда булды.

Кыз, сарайга кайткач, күзен ачып җибәрә һәм байтак вакыт аптырап тора. Ул бу төндә булып үткәннәргә ничек карарга да белми, өнемме бу, әллә төшемме дип аптырап тора...

Кыз, шулай төрлесен уйлап, ике ут арасында калып, бер карарга килә алмыйча, озак баш ватты. Ахырда, атам башка кешеләрдән ишеткәнче, үзем белдерим дип, кулына каурый каләм алды... озын хат язды. Бер хезмәтче белән хатны атасына җибәрде.

Патша, хатны укыгач, ачуыннан дөрләп янган утка керердәй булды. Үзенең вәзирләрен, галимнәрен, хакимнәрен һәм баһадирларын җыйды. Бергәләп кызның хатын укыдылар. Барысы да бик аптырап калдылар. Кайсылары: «Бу җен эшедер», икенчеләре: «Сихер эшедер»,— диделәр.

Күп киңәшә торгач, шундый карарга килделәр: барлык җарияләр[1], төн буе йокламыйча, кызның бүлмәсен бик нык сакларга, бүлмә ишеге төбенә кораллы сакчылар куярга, бөтен сарайны гаскәр белән урап алырга кирәк, диделәр.

---

[1] Җарияләр — бу урында сарай хезмәтендәге кызлар мәгънәсендә.

Кич булды, караңгы төшә башлады. Сакчылар куелды. Сарай тирәсендә чебен очарга да мөмкинлек калмады. Җарияләр, күзләрен йоммыйча, патша кызыннан күзләрен алмыйча, керфек какмыйча, аны саклап тора башладылар.

...Менә йолдызлар калыкты. Хәлвәфрүш Әбүгалисина янына килеп ялынды-ялварды, бүген дә кызны үзе янына китерүне үтенде. Әбүгалисина аны чын күңелдән кызганды. Аның теләген үтәүдән баш тарта алмады, үзенең белгәннәрен эшкә кушты.

Кыз үзенең сарайдагы бүлмәсендә урыныннан торды. Җарияләр аңа ташландылар, ыгы-зыгы купты. Барысы да: «Кая барасың?» да «Кая барасың?»— дип, аңа килепябыштылар. Кыз алар кулыннан ычкынды да юк булды. Җарияләр дә, ишек төбендәге сакчылар да, сарай әйләнәсендәге гаскәрләр дә аны тотып кала алмадылар. Бөтен сарай эче тавыш, кычкырыш, аһ-ваһ белән тулды.

Төрле якка таралып, ары йөгереп, бире йөгереп, таңга кадәр кызны эзләделәр, ләкин таба алмадылар. Ул төнне дә кыз хәлвәфрүш бүлмәсендә үткәрде. Таң атып, көн яктыра башлаганда, ул тагын үзенең бүлмәсендә иде.

Бу эшкә патшаның бик ачуы килде. Тагын үзенең сарай кешеләрен җыеп, киңәшмә уздырды.

Күп уйлый торгач, шундый карарга килделәр: «Кызның урыны янына бер савыт белән изелгән зәгъфран[1] куярга, әгәр тагын да шундый хәл була калса, кызның кулын зәгъфранга буяп җибәрергә кирәк»,— диделәр.

«Кыз, көн саен кич бара торган йортның ишегеннән кергәндә, аның тоткасын тотар, тотканда зәгъфранга буялган бармак эзләре калыр. Шул эзләр буенча ул йортны табу җиңел булыр»,— диделәр.

Билгеле вакыт җитеп, кыз урыныннан кузгала башлагач, аның кулын зәгъфранлы савытка тыгып алдылар. Чыннан да ул, хәлвәфрүшнең ишегеннән кергәндә, тотканы тотып, биш бармак эзе калдырды.

Ләкин Әбүгалисина үзенең гыйлеме аркасында бу хәлне белгән иде. Бер минут та кичекмәстән, шәһәрдәге

---

[1] Зәгъфран — сары буяу чыга торган үлән.

барлык йортларның, бүлмәләрнең һәм кибетләрнең ишек тоткаларына шундый ук биш бармак эзе төшерде.

Алтын канатлы миһер кошы күк йөзендә очып йолдыз-бодайларны чүпләп бетергәч, ягъни таң атып, йолдызлар күренми башлагач, кыз яңадан үзенең сараена кайтты.

Патша субашын[1] чакырып алды да:

— Хәзер үк шәһәрдәге барлык йортларның ишек бауларын тикшерегез,— диде.— Кемнең ишек бавында зәгъфранга буялган бармак эзләре күренсә, шул йортның хуҗасын, һич кичектермичә, каршыма тотып китерерсез. Мин аңа җәзасын бирим!— диде.

Субашы үзе белән берничә кеше алды да, «Мин ул җинаятьчене тотып кайтырмын, патшабызның мактавына лаек булырмын»,— дип уйлап, тәмле хыялларга чумып, сарайдан чыгып китте.

Ләкин, сарайдан чыгу белән, ул аптырап калды: патша сараеның ишек тоткасы да зәгъфранга буялган иде.

Кыз сарайдан киткәндә ишек тоткасын тоткандыр, бу шуның эзедер дигән уйга киләләр. Башка йортларны тикшерергә керешәләр. Ләкин кайсы гына йортка барып кермәсеннәр, барысының да ишек тоткасында бер үк төрле эзләр ярылып ята. Кемне тотып алып кайтырга белмичә, аптырап, сарайга кайттылар. Күргәннәрен патшага сөйләп бирделәр.

Моны ишеткәч, патшаның чиксез ачуы чыкты. Ул, ни эшләргә белмичә, сакалын йолкып бетерде. Шуннан соң кырык көн буена шәһәрдәге барлык өйләрне тикшереп торырга боерык бирде.

Патшаның боерыгын үтиләр, ләкин бу да бертөрле нәтиҗә бирми: кыз, һәр көн югалып, иртә белән генә өенә кайта.

Аптырап-йөдәп беткәч, патшага әйтәләр:

— Багдад патшасының Әбелхарис исемле зур галим һәм тирән акыл иясе бер вәзире бар. Бу бәладән бары ул гына коткарса коткара алыр. Багдад патшасына хат язып, илчеләр җибәрергә кирәк,— диләр.

Патшага бу киңәш бик ошый. Шатланып, Әбелхарисны чакырып китермәкче була. Күп бүләкләр белән илчеләр җибәрә.

---

[1] Субашы — гаскәр башлыгы.

Әбелхарисның Мисырга килүе һәм Әбүгалисинага каршы көрәше

Багдад патшасы Мисыр патшасыннан Әбелхарисны җибәрүен үтенеп язган хат алгач, бу турыда Әбелхарисның үзе белән киңәшергә уйлады. Аны чакырып китереп, Мисыр патшасының үтенечен сөйләде, үзенең дустын бу бәладән коткаруда бер ярдәм итүен сорады.

Моңа каршы Әбелхарис:

— Әгәр фәрманыгыз булса, баш өсте, мин анда барыйм, Мисыр патшасын бу бәладән коткарыйм,— дип ризалык бирде.

Юл хәзерлекләре күрделәр. Әбелхарис, килгән илчеләр белән бергә үк, Мисырга китәргә булды. Алар юлга чыктылар. Әбелхарис Мисыр патшасын зарыктырырга теләмәде; симия гыйлеме көче белән шул көнне үк Мисырга барып та җиттеләр.

Мисыр патшасы Әбелхарисны зур хөрмәт белән каршы алды. Өч көн буена бик яхшылап кунак итте. Дүртенче көндә, аңа сарайда булып торган хәлләр турында сөйләп, ярдәм итүен үтенде.

Әбелхарис Мисыр патшасына чын күңелдән ярдәм итәргә теләвен белдерде һәм эшенә кереште. Рәмел тактасын[1] алып, хикмәт капчыгын чишеп, айны айга, туфракны туфракка орып, тирән уйга чумды. Көнбатыштан көнчыгышка, күк өстеннән җир астына күчеп, әлеге хәлвәфрүш йортын эзләргә кереште.

Әбүгалисина Багдадтан патшаның Әбелхарисны китертүен белгән була. Шуңа күрә ул үзенең тора торган йортын Әбелхарис эзләп тапмаслык итеп яшерә. Рәмел тактасында Әбүгалисина белән егет тора торган йорт ерак диңгез уртасындагы бер утлы утрауда булып күренә. Әбелхарис кат-кат тикшереп караса да, көн саен патша кызы бара торган юл ерак диңгезләр аша үтеп, һәр яктан ут белән чорналган утрауга барып тоташа. Бу утрауның уртасында искиткеч зиннәтле бер сарай бар. Кыз һәр көн кич әнә шул сарайга бара торгандыр.

Ләкин Әбелхарис, ничаклы гына тырышса да, бу утрауның кайда, нинди диңгездә икәнлеген белә алмады. Шуннан соң ул патшадан кызны күреп сөйләшергә

---

[1] Рәмел тактасы — багу, күрәзәлек итү өчен кулланыла торган корал.

рөхсәт сорады. Патша рөхсәт иткәч, кыздан барысын да җентекләп сорашты.

Әбелхарис симия гыйлеме белән ерткыч бер карчыга барлыкка китерде. Аның күзләре йодрык кебек кабарып торалар, ә тырнаклары инә кебек үткеннәр иде. Әбелхарис карчыганы кызга бирде.

— Менә бу карчыганы ал. Егет өенә баргач, аны җибәрерсең, ул, сине җәфа чиктерүче кешенең йөрәген чукып, аны һәлак итәр,— диде. Тагын ул йортта ятрак ризык булса, шуның берәр кисәген алып кайтырга кушты. Шул юллар белән үзенең теләкләренә ирешмәкче булды.

Кыз, үзе генә калгач, кан-яшьләр агызып елады. Ул, бер яктан, хәлвәфрүшне ярата, аңа начарлык теләми, ә икенче яктан, никадәр яратса да, аңарга кәләш булуны үзенә түбәнлек саный иде...

Ләкин Әбүгалисина бу хәлне дә сизеп алган иде. Ул егеткә:

— Бүген синең яныңа килгәндә, кызның куенында карчыга булыр, кыз бүлмәңә килеп керү белән, менә шушы яулыкны карчыганың башына капла, юкса һәлак булырсың,— дип, симия гыйлеме белән ясалган яулык бирде.

Кыз килер вакыт җиткәч, Әбүгалисина хәлвәфрүшнең бүлмәсен Һиндстан тирәсендәге Мосакия утравындагы бер шәһәрнең йортларындагы бүлмәләргә охшатып бизәде. Һәм, шундагыча итеп, аш мәҗлесе әзерләде. Табынга шул утрау тирәсендәге суларда гына була торган фил балыгы итен куйды.

Кыз бүлмәгә килеп керде. Карчыганы җибәрмәкче булды. Хәлвәфрүш тиз генә карчыганың өстенә яулыкны ябып өлгерде, карчыга һәлак булды...

Ул үзенең үпкә сүзләрен сөйләүдә дәвам итте:

— И гүзәлләр солтаны! Мин урамда хәлвә сатып йөргәндә, сез мине сарайга чакырып алмаган булсагыз, мин сезнең нурлы йөзегезне күрмәгән булсам, боларның берсе дә булмас иде. Бу эшләрдә башлап сез үзегез гаепле, ә хәзер гөнаһсызга мине һәлак итмәкче буласыз,— диде.

Аңа каршы кыз:

— Һай, гүзәл егет! Сез пәриме, җенме әллә кешеме? Халык арасында безне ни өчен болай рисвай кыласыз, безне җәфа чиктерәсез, әгәр теләгегез безнең белән

кушылу булса, атамнан сорагыз, бәлки, никахлап бирер,— дип җавап кайтарды.

— И назлы иркәм!—диде хәлвәфрүш.— Мин җен дә, пәри дә түгел, чын кеше. Сезнең шикелле үк кеше. Сез минем күңелемне үзегезгә шулкадәр бәйләдегез, сезне күрмичә, минем һич тәкатем юк. Атагыздан сорасам да, ул сезне миңа бирмәячәк, чөнки сез — зур патшаның иркә кызы, ә мин — ярлы хәлвәфрүш. Шуңа күрә сезне күрү өчен гыйлем көченнән файдаланам...

Алар озак сөйләштеләр, бер-берсенә төрле үпкә сүзләр әйтештеләр. Ахырда, барысын да онытып, озак сөештеләр. Шуннан соң егет, кызны табынга утыртып, әзерләнгән ризыкларны ашавын үтенде.

Кыз төрле-төрле ризыкларны мактый-мактый ашады. Шул вакытта Әбелхарисның сүзе исенә төште. Аның куллары калтырый башлады. Шулай да ул бер кисәк фил балыгы итен алып, кулъяулыгына төреп, кесәсенә тыкты.

Патша кызы фил балыгы итен алып кайтып Әбелхариска бирде. Моны күргәч Әбелхарис, бик шатланып:

— Рәмел тактасы дөрес күрсәткән. Бу балык Һиндстан диңгезендә була. Димәк, утлы утрау да анда булырга тиеш. Хәзер без җинаятьченең эзенә төшәрбез,— диде.

Бу сүзләрдән патша да бик шатланды. Әбелхарисның акылына хәйран калды. Һиндстан патшасына ашыгыч рәвештә хат язып, аннан ярдәм сорап, илчеләр җибәрде.

Җилкәнле кораб өчен җил уңае туры килеп, илчеләр бик тиз барып җиттеләр. Һиндстан патшасына хатны һәм бүләкләрне тапшырдылар. Патша хатны укып карады. Анда: «Һиндстан диңгезендәге утлы бер утрауда яшәүчеләр тарафыннан безнең кызыбызга карата зур хөрмәтсезлекләр күрсәтелә»,— дип язылган иде.

Һиндстан патшасы хатны укыды да бот чабып көлде. Әбелхарис турында:

— Ахмак, надан хәким[1] икән ул. Һиндстан диңгезендә шундый утрау барлыгын, ул утрауда ут барлыгын белгән, ә ут эчендә кешеләр яшәргә мөмкин түгел икәненә башы җитмәгән, ул утрауга якын бару да мөмкин түгел бит,— диде.

---

[1] Хәким — акыл иясе, күпне белүче кеше.

Һиндстан патшасы Мисыр патшасына болай дип хат язды: «Без сезгә ярдәм итүдән баш тартмыйбыз. Шулай да ул утрау тирәсенә барырга батырчылык итә алмыйбыз. Әгәр ут эченә кереп йөрергә көченнән килсә, шул ахмак хәкимегезнең үзен монда җибәрегез. Ул башлап керсә, без аның артыннан барырбыз».

Илчеләр хатны алып кайтып патшага бирделәр. Хатны укыгач, патшаның ачуы килде. Әбелхарисны да бик каты әрләп ташлады.

— Син ахмак кеше икәнсең. Синдә гыйлем дә, хикмәт тә юк икән! Мине, зур расходлар тотып, Һиндстанга илчеләр җибәрергә мәҗбүр иттең. Хурлыкка төшердең,— диде.

Бу — Әбелхариска бик авыр тоелды. Ни эшләргә, ни әйтергә белми аптырап калды. Җир ярылса, җир тишегенә кереп китәрдәй булып оялды.

Әбүгалисина беркөнне мунчага барды. Ләкин, юынып чыкканнан соң гына, мунча хуҗасына түләргә акчасы юклыгын белде. Акча китергәнче яулыгын калдырып торырга уйласа да, мунча хуҗасы риза булмады. Ул бик начар, ахмак, комсыз кеше иде. Әбүгалисинаны әшәке сүзләр белән хурлады.

Читтән тыңлап торучыларның берсе:

— Һай, мунчачы әфәнде! Ике тиен акча өчен дәрвиш кешене шулкадәр мәсхәрәлисең. Мә, аның өчен үзем бирим,— дип, ике тиен акча чыгарып бирде.

Әбүгалисина акча бирүчегә зур рәхмәтләр әйтте, ләкин мунча хуҗасыннан үч алырга теләде. Ул, мунчага кереп, мунча миче янында нидер эшләде. Шул минутта мунчада ут бетеп, җылылык сүрелә башлады. Озак та үтми, мунча эчендә көчле салкын башланды. Сулар катты, стеналар ап-ак кар белән капланды. Кешеләр дер-дер калтырыйлар, тиз генә киенеп, җылыныр өчен, тышка чыгарга ашыгалар. Кешеләрнең чәчләре бозланып ката, аяклары идәнгә ябыша да куптарып ала алмыйча җәфаланалар иде.

Мунчачы, аптырап, мунчага үзе кереп карады, анда кар белән боздан башка нәрсә күрмәде. Аз гына вакыт эчендә өшеп үлә язды. Тизрәк тышка чыгып йөгерде. Шуннан соң гына үзенең зур ялгыш эшләгәнен сизеп алды. Дәрвишне эзләп караса да таба алмады.

Бу хәбәр патша сараена да барып җитте. Әбелхарис патшага:

— Хөрмәтле падишаһым! Мунча вакыйгасының безгә күп нәрсәләрне ачуы мөмкин. Мин хәзер эшнең төбен аңладым: бу шәһәрдә симия гыйлемен бик яхшы белүче бер кеше булырга тиеш. Мунчачыны чакырып алыйк та аның ярдәме белән ул кешене эзләп табарбыз,— диде.

Һиндстан вакыйгасыннан соң патшаның Әбелхариска ышанычы бетә язган иде. Шулай да вәзирләре Әбелхарисны яклагач, патша мунчачыны чакыртырга риза булды.

Мунчачыны чакырып китерделәр.

— Әгәр ул дәрвишне күрсәң таныр идеңме?— дип сорадылар.

— Әлбәттә, танырмын,— диде мунча хуҗасы. Аңарга берничә кеше ияртеп, шәһәрдән дәрвишне эзләргә чыгарып җибәрделәр.

Әбүгалисина үзен эзләүләрен белде. Чөнки аның кеше күзенә күренми йөри торган егетләре бар, һәрвакыт алар килеп хәбәр итеп торалар иде. Ул үзе дә яшеренергә, ихфа гыйлеме ярдәме белән күзгә күренми йөрергә булдыра алыр иде, ләкин юри алай эшләмәде. Киресенчә, һәркем күрерлек бер җирдә утырып торырга булды. Эзләүчеләр аны күрделәр. Мунчачы:

— Менә ул дәрвиш шушы кеше!— диде.

Тиз генә барып субашына хәбәр бирделәр. Субашы, килеп җитеп, Әбүгалисинаның якасына ябышты.

— Син кайда качып йөрисең? Сине сарайга чакыралар, әйдә киттек!— дип өстерәргә тотынды. Аңа каршы Әбүгалисина:

— Мин бер фәкыйрь кешемен. Сарайда һич эшем юк,— дисә дә, ай-ваена карамый, өстерәп алып киттеләр.

Шул арада Әбүгалисина кыяфәтен үзгәртте: үзе дә субашы кыяфәтенә керде. Әбүгалисина да, субашының якасына ябышып:

— Кайда качып йөрисең, әйдә, сине сарайга чакыралар,— дип өстери башлады. Җыелган кешеләр, боларны күреп, «кара, ике субашы сугыша» дип, кызыксынып карап торалар.

Шулай якалашып, алар патша сараена барып керделәр. Чын субашы, күз яше белән елап:

— И падишаһым! Тотып китерергә кушкан кешегез валлаһи шушы. Ул сихерче икән, мин аны барып тоткач, үзе дә субашына әверелде. Аны җәзалагыз,— диде.

Субашы кыяфәтендәге Әбүгалисина да, елаган булып, шуны ук кабатлады. Боларның кайсы чын субашы икәнен, кайсына җәза бирергә кирәклекне белми аптырап калдылар.

Бу вакыт шәһәрнең казые да сарайда иде.

— Боларны ни эшләтергә?— дип, аңа сорау бирделәр.

Ул:

— Ай-вайларына карамыйча, икесен дә дарга асарга кирәк. Бер субашы үлгәннән әллә ни булмас!— диде.

Аларның икесен дә асарга карар кылдылар. Бу хәбәр бөтен шәһәргә таралды. Хәлвәфрүш тә, ишетеп, бик тирән кайгыга төште.

Ләкин Әбүгалисинага бу юлы да үзенең гыйлеме ярдәм итте: ул үзен асарга әзерләнгән баш җәлладны субашы кыяфәтенә кертте, үзе баш җәллад кыяфәтенә керде. Ярдәмче җәлладларга кушып, субашы белән баш җәлладны астырды. Патша янына барып:

— Падишаһым, солтаным! Әмерегез җиренә җиткерелде,— диде. Шуннан соң үзе юк булды.

Бераздан асылган кешеләрнең субашы белән баш җәллад икәнен беләләр. Шәһәр халкы бу ике явызның үлүенә бик шатланды. Бары тик патша гына аларның үлүенә бик борчылды. Ул казыйны чакырып алды да:

— Бу эшкә син сәбәпче. Синең киңәшең белән иң ышанычлы ике арка таянычымнан аерылдым,— дип, бик каты ачуланды.

Ләкин Әбүгалисина казыйны болай гына калдырырга теләмәде. Халыкка күп җәберләр тидергән бу хакимне барлык кешеләр арасында адәм мәсхәрәсе ясап, патшаның үзе тарафыннан аңа җәза бирдертте.

Сораулар һәм биремнәр

1. Әбүгалисинаның бала чагы әсәрдә ничек сурәтләнә? Аңа нинди сыйфатлар хас?

2. Әбүгалисина һәм Әбелхарис тау куышына керергә ничек әзерләнәләр?

3. Хәлвәфрүш белән патша кызының мәхәббәте нинди киртәләргә очрый? Яшьләргә Әбүгалисина ничек ярдәм итә?

4. Әбелхарис нинди могҗизалар тудыра?

5. Ни өчен ул Әбүгалисинага каршы көрәшә? Хәлвәфрүшне кулга төшерү өчен нинди чаралар күрә?

6. Әбүгалисина патшага, Әбелхариска каршы ничек көрәшә? Әсәрдән шул урыннарны табып укыгыз.

7. Әбелхарисның Әбүгалисинага хыянәте нәрсәдә чагыла?

8. Повестьның әһәмияте нидән гыйбарәт?
9. Повесть буенча инша языгыз.

«ӘБУГАЛИСИНА» ПОВЕСТЕ ТУРЫНДА

«Әбүгалисина» — фантастик повесть, анда төрле могҗизалы хәлләр тасвирлана. Бу ягы белән ул әкияткә дә охшаган. Әсәрдән аңлашылганча, гадәттән тыш хәлләрнең чыганагы — Әбүгалисинаның белем көче. Ул гаҗәеп могҗизалар тудыра ала икән. Повесть шул хакта сөйли.

Әбүгалисина — чынлыкта булган реаль шәхес, Көнчыгышта киң танылган галим. Аның медицина өлкәсендәге китаплары күп гасырлар буена Европада дәреслек буларак файдаланыла. К. Насыйри аны хыялый нигезгә күчерә. Акыл көче, гыйлем куәтен раслау авторның мәгърифәтчелек карашларына туры килә.

К. Насыйри Әбүгалисинаның үтә зирәк, зиһенле булуына басым ясый. Шәкертләр аның киезе астына бер бит кәгазь салып куялар. Килеп утыргач, Әбүгалисина аптырап кала:

— Белмим, мәктәпнең түшәме төшкәнме, әллә идәне күтәрелгәнме? Ни булса да бар, элеккечә түгел,— ди.

Әбүгалисина белән Әбелхарис, тау куышлыгына бикләнеп калып, бер ел буена мәгарәдәге гыйлем байлыгын — китапларны өйрәнәләр. Моның бик тирән мәгънәсе бар. Дөньяның бөтен мәшәкатьләреннән аерылып, онытылып, күңел биреп өйрәнгәндә генә, гыйлемнең тирән серләренә төшенергә мөмкин дигән фикер уздыра автор.

Әбүгалисинаның гыйлем куәте хәлвә пешерүче егеткә мөнәсәбәтендә ачыла. Хәлвәфрүш һәм патша кызы бер-берсенә гашыйк булалар. Әмма мәхәббәт юлында бик күп киртәләр килеп чыга. Әбүгалисина гыйлеменең тылсым көче аларны җиңәргә, кыен хәлләрдән исән котылырга ярдәм итә. Әбүгалисина үзенең белемен гади хезмәт кешеләренә ярдәм итү, тормышларын җиңеләйтү өчен файдалана. Әсәрдә ул бик кешелекле, ярдәмчел зат итеп тасвирлана.

Әбелхарис исә патшаларга хезмәт итә. Шул җирлектә Әбүгалисина белән Әбелхарисның юллары кисешә. Әбелхарис туганына каршы көрәшкә кушылып китә. Ләкин аның белеме, тылсым көче Әбүгалисинаныкыннан кайтышрак булып чыга. Әбелхарис җиңелә, үкенечле рәвештә һәлак була. Әсәрдә ике гыйлем иясенең ике төрле максатка хезмәт итүе һәм моның күңелсез нәтиҗәсе сурәтләнә.

Габдулла Тукай
(1886—1913)

Татар шигъриятен үстерүгә тиңдәшсез зур өлеш керткән Габдулла Тукай хаклы рәвештә әдәбиятыбызның иң талантлы шагыйрьләреннән санала. Ул бары тик егерме җиде ел гына яшәде. Г. Тукай әйтерсең лә үзенең гомере аз икәнен алдан ук сизенде, йөрәге типкән вакытта мөмкин кадәр күбрәк язып калырга ашыкты. Халкыбызга гаять зур һәм затлы әдәби мирас калдырды.

Тормыш Габдуллага шактый ук рәхимсез була. Бер-бер артлы диярлек әти-әнисе үлеп китә. Бабасының да тормышы яхшыдан булмый, ятим малай күп балалы гаиләгә сыймый. Шул сәбәпле аның бер гаиләдән икенчесенә күчеп йөрүе башлана. Казанда да яшәп карый, тагын Өчилегә кайта, аннан Кырлайга алып китәләр. Ниһаять, язмыш Габдулланы Җаек шәһәренә китереп чыгара. Җаек — Г. Тукайны шагыйрь итеп җитлектергән кала. «Мотыйгия» мәдрәсәсендә алган белем, үзлегеннән күп уку, биредәге әдәби иҗат мохите аның таланты ачылуга ярдәм итә. 1907 елда моннан аерылып Казанга китү 21 яшьлек шагыйрь егеткә бик авыр була. «Пар ат» шигырендә ул Җаек белән «хуш, гомер иткән шәһәр» дип саубуллаша.

Аерылу никадәр моңсу булмасын, шагыйрь төшенкелеккә бирелми. Аны татар халкының мәркәзе — Казан көтә. Бу аның күңелен күтәреп җибәрә. Чыннан да, Казанда яшәгән алты ел вакыт — аның иҗатында иң нәтиҗәле һәм бай чор. «Су анасы», «Таз», «Эштән чыгарылган татар кызына», «Туган авыл», «Туган тел», «Көзге җилләр» һәм башка бик күп әсәрләр биредә иҗат ителә. «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш» поэмасын да шагыйрь Казанга кайткач яза.

Сораулар һәм биремнәр

1. Г. Тукайның «Исемдә калганнар» әсәрен хәтерегезгә төшерегез яки яңадан укып чыгыгыз. Шагыйрьнең тормыш юлын сөйләп бирегез.

2. Шагыйрьнең менә бу сүзләренең мәгънәсен ачып бирегез:

Азмы какканны вә сукканны күтәрдем мин ятим?!
Азрак үстерде сыйпап тик маңлаемнан милләтем.

3. Муса Җәлил болай дип язган иде:

Билгеләми гомер озынлыгын
Еллар саны, картлык җитүе.
Бәлки, менә шушы үлем безгә
Мәңге бетмәс яшәү китерер?

Бу шигырьдә әйтелгән фикерне Г. Тукайның тормышына һәм эшчәнлегенә мөнәсәбәтле киңәйтеп әйтеп бирегез.

4. Җаек (Уральск) шәһәре Г. Тукай өчен кайсы ягы белән кадерле һәм истәлекле?

5. «Пар ат» шигырендә автор бер шәһәрдән аерылуына моңсулана, икенчесенә баруына шатлана. Ни өчен?

6. Аерылып китсәм дә синнән гомерем таңында мин,
И Казан арты, сиңа кайттым сөеп тагын да мин.

Бу шигъри юлларга салынган хис-кичерешләрне аңлатып бирегез.

7. Казанга кайткач, шагыйрьнең иҗаты тагын да үсеп китә. Ни өчен дип уйлыйсыз?

ПЕЧӘН БАЗАРЫ, ЯХУД ЯҢА КИСЕКБАШ

I

Башлыйк әле сүзне Карәхмәт илә,
Яд итәрләр, кем белә, рәхмәт илә.

Алдымызда ат кәмитен күрәлем
Һәм Микитин җәмгатенә ирәлем[1].

Бу Казанда хуп-хуп эшләр күп торыр,
Һич моның тик бери тәкый[2] юк торыр.

Хак Тәгалә нәрсә кылса ирке бар,
Рус Микитиннең Казанда циркы бар.

---

[1] Микитин җәмгатенә ирәлем — Никитин циркына барыйк.

[2] Тәкый — янә.

Шунда бардыр бер мөселман пәһлеван —
Бик озын, бик көчле, гайрәтле җиван[1].

Шәп батыр, Зәркум кеби, Салсал кеби;
Хәйләгә оста, Сәет-Баттал[2] кеби.

Бер хикәят килде телемгә арый,
Яхшылап сөйләп биреп булса ярый.

Таңга калсын тиречеләр, итчеләр,
Шәмчеләр дә майчылар, кибетчеләр.

Берзаман бардым Печән базарына,
Шунда мин таптым азык язарыма.

Иртә берлән кайнамакта бу базар,
Кайда баксаң, анда тулган сәүдәгәр.

Кайсысы сатмактадыр[3], кайсы ала,
Берсе алдый, шунда берсе алдана.

Һәр заманны монда хәлләр шул икән,
Һәркем үз хәле белән мәшгуль икән.

Йөгрешәләр сөртенә дә абына
Барча мөэминнәр[4] «Көфер почмагы»на.

Нинди эш булган соң анда, нәрсә бар?
Бер сугыш чыкканмы әллә, йә пожар?..

Мин дә чаптым шунда мөэминнәр белән.
Мәскәүски якка күз салсам күрәм:

Тәгәрәп юл уртасыннан таш килә,
Таш түгел лә — бер киселгән Баш килә.

Баш килә шундый каты, шундый кызып,
Полный ход килгән трамвайдан узып.

---

[1] Җиван — егет.

[2] Зәркум, Салсал, Сәет-Баттал — дини риваятьләрдәге батырлар.

[3] Сатмактадыр — сата.

[4] Мөэминнәр — ислам динендәге кешеләр.

Һәр тараф тулган караучы — юк саны;
Баш «Көфер чаты»на җиткәч туктады.

Күрделәр кисек бер адәм башыны;
Агълаю килде[1] дә түкте яшене.

Гәүдәсе юк, бер гаҗәеп Баш ирер;
Шәһит ирер[2], ике күзе яшь ирер.

Юк аягы, гәүдәсе һәм юк кулы,—
Бер кисек баштыр, һаман сөйләр теле.

Сакалы ак, һәм йөзеннән нур чыкар[3],
Күз камашыр — һәркем йөзенә бакар[4].

Йөзен орды туфракка — кылды зари[5],
Зари-зари егълады шәмче Гали.

Башны күргәч, ихтыярсыз җан ачый:
Әй җаным, бу кайсы мескеннең башы?

Агълыйдыр һәркем күзеннән яшь сыгып,
Агълый кибеттән кәләпүшләр чыгып.

Һәм аяк астында яткан тиреләр
Барча: «Ай мескен дә, ай мескен!» — диләр.

Шунда тау-тау торган он капчыклары,
Агълыйла саилче кыз, карчыклары.

Агъламаска — бер мөселман башы бу,
Һәр мөселман бәндәнең җанашы бу.

Агълый Кисекбаш, моңын-зарын сөйли,
Ак сакаллар: «Нәрсә булды?» — дип сорый.

Кызганыч бер кыяфәт, яшьле күз
Берлә мескен Баш болай дип башлый сүз:

---

[1] Агълаю килде — елыйсы килде.
[2] Шәһит ирер — изге көрәштә гарипләнгән.
[3] Нур чыкар — нур чәчәр.
[4] Йөзенә бакар — йөзенә карар.
[5] Кылды зари — зарын сөйләде, аңлатты.

«Баштан үткәнне сөйлимен, тыңлагыз,
Мин хаҗи — бардым хаҗә[1] туксан тугыз.

Күп тәваф иттем[2] Хиҗаз сахрасыни,
Җиддәсен һәм Мәккәсен, Сангасыни[3].

Мин гласныйлыкта[4] тормышым янә
Бу шәһәрнең Думасында ун сәнә[5].

Һәм дә Мәскәүдән дә маллар алмышым,
Сумына туксан тиенне чәлмешем.

Итә ирдем көн дә бер Коръән хәтем[6],
Алмышым гомремдә унбишләп хатын.

Кич барыр идем «Тәтәйләр[7] рәте»нә,
Әүрелеп көндез кеше сурәтенә.

Бар иде картлыкта алган хатыным,
Бер балам,— аһ, күз нурым! аһ, алтыным!

Карт көнемдә бунлар[8] иптәшләр иде,
Яхшы юлдашлар вә сердәшләр иде.

Тартып алды бунларый миннән Дию,
Сезгә важибтыр[9] миңа ярдәм кыйлу.

Анларый алды да керде коега;
Кайгы куймый күзләремне уйкуга.

Кыйлмасагыз сез миңа ярдәм әгәр,
Сезгә миннән яүме мәхшәр дәгъва бар![10]

---

[1] Хаҗә — хаҗга.
[2] Тәваф иттем — әйләнеп йөрдем.
[3] Җиддә, Мәккә, Санга — Гарәбстандагы шәһәрләр.
[4] Гласныйлыкта — шәһәр Думасында әгъза булу.
[5] Сәнә — ел.
[6] Итә ирдем көн дә бер Коръән хәтем — көн дә бер тапкыр Коръәнне укып чыга идем.
[7] Тәтәйләр — аздыргыч хатыннар.
[8] Бунлар — болар.
[9] Важибтыр — тиештер.
[10] Яүме мәхшәр дәгъва бар — Мәхшәр көнендә, ягъни үлеп терелгән көндә дә даулармын.

II

Шунда картлар җәмгулыб[1] киңәштеләр:
«Нишлибез соң? агълап[2] эш булмас!» — диләр.

Кайсы әйтә: «Патшадан солдат сорыйк,
Ул Диюне ядрә белән аттырыйк».

Кайсы әйтә: «Садрый Максуди[3] барыр,
Мәсьәләне, бәлки, Мәҗлескә салыр[4].

Без аның чөн күп тырыштык шар салып,
Ахырында Думага да сайладык».

Кайсы әйтә: «Камчылы ишан[5] барыр,
Ул Диюнең, бәлки, сихерен кайтарыр».

Уртадан бер күп белекле[6] карт кеше
Әйтә: «Бу хакта минем фикерем шушы:

Тыңлагыз, бу тик Карәхмәтнең эше,
Инде ул, мәгълүмегез, көчле кеше.

Ул барып алсын Диюнең җаныны,
Кайтарыр ул бу Кисекбаш каныны».

Барча картлар: «Яхшы бу, яхшы!» — диләр.
«Вәт, менә рәхмәт! Бабай тапты», — диләр.

Бу бабай фикерен туры итсен Хода!
Итте бер мөэмин кеше шунда нида[7]:

«Миңлебай! бар тиз Карәхмәтне чакыр!» —
Чапты китте Миңлебай чатыр-чатыр.

---

[1] Җәмгулыб — җыелып.
[2] Агълап — елап.
[3] Садрый Максуди — Дәүләт Думасы депутаты, галим. Революциядән соң чит илдә яшәде.
[4] Мәҗлескә салыр — Дума утырышында тикшерүгә куяр.
[5] Камчылы ишан — авыруларны камчы белән кыйнап «дәвалаучы» дин әһеле.
[6] Күп белекле — күпне белүче.
[7] Нида — кычкыру, боеру.

Үтмәгәндер күз ачып йомган заман,
Килде дә җитте Карәхмәт каһреман[1].

Эстәде[2] Башны күтәреп бакмага:
Гайрәтен һәм куәтен күрсәтмәгә.

Ничә кем зур әйләде[3] — күтәрмәде,
Зәррә мыскал[4] җиреннән тибрәтмәде.

Һич күтәралмый аны, хәйран кала;
Көчләнә, тирли батыр, хәлдән тая.

Ул Баш әйтә: «Бу Карәхмәт шаштымы?
Ул күтәрерлек җиңел бер башмы бу?

Бер түгел, меңләп Карәхмәт килсә дә,
Хәтта Зайкин, Медведев[5] бер булса да,

Һич насыйп булмас аларга кузгату,
Файдасыздыр кузгатырга күз ату.

Чикмәсен бушка газапны — булмый да,
Чөнки бер мең пот тәгассыйб[6] бу мидә.

Бу мидә йөзләп гыйнад[7] амбары бар;
Бу мидә мең пот сыраның пары бар.

Бу мидә бардыр җәһаләт[8] ун вагон,
«Мин беләмлек» дәгъвасы — бер мең вагон».

III

Хазирун[9]: «Аh, нинди изге Баш!» — диләр,
«Тик янә урнына ябышмас»,— диләр.

---

[1] Каһреман — батыр.
[2] Эстәде — теләде.
[3] Ничә кем зур әйләде — күпме генә көч куйса да.
[4] Зәррә мыскал — бер мыскал да.
[5] Зайкин, Медведев — шул вакыттагы көрәшче батырлар.
[6] Тәгассыйб — фанатизм, искелекне яклау.
[7] Гыйнад — кирелек.
[8] Җәһаләт — наданлык.
[9] Хазирун — шундагылар.

Инде мөэминнәр каты кызгандылар,
Чын күңелдән Баш өчен сызландылар.

Һәм үрә торды батырның чәчләре,
Газбиләә[1] авызыннан утлар чәчрәде:

«Мин,— диде,— дөньяда тормыйм, ичмасам,
Шул Дию, залим башыны кисмәсәм.

Бармыймын хәтта Микитин циркына,
Шул Дию башына күңелем җилкенә.

Шунсыз инде бер дә рәхәт күрмәмен
Һәм Пугач—Зайкин[2] рәтенә кермәмен.

Йә үләм мин, йә шуның муйнын кисәм,
Хак гыйнаять әйләр ирсә[3], мин басам».

Бар халык та: «Бар, Карәхмәт, бар»,— диләр,
«Бу Кисекбаш хатынын коткар»,— диләр.

«Бармыйлармы? Мин барам, әлбәт, барам,
Бармасам, дөнья йөзе булсын хәрам!..»

Бу гаһедтән соңра[4] Башның күзләре
Яктырып китте — ачылды йөзләре.

Ул Баш әйтә: «Әй батыр, рәхмәт сиңа,
Йөкләдем мин бик авыр зәхмәт сиңа.

Барча иркеңнән вә циркыңнан җөда
Булдың[5] инде, бәс сиңа миннән дога.

Әйдәгез, әй әһле базар[6], берьюлы
Фатиха: уңсын Карәхмәтнең юлы!»

Шулвакыт куллар белән тулды сәма[7],
Чын күңел берлән кыла һәркем дога:

---

[1] Газбилә — ачудан.
[2] Пугач — Зайкин — көрәшче батырлар.
[3] Хак гыйнаять әйләр ирсә — Алла ярдәм итсә.
[4] Гаһедтән соңра — ант итүдән, сүз бирүдән соң.
[5] Җөда булдың — аерылдың.
[6] Әһле базар — базарда булучылар.
[7] Сәма — күк.

«И Ходаем, бир Карәхмәткә мәдәт[1],
Ушбу юлда бир аңар көч һәм сәләт!»

Берзаман куллар салындылар төшеп —
Күрделәр: килде трамвай җитешеп.

Пәһлеван вагонга җирләште[2] кереп,
Алды «пересадка» берлән бер билет.

Барча мөэминнәр озатып калдылар:
«И Ходаем, рәхмәтеңне сал!»— диләр.

Кузгалып китте вагон, җилдәй бара,
Баш йомарланып китә, җирдән бара.

Башны күргәч, кузгалып гайрәтләре,
Өрде барча итчеләрнең этләре.

Йөгерәләр аллы-артлы бер көтү
Кәкре койрыклар! — Кая Башны җитү!

Ул барадыр йөгерек аттан да каты
Һәм җәядән аткан уктан да каты.

Үз хәленчә китмәдә тыр-тыр вагон,
Таш ата Башка малайлар яльгабун[3].

Калды уң якта «Китаплар ханәсе»,
Сулда — «Әлислах» идарәханәсе[4].

Бер сәгать, бер көн вә өч көн киттеләр,—
Зур завод Крестовниковны үттеләр.

Җиде көне, төне чөнки киттеләр,
Нагәһан[5] бер сахрая[6] ирештеләр.

---

[1] Мәдәт — ярдәм, мөмкинлек.
[2] Җирләште — урнашты.
[3] Яльгабун — уйнап.
[4] «Әлислах» идарәханәсе — «Әлислах» газетасы урнашкан бина.
[5] Нагәһан — бервакыт.
[6] Сахрая — сәхрәгә.

Шунда җиткәчтен трамвай туктады,
Баш йомарланып барадыр туктамый.

Туктагач шунда сихерле машина,
«Нишлибез?» — диде Карәхмәт Башына.

Ул Баш әйтә: «Син вагоннан төш хәзер,
Бик якынлашты кирәкле төш хәзер.

Без барыйк азрак җәяү алга табан;
Иштә[1] бу алдыңдагы күлдер — Кабан,

Бар дорыр[2] күлнең төбендә бер кое,
Шунда керде ул теге залим Дию!»

IV

Сүз рәте килгәч, итәм әзрәк бәян[3],
Таки[4] яшьрен күл төбе булсын гаян[5].

Анда һәртөрле гаҗәпләр бар да бар:
Кып-кызыл алтын шәһәр, җиз карьяләр[6];

Мөгезе мәрмәр боланнармы кирәк,
Алты йөз башлы еланнармы кирәк.

Су анасы, — бик явыз, йөзе кара, —
Ел да бер угыланны йә кызны ала.

Шул заман, кем, килде Мәскәү гаскәре[7],
Бу Казанга туп атарга башлады.

Шулвакыт ханнар, вәзирләр качтылар,
Барча малны ушбу[8] күлгә сачтылар.

---

[1] Иштә — менә.
[2] Бар дорыр — бардыр.
[3] Итәм бәян — сөйләп бирәм.
[4] Таки — өчен, дип.
[5] Гаян — ачык.
[6] Карья — авыл.
[7] Килде Мәскәү гаскәре — 1552 елда Явыз Иван Казанны сугышып ала.
[8] Ушбу — шушы.

Сачтылар алтын-көмешнең һәммәсен,
Ягъни «безнең мал кешегә калмасын».

Шул заманнан бирле, кем, алтын-көмеш
Күл төбендә һәм хисапсыз күп, имеш.

«Бер заманда, шөбһәсез, бу күл кибәр»,—
Дип, гакыллы зур хакимнәр сөйлиләр.

Киптисә, бер дәфга[1] кузгалып бары —
Күл буеның мәдрәсә талибләре[2] —

Барча байлыкны җыячаклар, имеш,
Һич һөнәрсез[3] бай булачаклар, имеш.

Ел ел артыннан һаман үтмәктәдер,
Күл буе талибләре көтмәктәдер...

V

Әйдә максутка! Алар көтсен әле,
Сүз Кисекбашка килеп җитсен әле.

Ул Карәхмәтнең билендә бавы бар;
Бауның алты мең колачлы буе бар.

Бау белән ул эшне яхшы җайлады:
Бер очын Башның теленә бәйләде.

Бер очын учлап, Кабанга чумды ул,
Туп-туры шуннан коега тотты юл.

Ул төшә, бер көн төшә, өч көн төшә;
Туктамый инмәктәдер[4] көндез кичә.

Бер — аягы әйләнәдер, бер — башы,
Һәр минут — һәрдәм[5] Хозырдыр[6] юлдашы.

---

[1] Бер дәфга — бердән.
[2] Талибләр — шәкертләре.
[3] Һич һөнәрсез — эш рәте белмичә, тик торып кына.
[4] Инмәктәдер — төшүен дәвам иттерә.
[5] Һәрдәм — һәрвакыт.
[6] Хозыр — Хозыр Ильяс. Дин өйрәтүе буенча, ул — мәңге үлми торган пәйгамбәр. Төрле кеше рәвешенә кереп, башкаларга изгелек эшләп йөрүче.

Ул «инә», «Алла» сүзен тәкрар кыйла,
Тышта[1] агълыйдыр Кисекбаш, кайгыра.

Нәкъ төшеп киткәнгә ун тәүлек тула,—
Ахыры җиргә аяклары төртелә.

Пәһлеван, гаять арып, эштән чыгып,
Ун минут торды катып, гакълын җыеп.

Бервакыт безнең батыр ачты күзен:
Бер сарай алдындадыр күрде үзен.

Шундый яхшыдыр ки, һич мондый сарай
Салмагандыр Кәчимеский Ибырай[2].

Капка башында яшел ләүхә[3] тора;
Анда иштә[4] ушбу сүзләр укыла:

«Монда сакин бужи фирка җания,
Табигыйннәр мәзһәбе Гайнания[5].

Тартты, куптарды Карәхмәт капканы,
Соңра тиз-тиз элгәрегә[6] атлады.

Керде дә күрде: сарайда бер хатын
Җәлеб итәрлек һәр кешенең дикъкатен:

Йөз нуры дүрт якны әнвәр әйләгән[7],
Тәңренең гыйшкы аңа кяр әйләгән[8].

Намаз укыр ул ахирәт хатыны,
Аһ итәр — күккә чыгадыр төтене.

---

[1] Тышта — өстә, күл читендә.

[2] Кәчимеский Ибырай — бөтен малын сатып эчеп, туздырып бетергән Ибраһим исемле (Касыйм шәһәреннән) сәүдәгәр.

[3] Ләүхә — такта.

[4] Иштә — менә.

[5] Монда коткаручы Ходай фиркасенә (партиясенә), Гайнания мәзһәбенә (сектасына) иярүчеләр тора.

[6] Элгәрегә — эчкә.

[7] Әнвәр әйләгән — нурландырган.

[8] Кяр әйләгән — йогынты ясаган.

Күз яше сәҗдә җирене болгамыш[1];
Ул Кисекбашның хәлале[2] бу, имеш.

Үтте аннан, китте башка бүлмәгә,
Шундый күренеш — кызганычтыр күрмәгә:

Анда биш йөзләп мөселманнар тулы,
Багълыдыр[3] һәрберсенең аяк-кулы.

«Алла, Алла! Саклый күр утдин!»— диләр,
«Кыл шәфәгать[4], йа Баһаветдин[5]!»— диләр.

Сикерәләр, җенләнәләр үзләре,
Һәм акайган, кот очарлык күзләре.

Чөн болар һәп[6] пәһлеванны күрделәр;
Бер авыздан бөйлә фөрьяд кыйлдылар[7]:

«Мәрхәмәт ит, и Карәхмәт, безгә син,
Безне коткар, из Диюнең измәсен.

Һәр минут үткән саен, без куркуда:
Бу Дию һәр көн бишәр адәм суя.

Күп идек без былтыр, үткән көз генә,
Инде калды барчабыз биш йөз генә».

Шунда бер бүлмә күренде — шактый киң;
Күрде батыр: шунда яткан ул ләгыйнь[8].

Биниһая[9] зур башы — гөмбәз кадәр;
Ни сәбәптәндер, башында фәс[10] тә бар.

---

[1] Сәҗдә җирене болгамыш — намаз укыган урынын чылаткан.

[2] Хәлале — хатыны.

[3] Багълыдыр — бәйләүледер.

[4] Шәфәгать — шәфкать.

[5] Баһаветдин — Идел буе һәм Себер мөселманнары арасында изге булып танылган Хуҗа Баһаветдин (1804—1893). Гайнан Вәисевнең этисе.

[6] Чөн болар һәп — кайчан боларның һәрберсе.

[7] Фөрьяд кыйлдылар — ачынып еладылар.

[8] Ләгыйнь — ләгънәт суккан.

[9] Биниһая — чиксез.

[10] Фәс — төрекләр кия торган чуклы баш киеме.

Салынып төшкән килешсез мыегы —
Бик озындыр, мисле[1] күсе койрыгы.

Бармаклары охшар адәм гәүдәсе,—
Күп татарны имгән ирде ул гасый[2].

Билгеле инде, Карәхмәт курыкмады;
Ул аны: «Тор! Тор!» — диюбән[3] төрткәли.

Нәгъръләр[4] берлән Диюне уйгата,
Һич уйганмый уйкусыннан, ул ята.

Төрткәли торгач, ниһаять, уйгана,
Куркынычлы күзләре уттай яна.

Ул Дию уйганды: дүрт якка бакар,
Көфер сүзләр, агъзыйдин[5] утлар сачар.

«Ник йөрисең монда рөхсәтсез кереп,
Һич оялмый тәмле уйкум боздырып?

Белмисең, махсус колониям бар минем,
Мәхкәмәм[6] бар, автономиям бар минем.

Курыкмадың, монда ничек кердең кыеп,
Бар икән йөргән кеше җаннан туеп!»

Язмыймын сугыш нә рәсмә[7] булганын,
Кайсысы җиңгән вә йә җиңелгәнен.

Гөрзи[8] төшкәч, кайсы билдән батканын,
Кайсысының маңгаеннан батканын.

Кариәм[9], иткел канәгать барына,
Итмәсәң — әйдә Печән базарына.

---

[1] Мисле — нәкъ.
[2] Гасый — гөнаһлы.
[3] Диюбән — ди-ди.
[4] Нәгъръләр — кәчле тавыш.
[5] Агъзыйдин — авызыннан.
[6] Мәхкәмәм — тазалыгым, ныклыгым.
[7] Нә рәсмә — ничек, ни рәвешле.
[8] Гөрзи — дини әкиятләрдәге зур чукмар.
[9] Кариәм — укучым.

VI

Иртә берлән кайнамакта ул базар,
Анда да монда кызадыр сәүдәләр.

Кызса да гадәттәгечә сәүдәләр,
Әллә ник бүген күңелсездер базар.

Һәр мөселман әллә нигә кайгылы,
Нәрсәгә хәмлитмәгә[1] бу кайгыны?

Юк, аларга кайгырырга юл да бар:
Нәкъ бер айдыр — юк Кисекбаштан хәбәр.

Җәмгулыб[2] өч-дүрт кеше һәр чат саен,
Гәпләшеп кайгырталар Башның хәлен,

Ягъни ул мескенгә ни булган икән?
Ике якның кайсысы җиңгән икән?

Әһле ислам шул рәвешчә яхзәнүн[3]...
Күренә шул хәл ерактан, ах, вагон!

Нәрсә булган? Нинди хикмәт, кем белә?
Ташбака төсле, вагон әкрен килә.

Өч сәгать үтте күренгәннән бире,
Юк әле асла[4] якынлашкан җире.

«Ник болай бу?» — дип гаҗәпләнгән базар,
Әйләмәктә пассажирлар интизар[5]

VII

Тын гына торган вакытта шул рәвеш
Килде ямьсез, куркынычлы бер тавыш.

Бик каты күк күкрәгән төсле була,
Җир ярылган, тетрәгән төсле була.

---

[1] Хәмлитмәгә — сылтау.
[2] Җәмгулыб — җыелып.
[3] Яхзәнүн — кайгыралар.
[4] Асла — һич.
[5] Интизар — зарыгу.

Бер — арысланнар акыргандай була,
Бер — кәтү ишәк бакыргандай була.

Күз ачырмаслык чыгып комлы буран,
Басты золмәт[1] җир йөзене шул заман.

Һәр тараф золмәт, күренмидер кояш,
Куркуга төште кешеләр — карт вә яшь.

Һич кеше белми: ни хикмәт бу, ни бу?
Әллә чынлап та Кыямәт көнме бу?

Әллә бер «койрыклы йолдыз» төштеме?
Әллә Тәңре сур өрергә[2] куштымы?

Дөньяга соңгы минутлар килдеме?
Әллә ханның мәсҗеде[3] җимерелдеме?

Әллә тәүбә капкасы ябылдымы?
Әллә бер бай корсагы ярылдымы?

Ташпулатлар җөмлә[4] дер-дер селкенә...
Каршылык юктыр Ходайның иркенә.

Әрҗәдә читек-кәвешләр кузгала,
Һәм өеп куйган кәләпүшләр ава.

Танымый дуст дустны, кардәш кардәшен,
Һәр кеше куркып укый «ләхәүлә»сен,

Ни бәла килде Казанның халкына?
Очрадылармы Ходайның каһренә?

VIII

Бәс, шу рәсмә куркышып торган заман
Чыкты аңсыздан кояш, китте тузан.

---

[1] Золмәт — караңгылык.
[2] Сур өрү — дин өйрәтүе буенча, Кыямәт көнне, үлгән кешеләрне терелтү өчен, махсус фәрештәнең быргы кычкыртуы.
[3] Хан мәсҗеде — Сөембикә манарасы.
[4] Җөмлә — барысы.

Күрделәр: җитте килеп мәгълүм вагон,
Тагылып артына бернәрсә тагын.

Ни күрәләр: өнме, ялган төшме бу? —
Тагылып килгән теге фәсле Дию.

И дулый! Мәлгунь Дию и тартыла!
Акыра ямьсез каты — җир селкенә.

Бите-башы канланып беткән янә;
Әйләнәсендә Кисекбаш әйләнә...

Сөйрәлеп җирдән Дию килгән икән,
Һәм вагон шуннан озак торган икән.

Бу Диюдән бу буран купкан икән,
Куркытучы шул Ходай суккан икән.

Инде һәркем күңеленә шатлык тула,
Ул Кисекбаш елмаеп көлгән була.

Шул минут чыкты вагоннан пәһлеван,
Күтәреп башыны арыслан сыман.

Чөн Печән базары халкы күрделәр,
Барча күрешмәк өчен йөгерделәр.

Җөмлә бердән: «Әссәлам! дә әссәлам!»
Һәм Карәхмәт: «Вәгаләйкемәссәлам!»

Һәр мөселман дәрт белән куккә оча:
Бер Кисекбаш, бер Карәхмәтне коча.

Чыкты вагоннан тагын бер ир бала,
Бик чибәр — күргән кеше хәйран кала.

Чыкты тагын да чапанлы бер хатын,
Җәлеп итәрлек тиречеләр дикъкатен.

Бер хаҗи шул хәл хатынга күз кыса
Һәм дә яп-яхшук оятсыз сүз куша.

Ул Кисекбаш күрде дә бу тәкъваны[1]:
«Тимә хатынга!» — диеп, бармак яный.

---

[1] Тәкъва — изге кеше.

«Белмәдем мин!» — дип, хаҗи зари кыйла,
Күзләреннән яшьләрен җари кыла[1].

Шул вакытта Камчылы ишан килә;
Ул Кисекбашны тотубән өшкерә.

Күрделәр: Баш яшь егет булды янә,
Кул-аягы, гәүдәсе килде янә.

Бу кәрамәтне[2] күзилә күрделәр,
Тәңрегә мең-мең шөкерләр кылдылар.

Ул Дию күздән югалды юк булып,
Очты Яңа Бистә якка ут булып.

Сез беләмсез: ул Кисекбаш әл дә бар;
Көн күрә яхшы гына, ул — сәүдәгәр.

Дин юлында күп газап күргән өчен,
Армый-талмый дин өчен йөргән өчен,

Пәһлеванга бирделәр алтын сәгать,
Чылбыры юк, белмимен, нидер сәбәп...

Фагыйләтен, фагыйләтен, фагыйләт,
Ну, Печән базары халкы күңле шат!

ПЕЧӘН БАЗАРЫ, ЯХУД ЯҢА КИСЕКБАШ» ПОЭМАСЫ ТУРЫНДА

Габдулла Тукайның замандашы, күренекле язучы һәм драматург Фатих Әмирхан шагыйрьнең 1907 елда басылган шигырьләр дәфтәренә бәяләмә яза. Ул җыентыктагы «Китмибез!», «Ишек бавы», «Хөррият хакында», «Мәдрәсәдән чыккан шәкертләр ни диләр?», «Көз» кебек матур тасвирлы, саф татар телендә язылган шигырьләргә соклануын белдерә дә: «Моннан соң Габдулла әфәндедән чын, саф татар телендә язылган озын-озын поэмалар көтәбез»,— дип куя. Ягъни каләмдәше көчен шигырьләр язуда раслады, ди, инде зуррак күләмле әсәрләрен күрәсе килүен әйтә.

---

[1] Җари кыла — агыза.
[2] Кәрамәтне — гадәттән тыш хәлне.

Әлбәттә, әсәр кемнең дә булса әйтүе белән генә язылмый. Әсәр иҗат ителсен өчен, ниндидер этәргеч кирәк. «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш» әсәрен язарга нәрсә сәбәпче булган? Г. Тукай үзе болай ди:

Берзаман бардым Печән базарына,—
Шунда мин таптым азык язарыма.

Базар — сату-алу урыны. Алар элек-электән һәр шәһәрдә, зуррак авылларда да булган. Казан кебек зур шәһәрләрдә хәтта берничә базар эшләп килгән.

Г. Тукайның «Исемдә калганнар» исемле автобиографик әсәрен сез, әлбәттә, яхшы хәтерлисездер. Кечкенә Габдулла үзе дә шушы Печән базарына китерелә. Аның үз тормышы да шушы базар белән бәйләнгән булган.

Г. Тукай поэмада Печән базарындагы хәлләрне һәм андагы кешеләрнең бөтенесен дә күрсәтүне максат итеп куймаган. Ул базарның бер генә өлешен — «Көфер чаты»н гына ала. (1911 елда Г. Камал да «Безнең шәһәрнең серләре» әсәрендә шушы урынны күрсәткән иде.) Ник дигәндә, монда үзенең шкаф кадәр генә ларегыннан вак-төяк белән сату итүче Хафиз исемле кеше, үзе кебек вак, гайбәтчел, икейөзле адәмнәрне янына җыеп, узып баручыларны мыскыллап кала икән. Аларны кяферләр[1] дип атый, тузга язмаган сүзләр сөйли һәм шул шөгылен файдалы эш дип исәпли, кешеләр алдында үзен изге бәндә итеп күрсәтергә тырыша. Г. Тукай әлеге кешеләрне көлкегә калдырырга тели. Бу омтылышны тормышка ашыру өчен, сатирадан да үткен корал юк. Менә ни өчен Г. Тукай «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш» поэмасын сатира алымы белән яза.

Хәзер инде Кисекбашның кем икәнлеген ачыкларга кирәк.

XIII—XIV гасырларда Идел буенда «Кисекбаш китабы»[2] дигән әсәр язылган. Ул болай башланып китә:

Башлыйк сүзне Алла исеме белән,
Булыйк төн һәм көн Алла белән.

Алдыбызда Аллаһыны күрербез,
Мостафаның[3] җәмгатенә[4] керербез.

---

[1] Кяфер — гөнаһлы, Аллага каршы булган кеше.
[2] Хәзерге телгә күчерелде.
[3] Мостафа — сайланган; Мөхәммәт пәйгамбәрнең бер исеме.
[4] Җәмгатенә — тирәлегенә.

Сөйләр сүзем бер яхшы дастан[1],
Йөрәген шатландырыр дусның.

Дөньяда яхшы эшләр күп булыр ул,
Моның кебек берәү һич юктыр ул.

Бер хикәят килде хәтеремә,
Ходай булышса аны сөйләргә...

Бу дастанда нәрсә турында сүз бара соң? Бер кешенең чибәр хатыны һәм улы була. Көннәрдән бер көнне Дию пәрие бу кешенең, башын гына калдырып, гәүдәсен ашый; улын кабып йота; хатынын, урлап, коега алып төшеп китә. Гәүдәсез калган Баш, ягъни Кисекбаш, Мөхәммәт пәйгамбәр янына килә, үзенең кайгысын сөйләп бирә. Пәйгамбәрнең батыр сугышчысы Гали Дию артыннан китә, бу явыз көчне җиңеп, теге кешенең чибәр хатынын алып кайта. Пәйгамбәр, өшкереп, бу кешенең башын гәүдәсенә ялгый. Шушы хәлләрне күреп, Кисекбаш Аллаһы Тәгаләнең һәм Мөхәммәт пәйгамбәрнең кодрәтенә тагын бер тапкыр инана һәм дингә турылыклы булып яшәргә карар кыла. «Кисекбаш китабы»ның (ягъни «Иске Кисекбаш»ның) эчтәлеге шуннан гыйбарәт.

Г. Тукай, Печән базарындагы вакыйгаларны сурәтләү өчен, халыкка шактый мәгълүм булган шушы әсәрнең төзелешен өлге итеп ала, әмма аның калыбына яңа эчтәлек сала. Моның өчен ул «Кисекбаш китабы»ндагы образларны «Кәфер почмагы»ндагы кешеләр белән алыштыра. Киселгән Баш — шул вакыттагы бер татар кешесе. Ләкин гади генә кеше түгел, шәһәр Думасында ун ел депутат булган, сәүдәгәр. Менә нинди кеше икән әлеге гәүдәсез калган зат! Гәүдәсез Баш үзенең зарын Печән базары әһелләренә килеп сөйли, ә бу кешеләр исә Башның гәүдәсен кайтарыр өчен нинди чара күрергә дип киңәшәләр.

Ул елларда Казанда бер рус кешесе цирк тота. Татарлар, гөнаһыннан куркып, концерт-спектакльләргә бик йөрмәсәләр дә, циркка барудан тыелмыйлар. Чөнки анда атлар катнашындагы уеннар да була. «Ат кәмите» карау безнең халык өчен гадәти әйбер исәпләнә. Әлеге цирк хуҗасы, татарларны үзенең тамашаларына тагы да күбрәк җәлеп итү өчен, рус көрәшчеләре белән бил алышырга каяндыр (төрек булырга

---

[1] Дастан — хикәят, хикәя.

тиеш) мөселман көрәшчесе Карәхмәт (Кара Әхмәт) дигән кешене чакырта. Татарлар исә бу батырны бик тиз үз итәләр. Печән базарындагылар, нишләргә белмичә аптырашып торганда, шушы Карәхмәтне искә төшерәләр. Аны тиз генә чакырып та китерәләр.

Вакыйгалар әлеге тәртиптә генә барса, әлбәттә, поэма гадәти, җиңелчә юмор белән генә өртелгән әсәр булып кабул ителер иде. Г. Тукайның максаты — Кисекбашны һәм «Көфер почмагы» әһелләрен фаш итү, укучы алдында аларны көлкегә калдыру. Моның өчен ул бик кызыклы алым китереп кертә. Ярдәм итәргә килгән Карәхмәт, үзенең көчле икәнлеген күрсәтү өчен, әлеге Башны күтәреп карарга уйлый. Ул циркта әллә нинди пәһлеваннарга каршы көрәшә, ә монда бары тик бер Баш кына. Әмма, ни хикмәттер, Башны урыныннан да кузгата алмый. Биредә Г. Тукай гипербола, ягъни арттырып сурәтләү алымын куллана. Әлеге Баш чамасыз авыр, чөнки анда мең пот (16 тонна) искелекне яклаучы фикер, мең пот сыраның пары, тискәрелек тутырылган йөзләп амбар, ун вагон наданлык, бер мең вагон «мин беләм» дип һавалану, ун келәт иске әйбернең һәммәсе изге була дигән уй, егерме склад һәр җәдит[1] — кяфер дип раслау бар. Күргәнебезчә, Г. Тукай бу Башның эчтәлеген әнә шулай бик образлы итеп тасвирлый. Моның өчен ул «фикер», «тискәрелек», «наданлык», «һавалану» кебек абстракт төшенчәләрне җисмиләштерә, ягъни авырлык үлчәү, күләм берәмлекләре ярдәмендә зур итеп күрсәтә. Боларны ишеткәч уйга каласың: бу Башта бер дә файдалы, кирәкле фикерләр юк икән ич! Ул — киренең дә киресе, тискәренең дә тискәресе. «Көфер почмагы» кешеләре Башның бу сыйфатларын ничек бәялиләр соң? Иң кызыгы да шунда: тыңлап торучылар һәммәсе дә: «Аһ, нинди изге Баш!»— диешәләр. Ә нигә шулай диләр соң? Хикмәт шунда: алар үзләре дә Баш әйткән сыйфатларга ия. Шуңа күрә Башка теләктәшлек күрсәтәләр дә.

Дию пәрие — татар әкиятләрендә була торган куркыныч образ. «Кисекбаш китабы»на да ул шуннан килеп кергән. Әмма әкиятләр дә, «Кисекбаш китабы» да — фантастик әсәрләр. Г. Тукай да сатирик поэмасын әкият рәвешендә яза. Ләкин анда катнашучыларның һәммәсе — егерменче йөз башы татар тормышында булган шәхесләр. Шундыйларның берсе — Гайнан. Шагыйрь аны Дию урынына куеп сурәтли. Ул вакытта

[1] Җәдит — яңалык яклы кеше.

чыннан да андый кеше яшәгән. Сардар Гайнан Вәисев үзенең тарафдарлары белән «Коткару фиркасе» төзи. Әлеге фирка (партия) диннең һәм аның әһелләренең патшага хезмәт итүен теләми. Алар дин тотучыларның аерым бер зур төркемен булдырырга омтылалар, милләтнең азат булуын максат итеп куялар. Хәтта үзләренең хәрби полкларын да төзиләр. Җитәкчесе Вәисев 1918 елның 28 февралендә үтерелә. Аның гәүдәсе Казанның Үзәк мәдәният һәм ял паркындагы туганнар каберлегенә күмелгән. 1919 елда Яңа Бистәдәге бер урамга аның исеме дә бирелгән булган. Әмма Г. Тукай вәисевчеләр төзегән бу мәзһәбнең (төркемнең) чын асылын төшенеп җитмәгән булырга тиеш. Һәрхәлдә, Гайнанны тискәре итеп сурәтләвеннән шул аңлашыла.

Карәхмәт Диюне җиңә. Башның хатынын Печән базары әһелләре алдына кайтарып куя. Камчылы ишанның өшкерүе була, Баш гәүдәсенә ялгана, җитмәсә, яшь егет кыяфәтенә керә. «Көфер почмагы»ндагылар, шатланып, иркен сулыш алып куялар.

Г. Тукай бу әсәре белән үзен көчле сатирик, үткен сүзле, төгәл тасвирлар белән эш итәргә сәләтле шагыйрь итеп күрсәтте. Татар әдәбиятында пародиянең яхшы үрнәген бирде.

«Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш» поэмасында шагыйрьнең сатира көче аеруча нык сизелә. Бу — сурәтләү чараларын уңышлы һәм урынлы кулланудан килә. Мәсәлән, сынландыру алымы әсәрдә шактый еш очрый. Бу исә андагы вакыйгаларны ачыграк күзалларга ярдәм итә. Чынбарлыкта кәләпүшләр, тиреләр, он капчыклары елый алмый. Ә поэмада аларның елавы хәлнең көлкелеген тагын да арттырып җибәрә. Фатих Әмирхан, әсәрне шагыйрьнең үз укуында тыңлагач, болай дип яза: «Халык, җөмлә тәмам булганлыгын да көтә алмыйчан, самими бер көлкегә тотылып, бөтен залны тутырып, кул чабалар һәм укучыны бүлеп, әллә никадәр туктап торырга мәҗбүр итәләр иде».

Ә Галимҗан Ибраһимов: «Әсәрне игътибар белән укып чыгучы монда татар дөньясының каралыкларын бик күп очратачактыр»,— дип, сурәтләнгән хәлләрнең чынлыкка туры килүен раслый.

Халык шагыйре Сибгат Хәким язганча, «Тукайның җиде еллык иҗат гомере батырлыктан тора. Иҗатта батырлык!.. Язучының батырлыгы — ул хакыйкатьне курыкмый әйтү. Сәнгать дөньясына бер каләм иясенең дә кулы тимәгән көчле

сатирик образлар алып кергән Тукай, әгәр «Яңа Кисекбаш» поэмасыннан башка берни язмаса да, үз эшен эшләгән булыр иде.

Монда үз заманының кеме генә юк! Шул катлаулы дөньяны Тукай шөпшә оясын туздырган кебек тузгыта, астын өскә китерә.

Поэмада реаль тормыш белән фантастика бергә аралаша. Кисекбаш утырган трамвай Кабанга хәтле юлны җиде көн, җиде төн үтә. Карәхмәт күлнең төбенә ун тәүлек тулганда гына төшеп җитә... Кабан күле бу поэмадан соң серле булып калды... Кабан күленең төбен һаман күрәсе килеп яши. Күп вакыт үтте, татар поэзиясенә яңа талантлар килде, һәм иксез-чиксез санда төрле темаларга төрле озын-озын поэмалар язылды. Ләкин яхшылары аз. Яхшы дигәннәрен дә «Яңа Кисекбаш» белән янәшә куеп булмый...»

«Кисекбаш»ка гыйлавә»[1] дигән шигырендә Г. Тукай үзе болай ди:

Көлкеле чыкты: ярарлык ул ягы,
Әмма бик яхшы түгел гармун ягы.

Димәк, шагыйрь әсәрнең сәнгатьлелек ягы («гармун ягы») белән бик үк канәгать булмаган. Ләкин чынлыкта әсәр бик үтемле, кызыклы, образлы язылган. Экият рәвешендә бирелүе аны укуны тагын да җиңелләштерә.

«Иске Кисекбаш» әсәрендә тискәре образ бары Дию генә. Бүтән барлык уңай образлар шушы явыз көч белән көрәшкә ташланалар. Г. Тукай әсәрендә исә бер уңай образ да юк. Хәтта Диюне җиңгән Карәхмәт тә мактанчык, ясалма герой буларак күренә. «Иске Кисекбаш» пәйгамбәрне зурлый, ислам диненә хөрмәт уятуны максат итеп куя. Г. Тукайның «Яңа Кисекбаш»ында исә кайбер дин әһелләре тәнкыйть ителә.

Ләкин бу әле Г. Тукай ислам диненнән көлгән дигән сүз түгел. Киресенчә, ул ихласлы дин әһелләрен хөрмәт иткән. Җаектагы Мотыйгулла хәзрәткә булган уңай мөнәсәбәте шуны күрсәтә. Ул динне үз файдаларына хезмәт иттерүчеләрне яратмаган. Дини өйрәтүләрне көлке хәленә төшерүчеләргә дә аңардан нык эләккән. «Печән базары»ндагы бер төркем фанатиклар — шундый кешеләр.

«Көфер почмагы» кешеләренең иң зур ялгышы — эшкә ашмас буш, кысыр хәсрәт артыннан йөрүләре. Менә ни өчен

[1] Гыйлавә — өстәмә.

«Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш» әсәре укучыларны үз яшәешләренә тәнкыйть белән карарга өйрәтә. Файдалы, кызыклы тормыш белән яшәргә, милләтне алга алып китәрдәй эш белән мавыгырга кирәклеген искәртә.

Сораулар һәм биремнәр

Беренче дәрескә

1. Сез «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш» әсәрен өйдә укып килдегез. Поэманың эчтәлеген сөйләгез. Аерым урыннарын укып күрсәтегез.

2. Халык авыз иҗатына хас булган сыйфатларны табыгыз:
а) образларда;
ә) сюжет төзелешендә;
б) сурәтләү үзенчәлегендә.

3. Поэмадагы вакыйгаларны чынбарлыкка китереп бәйли торган якларны билгеләгез:
а) образларның прототиплары;
ә) вакыйга бара торган урыннар;
б) XX йөз башы татар тормышына хас булган күренешләр.

4. Хикәяләүчене сез нинди кеше итеп күз алдына китерәсез?

5. Кисекбаш образының, ягъни шул замандагы иске фикерле сәүдәгәрләрнең, яшәү рәвеше нинди булган?

6. «Көфер почмагы» кешеләренең җыелма портретын сез ничек итеп күз алдына китерәсез?

7. Ни өчен әсәрне сатирик поэма дип атыйбыз? Сатирик үткенлеккә ирешүдә сынландыру алымының әһәмиятен әйтегез.

Икенче дәрескә

1. Әсәрнең жанры — сатирик поэма. Беренче дәрескә бирелгән сорауларга нигезләнеп, шуны дәлилләгез.

2. Әлеге әсәр — бер үк вакытта пародия дә. Ни өчен?

3. «Иске Кисекбаш» белән «Яңа Кисекбаш»ны чагыштырып сөйләгез. Ике әсәр арасындагы охшаш һәм аермалы якларны табыгыз.

4. Г. Тукай поэмада гиперболадан уңышлы файдаланган. Сурәтләү чарасы буларак, гиперболаны аңлатып бирегез һәм мисалларын әсәрдән табыгыз.

5. «Габдулла Тукай» дип исемләнгән фотоальбомнар белән танышыгыз (Татар. кит. нәшр., 1966 яки 1986). Б. Урманченың «Печән базары» (1975) рәсемен җентекләп карагыз. «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш» поэмасына Г. Арсланов эшләгән иллюстрацияләргә игътибар итегез (1926). Уку елы дәвамында Р. Гобәйдуллинның «Кисекбаш» балеты музыкасы белән танышырга тырышыгыз.

Өченче дәрескә

Г. Тукайның «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш» сатирик поэмасы буенча фикер алышыгыз. Анда түбәндәге сорауларны ачыкларга мөмкин:

1. Печән базары безнең күңелдә уңай да, тискәре дә хисләр уята. Бу базар татар халкы тормышында нинди урын тоткан?

2. Ни өчен Г. Тукай, Г. Камал кебек күренекле әдипләр икесе дә шәһәребезнең шушы урынын үз әсәрләрендә сурәтләргә теләделәр икән? Ике әсәрне дә файдаланып сөйләргә тырышыгыз.

3. «Шагыйрь, «Көфер почмагы»ның шул вакыттагы кешеләрен тәнкыйтьләп, халкыбызның киләчәге турында кайгырта» дигән фикер белән килешәсезме? Күл буе мәдрәсәсе шәкертләре турында сүз барганда, сез ниләр уйлыйсыз?

4. Кисекбашка ярдәм итү өчен нигә патшага да, депутатка да мөрәҗәгать итмиләр? Ни өчен бу эшкә Карәхмәтне чакыралар?

5. Карәхмәт образының сатирик яклары нәрсәләрдә күренә?

6. Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов, С. Хәкимнәрнең әлеге әсәргә карата әйтелгән фикерләре белән сез килешәсезме? Сатирик әсәрләргә хас булганча, халыктагы тискәре сыйфатлар арттырылып бирелмәгәнме? Егерменче йөз башы татар тормышы турында укыганнарыгызга таянып, халкыбызга хас булган төп сыйфатлар турында сөйләгез.

7. «Мин Кисекбашны нинди итеп күз алдына китерәм?», «Печән базары әһелләре, Г. Тукай сурәтләвенчә, кемнәр алар?», «Поэмадагы әкият алымнары» кебек темаларга инша языгыз.

Гаяз Исхакый
(1878—1954)

Гаяз Исхакый 1878 елның 22 февралендә (яңача) Казан губернасы Чистай өязе Яуширмә авылында Гыйлаҗетдин хәзрәт гаиләсендә туа. Биш яшендә укырга өйрәнә, Чистайда, Казанның Күл буе, Әмирхановлар мәдрәсәләрендә белем ала. 1898 елның көзендә Татар укытучылар мәктәбендә Х. Ямашев, Г. Коләхмәтовлар белән бергә укый. 1902 елның көзендә Оренбургның «Хөсәения» мәдрәсәсенә укытучы булып килә. 1903 елның җәендә, ата-анасы ихтыярына буйсынып, авылга кайтып мулла була, ләкин 1904 елда Казанга килеп, революцион хәрәкәткә кушылып китә, «Таң йолдызы», «Тавыш» газеталарында эшли. 1906 елның 30 октябрендә кулга алынып, Казан, Чистай төрмәләрендә утырып чыга. 1907 елның 4 июнендә кабат кулга алына, өч елга хөкем ителеп, Архангел губернасына сөргенгә җибәрелә. 1908 елның җәендә качып, Петербургка килә, аннары Төркиягә чыгып китә. 1911 ел ахырында кабат Петербургка кайтып, чит кеше исемендәге паспорт белән яши, 1912 ел башында яңадан кулга алынып, сөрген срогын тутыру өчен, Архангел губернасына озатыла. Амнистия нәтиҗәсендә 1913 елның мартында азат ителә. Ул «Ил» газетасы чыгара башлый, соңыннан эшчәнлеген «Сүз», «Безнең ил» газеталарында дәвам иттерә.

Г. Исхакый 1917 елгы Февраль революциясен шатланып каршы ала. Ике ел элек туктатылган «Ил» газетасын 1917 елның 5 апреленнән кабат тергезеп җибәрә. Ул Мәскәү мөселман халкы рәисе итеп сайлана, милли-мәдәни автономия идеясен күтәреп чыга. Октябрь революциясеннән соң милли оешмалар туздырыла, җитәкчеләре кулга алына. 1917 елның 22 ноябрендә

Уфада узган Милли Мәҗлес Г. Исхакыйны Версаль солых конференциясенә делегат итеп сайлый. Әдип шул делегация составында чит илгә китә һәм шуннан Ватанга әйләнеп кайтмый. Ул Харбин, Париж, Берлин, Варшава шәһәрләрендә яши.

1933 елның көзендә Ерак Көнчыгышка барып чыга, шунда өч ел яшәп, Япония, Кытай, Манчжуриядә яшәүче татарларны «Идел — Урал» байрагы астына тупларга омтыла. 1928 елдан 1939 елга кадәр Г. Исхакый Берлинда «Яңа милли юл» исемле журнал чыгара, 1935 елда Кытайда «Милли байрак» газетасына нигез сала. 1939 елның июль аенда Гитлер Германиясе Польшага һөҗүм иткәч, Г. Исхакый, язмаларын, архивын калдырып, ашыгыч рәвештә Төркиягә чыгып китә, Истанбул, Анкара шәһәрләрендә яши. 1954 елның 22 июлендә Анкарада вафат була, һәм үзенең васыяте буенча Истанбулда җирләнә.

Гаяз Исхакый бөтен тынгысыз тормышын, дәртен, талантын татар халкының азатлыгы, башка милләтләр белән тигезлеге, рухи үсеше өчен көрәшкә багышлады.

КӘҖҮЛ ЧИТЕК[1]

(Хикәя)

Минем әти бүген Казаннан кайта. Улмы? Ул миңа саплы калач китерә. Аннары миңа читек китерә. Өр-яңа читек.

Аның саурысы[2] синең апаңның намазлык чигә торган үрнәге кебек чәчәкле була.

Аның олтаны — болгар олтаны, кырыеннан киселгән. Ярып ук киселгән. Үзе кып-кызыл төсле. Кура җиләге төсле кызыл түгел, зияб[3] төсле кызыл.

Аның балтыры шадраланып тора, чем-кара.

Миңа әти кәҗүл читек китерә...

Иртәгә гаеткә мин кәҗүл читек киеп барам.

Беләмсең, Миңлегали?

Минем читек балтырының очы кып-кызыл иттереп тар сахтиян[4] тоткан була, ул әнинеке кебек түгәрәкләнеп беткән булмый... тип-тигез киселгән була.

[1] Кәҗүл читек — кәҗә тиресеннән эшләнгән читек.

[2] Саурысы — ат тиресеннән эшләнгән күн.

[3] Зияб (зяблик) — кызылтүш.

[4] Сахтиян — сарык һәм кәҗә тиресеннән эшләнгән күн.

Ул әкертен генә шыгырдый. Солдаттан кайткан Фәхри малаеның итеге шыгырдаган кебек түгел — шыгыр-шыгыр шыгырдый...

Безнең әни иртәгә бәйрәм ашы пешерә. Әйдә, тизрәк чабыйк. Көтү тиз керсен иде дә, сыерларны тиз табып кайтсак иде.

Әйеме, Миңлегали?

Миңа иртәгә гаеткә киеп барырга әби чапан тегә, минем чапан җем-җем итеп тора. Әби әйтә: «Мондый чапанны бохар патшасының угылы гына киядер,— ди.— Ул саранҗы[1]»,— ди... Ул әле өр-яңа. Өр-яңа! Әби әйтә, саранҗы искерми, ди.

Ул әтинең ашка йөри торган чапаны иде. Аның җиңнәре миңа нәни генә була.

Ямь-яшел!..

Мулла абый миңа иртәгә чалма чалып бирә.

Мин гаеткә барам.

Син тәһарәт төзи беләсеңме?..

Мин беләм... Авызга өч мәртәбә су аласың, аннан соң әти төсле итеп тамак кырасың:

— Эһе-эһе.

Аннан читеккә мәсих кыласың[2].

Кәҗүл читеккә мәсих кыласың.

Минем кәвешем әле өр-яңа... Өр-яңа... Мин аны кимәгәнгә, әзрәк кибеп киткән. Әби әле аны суга салып куйды. Аннан соң әби каз мае белән майлый, ул өр-яңа була.

Өр-яңа!..

Әти миңа перәннек тә алып кайта.

Мин сиңа да бирермен...

Миңлевәли малаена бирмим... Бая туп уйнатмады.

Чү-кә!.. Әйе, әнә көтү күренә. Тиз бул. Чап! Син күпернең Шәмсиләр ягында тор, мин — югары оч ягында.

Ишетәмсең, Миңлегали?

Әнә, әнә чылтыр-чылтыр тырантас чылтыраганы ишетелә.

Ул безнең тырантас.

Мөәзиннәрнеке бит тимерле түгел...

Мулла абый әтине Казаннан алып кайта.

---

[1] Саранҗы — саржа (тукыма).

[2] Мәсих кылу — сусыз гына тәһарәт төзү хәрәкәтләрен ясау.

Миңа читек алып кайта. Йөгер. Әнә сыерлар су эчәргә төштеләр...

— Миңлегали, Әхмәдулла! Миңлегали, Әхмәдулла!

— Нәрсә?

— Минем ак башлы тананы югары очка җибәрмәгез әле... Иртәгә борчак белене бирермен...

— Миңа синең борчак беленең кирәкми, безнең әни коймак пешерә.

— Безнең әни кыстыбый ясый... Алып кайтыш инде. Җизниләр бакчасында айбагар бар, сезгә дә бирермен... Әйдә... Тиз! Миңа әти яңа читек алып кайта, кәҗүл читек...

— Әй, малайлар... Куркытма! Әй, пычак кергере!.. Сыерымны кая алып барасың?

*

— Әхмәдулла!.. Әхмәдулла!.. Әтиең кайтты!.. Әтиең кайтты!

— Әйдә ку, Миңлегали! Ку!

— Әби, сыерны куып алып кайтма, каймагы чайпала, ди... Минем әти кайткан, миңа кәҗүл читек алып кайткан... Өр-яңа кәҗүл читек. Әнә тырантас... Әй, җаным тырантас... Кара, алаша, мескен, тирләгән... Минем читек авыр микәнни?..

— Әхмәдулла, Әхмәдулла! Сыерларны алып кайттыңмы?..

Әнә Рәбига тәрәзәдә, кулына нәни генә каймалы читекләр тоткан...

— Әләлики-кызыкый, әләлики-кызыкый. Яңа читегем, яңа читегем... Абый, абый, яңа читегем...

— Бик исем китте... Үземә дә әти яңа читек алып кайткан. Миңа — мулла абзыйныкы кебек кәҗүл читек.

— Әләлики-кызыкый, әләлики-кызыкый...

*

Әти түр башына утырган, аның янына — мулла абый. Самовар гаеткә дип ачылган[1], самовар көлә-көлә җырлый.

Әни чәй ясый, әби әллә нәрсә сөйли.

---

[1] Ачылган — чистартылган.

— Әйдә, угылым, әйдә, угылым, әйдә, Әхмәдулла бәбкәм!

Әни баштан сыйпый, әби аркадан кага.

— Кил, угылым, үз яныма утыр.

Әти мине үз күршесенә утырта.

Рәбига нәни генә читекләрен кочаклаган да кулы белән сыйпап сөя, битенә китерә, үбә, тиле!..

— Әти, миңа читек алып кайттыңмы?

— Кайттым, угылым, кайттым. Әнисе, Әхмәдулланың саплы калачын бир әле.

Саплы калач, саплы калач, әләлики-кызыкый, әләлики-кызыкый!— Мин Рәбиганы кызыктырам.

— Синең саплы калачың юк...

— Минем читегем бар, минем читегем бар...

— Минем дә читегем бар, минем дә читегем бар. Әти, читегем кая?

— Кәҗә Вәли килененең угылы кызамык чыгарган икән, угылым, ул сиңа дигәнне ураза гаетенә генә өлгертәм диде... Аннан Миңлесәхип апаларның кодаларыннан гына алдым.

Мулла абыйга:

— Кая әле, Фәхрулла. Әхмәдулла читеген бир әле. Зур булмаса ярар иде, угылым.

Абый көлемсерәде.

Мин:

— Юк, юк, булмый. Минем нәни генә читегем була. Нәни генә. Әти! Кәҗүлме?

— Кәҗүл, угылым. Менә читек.

Бу читек бөтенләй башка. Аның олтаны да кыпкызыл. Битлекләре, балтыры да дулкынланып тора. Ләкин... Ул ни дип кәҗә Вәли килененең угылы кызамык чыгарган?

— Йә, ки, угылым. Йә, ки, зур булмасмы? Зур булса, мулла абыеңа бирерсең...

Читекнең эченә тәпиләремне тыгам. Аның төбенә аягым барып җитми. Тирә-юньнәрендә минем балтырларым-чалтырларым кысылып, кочакланып тормый.

— Тор, угылым. Тор, бисмилла... Йә, тор!

Мин торып бастым. Читекнең кунычы бот төбенә җитте. Аяк башым аның төбен барып таба алмады. Мин төбенә аяк җитми торган суга чумган кебек булып киттем.

— Зурракмыни?.. Тегүче Хисами да юк бит шуны кечерәйтергә... Анда ук әйттем, безнең Әхмәдулланың тәпиләре әле нәни генә булыр, дидем. Миңлесәхип абыстаңның кодасы: «Юк, булмас, хәзрәт, мәхдүм үсәр әле. Бу елгы гаеткә зур булса, киләсенә чак булыр»,— ди.

Рәбига, тиле, һаман: «Әләлики-кызыкый, әләлики-кызыкый!»— ди. Бик исем китә инде. Минем үземнең дә читегем бар. Бар шул!

Мин читекне әйләндереп-әйләндереп карадым... Тагы кияргә аякларымны керттем, тагы икесе дә төбенә барып җитә алмады.

— Эч, угылым, чәеңне. Әнә саплы калачыңны ал.

Мин читеккә карадым, караган саен ул миңа дошман төсле күренә килде. Мәхәббәтсез читек, дәүкәди читек...

— Рәбига, әләлики-кызыкый, әләлики-кызыкый... Минем чапаным бар!..

— Бар, бәбкәм, бар...

— Минем чыбыркым бар...

— Минем курчакларым бар...

— Тиле!.. Малайлар курчак уйныймыни? Мин катынша түгел.

— Эч, угылым, чәеңне. Иртәгә менә мулла абыең үзеңә чалма чалып бирер. Чапаныңны киярсең. Читегеңне әллә, угылым, гаеткә киеп барырга мулла абыеңа бирәмсең? Аның, мескеннең, гаеткә читеге дә иске...

Мин күземне күтәреп карадым, читек тә кызганыч, мулла абый да кызганыч. Бәхетсез читек, нәни түгел читек! Бу кәҗүл дә түгелдер әле... Түгел!

Мин читекләрне мулла абыйга суздым.

Әти, әни һәм әби һәммәсе:

— Менә рәхмәт, менә рәхмәт, мулла абыең менә сиңа чалма чалып бирер. Киләсе гаеткә кәҗә Вәли килененең угылы кызамыктан терелер дә, сиңа нәни генә, үзеңнең тәпиләрең кебек кенә читек килер. Казанның үзеннән: «Ошбу читек тапшырылса иде Габдулла авылындагы Әхмәдулла мәхдүмгә»,— дип, атыңа язылып килер. Килер шул!

Мин ураза бәйрәмендә өр-яңа кәҗүл читек киеп гаеткә барырмын.

«Әти! Ураза гаете еракмы?»— дияргә башымны күтәрдем. Мулла абый, әти, әни бер-берсенә карашып елмаешып торалар.

Миңа, бердән, минем хәзер дә читегем юк, ураза гаетендә дә читегем булмас, аннары да булмас кебек тоелды. Тамагымны әллә нәрсә кытыклады, борынга әллә ни тулды, күзне әллә нәрсә юешләтте. Биттән кайнарланып әллә нәрсә агып төште...

«Минем читегем юк, минем кәҗүл читегем юк»,— дип, әллә кем минем эчемдә сыкранып кычкырына башлады.

Мин тавышланып еларга тотындым. Саплы калачны алмадым. Чәйне эчмәдем. Акырып барып мендәргә яттым; мине әти дә яратмый, миннән мулла абый да көлә; мине әни дә, әби дә сөйми... Читегем юк... Рәбиганың читеге бар, минем читегем юк.

Әни торды.

— Ни булды сиңа, угылым? Синең бит читегең бар, тик кәҗә Вәли килененең баласы кызамыктан авырганга нәни генә өлгермәгән.

Әби:

— Менә мин сине акыллы дип чапан тектем. Син зур башың белән елап утырасың.

Әти дә:

— Елама, елама! Алай булса, мулла абыеңны кызганмасаң киеп бар.

Минем күз алдыма тагы шул мәхәббәтсез читек килде. Мин тагы кычкырып еладым.

Әни:

— Тукта инде, акыллы бул. Мә, алай булса, үз читегемне бирәм.

Әни каймалы зәңгәр җирлекле читек күтәреп килде.

— Мә, ки, үзеңә булсын.

Рәбига, почмакта читеген кочаклап:

— Мин бирмим, мин бирмим,— дип акырырга тотынды. Тиле, мин катыншамыни хатыннар читеген кияргә?

Мулла абый:

— Мин сине зур булды, мәдрәсәгә алып барырмын дип тора идем. Син анда да шулай елап йөдәтсәң, алмыйм инде,— диде.

Әби:

— Мин сиңа үзем кәҗүл читек тегәм, үзем тегәм. Менә күр дә тор, үзем тегәм. Иртәгә чапаныңны киярсең. Читегеңне киярсең. Мәхдүм булып гаеткә барырсың.

Мин күземне ачтым. Рәбига, тиле, авызын ыржайтып елап утыра. Тиле! Гарәфә көнендә еларга ярыймыни? Тиле! Фәрештәләр тәсбих әйткәндә еларга ярыймыни? Әни авырса нишләрсең?

Мине җилтерәтеп самовар янына алып киттеләр. Әни чәй ясады. Әти бал кашыгы белән бал алып бирде. Әби чапанымны, яшел чапанымны кигезеп карады.

— Бар да тәмам. Өр-яңа чапан, төймәсен генә тагасы бар. Иртәгә менә читек тә өлгертәм.

— Нәни читекме, әби?

— Нәни читек, угылым.

— Кәҗүл читекме, әби?

— Кәҗүл читек.

Мин саплы калач белән малайларны кызыктырырга, ындырлар артына сыерлар ашатырга чыктым. Иртәгә минем кәҗүл нәни читегем була.

Караңгы төшеп өйгә кайтканда, әби түр башында утырган да, колак артларына җеп белән эләктергән күзлеген кигән дә, чынаяк аслыгында ак май белән корымны бергә изеп маташа.

Аның янында әнинең иске читеге, Сәрби әбинең үлек өстеннән бирелгән каймасыз кызыл читеге.

— Әби, нишлисең?

— Бар, ят, угылым, бар. Әнә Рәбига — акыллы кыз, күптән йоклый. Иртәгә гает бит. Гаеткә тора алмассың. Бар, ят!

— Әби, читегем өлгердеме?

— Юк әле, юк. Мин аны намазымны укыгач кына тегәм. Бар, ят.

Әбинең миңа читек тегүен, кәҗүл читек тегүен күрәсем килсә дә, гаеткә тора алмам дип яттым.

Юрганның кырыеннан гына әбинең нишләгәнен карап яттым. Әби, аркасы белән утырганга, нишләгәне күренмәде.

Бүлмә тактасының шәүләсендә генә аның калын бармаклары әллә нәрсә өстеннән бик кызулап йөргәне, аның әллә ни ышкыганы шәйләнде.

Минем күз алдыма нәни генә читек, кәҗүл читек килеп басты. Ул минеке.

Кил, кил, кәҗүл читек. Иртәгә гает, кәҗүл читек, иртәгә гает!

*

— Тизрәк, угылым! Тәһарәт ал! Әтиең китте. Әнә мулла абыең сиңа чалма чалырга көтеп тора. Тор, балам, тор. Бүген бит гает.

— Әби! Читекне бетердеңме?

— Бетердем, бетердем, мә комган.

Тышта суык кына җил тәнне кытыклаган кебек булды. Ашыга-ашыга авызга су алганда, эти кебек иттереп «эһе-эһе» дияргә дә оныттым. Битләрне рәтләп еебереп бетермәенчә йөгереп кердем.

— Мә, угылым, күлмәк-ыштаныңны.

Мулла абый, калын гына тавыш белән:

— Тизрәк, Әхмәдулла. Миңа барырга вакыт!

Күлмәкне алай-болай киеп, кыска җиңле казакине кия-кия түргә чыктым. Анда әби чапан тоткан. Мулла абый чалма тоткан.

— Кил, утыр, бисмиллаһи... Йә, элгәре уң кулыңны бир!

Әби чапан кидерде.

— Утыр, Әхмәдулла, утыр.

Мин чәч ала торган тәбәнәк урындыкка утырдым.

— Башыңны туры тот!

Мулла абый акрын гына минем баш тирәсендә кызыл телем җуллы ак чалманы сарырга тотынды.

Әби әллә кайдан балтыр чүпрәкләр белән читек алып килде.

— Әби, читекме?

— Читек, угылым.

— Кәҗүл читекме?

— Кәҗүл, угылым.

Мин күзем белән кәҗүл читекне эзләргә тотындым: кап-кара читек тора.

— Әби, күрсәт!

Мулла абый, калын тавыш белән:

— Башыңны борма! Чалмаң бозыла.

Мин, яхшы айгыр кебек, муенымны туры тоттым. Әби минем аякларга балтыр чүпрәк урады. Бисмилла әйтеп, уң аякка читек кигезде.

Минем күңелгә рәхәт кереп китте. Мин тагы аягымны, кәҗүл читекле аягымны карарга башымны бордым. Мулла абый тагы: «Тик тор!» — диде.

Менә әби икенчесен дә кигезде.

Чалма да чалынып бетте.

— Йә, тор, Әхмәдулла.

Тордым. Аяктагы читек кап-кара булып, җем-җем итеп тора.

Чапан — ямь-яшел.

Чалма — чуп-чуар.

Әби:

— Менә нинди зур шәкерт булды,— дип, аркамнан какты.

Әни, килеп, ислемай сөртенә торган мулла абыйга:

— Әхмәдуллага да хушбуй сөрт,— дигәч, мулла абый ислемай шешәсенең тыккычы белән минем борын төбеннән бер сызып узды.

Борынга әти исе керде.

Мулла абый: «Йә, тиз бул!»— дип кызулагач, мин, әле чапаныма, әле читегемә карап, өйалдына чыктым.

Анда минем әле өр-яңа, әби кичә генә каз мае белән майлаган кәвешем кечкенә булганга, мин әбинең яшел башмагын гына киеп киттем.

Мәчет йортына әллә никадәр халык җыелган. Мулла абый барып җитеп тамак кыргач та, бар да торып юл бирде. Ул алга, алга китте. Мин дә, малайлардан узып, аларның алдындагы сафка утырдым.

Мин — мулла малае! Минем чалмам, чапаным, читегем бар!..

Иртә намазын укыдык. Әти вәгазь сөйләргә тотынды. Мөәзин абзый: «Сафланыгыз!»— дип, кешеләрнең аякларына тибеп йөрде.

Әтигә, мулла абыйга бөтен кеше, берсе артыннан берсе барып, акча биреп килделәр. Минем артта малайлар кызыгып карап торалар.

Ә шулаймы? Таз шайтан! Миңа шалкан бирмәгән идең. Ә алаймы? Минем чапаным бар! Минем читегем бар, кәҗүл читегем бар!

Мин кулым белән читегемне тотып карадым: йомйомшак, майлы кебек.

Менә кояш чыкты. Мәчет йорты тирәсенә киенгәнбизәнгән кызлар, хатыннар, малайлар тулды. Барысы да миңа карый: «Әнә Әхмәдулла! Әнә Әхмәдулла... Әнә аның чапаны ямь-яшел, әнә аның чалмасы чупчуар!»— ди.

— Туктагыз әле. Гает намазына торыйк, аның кәҗүл читеген дә күрерсез...

Менә мөәзин абзый әллә нәрсә сөйләде. Менә зур тавыш белән, әти: «Аллаһы әкбәр!» — диде.

Һәммә кеше кулын күтәрде, төшерде. Мин дә күтәреп төшердем.

Арттан теге Таз, аның артыннан тагы әллә кем, берәм-берәм көләргә тотындылар:

— Әхмәдулла әнисенең читеген кигән... Әхмәдулла әнисенең читеген кигән!

Малайлар пырхылдады:

— Әнисенең читеген кигән, әнисенең читеген кигән...

Мин серне белдермәскә тырыштым.

Әти кычкырып «Әлхәм» укырга тотынды.

Малайлар һаман «Әнисенең читеген кигән» дигәнне такмаклаудан бушамадылар.

«Ә, Таз! Көнлисеңме? Кәҗүл читектән көнлисеңме?»

Менә рөкүгъка[1] киттек.

Ни күзем белән күрим! Минем читегемнең битлеге бөтенләй кып-кызыл. Балтырының кайбер җирендә кап-кара нәрсә ялтырап торса да, кай җирләрендә кызылланып киткән, ул ала-кола. Рөкүгъта малайлар «сөбханә раббел-газыйм» урынына: «Әнисе читеген кигән, әнисе читеген кигән», — диләр.

Түгел, ул болай гына кызарган. Минем чапаным да бар. Чапаным ямь-яшел.

Менә тагы тордык. Малайлар пырых-пырых көләләр:

— Әхмәдулланың чапанына корым ягылган! Кап-кара корым...

— Әнисенең читеген кигән. Әтисенең чапанын корымлаткан...

Тагы рөкүгъка бардык.

Ни күзем белән күрим: чапанымның алгы чабулары дегеткә буяган кебек кап-кара булган.

«Әттәхият»тә[2] малайлар:

— Әнисенең читеген кигән, әнисенең читеген кигән, әнисенең читеген кигән, катынша, катынша, — дип укыдылар.

Әти сәлам бирде:

---

[1] Рөкүгъ — намазда иелеп тору, тезләнү.

[2] Әттәхият — намазда тезләнеп утырып укый торган дога.

«Аллаһы әкбәр!» Бөтен халык сикереп торды. Мине малайлар чорнап алдылар.

Һәммәсе авызын җәйгән, һәммәсе көлә: «Әнисенең кызыл читеген кигән».

Мин һаваланып кына:

— Таз шайтан, айбагар карагы!..— дип киттем. Барып башмакларны кидем.

Малайлар тагы гөж иттереп көлделәр:

— Әбисенең башмагын кигән, Әхмәдулла әбисенең башмагын кигән.

Карасам: чын да әбинең башмагы. Әнинең Сәрби әби өстеннән килгән кызыл читеге. Аның балтыры бешердәп төшкән. Аның эченнән балтыр чүпрәгенең очлары күренеп тора.

Яшел чапанның бер җире ямь-яшел, бер җире капкара булып корымлы майга буялган...

Бер малай төртеп җибәрде. Икенчеләре көлеп куйдылар. Тагы берсе төртте. Минем бер башмагым аяктан чыкты, аны кия алмаганга кулыма алдым. Берсе чалмамның коерыгыннан тотты. Ул сүтелеп китте.

Малайлар тагы көлә. «Әнисенең читеген кигән» дигәнне көйләргә керештеләр. Мин кызу-кызу атларга башладым. Берсе чабуымнан тотты. Мин аның кулын тешләдем. Берсе сүтелә башлаган чалманың очын алып китте. Мин аны куа башлагач, икенче башмагым төште.

Капка төбенә җиткәндә, әбинең:

— Оятсызлар, кая, колагын кисим!— дигән тавышын ишеттем. Күземә яшь тулды.

Умарта кортыннан качкан кеше кебек, капкадан атылып кердем. Урамнан гөж итеп малайларның көлүләре, «Әнисенең читеген кигән» дигән такмаклары мине озатты. Хушбуй исле сумса, пәрәмәч тәме чыккан өй каршы алды.

Әбинең:

— Бәйрәм мөбарәк булсын, угылым!— дип, аркамнан кагуына мин акырып елап җибәрдем.

1912 ел

Сораулар һәм биремнәр

1. «Кәҗүл читек» хикәясендә нинди вакыйгалар тасвирлана?

2. Әхмәдулланың кәҗүл читек белән бәйләнешле кичерешләре турында сөйләгез.

3. Бәйрәм көнне Әхмәдулла ни өчен кыен хәлдә кала?

4. Бу вакыйга турында кем сөйли?

«КӘҖҮЛ ЧИТЕК» ХИКӘЯСЕ ТУРЫНДА

Хикәядә элеккеге татар тормышындагы көндәлек вакыйга тасвирлана. Әхмәдулла мәхдүмгә әтисе гаеткә затлы милли читек алып кайтырга вәгъдә итә. Малай моны түземсезлек белән хыялланып көтә. Ләкин тегүче читекне бу бәйрәмгә өлгертә алмаган икән.

Әмма әсәр моның белән бетми әле. Вакыйга икенче бер ситуациягә уралып дәвам итә. Әбисе, малайның күңеле төшмәсен дип, бер төн эчендә аңа кәҗүл читек тегеп бирергә була. Ак майга корым кушып, кара буяу ясый. Шуның белән читекнең төсен үзгәртеп, оныгына кидерә. Читек малайга таман гына, үзенә килешеп тә тора. Ләкин нәкъ менә җаваплы мизгелдә, мәчеттә намаз укыганда, малайлар күз алдында читек Әхмәдуллага хыянәт итә: мае-корымы чапанга буялып бетә, әби читеге икәнлеге беленә.

Хикәядә баланың читек белән бәйләнешле кичерешләре тасвирлана. Вакыйга барышында аның кәефе әледән-әле үзгәреп тора: читекне көтү шатлыгы да, үз ишләре арасында мактанып алырга омтылу да, күңелсез финал да бар монда. Әсәр бала күңелендәге кичерешләрне төгәл сурәтләве белән әһәмиятле.

Дәрдемәнд
(1859—1921)

Дәрдемәнд (Мөхәммәтзакир Мөхәммәтсадыйк улы Рәмиев) 1859 елның 23 ноябрендә Оренбург губернасының Эстәрлетамак өязе Җиргән авылында сәүдәгәр гаиләсендә туа. 1862 елда аларның гаиләсе Орск өязендәге Юлык авылына күчеп китә. Әтисе шунда алтын приискасы ачып җибәрә. Закир башлангыч белемне гаиләдә ала, аннары Моллакай авылы мәдрәсәсендә укый. 1880 елда Төркиягә китә, Истанбул шәһәрендә төрек телен, әдәбиятын өйрәнә. 1881 елның ахырында Россиягә кайткач, абыйсы Шакир белән бергәләп, нәшрият ачып җибәрү өчен тырышып йөри. Ләкин аларның бу теләкләре 1905 ел революциясеннән соң гына тормышка аша. 1906 елның 21 февраленнән алар «Вакыт» исемле көндәлек газета һәм 1908 елның 10 гыйнварыннан «Шура» исемендәге әдәби-иҗтимагый журнал чыгара башлыйлар. Бу басмалар 1918 елга кадәр чыгып килә. Аларда төрле юнәлештәге әсәрләр, шул җөмләдән Галимҗан Ибраһимов, Шәриф Камал, Мәҗит Гафури, Шәехзадә Бабич һәм, әлбәттә, Дәрдемәнд әсәрләре басылып килә. «Вакыт» газетасының аерым саннарына берничә тапкыр арест, ә редакторына штраф салына. Газетаны саклап калу өчен, Дәрдемәндкә байтак тырышырга туры килә. 1912 елда шагыйрьнең абыйсы Шакир Рәмиев фаҗигале төстә һәлак булгач, газета-журнал чыгару мәшәкатьләре тулысы белән Дәрдемәнд җилкәсенә төшә.

Дәрдемәнд I Дәүләт Думасына депутат итеп сайлана, Оренбург шәһәр идарәсе әгъзасы була. Ярлыларга ярдәм, ятимнәрне тәрбияләү комитетларын җитәкли. Ул үз исәбенә чит илләрдә студентлар укыткан, татар мәктәпләре, мәдрәсәләре өчен дәреслекләр алып биргән.

1917 елгы Октябрь революциясеннән соң ул чит илгә чыгып китми, туган туфрагында торып кала. Алтын приискаларын Совет дәүләтенә тапшыра. Башта Оренбургта яши, соңрак Орск шәһәренә кайта, мәдәният эшләре белән шөгыльләнә, татар орфографиясен камилләштерү проектларын төзи. Гражданнар сугышы беткәч, газета-журнал чыгару эшен яңартып җибәрү өмете белән яши.

Ул, Оренбургтан кайтканда поездда салкын тидереп, 1921 елның 9 октябрендә Орск шәһәрендә вафат була.

КОРАБ

Шаулый диңгез...
Җил өрәдер...
    Җилкәнен киргән кораб!
Төн вә көндез
Ул йөрәдер:
    Юл бара ят ил карап...
Чыкты җилләр,
Купты тулкын —
    Ил корабын җил сөрә!..
Кайсы юллар,
Нинди упкын
    Тарта безне җан сорап?!

1908 ел

РӘСЕМ

(Нәвоидан)

Тәнкәен ак, түшкәйләрен киң яраткан,
Биткәенең иң очында миң яраткан;
Саклар өчен зифа буен яман күздән,
Чәчкәйләрен аяк белән тиң яраткан!

1908 ел

* * *

Урысча күп сүзең, азы татарча,
Белалмыйм, кем син — урысмы, татармы?
Ничектер белмәдек исме шәрифең:
Хәсәнме, юкса Иванмы, Макармы?..

* * *

Куанды ил, канат какты мәләкләр,
Шашып, аң-таң булып, шайтан төкерде!..
Җитәр, җилкенмә, йолкынма, күңел, син,
Кияү булсаң да, ул туйга түгел син!
Җиһан тормыш туен иткән чагында,
Синең урның — үлекләр аймагында[1].

* * *

Җәй үтте...
Кар-яңгырлы көз урнашты,
Күк тугайның бавырына боз урнашты.
Гөл кипте,
Сабагында кинә калды[2].
Былбыл!
Сиңа бер бөртек инә калды.

ВИДАГЪ[3]

Тәгәрәп-уйнап
Буй үскән
　Туган илем, исән бул!
Чәч кузгатып,
Җай искән
　Таңгы җилем,
　　　исән бул!

Йөгереп-йөгереп
Туктаган...
Яулык болгап
Сыктаган
　Нәзкәй билем,
　　　исән бул!

Сораулар һәм биремнәр

1. «Кораб» шигырендә Дәрдемәнд «ил корабы» дигәннән нәрсәне күздә тота?

2. Ни өчен ул давыл вакытындагы корабны сурәтли?

3. Шигырьдәге аваздаш яңгырашлы сүзләрне, эчке рифмаларны табыгыз. Ни өчен кирәк ул аваздаш яңгыраш?

4. Туган телне белмәүчеләргә, ике телне буташтырып сөйләүчеләргә мөнәсәбәтен Дәрдемәнд ничек белдерә? Бу мәсьәлә безнең көннәрдә актуальме?

---

[1] Үлекләр аймагында — үлекләр арасында.
[2] Кинә калды — чәнечке калды.
[3] Видагъ — аерылышу, саубуллашу.

5. «Җиһан тормыш туен иткән чагында,
Синең урның — үлекләр аймагында» дигән сүзләрнең мәгънәсен сез ничек аңлыйсыз?

6. «Былбыл!
Сиңа бер бөртек инә калды» дигән җөмлә иҗтимагый тормыштагы нинди драманы аңлата?

7. «Видагъ» (аерылышу) шигырендә нинди хисләр тасвирлана?

8. «Кораб» шигырен ятлагыз.

ДӘРДЕМӘНД ШИГЫРЬЛӘРЕ ТУРЫНДА

Дәрдемәнд үзенең әсәрләрендә ихлас хисләрен, кичерешләрен тасвирлаган. Шуңа күрә ул аларны тик үзе өчен генә, тойгы-фикерләрен образга күчереп юану өчен генә язган дип әйтүчеләр дә булды. Ләкин болай уйлау дөреслеккә туры килеп бетми. Тирән белемле, киң карашлы, Көнчыгыш һәм Көнбатыш поэзиясе традицияләрен яхшы үзләштергән зур талант буларак, ул ил, халык яшәеше турындагы мөһим мәсьәләләрне яктырта, шулар белән укучыларга мөрәҗәгать итә. Дәрдемәнд, каләмгә мөрәҗәгать итеп, тормыш турында, күңел серләре, моңлы уйлар хакында язарга өнди, шагыйрьнең бурычын кешеләргә юл яктыртуда күрә.

«Дәрдемәнд» — Закир Рәмиевнең псевдонимы. Ул «сагышлы», «моңсу» дигәнне аңлата. Аның поэзиясендә моңсу аһәңнәр еш кына ишетелә. Тормыш, хәят турында уйланганда, ул аның ахырын, финалын, буыннар алмашынып торуын да истән чыгармый.

Шагыйрьнең «Кораб» шигыре 1908 ел башында басылып чыга. Монда фикер символик сурәтләр ярдәмендә белдерелгән. Давылда калган ил корабы образын кайбер галимнәр халык, татар милләте мәгънәсендә аңлаталар. Ничек кенә булмасын, «Кораб» шигырендә шагыйрьнең ил, милләт язмышы, аның киләчәге турында борчылып уйланулары чагыла.

Кайсы юллар,
Нинди упкын
Тарта безне җан сорап?!—

дигән сорау аңа һич тынгылык бирми. Бу сорау бүген дә бик актуаль яңгырый.

«Кораб» шигыре сәнгатьчә бик төгәл эшләнгән. Тезмә ахырларындагы рифмалардан тыш (кораб — карап, өрәдер — йөрәдер), эчке рифмалар актив кулланылган (диңгез — көндез),

ритмны көчәйтүдә ярым пауза һәм ачык иҗек мөмкинлекләре бергә кушылган, тезмә уртасында ярым тынышлар дүртенче иҗектән соң, ачык иҗекләр ритмик буынның икенче иҗегендә тезелеп киләләр. Аллегорик, символик сурәт укучыны тирән уйланырга мәҗбүр итә. «Кораб» — бик җыйнак, күп мәгънә сыйдырышлы шигырь.

Дәрдемәнд поэзиясендә күңел җылысын салып язган самими шигырьләр, кешенең гүзәллеген чагылдырган парчалар да очратабыз. Бер строфадан торган «Рәсем» шигырендә Дәрдемәнд сылу, зифа кызның портретын сүз-бизәкләр ярдәмендә сурәтли. Көнчыгыш поэзиясендә җырланган матурлык идеалын гәүдәләндерә.

Шагыйрь иҗатында чәнечкеле, төртмә шигырьләр, эпиграммалар да билгеле бер урын ала.

«Урысча күп сүзең, азы татарча...» дип башланган шигырендә шагыйрь туган телен рәтләп белмәүчеләрдән көлә.

«Куанды ил, канат какты мәләкләр...», «Җәй үтте...» дип башланган шигырьләрен Дәрдемәнд матбугатта бастырып чыгармый. Ул аларны, күрәсең, күңелендәге хисләрен бушату өчен генә язган булса кирәк. Боларда ул Октябрь революциясеннән соңгы иҗтимагый шартларда үзенең урынын, яңа яшәешнең шагыйрь поэзиясенә мөнәсәбәтен билгеләргә тырыша. Җиһан тормыш туен иткән чагында, үзенең урынын үлекләр аймагында күрә. Мондый хәл аны, әлбәттә, иҗатка рухландыра алмый.

Гөл кипте,
Сабагында кинә калды.
Былбыл!
Сиңа бер бөртек инә калды,—

дип яза ул «Җәй үтте...» дип башланган шигырендә.

Шул ук вакытта ул «Видагъ» (аерылышу) шигырендә туган илнең газиз, җанга якын булуы, яшәгән төбәктән, нәзкәй билдән аерылуның никадәр читен, аяныч булуы турында уйлана. Шигырьләренең үзгә бер моңы, матур, килешле яңгырашы, фикер, хисләрнең тирәнлеге, ихласлыгы, халәт, кәефнең бик күп төсмерләрен гәүдәләндерүе белән ул иң күренекле шагыйрьләр рәтендә тора. Аның әсәрләре, Г. Тукай иҗаты кебек, безнең поэзияне яңа бер югарылыкка күтәрде, Н. Исәнбәт, М. Җәлил, Х. Туфан, С. Хәким һәм хәзерге урта буын шагыйрьләрдән Р. Харис, Р. Фәйзуллин һәм башкалар өчен шигъри мәктәп булды.

Кәрим Тинчурин
(1887—1938)

Татар театры тарихында Кәрим Тинчурин драматург булып кына түгел, артист һәм режиссер, театрны оештыручылардан буларак та гаять зур урын алып тора.

Риза Ишморат

Татарстаннан читтәге күп кенә төбәкләрдәге кебек үк, Пенза өлкәсендә дә татарлар байтак яши. Мәсәлән, анда Аккүл исемле авыл бар. 1887 елның 15 сентябрендә биредә Гали ага гаиләсендә бер малай дөньяга килә. Аңа Кәрим дип исем кушалар. Бу — татар драматургиясе һәм театр сәнгате өлкәсендә бик зур хезмәтләр калдырачак Кәрим Тинчурин була. Ләкин, әле иҗат кешесе булганчы, аңа шактый кыен юл үтәргә туры килә.

Башлангыч белемне ул үз якларындагы мәдрәсәдә ала. Аннан соң белемен арттыру теләге белән Казанга юнәлә. «Казан якларына унөч яшьлек яшүсмер бер малай килеп чыга,— дип яза Р. Ишморат.— Аягында агач башмак, башында түбәтәй аның. Бәхет эзләп килгән ул. Зур гына күзле, ягымлы карашлы, чая гына бу малайның бер теләге бар — уку, белем алу, адәм рәтле кеше булу. Теләге бар, акчасы юк. Ничек тә акча табарга кирәк. Һәм ул бер хәрчәүнигә[1] савыт-саба юучы булып эшкә керә. Авыр, шапшак эш. Кәрим түзә. Түзмәс иде дә соң, кая барсын? Ниһаять, ул үз заманында әйбәт уку йорты булып исәпләнгән, дөнья белемнәре дә укытыла торган «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә уку бәхетенә ирешә. Тырышып укый. Ә җәен кая

[1] Хәрчәүни — ашханә.

да булса барып эшли, акча юнәтә». Менә шулай укый Кәрим. Әмма ул мәдрәсәнең уку программасыннан канәгать булмый. Аның иптәшләре дә фәннәрнең төрлесен, бигрәк тә тормыш-көнкүреш өчен кирәк булганнарын үзләштерергә телиләр. Әмма мәдрәсә хуҗалары аларның теләген канәгатьләндерми. Моңа җавап итеп, сиксән җиде шәкерт мәдрәсәне ташлап чыгалар. «Алар арасында Кәрим Тинчурин да була. Кәрим үзлегеннән укуын дәвам иттерә. Хәтта өлгергәнлек аттестаты алу өчен имтихан бирү, университетка керү турында хыяллана. Ләкин хыяллар тик хыял булып кына кала. Кесәнең бушлыгы, татар малае булуы да комачаулый.

Уй һәм хисләре ургып торган Кәрим яза башлый. Башта хикәяләр, новеллалар, шигырьләр яза. Ул Габдулла Кариев, Сәхибҗамал Гыйззәтуллина, Касыйм Шамильский, кыскасы, «Сәйяр» труппасына тупланган, татар театрының нигез ташын салган кыю йөрәкле артистларның олы һәм мактаулы эшләрен күрә, алар белән таныша. Галиәсгар Камал пьесасы буенча куелган спектакльләр аны таң калдыралар. Һәм ул 1910 елны «Сәйяр» труппасына хезмәткә керә»[1].

Дөрес, әле ул театрда эшли башлаганчы — 1906 елда ук сәхнә әсәрләре яза башлый. «Беренче чәчәкләр», «Назлы кияү», «Йосыф — Зөләйха» кебек әсәрләре аны драматург итеп таныта. Соңрак ул үзе «Сәйяр» труппасын җитәкли. 1922 елда Татар дәүләт театрын оештыра. Үзе дә спектакльләрдә артист буларак катнаша. Бер үк вакытта бик күп әсәрләр иҗат итә. «Сакла, шартламасын!», «Казан сөлгесе», «Сүнгән йолдызлар», «Тутый кош», «Американ», «Җилкәнсезләр» кебек комедияләр; «Зәңгәр шәл», «Ил», «Кандыр буе» музыкаль драмалары аның талантының олы һәм киң колачлы булуы турында сөйли.

Кәрим Тинчуринның гомере вакытсыз өзелә. Ул — шәхес культы корбаны. 1938 елның 15 ноябрендә фаҗигале төстә юк ителә[2]. Бу вакытта аңа бары илле бер яшь була.

Сораулар һәм биремнәр

1. Кечкенә Кәрим төпле белем алу өчен нинди кыенлыкларга түзә?

2. Мәдрәсәне ташлап чыгуының сәбәпләрен аңлатып бирегез.

---

[1] Ишморат Р. Дусларым, остазларым. Истәлекләр.— Казан.— 1988.— 52—54 б.

[2] Гилязев А., Литвин А. Приговор приведен в исполнение.— Вечерняя Казань.— 1990.— 10 мая.

3. Кәримнең театр, драматургия белән кызыксынып китүенә нәрсә этәргеч булган?

4. Кәрим Тинчурин — драматург, режиссер, артист һәм театр сәнгатен оештыручылардан берсе. Ни өчен шулай әйтәбез?

5. Кәрим Тинчуринның кайсы әсәрләрен укыганыгыз, алар буенча куелган нинди спектакльләр караганыгыз бар? Шулар турында сөйләгез.

6. Татар театры оешуга 100 ел тулды. Бу юлда К. Тинчуринның хезмәтләрениләрдән гыйбарәт?

МӘДРӘСӘДӘ БЕРЕНЧЕ КӨН[1]

Ата, улы Хафизны мәдрәсәдә калдырып, үзе шул көнне үк авылга кайтып китте. Чит җирдә, танымаган кешеләр арасында, Хафиз башта бик ямансулады. Бүре баласы төсле, читтә ятсынып торган мужик малаен шәкертләр, урап алып, «сайратырга» керештеләр. Ул заманнарда мәдрәсәгә яңа гына килгән шәкерткә «сәхра» диләр. «Сәхраны сайрату» шәкертләрнең иң яраткан эшләре инде. Шәкертләрнең берсе, Хафизның янына утырып:

— Апаң бармы?— дип, беренче сорауны бирде. Хафиз, аны-моны абайламыйча:

— Бар,— диде.

Колга төсле озын буйлы шәкерт, аның ияк астыннан сөеп:

— Апаң да үзең төсле үк матурмы соң?— диде. Хафиз бу сорауга җавап бирмәгәч, икенче шәкерт, аның кулларын сыйпый-сыйпый:

— Өеңә хат язганда, миңа да әйтергә онытма. Мин апаңа сәлам хаты язып җибәрермен. Белмәссең, чәчләребез бәйләнгән булса, куеныңа кереп, җизнәң булуым да бар,— диде.

Хафизга шәкертләрнең бу сүзләре ошамаганлыктан, ул, шәкертләргә арты белән борылып, ипи төягән капчыгы өстенә ятты. Бу хәлне күреп торган чиста киемле, ак йөзле Сөләйман дигән шәкерт, алга чыгып:

— Юк-бар сүзләрегез белән егетнең башын катырмагыз,— диде дә, Хафизны аркасыннан сөеп: — Сөйләшмә син алар белән. Монда караңгыда утырма. Әйдә минем урынга!— дип, аны яхшы киезләр җәелгән якты урынга илтеп утыртты.

[1] Хикәягә бу исем дәреслек-хрестоматияне төзүчеләр тарафыннан бирелде.

Хафизга бу шәкерт бик ошады. Шәкертләр акрынлап аның тирәсенә тагын җыела башладылар.

Әлеге Сөләйман, бик мөлаем, йомшак тавыш белән:

— Исемең ничек?

— Хафиз.

— Әтиеңнең исеме ничек?

— Яуметдин.

— Әтиең кайтып киттемени?..— дип сорашуына Хафизның күңеле тулып, бугазына яшь тыгылганлыктан, ул сүзен әйтә алмады. «Ие, кайтып китте шул» дигән мәгънәне башы белән изәп кенә аңлатты.

Сөләйман, аның кайгысын уртаклашкан булып, авыл хәлләрен сорашканнан соң, кинәт:

— Сезнең авылда үз мунчагыз бармы?— дип сорады.

— Юк.

— Ничек соң алай, мунча кермичә генә торасызмыни?

— Күрше Әхмәдулла агайларныкына ягабыз.

— Алай. Су буендамы әллә яр астында гынамы? Мунчаны әйтәм.

— Су буенда.

Хафиз, шәкертнең иплелегенә хәйран калып, барлык күңеле белән аңа ышанды. Сөләйман, аның йөрәгенә кереп, үзенә Хафизны тәмам ышандыру өчен, бик мөлаем гына:

— Шулай, су буенда торасыз икән, алай булгач, сездә кош-корт та күптер инде?

Хафизның бу шәкертнең яхшылыгына бөтенләй исе китте. Барлык шәкертләр шуның төсле булсалар, нинди яхшы буласы икән, дип уйлый-уйлый:

— Бар. Кош-корт бездә бар.

Сөләйман, хәйләкәр төлке төсле, күзләрен мөлдерәтеп, сораштыруын дәвам итте:

— Нинди кошлар сездә бар?

— Каз, үрдәк, тавык.

— Тагы нинди кошлар бар?

— Чыпчык, чәүкә, карга.

— Алар безнең якларда да бар. Тагын нинди кошлар бар?

— Карлыгач, саескан,— диюгә, Сөләйман, гаҗәпләнгән булып:

— Саескан дигән кош сезнең якларда торамыни? Кара син аны, бу бик гаҗәп бит!.. Карагыз әле, егетләр,

китапларда очрый торган саескан дигән кош болар авылында тора икән!— дип, Хафизга бармагы белән төртеп күрсәтте.

Икенче шәкерт ышанмаган булып кыланды:

— Ялгышадыр ул. Саескан алар җирендә булмас.

Хафиз, үзенә үзе бик ышанып:

— Булмаганны бар дип, ялганлап тормам,— дип, теге шәкертнең авызын томалады.

Сөләйман, Хафизның сүзләрен куәтләргә тырышып:

— Алай. Сездә булмаса булмас. Әмма алар җирендә булуы да бик мөмкин,— диде.

Теге шәкерт, һаман әле ышанмаган булып:

— Алар җирендә дә саескан юк. Ялганлый ул!— диде.

«Ялганлый» дигән сүз, Хафизның йөрәгенә ук булып кадалган төсле, күңелен әрнетте. Шуңа күрә ул, үпкәләгән тавыш белән:

— Әй, ялганлый ди!.. Булмаганны бар дип ялганлаган өчен, акча бирүче юк бит монда,— диюгә, Сөләйман, Хафизның тапкырлыгы өчен үзенең шатланганлыгын күрсәтергә тырышып:

— Дөрес, бик дөрес. Булмаганны бар дигән өчен, акча бирүче юк,— диде.

Теге шәкерт, уңайсызланган булып:

— Юк, мин сине ялганлыйсың дип әйтмим. Бәлки сездә башка берәр кошны йә торнаны саескан дип йөртә торганнардыр.

Хафиз, үзенең җиңүенә мавыгып, җанланып:

— Торнаны саескан дип йөртергә бездә дураклар юк ла,— диде.

Теге шәкертнең һаман әле җиңеләсе килмәде. Ул, кәләпүшен каш өстенә төшереп:

— Сездәге саескан нинди була икән, хуш, ишетеп карыйк!— диде.

Хафиз, саесканны сөйләп мавыгып китеп, хәтта саескан булып сикергәләп, саесканча йөреп тә күрсәтте. Теге шәкерт һаман ышанмады.

— Әй, син сөйләгән ала карга бит ул. Егетләр, болар ягында ала каргага саескан диләр икән.

Шәкертләр көлештеләр. Хафизның нахакка җиңеләсе килмәде. Башта ала карга булып, соңыннан саескан булып кычкырып, ала карга белән саескан арасындагы аерманы аңлатырга тырышты.

Сөләйман, Хафизга ышанган булып, Хафизның алар белмәгән бик күп нәрсәләрне белүенә гаҗәпләнгән төсле, йомшак тавыш белән:

— Сезнең якларда кәҗә асрыйлармы?— дип сорап куйды.

— Асрыйлар.

— Мисыр кәҗәсеме әллә Бохара кәҗәсеме?

Хафиз, андый кәҗәләрне беренче тапкыр ишеткәнлектән, бераз аптырап:

— Белмим мин. Бездә үзебезнең кәҗәләр генә,— диде.

— Кәҗә булса, йә Мисыр, йә Бохара кәҗәсе була. Аларны бер-берсеннән койрыкларыннан гына аерып була. Сезнең яктагы кәҗәләрнең койрыклары нинди?— диюгә, Хафиздан ярты сәгать чамасы кәҗә койрыгы турында сөйләтү белән генә канәгатьләнми, кәҗә булып кычкырттылар да.

Шуннан хәлфә сыман, сакаллы бер шәкерт, алга үтеп:

— Тау ягында безнең якларда булмаган нәрсәләр күп булсалар да, ә менә тау як хатыннары ипи сала белмиләр!— дип, мәсьәләне кабыргасы белән куйды.

Хафизның әнкәсе ипи сала белүе белән бөтен авылда атаклы булганга, сакаллы шәкертнең бу яласы Хафизга бик авыр тоелды. Ул әнисе пешергән ипиләрнең тәмлелеген күрсәтер өчен, капчыгыннан бер ипине чыгарып, шәкертләргә авыз иттерә-иттерә, анасының абруен саклау юлында бер бөтен ипинең беткәнен сизмичә дә калды.

Сакаллы шәкерт һаман үз сүзендә тора:

— Дөрес, бу ипи карап торырга яхшы. Аз гына ашаганда тәмле дә төсле. Ләкин аны бер телемнән артык ашап булмый. Эчне күптерә.

Сөләйман, Хафиз ягыннан төшеп:

— Мондый ипине күргәнең юк әле синең, әгәр дә бу ипи, син әйткәнчә, эч күптерә торган булса, менә бу акча синеке,— дип, кесәсеннән егерме тиен көмеш акча чыгарып өстәлгә салды.

Сакаллы шәкерт тә бирешми:

— Әгәр дә ипине, су эчмичә, өч телем ашаган кеше эче күбеп шунда үлмәсә, менә акча сиңа булыр!..— дип, тәбәнәк сәкегә илле тиенлек көмеш акча чыгарып салды.

Шау-шу башланды. Шәкертләр ике якка бүленеп, Хафиз әнисе пешергән ипи турында талаша башла-

дылар. Хафизның сакаллы шәкерткә җен ачуы чыгып, ун кадаклы иң зур ипине капчыгыннан чыгарып, сакаллы шәкертнең борынына төртте:

— Шушы ипи эч күптерә дисеңме?!

— Күптерә генә түгел, үтерә дә, дим, энекәш.

Алда бик зур эшләр торган төсле, бик җитди кыяфәт белән, Сөләйман:

— Якташ, дөресен әйт, ипиең эчне күптерәме, юкмы?— дигән булды.

— Юк. Җир йотсын, юк. Безнең әни төсле ипи салучы безнең авылда гына түгел, тирә-юньдә дә юк!— диюгә, Сөләйман, бик зур яшерен сер ачкан төсле, Хафизның колагына пышылдады:

— Май кап, сакал үстереп, акыл үстермәгән теге ахмакны кызык итәбез. Кая, бир ипиеңне?..— дип, Хафиз кулыннан зур ипине алып, һавага күтәрде: — Җәмәгать, туктагыз!.. Туктагыз!..

Шәкертләр тындылар.

— Менә ипинең иясе Мөхәммәтхафиз, ипинең яхшылыгын күрсәтер өчен, болай итмәк була. Шушы ипинең үзегез теләгән җиреннән өч зур телем кисеп бирсәгез, сусыз, чәйсез шуны ашап бетерәм, ди. Эчем күбеп үлмичә калсам, илле тиен миңа булыр, ди. Габделхак абый, син шуңар ризамы?— дип, сакаллы шәкерткә ишарә ясады.

Сакаллы шәкерт, бераз аптырап калган төсле булып:

— Әйткән сүздән кайткан юк. Ләкин ипине мин үзем кисеп бирәм,— диюгә, ипине кем кисү турында тагы җәнҗал купты. Ахырдан бөтен ипине телемнәргә кистеләр, Хафиз, күзе бәйләгән килеш, бәхетенә тигән өч телемне алып ашап бетерергә тиеш булды. Иң кечкенә кисәк чирек кадактан да ким, зур кисәк кадак ярымнан артык булмаска тиеш дип килештеләр шәкертләр. Хафизның ипиен телемнәргә турап өстәл өстенә өеп куйдылар. Үзенең күзләрен сөлге белән бәйләделәр.

Хафиз чама буенча кечкенәрәк бер кисәкне алып, күзе бәйләнгән килеш, ашыкмыйча гына ашарга тотынды. Шәкертләр тындылар. Беренче кисәген ашап бетерүгә, икенче кисәккә дип кул сузды, ипи эләкмәде. Капшанып-капшанып та бер телем икмәк таба алмагач, күзендәге сөлгене ташлап, өстәлдә бер кисәк ипи һәм үз янында бер шәкертнең дә калмаганын күреп, аптырап, як-ягына каранды.

— Ипиләр кая?— дип, үзе ышанган Сөләйманнан сорады.

Сөләйман, Хафизның сүзенә бик гаҗәпләнгән булып:

— Үзең ашап бетердең ич!— диюгә, шәкертләр мәдрәсәне күтәреп көлештеләр. Хафизның җен ачулары чыкты:

— Мин бер генә телем ашадым. Бөтен ипи иде бит!

Сөләйман тагын да гаҗәпләнгән булып кыланды:

— Карагыз әле, кара, күз бәйләп бер бөтен ипи ашап бетергәнен дә сизмәгән. Болай булгач...— дип, сандык өстенә басып, азан әйтә башлады. Азан бетүгә: — Мөхәммәтхафиз Яүметдин угылының моннан соңгы исем шәрифе «Бирән Хафиз» булыр, Аллаһы әкбәр!— диюгә, аптыраудан, алданудан башы әйләнеп торган Хафизны шәкертләр, тирә-яктан әйләндереп алып, кайсы чеметеп, кайсы маңгаена чиертеп, кайсыберсе учы белән борынын кирегә кайтарып яңа, исем белән аны котладылар. Тәбәнәк буйлы шәкерт, авызын ерып, Хафизның каршысына басып:

— Сездә атлар ничек кешни?..— дип, үкчәсе белән Хафизның аяк бармагын сытарлык итеп басты.

Хафиз, алданганлыгын сизеп, ачудан һәм аяк бармагы авыртуга чыдый алмыйча сикереп торды:

— Бездәге атлар кешнәмиләр. Менә шулай тибешәләр!..— дип, аяк куеп, шәкертне чалып екты. Сөләйман аны шәкертләрдән кыйнатмас өчен, култыклап ишек төбенә алып килеп, үз урынына утырта-утырта:

— Болай булгач, пишкадәм булып чыгарсың, Алла боерса!..— дип, шәкертләргә авыл малаен җәберләүдән туктарга ишарә ясады. Хафиз төн буенча сулкылдыйсулкылдый елап чыкты. Атасы кайтып китмәгән булса, бу хурлыктан соң мәдрәсәдә бер сәгатькә дә калачак түгел иде.

Көннәр, айлар, еллар үткәч, Бирән Хафиз үзе дә авылдан яңа килгән «сәхра малайларын сайратып», аларга үзе алган фатихадан өлеш чыгара башлады.

Сораулар һәм биремнәр

1. Уналты яшенә кадәр туган авылыннан башка җирдә торып карамаган Хафизның атасыннан аерылып калгач булган халәтен аңлатып бирегез.

2. Мәдрәсә шәкертләре яңа шәкерт янына җыелалар. Аларның бу очракта кимендә ике максатлары бар. Бу максатлар нидән гыйбарәт?

3. Сөләйманны оста психолог дип әйтергә мөмкин. Бу нидә күренә?

4. Хафизның капчыгындагы ипине чыгарттырыр өчен, малайлар нинди алымнар кулланалар?

5. Хафизны гарьләндергән сәбәпләрне санап чыгыгыз.

6. Мондый «сабак алган» Хафиз ни өчен соңыннан үзе дә яңа килгән малайларны кыерсыту юлына баса?

7. «Явызлык явызлык тудыра» дигән темага сөйләшү уздырыгыз.

БҮРЕ ЗӘХМӘТЕ

Карт сунарчыларның әйтүләренә караганда, искәрмәстән бүренең койрыгыннан эләктерсәң, ул ерткычлык инстинктын югалта икән. Әгәр дә инде эләктерә алмыйсың икән, ул чагында «бүре зәхмәте» үзеңә йогып кала, ди.

Сөләйман укыган мәдрәсәдә авыру шәкертләрне дәвалау, аларга беренче ярдәмне күрсәтү «Комган хәлфә» дигән бер хәлфәгә тапшырылган иде. Ул үзе, гомерендә саулык саклау турында бер генә китап укып чыкмаса да, авыру шәкертләргә диагноз куеп, аларны дәвалау аркасында мәдрәсәдә бик зур абруй белән файдалана. Аның табиблык карьерасына юл ачкан сәбәпләрнең беренчесе үзенең «бүре зәхмәте» дигән җәнлекләр авыруына дучар булуы булган. Гәрчә аның үз гомерендә чын, тере бүрене күргәне булмаса да, авыруын ул «бүре зәхмәте» ди торган иде. Бу авыруны ул, мәдрәсәдә җен күреп, сунарчылар законы буенча, аның койрыгыннан эләктерә алмавы аркасында эләктергән, имеш. Шул авыруын дәвалый-дәвалый, үзе дә «табиб» булып китеп, биш йөз шәкертнең саулыгын саклау эше аңа тапшырыла. «Бүре зәхмәте» авыруына мөбтәля[1] кешегә борчылырга, шатланырга ярамаганлыкны шәкертләр Комган хәлфәнең үзеннән күреп беләләр иде. Ул, берәр нәрсәгә аз гына борчылса да, комганын күтәреп йөгерә торган булган, мескен. Дәрескә кергән чакларда да, комганын сыйныфның ишеге төбендә калдырып, аны һәр хәтәргә әзер тота. Шуңа күрә бу хәлфәне шәкертләр «Комган хәлфә» дип йөрттеләр.

Кышкы озын төннәр мәдрәсә шартларында тагын да озая төшәләр. Менә шул кышкы озын төннәрнең берсе

---

[1] Мөбтәля — дучар булган.

Сөләйманнар йоклый торган бүлмәгә хәтәр китерде. Бу хәтәргә баштарак артык игътибар ителмәсә дә, соңга таба, хәтәр һәр көн кабатлана башлагач, аның хакында чынлап уйлый башладылар.

Ул хәтәр моннан гыйбарәт: шәкертләре йоклый торган бүлмәнең уртасына асылган җиделе керосин лампасы һәр көн унике сәгатьтән соң үзлегеннән сүнә башлады. Аның үзлегеннән сүнүенә ышанмадылар. Тикмәгә генә булмас, монда берәр хикмәтле сер булырга кирәк дип, бер төнне шәкертләр, сүндерүчене тотар өчен, дүрт почмакта дүрт шәкертне, яшереп, сакка куйдылар. Шул сакчыларның күз алларында лампа гадәттәгечә сүнә. Иртә белән торып лампаны тикшерәләр, аның бөтен нәрсәсе җирендә табыла. Керосины да ярты савыттан артыграк булып чыга.

Бу хәл шәкертләрне аякка бастырды. Бу хәтәрнең серенә төшәр өчен, Комган хәлфәгә киңәшкә барырга туры килде. Комган хәлфә, шәкертләрнең сүзләрен тыңлаганнан соң:

— Ут сүнгәч, йоклаучы шәкертләр ыңгырашалармы?— дип сорады.

— Ыңгырашмаган кая, ут сүнүгә, йоклаучыларның кайберәүләре елый, кайберәүләре борыла-борыла акыра башлыйлар!— дигәч, Комган хәлфә, агарынып:

— Сезнең бүлмәдәге лампаны сүндерүче — җен!.. Мотлака[1], җен эше ул,— диде.

— Нишләп җен булсын! Сәгать уникегә хәтле яна бит ул,— дип, шәкертләр аның бу фикеренә каршы төштеләр.

— Менә хикмәт тә әнә шунда шул. Җеннәр төнге сәгать уникегә хәтле богауда булалар. Сәгать уникедән соң богаудан ычкындырылалар. Менә шул чагында алар, сезнең бүлмәгезгә кереп, лампагызны сүндерәләр,— дип, үз сүзендә нык торды.

— Безнең бүлмәбез җеннәр сәер кыларлык[2] алай зур да түгел.

— Илле биш шәкерт ындыр табагындагы сугылырга әзерләнгән көлтәләр төсле әлиф яткач[3], идәндә шәмдәл

---

[1] Мотлака — һичшиксез.

[2] Сәер кыларлык — уен уйнарлык, шаярырлык, күңел ачарлык.

[3] Әлиф яткач — сузылып яткач.

куярлык та буш урын калмый. Ишектән керә, дияр идең, бердәнбер ишекне ачык калдырып йокларга рөхсәт ителми. Төннәрен төн буе элгечтә тора. Тәрәзәдән керә, дияр идең, безнең бүлмәдә генә түгел, бөтен мәдрәсәдә бер генә дә мәнфәз[1] юк, дигәч, Комган хәлфә, мендәрен астына куеп, уңайлап утырып:

— Каян керсә дә кергәндер, әмма бу эш — җен эше. Әгәр дә чарасын күрмәсәгез, бара-бара лампа сүндереп кенә калмас, башка төрле зарарлар да китерә башлар, Алла сакласын! Җенне, мотлака, сагалап тотарга кирәк булыр, сез аны тотканда, койрыгыннан тотарга тырышыгыз. Аның хәйлә, мәкерләре койрыгында була,— диде, үзе, комганын тотып, бүлмәдән чыгып китте.

Вәкилләр Комган хәлфәнең сүзләрен шәкертләргә кайтып сөйләгәч, бичараларның котлары алынды. Йоклаганда юрган асларыннан башларын түгел, борыннарын да чыгармый башладылар. Комган хәлфәнең сүзләре чын булды. Шушы бүлмәдәге шәкертләр берәмберәм авырый башладылар. Шуннан соң шәкертләр, һәр төн ике шәкертне лампа астына сакка куеп, җенне тотарга план кордылар. Ләкин бу чарадан бертөрле дә файда чыкмады. Сәгать уникедән соң лампа да шулай ук сүнә, шәкертләр дә шулай ук саташып ыңгырашалар. Җенне койрыгыннан тоту түгел, үзен дә күрә алган кеше булмады. Бу күңелсез хәбәр бөтен мәдрәсәгә таралып, бу бүлмәдә торучы шәкертләрдән «җенлеләр» дип көлә башладылар. Шуннан соң Нури солдат дигән берәү «җеннәр ияләнгән» бүлмәдә торучы шәкертләргә ярдәмгә килеп, лампаны Коръән битләре, керәнҗә догалыклары белән уратып алырга киңәш бирде. Солдат кеше батыр була бит ул, шул төнне үзе дә шәкертләр белән бергәләп җенне тотарга булды. Җенне тотып бәйләр өчен алып килгән бауның бер башына — хөрмә төшләре, икенче башына Мәрьям ана күз яшьләре дигән тисби ташлары таккан. Шулай итмәгәндә, бау җенгә чыдамый икән. Солдат саклаган төнне, үч иткән төсле, җен лампаны уникенче яртыда ук сүндереп китте.

Ут сүнүгә, шәкертләр, бәлки, чыдарлар да иде. Ләкин ул үзенә тозак корылганны сизенеп, язга таба шәкертләргә тәмам үчекте. Башта ике генә шәкерткә, соңга таба унлап шәкерткә зәхмәтен тидерде.

[1] Мәнфәз — форточка.

Ат юлы белән озатырга мөмкин булган авыру шәкертләрне дамелла төннәрдә авылларына, үз өйләренә озаттырды. Китә алмаганнарны мәдрәсәнең хастаханәсенә чыгарып, дүрт атнага бер тапкыр мәдрәсәгә килә торган часть докторы күрмәсен дип, өсләреннән бикләтеп тә куйдырды. Авырулар янына Камали кизү белән Комган хәлфәдән башка берәүне дә кертмәделәр.

Йогышлы бу авыруга Комган хәлфә «җен зәхмәте!» дип исем бирде. Дамелла Комган хәлфә белән килешмәде.

— Җен зәхмәте рус телендә тиф дигән авыру була икән. Бәс, мәдрәсәдә андый авыру барлыгы сизелсә, аны яптырулары бар. Бинабәрин[1] моннан соң мәдрәсәдә «җен зәхмәте» яхуд «тиф» дигән сүзләрне телгә алмаска!..— дип, хәлфәгә боерык бирде.

Комган хәлфә аптырап тормады:

— Алайса, тәкъсир, шәкертләрнең бу авырулары «бүре зәхмәте» була икән. Ул авыру йогышлы түгел. Менә фәкыйрегез ун елдан бирле шул авыру белән авырып торабыз...— дигәч, дамелла мәдрәсәдә башланган тиф авыруын «бүре зәхмәте» дип атарга фәрман бирде, һәм шул турыда мәдрәсә ишегалдында игъланнар ябыштырылды.

Яз җитеп, тәрәзәләр ачылуга, Ходаның хикмәте, җен юкка чыкты. Җәмәгать сәкесендәге лампа төн буенча ялтырап яна торган булды. Шулай да авырулар мәдрәсәнең хастаханәсенә генә сыеша алмый башладылар.

Сораулар һәм биремнәр

1. Мәдрәсәдә шәкертләрнең сәламәтлеген саклау «хезмәте» ничек оештырылган?

2. Комган хәлфәнең сәламәтлек саклау, дәвалау «белгече» буларак әзерлеге нидән гыйбарәт?

3. Мәдрәсәдә төн уртасы да җитмичә лампа сүнүнең чын сәбәбен шәкертләр ни өчен белмиләр?

4. Комган хәлфәнең сүзен раслагандай, кайбер шәкертләрнең чыннан да авыруга дучар булулары нилектән дип уйлыйсыз?

5. Лампа кайчан һәм нилектән сүнүдән туктый? Хикәянең шул урынын табып укыгыз.

6. Шул чор яшьләренең мәдрәсәләрдәге уку программаларына реформа (үзгәреш) кертүне таләп итүләренең сәбәбен бу хикәядән аңлый алабызмы?

---

[1] Бинабәрин — шуңа күрә.

КӘРИМ ТИНЧУРИН ХИКӘЯЛӘРЕ ТУРЫНДА

Сезгә тәкъдим ителгән ике әсәр дә язучының «Мәрҗәннәр» дигән хикәяләр җыентыгыннан алынды. Әлеге хикәяләрен язып, К. Тинчурин үзенең чәчмә әсәрләр иҗат итүдәге осталыгын да раслады.

Мәдрәсә тормышы язучының үзенә дә яхшы таныш. Төрлесе төрле яктан җыелып, ачлы-туклы яшәгән шәкертләрнең көне сабак[1] белән генә чикләнмәгән, әлбәттә. Биредә үзенә күрә өстен катлаулар булган кебек, ярлы, физик яктан көчсезләре дә күп булган. Эчке тәртипнең язылмаган кануннарын әнә шул үзләрен хуҗа итеп сизеп, башкаларны үзләренә хезмәт иттереп яшәүчеләр барлыкка китергәннәр. «Мәдрәсәдә беренче көн» хикәясендә без Сөләйман шәкертне шундыйларның берсе буларак күрәбез. Аны кешегә карата нинди дә булса яман эш кылыр дип бер дә уйламыйсың. Ул «чиста киемле, ак йөзле», тавышы да «мөлаем, йомшак», сөйләшүе дә ипле. Аның йоклый торган урын-җире дә бүлмәнең якты бер өлешендә, анда яхшы киезләр җәелгән.

Сөләйман — яхшы психолог. Ул ят яшүсмернең ышанычын яулап алуның серләрен яхшы белә. Башкаларның мыскыллавыннан ачуы килгән Хафизны күңелсез хәлдән аралап алучы булып кылана, әйтергә кирәк, моны зур осталык белән башкара. Нәтиҗәдә, Хафиз аның белән сөйләшеп китүен сизми дә кала.

Хафиз төшеп калган малайлардан түгел. Ул — авылда чакта «Сабан туенда батырлар белән көрәшкән» егет. Биш елдан бирле, ягъни унбер яшеннән, авылдагы иң авыр эшләрнең берсен башкара — ат белән җир сукалый. Авыл халкы да аны «уңган, булган, матур егет булып үсә» дип мактыйлар. Авылда булса, ул үзен болай кимсеттереп тормас иде. Чит бер урында, бигрәк тә шәһәр җирендә, ул әле үзен җайсыз хис итә. Шулай да бик үк куркып та тормый, үзенә карыккан берәүне чалып ега.

Таза малай булса да, Хафиз — күңеле, тәрбиясе белән беркатлы авыл баласы. Ул Сөләйманның һәм башка шәкертләрнең үзен үчекләүләрен, капчыгындагы ипиләрне алдап-йоллап алырга тырышуларын абайламый. Ипиләреннән колак каккач кына, үзенең алданганын аңлап ала, аның күңелендә ачу хисләре кабына. Әлеге күңелсез хәлнең юшкыны еллар үткәч тә онытылмый. Тора-бара үзе дә әнә шундый беркатлы малайларны «кызык итүдә» катнаша башлый.

---

[1] Сабак — дәрес.

Халыкта шундый сүз бар: кош оясында ни күрсә, очканда шуны кыланыр, ди. Шуның төсле, яңа килгән шәкертләрнең мыскыл ителү сынавын үтүләре бередә бер гадәткә әверелгән. Моны үзенә күрә бер гадәти хәл буларак кабул иткәннәр. Мондый әхлакый-психологик мохиттә кешенең холык-гадәте дә шуңа бәрабәр формалаша, ягъни ул башкаларга карата әдәпсез мөнәсәбәт күрсәтүдән тәм таба башларга мөмкин. Мондый хәлләр булмасын өчен, иң әүвәл әнә шул гомуми хәл-әхвәлне савыктырырга, мохитне мондый «кызык итүләргә» урын калдырмаслык итеп үзгәртергә кирәк. Әлеге хикәядән туган төп нәтиҗә шуннан гыйбарәт.

Г. Исхакый «Ике йөз елдан соң инкыйраз» дигән әсәрендә болай дип язган иде: «Манигы тәрәккыйнең икенчесе — мәдрәсә-мәктәп эшләренә әһәмият бирмәвебездер. Тәрбия ни? Уку ни? Укыту ни икәнен белмәгән кешеләргә шул эшне тапшыру һәм көлке, һәм кайгылыдыр». (Алга китүебезгә киртә булган сәбәпләрнең икенчесе — мәдрәсә-мәктәп эшләренә әһәмият бирмәвебез. Нәрсә ул тәрбия, нәрсә ул уку, нәрсә ул укыту икәнен белмәгән кешеләргә шул эшне, ягъни укыту-тәрбия эшен тапшыру көлке дә, аяныч та.) Димәк, төп сәбәп әлеге малайларда түгел. Патша Россиясе хөкүмәтенең аз санлы милләтләрнең балаларын укыту-тәрбияләү өчен кирәкле шартларны тудырмавында. Бу эштә тиешле әзерлеге булмаган кешеләр эшләвендә. Шәкертләрнең тормыш-көнкүрешләре дөрес оештырылмавы, яшәү рәвешләре белән кызыксынуның булмавы, иң гади генә дәрәҗәдә булса да дөньяви белем бирелмәве Хафиз кебек малайларны әнә шундый язмышка дучар итә дә.

К. Тинчурин бу хәлләрне яхшы белә, алар турында ачынып яза. «Бүре зәхмәте» хикәясе бу яктан аеруча гыйбрәтле. Биш йөзләп шәкерте булган мәдрәсәдә сәламәтлек саклау мәсьәләсен хәл итүне «Комган хәлфә» дип йөртелүче кешегә тапшырганнар. Беренчедән, ул үз гомерендә медицина буенча бер генә китап та укымаган, икенчедән, үзе дә — психик авыру кеше. Дөрес, хөкүмәт органнары, мәдрәсә укучыларына күз-колак булу өчен, чын докторны билгеләгәннәр. Әмма ул бирегә айга бер генә килеп китә. Әлеге «Комган Хәлфә» дигән «табиб» анда да авыру шәкертләрне бу докторга күрсәтмәскә тырыша. Димәк, чын хәл мәдрәсәнең биек коймалары эчендә яшереп тотыла. Шәкертләрне «җен зәхмәте», «бүре зәхмәте» дигән «диагнозлар» куеп «дәвалаучы» Комган хәлфә автор тарафыннан көлке утына тотылган.

Ут дигәннән, азмы-күпме физика фәне белән таныш кеше белә: лампа янсын өчен өч шарт кирәк: лампага керосин салыну, кислородның җитәрлек күләмдә булуы һәм шырпы белән ут кабызып җибәрү. Шул шартлар үтәлгәндә, керосинның соңгы тамчысына кадәр ут яна да яна. Әлеге нәрсәләрнең берсе генә булмаса да, лампаның януы мөмкин түгел.

Ә биредә ничек? Артык зур булмаган бер бүлмә идәнендә, шәмдәл куярлык та урын калдырмыйча, илле биш егет йоклый. Тәрәзәдә форточка да юк. Ишекне төнгә элгеч белән эләктереп, ябып куялар. Лампа түшәмгә асылган. Мәдрәсәдәге тәртип буенча, лампа төн буе янып чыгарга тиеш икән. Әмма ул төн уртасы җиткәндә сүнеп китә. Бер көн шулай, ике көн шулай... Барысы да аптырыйлар. Илле биш кешенең берсе дә бу сүнүнең сәбәбен әйтеп бирә алмый. Хәлфәдән сорагач, аның җавабы әзер: җен эше! Төрле җен-пәриләр турында күп ишеткән шәкертләрнең кайберләре моны ишетеп куркып кала. («Йоклаганда юрган асларыннан башларын түгел, борыннарын да чыгармый башладылар».) Нәтиҗәдә, бүлмәдә торучылар арасында, нерв киеренкелеге сәбәпле, авыручылар да күренә башлый.

Әмма вакыты белән, ягъни көн җылынгач, мәсьәлә үзеннән-үзе хәл ителә. «Яз җитеп, тәрәзәләр ачылуга, җен юкка чыкты. Җәмәгать сәкесендәге лампа төн буена ялтырап яна торган булды». Ачык тәрәзәдән саф һава кереп торгач, янмый нишләсен, яна инде. Чөнки физика канунын бозып булмый бит. Үзләре аңламаган бөтен нәрсәне җен-парига сылтаган Комган хәлфәләр сәламәт балаларны бозучы «табиблар» булудан уза алмыйлар. Г. Тукай, шундый хәлләрне күздә тотып, юк-барга ышанучы кешеләрдән көлеп, болай дигән:

Җен-фәлән дип сөйләшүләр искеләрдән калган ул;
Сөйләве яхшы, күңелле — шагыйранә ялган ул.

Син әле үс һәм укы күп, шунда аңларсың барын;
Мәгърифәт нуры ачар күп нәрсәләрнең ялганын.

Мөстәкыйль эш өчен биремнәр

1. К. Тинчуринның «Мәрҗәннәр» исемле хикәяләр җыентыгын тулысынча укып чыгарга тырышыгыз.

2. Г. Ибраһимовның «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» исемле хикәясен укуны да максат итеп куегыз.

3. Р. Фәхреддиннең «Шәкерт илә студент» әсәрендә сурәтләнгән ике яшь кешенең халәтен чагыштырып, язма эш башкарыгыз.

Һади Такташ
(1901—1931)

Җуйдык сине, Һади,
Утыз яшьтә —
Иртә киттең безнең арадан;
Юк, китмәдең, шагыйрь,
Йөрәкләрдә
Терелттек без сине яңадан.

Гали Хуҗи

Һади Такташ — әдәби иҗат бәйгесен Г. Тукай, Дәрдемәнд, М. Гафури, Ш. Бабич, С. Рәмиев кебек зур шагыйрьләрдән ялгап алып китүче һәм аны, тагын да биеккә күтәреп, М. Җәлил, Ф. Кәрим, Х. Туфан, С. Хәким, И. Юзеевлар кулына тапшырган олы талант. Ягъни Һ. Такташ — үз вакытының иң күренекле шагыйрьләреннән берсе. Ул иҗат иткән егерменче елларны, һич икеләнмичә, татар шигърияте тарихында Һади Такташ чоры дип атарга мөмкин.

Һ. Такташ, утыз бер яшен дә тутыра алмыйча, дөньядан китте. Әлеге кыска гына вакыт эчендә дә ул зур мирас калдырырга өлгерде.

Һади Хәйрулла улы Такташев 1901 елның 1 гыйнварында туган. Туган авылы — Сыркыды. Әлеге авыл хәзерге Мордва Республикасының Торбеево районына керә. Булачак шагыйрьнең әтисе Хәйрулла агай, әнисе Шәмсениса апа — гади крестьяннар. Әмма икесе дә укый-яза белгәннәр. Әнисе шигъри күңелле, нечкә хисле булган. Бик күп җырлар, әкиятләр белгән, аларны матур итеп сөйләгән, үзе дә җырлар чыгарган. «Әни хәзер дә әле миңа хатларын җырлар белән яза. Ләкин ул үзенең җырчы икәнен белми»,— ди шагыйрь әнисе турында.

Малай укырга-язарга башта әти-әнисеннән өйрәнә. Аннан соң авыл мәдрәсәсендә укый. Үсә төшкәч, аны Пешлә мәдрәсәсенә бирәләр. Сыркыдыдан утыз чакрымдагы бу мәдрәсәдә малай бик тырышып укый. Шул вакытта чыккан газета-журналлар белән танышып барырга тырыша. Г. Тукай һәм С. Рәмиев шигырьләрен яратып укый. Кызганычка каршы, тормышлары авырлашып китү сәбәпле, Һади бу мәдрәсәне ташларга, Бохарага барып, эшкә урнашырга мәҗбүр була. Кибет тотучы байларда хезмәтче малай булып йөри. Аңа торабара хәтта кибетче хезмәтен башкарырга да туры килә. Ләкин бу эшләрнең берсе дә малайның күңеленә ятмый. Ул белемле кешеләр, укытучылар белән аралашырга тырыша. Рус телен һәм әдәбиятын өйрәнергә омтыла. Шигырьләр язып карый, әмма аларны уңышсыз дип санап яндыра бара. Шул вакытларда иҗат ителгән әсәрләрдән «Газраилләр» һәм «Караңгы төннәрдә» шигырьләре генә сакланган. Россиядәге революция тәэсирендә Бохарада да, әмирне бәреп төшерү өчен, көрәш башлана. Һ. Такташ та шул хәрәкәтләрдә катнаша. Хуҗалары бу тынгысыз үсмерне эштән чыгаралар. «1917 елның Февраль переворотын мин эшсез калган хәлдә каршыладым»,— ди ул үзе.

Һ. Такташ 1918 елга кадәр шигырьләрен беркайда да бастырмый. Шул елның 21 гыйнварында Ташкентта аның «Төркстан сахраларында» исемле шигыре дөнья күрә. Шуннан соң ул туган якларына кайтып китәргә мәҗбүр була. Бер ел Сыркыды авылында башлангыч мәктәптә укыта. 1920 елда исә Оренбургка барып урнаша. Моның сәбәбен ул болай аңлата: «Әдәби эшкә дәрт һәм белемемне тагын да күтәрү теләге мине Оренбургка китерде». Монда ул «Юксыллар сүзе» газетасында сәркатип булып эшли. Үз шигырьләре дә шушы ук газетада күренә башлый. 1921 елның язында ул Ташкентка күчә. Анда әдәбият укыта, «Белем йорты» журналында җаваплы сәркатип була. Шул ук вакытта әдәби иҗат эшен дә киң җәелдерә. «Җир уллары трагедиясе» исемле әсәре дә Урта Азиядә яшәгән вакытта языла.

Шулай да аның күңеле татар әдәбияты һәм сәнгатенең үзәге булган Казанга тартыла. 1922 елның көзендә ул Казанга килеп урнаша. Татар театрында, «Чаян», «Авыл яшьләре», «Азат хатын», «Яңалиф» журналларында эшли. Аның таланты чынчынлап нәкъ менә Казанда яшәгән вакытта ачылып китә дә. Тик 1931 елның 8 декабрендә бик яшьли үлеп китә. Иҗаты ярты юлда өзелеп кала. Аның гәүдәсе Казанның Үзәк мәдәният һәм ял паркындагы туганнар каберлегендә күмелгән.

ШАГЫЙРЬ ИҖАТЫНЫҢ ҮЗЕНЧӘЛЕГЕ

Һади Такташ үзенә кадәрге мең еллык татар шигъриятен, мифологияне яхшы белә, аңа таяна һәм анда булганнарны иҗади файдалана. Мәсәлән, борынгы әдәби әсәрләрдә фәрештә, пәйгамбәр, Газраил образлары еш очрый. Бу образлар Һ. Такташ әсәрләренә дә килеп керә. Мәсәлән, Газраил образы. Ул, дин өйрәтүе буенча, җан алучы фәрештә. «Күктән сөрелгәннәр» шигырендә Газраил исә үзе күк кануннарына каршы сугыш ачам дип белдерә. Әмма бу бер үк вакытта җирдә яшәп килүче гаделсезлекне күралмау, аларны бетерергә өндәү иде. «Җир уллары трагедиясе» турында да без нәкъ шулай дип әйтә алабыз. Әсәрнең герое Кабил — шушы тигезсез көрәш корбаны. Чөнки зур көчләр алдында ялгыз көрәшче уңышка ирешә алмый. Әмма шагыйрь бу үлемнең олы мәгънәгә ия булуын әйтә:

Үлде ул... Үлде... Ләкин
Ишетелми калмас зарлары,
Җиргә сеңмәс, мәңге кипмәс
Монда тамган каннары...

Кешенең гаделлек өчен көрәше гәрчә ул әлегә уңышсыз тәмамланса да югалмый, эзен җуймый. Әйе, яшәешне изгелек, намуслылык, тырыш хезмәт, кешеләргә җылы мөнәсәбәт белән генә матурларга мөмкин.

«Бакчачылар» шигырендә автор тормышны ямьләргә тиешле кешеләрнең һичшиксез киләчәгенә ышаныч белдерә. Такташ халкыбызның алдагы тормышын гаять матур итеп күзаллады һәм шуны үзенең гүзәл әсәрләрендә гәүдәләндерде.

«МОКАМАЙ» ӘСӘРЕ ТУРЫНДА

Һ. Такташның «Мокамай» шигыре — халыкка аеруча киң таралган, яратып укыла торган әсәрләрнең берсе. Аны бик күпләр тулысынча яки аерым өзекләрен яттан беләләр. Язылуына җиде дистә елдан артык вакыт узса да, әсәр искерми, халык хәтерендә яши.

Ни өчен шулай дигән сорау туа. Теләсә кайсы әсәр мондый бәхетле язмышка ия була алмый бит. Ә «Мокамай» әсәре һаман ялыктырмый, аны укыган саен укыйсы килә. Әсәр белән очрашкан саен, аннан ниндидер яңа мәгънәләр, үзең өчен яңалык

булып тоелырлык фикерләр табасың. Моның төп сәбәбе, әлбәттә, Һ. Такташның искиткеч таланты шагыйрь булуы диярге кирәк. Тагын бер сәбәбе — әсәрнең үзәк өзгеч фаҗигале хәл уңае белән иҗат ителүендә.

Һадиның туган авылы Сыркыдыда яшьтән бергә уйнап үскән Мөхәммәтҗан исемле дусты була. Авылда бер гадәт бар: кешенең исемен кыскартып, кушамат хәленә китереп сөйләшү киң таралган. Мөхәммәтҗанны да Мокамай дип йөрткәннәр. Һадины бала чагыннан ук белгән Йосыф бабай 1959 елда Казаннан килгән әдәбият белгечләре Илбарис Надыйров белән Рим Кәримовларга менәниләр сөйли: «Мокамай белән гел бергә иделәр. Мокамай чыбыркы ишәргә, чабата ясарга оста иде. Сандугач кебек чут-чут итеп сызгыра, талдан сыбызгы да ясый белә. Аннан оста йөзүче, чумучы малай бөтен авылда юк. Ап-ак тула оектан, матур итеп үргән чабатадан йөри иде. Аларның тормышлары гомер бакый фәкыйрь үтте. Әнисе белән торды ул. Ызбалары Һадиларга күрше генә иде. Бик дуслар иделәр. Мокамай эшкә оста иде, Һади телгә оста иде» (Совет әдәбияты.— 1959.— Гыйнвар).

Һади белән Мокамай янәшә йортларда үсәләр. Бөтенесе дә, ягъни яхшысы да, яманы да күз алдында. Күрәсең, дустының яхшы яклары күбрәк булгандыр, Һади әнә нәрсә ди бит: «Синең яхшы иде күңелең». Әмма балачакта төрле ярамаган эшләр дә кылына. Күрше бакчасыннан берәр алма да өзеп аласың. Г.Тукай «Исемдә калганнар» дигән истәлекләрендә язганча, «без бакчадагы яшел суганнар башына бер дә кәҗәдән ким бәла булмыйдыр идек». Шуның кебек, әлеге Мокамай да көннәрдән бер көнне «ялгышып кына» күрше карчыгының тавык кетәклегеннән йомырка эләктереп чыккан. Бу хәбәр күрше-тирәгә таралган. «Телгә оста Һади» шушы вакыйгага үз мөнәсәбәтен белдерми калмаган, такмак чыгарган.

Дыр-дыр дырабан,
Мокамай йомырка урлаган...

Һ. Такташ соңыннан язганча, бу аның үз гомерендә ясаган беренче шигъри тәҗрибәсе булган. Балалыгы сәбәпле, ул әлеге такмак белән якын дустының хәлен тагын да катлауландыра төшкәнен уйлап та тормаган. Шушы такмак Мокамай исемен әдәбиятка бер сәхифә итеп кертеп җибәрүгә сәбәп булган.

Күрәбез: такмакмы, бәетме, шигырьме әллә хикәяме — әдәби әсәрне язу өчен, авторга бер этәргеч булырлык сәбәп,

вакыйга, хәл-әхвәл кирәк. Бу дөньяда сәбәпсез-нисез бернәрсә дә булмый. Һади да Мокамай турындагы беренче такмагын уйнап кына чыгара. Башка берәү түгел, нәкъ менә Һади чыгара, чөнки ул «телгә оста». Күз алдына китерегез, Һади булмаса, ул Мокамайны бүген кем белер иде? Беркем дә. Без исә шагыйрьнең шушы юлларын укып елмаеп куябыз, ирексездән үзебезнең бала вакытларны искә төшерәбез.

Мокамай шагыйрь күңелендә шушы шуклыгы белән генә истә калса, бер хәер иде. Әмма бу исем аның иҗатына тагын бер тапкыр килеп керә. Бу юлы инде чын шагыйрь булып танылган Һади Такташ аны гомумиләштерелгән зур фикерләр әйтү өчен файдалана.

Эш шунда: 1920 елда Һади авылдан үзәк өзгеч хәбәр ала — Мокамай үлгән. Ничек үлгән? Үзен үзе һәлак иткән. Мондый хәбәр аны бик нык тетрәндерә. Һади бу хакта болай дип язган: «Күземә яшьләр килде. Минем иң якын дустым Мокамай үлгән». Әмма шуннан узып берни дә эшли алмый.

Мондый хәтәр үлем белән дөньядан үткән кешеләр турында, гадәттә, безнең халык бәет иҗат итә. Һади, шагыйрь буларак, бу үлемгә бөтенләй башкача карый. Ул әлеге хәлгә үз югарылыгыннан торып бәя бирә. Аның югарылыгы — шагыйрьлеге. Мокамай белән бергәләп үткәргән көннәре инде ерак калган. Шуңа күрә шагыйрь артка — үткәннәргә борылып карый. Аңа инде ул чаклар чынбарлыкта түгел, бәлки әкияттә генә булган сыман тоела. Шуңа күрә ул «үткәннәрем авыр әкият минем» дип әйтә. Моның белән үз тормышы да гади генә булмаганлыгына ишарә ясый. Ятим Мокамай исә тагын да авыррак шартларда үсә. Алар бергәләшеп нинди генә авырлыкларны кичмәгәннәр дә, нинди генә маҗаралы хәлләргә төшмәгәннәр? Шуңа күрә шагыйрь берничә урында үзе һәм Мокамай турында «әкияттәге ике бала кебек» ди.

Хәтерлисездер: әкиятләрдә еш кына кешеләр ике юл чатында калалар. Берсеннән китсәң — һәлакәткә, икенчесе буенча барсаң, бәхеткә юлыгасы белдерелеп куела. Кайчакта әкият каһарманы кыен юлны сайлый. Җырда әйтелгәнчә, «җиңел килгән бәхет, бәхетмени, эзләп тапкан бәхет кадерле». «Мокамай» әсәрендә исә мондый юл ак каен кәүсәсенә меңү белән алмаштырылган. Менә алганы офыкларны, бәхет табу юлларын күбрәк күрә алган, менә алмаганы югалган, юкка чыккан.

Кеше, дин өйрәтүләре буенча да, үз-үзенә кул салырга тиеш түгел. Бу зур гөнаһ санала. Мондый кеше халык хәтерендә

яхшы булып сакланмый. Тормышта кыен хәлләр күп була, шул ук вакытта алардан исән-имин чыгу юллары да табыла:

Карурманын карурман,
Карурман диеп тормам,
Чыгармын бер моннан,—

дигән ди урманда адашкан бер кеше. Эзләгән, хәрәкәт иткән кешене юл бәхет юлына алып чыкмый калмый. Шагыйрь Мокамайны юл эзләмәүдә, хәрәкәт итмәүдә күпмедер гаепли дә:

Тик син ачлык тырнагыннан,
Түбәнлектән
Чыгу юлын гына белмәдең...—

ди. Мокамай юлында очраган карурманның исеме — ачлык, ялангачлык, фәкыйрьлек. Бу хәлдән ялгыз гына түгел, ә бергәбергә, кулга-кул тотынып кына чыгып була, дип әйтергә тели шагыйрь.

Мондый зур фикерләрне әйтү өчен, бәет кысалары гына тар. Һади Такташ, дустының фаҗигасеннән тетрәнеп, үз чоры өчен бик тә әһәмиятле фикерләр әйтү югарылыгына күтәрелә. Мокамай хәлендәге үз юлын таба алмаучылар йөзләрчә-меңнәрчә булган. Ләкин алар өметләрен өзмәгәннәр. Әсәрдә әйтелгән фикерләр инде үлгән Мокамайга түгел, исәннәр өчен кирәк.

Әсәрне язганда Һ. Такташ тагын бер изге максатны күздә тоткан. Ул моны ачык итеп әйтә: «Минем бурычым, Мөхәммәтҗан, йолу синең яман атыңны!» Игътибар итегез: болай дигәндә, Һ. Такташ «Мокамай» дип дустының исемен бозып әйтми, бәлки, авыз тутырып, тулысынча яза — Мөхәммәтҗан ди. Шагыйрь дустының якты истәлеген авылдашлары һәм халык хәтере алдында акларга тели. Әйтергә кирәк, ул үзенең максатына ирешә дә. Мокамай менә ничә буын хәтерендә бер үк вакытта моңсу һәм якты образ булып яшәвен дәвам иттерә.

Сораулар һәм биремнәр

1. Шигъри әсәрдәге «мин» образын без, гадәттә, лирик герой дип атыйбыз. Бу әсәрдәге «мин» образы шагыйрьнең үзе белән чын мәгънәсендә туры килә. Буниләрдә күренә?

2. «Мин» һәм Мокамай бала чагында нинди сыйфатларга ия булалар? Алар өчен уртак һәм аермалы якларны күрсәтегез.

3. Һадида шагыйрьлек билгеләре ничек беленә башлый?

4. Дустының һәлакәте уңаеннан шагыйрь ни өчен бәет түгел, ә шигырь иҗат итә?

5. Шагыйрь ни өчен үзләре турында кайта-кайта «әкияттәге ике бала кебек» ди?

6. Ике дусның язмышы төрле булуын шагыйрь ничек аңлата?

7. «Кеше үз язмышына үзе хуҗа» дигән фикерне дәлилләгез.

МОКАМАЙ

Белмим,
Әллә күпкә,
Әллә бик озакка,
Ахры, мәңге онта алмамын
Тамбов урманнары уртасында
Усак яфраклары шаулавын...
Алар мәңге минем хыялымда
Шаулый-шаулый яфрак ярырлар,
Карт имәннәр, калмый минем арттан,
Кая барсам озатып барырлар...
Бер җирдә юк андый ак каеннар,
Бер җирдә юк андый урманнар,
Бер җирдә юк камыш сабаклары —
Андагыдай шаулый торганнар...

Әкияттәге ике бала кебек,
Каен башларына үрмәләп,
Ике штансыз малай дөнья белән
Танышып йөргән идек бергәләп...
Беребез сары чәчле, беребез кара:
Сары чәчлесе ул мин идем;
Кара чәчле, коңгырт кара күзле,
Кәкре аяклы дустым, җанкисәгем,
Ул, Мокамай бәгърем, син идең...
Ак каенга аслып менгән кебек,
Мин тормышта һаман яктыга,
Югарыга табан юл алдым;
Менгән саен җирнең матурлыгын,
Яктылыгын күбрәк күралдым...
Ә син менәлмәдең,
Калдың,
Югалдың...

Әкияттәге ике бала кебек —
Икебез дә кара борынлы,

Зурлар кебек, кулны артка куеп
Йөри идек таптап болынны...
Һәрбер нәрсә безгә яңа иде,
Һәрнәрсәгә исебез китә иде,
Бернәрсә дә бездән качмый иде,
Бар нәрсәгә кулыбыз җитә иде...
Күпме кыен күрдек шуның өчен,
Күпме тал чыбыгы ашадык;
Әкияттәге ике бала кебек,
Күпме «җәфа чигеп» яшәдек...
Кем уйлаган шушы шаярулар
Синдә кәсеп булып калыр дип,
Уйнап башланган эш тормышыңны
Һәлакәткә алып барыр дип...
Хат язсам да хәзер соңга калдым,
Укымассың минем хатымны,
Ләкин минем бурчым, Мөхәммәтҗан,
Йолу синең яман атыңны!
Син гомереңне усал исем белән,
Канлы пычак белән чикләдең...
Әллә ничек булды синең гомер,
Син, Мокамай, әллә нишләдең!..
Әкияттәге ике бала кебек,
Каен башларына үрмәләп,
Ике штансыз малай дөнья белән
Танышып йөргән идек бергәләп...
Ак каенга аслып менгән кебек,
Мин тормышта һаман яктыга,
Югарыга табан юл алдым;
Менгән саен җирнең матурлыгын,
Яктылыгын күбрәк күралдым...
Ә син менәлмәдең...
Калдың, югалдың...
Үткәннәрем авыр әкият минем,—
Ул әкиятне әгәр сөйләгәндә
Чаглып китсә синең күләгәң,
Юк, юк,
Мин ант итәм: һичбер вакытта да
Сине карак итеп сөйләмәм...
Син яшәргә хаклы кеше идең,
Син яшәргә җирдә теләдең.
Тик син ачлык тырнагыннан,

Түбәнлектән
Чыгу юлын гына белмәдең...
Ә бит
Бергә чабаталар үреп йөргән чакта,
Син остарак миннән үрәйдең,
Минем матур итеп үрәлмәүне
Булдыксызлыгымнан күрәйдең...
Ник соң бу болай булды әле,
Ничек һәлакәтең күрмәдең,
Ник, Мокамай, соң син тормышыңны
Чабатаңдай матур үрмәдең?!
Син гомереңне усал исем белән,
Канлы пычак белән чикләдең;
Әллә ничек булды синең гомер,
Син, Мокамай, әллә нишләдең!..
Ә бит безнең гомер матур урманнарда
Май аедай матур башланды;
Әкияттәге ике бала кебек,
Икебез ике якка ташланды...
Синең тормыш авыр әкият булды,
Ул әкиятнең соңгы битләрен
Син зур исем, мәңге онтылмаслык
Эшләр белән бизәп китмәдең...
Син адаштың,
Ләкин син яхшы идең,
Синең яхшы иде күңелең,
Тик белмәдең тормыш баткагыннан
Ялгыз чыгу мөмкин түгелен...
Син белмәдең,
Кешеләр җирдә тормыш баткагыннан
Чыгу юлын бергә эзлиләр;
Ялгыз калып, ачтан үлмәс өчен,
Күмәк тормыш җирдә төзиләр...
Үткәнемне әкият итеп сөйләгәндә
Чаглып китсә синең күләгәң,
Юк, Мокамай, һичбер вакытта да
Сине усал итеп сөйләмәм...
Син ярлы идең, ләкин эш сөя идең,
Синең яхшы иде күңелең,—
Син белмәдең сыйнфый бөлгенлектән
Алай чыгу мөмкин түгелен...

Сораулар һәм биремнәр

1. Шигырьне мәгънәви кисәкләргә бүлеп карагыз. Шул мәгънәви кисәкләргә исемнәр бирегез.

2. Шигырьне яттан сәнгатьле итеп укырга өйрәнегез.

3. Әсәрдәге кайсы фикерләр, кайсы шигъри юллар халыкның гадәти сөйләмендә еш кулланыла? Шуларны билгеләгез.

Һади Такташ иҗатын күренекле әдәбият галимнәре өйрәнгәннәр. Галимҗан Нигъмәти, Гомәр Гали, Гали Халит, Хәсән Хәйри, Тәлгат Галиуллин — шуларның кайберләре. Алар арасында Казан педагогия институты укытучысы Мөхәммәтша Мамин аерылып тора. Галим 1941 елда «Такташ поэзиясе» дигән китап бастырып чыгара. Әйтергә кирәк, бу хезмәт Һади Такташ шәхесенә һәм иҗатына багышланган китапларның иң уңышлыларыннан, ул әле бүген дә үзенең әһәмиятен югалтмаган. Аның «Мокамай» әсәре турында язган юллары да эстетик анализның матур үрнәге була ала.

Менә алар: «Такташ пейзажларының характерлы ягы шунда ки, ул аларны коры табигый күренешләр итеп кенә бирми, бәлки иҗтимагый вакыйгаларны ачыклаучы декорация итеп файдалана. Ул аларны төп сурәтләр белән чагыштыру өчен һәм әсәрдәге вакыйганың нинди шартларда булуын күрсәтү өчен дә файдалана. Мәсьәләне ачыграк күрү өчен, кайбер мисалларга тукталыйк.

«Мокамай» әсәренең беренче бүлеген Такташ пейзаж белән башлап китә, бу башланышны экспозиция урынында бирә. Шушы шартларга нигезләнеп, ул әсәрнең бөтен композициясен төзи».

«Гадилектә — даһилык» дигән сүзне ишеткәнегез бардыр. Чыннан да, бөек нәрсәләр, гадәттә, гади була, дөресрәге, шулай булып тоела. Һ. Такташ хикәяләүне бик гади итеп башлап җибәрә:

Белмим,
Әллә күпкә,
Әллә бик озакка,
Ахры, мәңге онта алмамын
Тамбов урманнары уртасында
Усак яфраклары шаулавын...

Туган ягын ярату, якын күрү һәр сүзеннән сизелеп тора. Җанга якын таныш табигатьне сурәтләгәннән соң, җайлап кына, сискәндерми генә вакыйгаларның төп геройларына килеп җитә. Анда да Мокамайны гына түгел, аның янында

шагыйрь үзен дә күрә. Чөнки ул үткәннәрне әкият итеп сөйли, әлеге әкият эчендә, һичшиксез, ул үзе дә бар. Менә шушы янәшә тасвирлауда аларның үзләренә генә хас холык-фигыльләре, сыйфатлары ачыла. Лирик герой дустын шулкадәр яхшы белә, мин сине кара итеп, усал итеп сөйләмәм дип, кат-кат әйтә. Аның булдыклылыгына, төрле һөнәрләргә оста булуына басым ясый. «Ник син тормышыңны чабатаңдай матур үрмәдең» дип, үкенечле хисләрен белдерә. Мокамай, чыннан да, лирик геройның үзе кебек бәхеткә, югарыга таба юл алырга лаек егет.

Әмма Һади Такташ бу әсәрен язганда бер бик тә мөһим нәрсәне белми. Мөхәммәтҗан үз-үзен үтермәгән, аны һәлак иткәннәр икән бит. Мокамайның үзеннән өч яшькә олырак булган Фатыйма апасы 1959 елда әле исән була, ул боларны сөйли: «Бәхет күрә алмады, бичара. Бик яшьли әрәм булды шул. Нахак бәла аркасында». Мокамайны бер байның арба тәгәрмәчен урлауда гаеплиләр, авыл Советының базына ябып куялар. Байның куштаннары егетне үтергәнче кыйныйлар. Җитмәсә, хурлыгына чыдый алмыйча, үзен үзе үтерде дигән хәбәр тараталар. «Һади булмады шул, Һади,— ди апасы.— Һади булса, Мөхәммәтҗаныбыз исән калыр иде. Аны яклар кеше дә булмады. Ахырдан артыннан йөрүче дә булмады... Мөхәммәтҗан үлгәч, Һадидан хат килгән иде. «Йөрәгем өзелде инде, апаем, ятим калдым, нишләрмен»,— дип ачыргаланып язган иде. Һади да Мөхәммәтҗанны кулаклар үтергәнен белмәгән шул...» (Такташ турында истәлекләр.— 1980.— 49 б.) Әйе, дөресен белгән булса, Һ. Такташ бу әсәрне бөтенләй башкача язар иде. Һәрхәлдә, шигырьдә «минем бурычым, Мөхәммәтҗан, йолу синең яман атыңны» дигән юллар булмас иде. Булмаган яман атны юарга да кирәкми бит.

Сораулар һәм биремнәр

1. Һ. Такташ иҗатын өйрәнгән әдәбият галимнәре турында сез ниләр беләсез?

2. Әдәбиятчы М. Мамин шагыйрь иҗатының нинди үзенчәлеген билгели?

3. Һ. Такташның әсәрләре күпчелек очракта сөйләм шигыре буларак язылган, аларны, бик теләсәң дә, көйләп укып булмый. «Мокамай» әсәрендә бу үзенчәлек сакланганмы?

4. Һ. Такташ Мокамай үлеме турында дөреслекне белсә, аның турында әсәрен ничегрәк итеп язар иде икән? Сез ничек уйлыйсыз?

5. «Ике егет — ике язмыш» дигән темага иншa языгыз.

Мирсәй Әмир
(1907—1980)

Мирсәй Әмир (Мирсаяф Мәсәлим улы Әмиров) 1907 елның 6 гыйнварында Башкортстанның Мәләүез районы Җиргән авылында крестьян гаиләсендә туа. Яшьли ятим калып, туганнан туган абыйсы гаиләсендә, аннары балалар йортында һәм Эстәрлетамак шәһәрендәге җидееллык үрнәк-тәҗрибә мәктәбе интернатында тәрбияләнә. 1925 елда Яңа Карамалы волость башкарма комитеты хезмәткәре һәм бер үк вакытта авыл комсомол ячейкасы секретаре вазифаларын башкара. 1926 елда Казандагы сәнгать техникумына укырга керә. Ике ел укыганнан соң, «Кызыл яшьләр» газетасы һәм «Авыл яшьләре» журналы редакциясенә җаваплы секретарь булып күчә. 1929—1931 елларда М. Әмир Кызыл Армия сафында хезмәт итә, аннан кайткач, берникадәр вакыт «Чаян» журналында әдәби хезмәткәр, аннары 1934 елга кадәр Татарстан китап нәшриятының матур әдәбият бүлегендә редактор булып эшли. 1934—1936 елларда югары уку йортына керергә теләүчеләр өчен марксизм-ленинизм институты каршында оештырылган әзерлек курсында укый. 1937 елда Мәскәүдә М. Горький исемендәге Әдәбият институтында читтән торып укый башлый. Сугыш чорында М. Әмир Татарстан радио комитетында редактор булып эшли. 1943 ел башында ул Төньяк-Көнбатыш фронтка китә, өч ай чамасы «Ватан өчен» исемле татарча фронт газетасы редакциясендә эшли.

Ул 1937, 1961—1962 елларда республика Язучылар берлеге рәисе вазифасын башкарды. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе дигән мактаулы исемгә лаек булды. М. Әмиргә республикабызның Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге бирелде.

М. Әмир 1980 елның 1 июнендә вафат булды.

АГЫЙДЕЛ

(Өзекләр)

XVII

Спектакль башланырга биш минут вакыт калганда, көтелмәгән бер бәла килеп чыкты.

Кичәбезнең сөйләүләр өлеше бетеп, тәнәфес игълан иткән вакытта, безнең күңелләр артык күтәренке иде. Пәрдә төшерелеп, сәхнә артында калгач, без Гаяз белән яхшы тойгыларыбызны уртаклашып алдык.

— Йә, Ильяс, синең кәефләр ничек, эшләр бара бит? — диде Гаяз.

— Көтелгәннән дә артыграк,— дидем мин.

— Тик Имәли генә бераз арттырыбрак җибәрде. Бу чаклы масса алдында ул кадәр ачылу кирәкмәс иде, ә?

— Беркатлырак шул ул, аны аңа аңлатырга кирәк булыр.

— Зарар юк, гомумән алганда, безнең файдага. Тик менә Артыкбикә килмичә начар итте.

— Әйе шул, ул да килгән булса, дөньябызның тәгәлләнмәгән җире калмый иде. Бик күңелсез булды аның килмәве.

Чынлап та, Артыкбикәнең юклыгы тагын да яхшырак тойгылардан мәхрүм итә иде безне.

Ул арада безнең яныбызга гримланган артистларыбыз җыела башлады. Аларны күрүгә, Гаязның да төп эше исенә төште; ул, ашыга-ашыга, Хәлил булып киенергә, гримланырга тотынды. Минем яныма Мәһибикә килде. Өстенә биле бөрелеп тегелгән киң чуар күлмәк кигән, башына зур яшел яулык ябынган, ябь-яшь битенә калын-калын сызыклар сызган — янәсе, карт хатын булган...

— Ильяс абый, гримым әйбәтме?— дип сорады ул миннән. Зур кара күзләрен тутырып ачып, күзләремә карады да, елмаеп, башын түбән иде. Карчыклардан бигрәк, бите-башы балчыкка каткан балаларга охшый иде ул.

— Юк, Мәһибикә, болай ярамый,— дидем мин,— кил үзем төзәтим,— дидем. Грим өстәле янына алып килеп, карт хатынга охшатырга тотындым. Чем-кара сызыкларны кызгылт буяу белән күләгәләп, җыерчыкка охшата төштем. Күзләренә тарткан сөрмәсен бетердем.— Болай да синең күзләрең тарантас тәгәрмәче хәтле,— дип көлдем,— карчыкларның күзләре алай

булмый.— Ул минем төзәтүемә, битләреннән сыйпавыма иркәләнеп, риза булып торды.

Аны рәтләп бетерергә өлгермәдем, Зоя килеп бүлдерде:

— Ильяс, кара әле, минем гримым ярарлыкмы?

Зояга борылып карау белән каушап, кычкырып җибәрдем:

— Юк, юк, һич ярамый. Бу мөмкин түгел!

Ул Галиябануны — авыл кызын — революциягә кадәр булган татар авылы кызын уйный. Үзе, ярты күкрәген ялангач калдырып, зур ачык якалы ак кофта кигән. Бөдрәләндереп кабарткан сары чәчләре өстенә кечкенә калфак кадаган булган. Җитмәсә, тездән генә итеп тегелгән зәңгәр юбкасы астыннан тыгыз ефәк оеклар ялтырый. Аягында биек үкчәле туфли.

— Юк, юк, Зоя, хәзер киемнәреңне алыштыр. Син авыл кызын — крестьян кызын уйныйсың. Сиңа әзерләгән киемнәр бар бит.

Зоя минем сүзләремә аз гына да илтифат итмәгән кыяфәт белән көлде һәм, кирәксез кыланышлар белән боргалана-боргалана:

— Ә миңа шушылай килешә,— диде.

— Һичшиксез, алыштырырга кирәк, тиз бул. Башларга вакыт җитте,— дидем.

— Мин алыштырмыйм.

— Алыштыр!

Ахрысы, катырак кычкырып җибәргәнмендер, янызга ашыга-ашыга Гаяз килеп җитте. Ул Хәлил булып киенеп, бизәнеп өлгергән иде инде.

— Нәрсә бар, нинди кычкырыш?— диде ул.

— Менә Галиябануның киемнәрен кара әле, нинди чибәр!— дидем мин, Зояны күрсәттем.

— А-а... һич ярамый,— диде Гаяз.— Нинди рольдә уйнаганыңны белмисеңмени син, Зоя? Алыштыр, тиз бул!

Зоя һаман киреләнде:

— Миңа шушылай килешә.

Гаяз кыза төште:

— Сиңа килешүдә эш түгел. Авыл кызы булып киен. Тиз бул. Вакыт бетте бит.

— Юк, мин шушылай уйныйм.

— Бу нинди капризлану?— диде Гаяз, тавышын күтәреп.— Бүгенгә генә ташлап тор ичмасам шул мещанкалыгыңны!

— Алайса, мещанка булмаган кызларыгызны табыгыз,— диде дә Зоя, борылды да китте.

Без, Гаяз белән икәүләп, аның артыннан ташландык. Икебез ике иңбашыннан тотып туктаттык.

— Бу ни эшләвең, Зоя? Хәзерләнгән спектакльне җимермәкче буласыңмы?

— Мещанка булмаган кызларыгыз уйнасын,— диде Зоя, башындагы калфагын алып ыргытты.— Мин кайтып китәм.

— Комсомолка икәнлегеңне онытгыңмыни?

— Комсомолка булса, мин сездән мыскыл ителер өчен комсомол түгел. Комсомолка булмасам да, бик исем китми. Комсомолкаларыгыз уйнар.

— Мәҗбүр итәбез без сине!— диде Гаяз.

Зоя, мәсхәрәле елмаю белән безгә карап: «Рәхмәт»,— диде дә киенү бүлмәсенә чыкты.

Гаяз белән күзгә-күз карашып, аптыраашта калдык.

— Нишлибез?

— Бернишләр хәл юк, хатын-кызлар җитмәве үтерә. Болай да бит карчык ролендә малай кеше уйный.

— Әйе, бернишләр хәл юк, Ильяс, риза булырга туры килә. Уйнасын шул киемендә. Соңыннан кирәген бирербез кабахәтнең.

Икәүләп Зоя кергән бүлмәгә ташландык. Ишек бикле иде.

— Зоя, ач әле.

Эчтән җавап булмады. Йомшаграк тавыш белән дәшеп карадык. Җавап булмады. Залда халык, пәрдәнең тизрәк ачылуын сорап, кул чаба башлады.

— Зоя, ач, анда безнең әйберләребез бар!— дип өзгәләндек без.

Ишек ачылды. Үзенең көн дә кия торган гади киемнәрен киенеп, Зоя килеп чыкты. Безгә эндәшмичә, сәхнәдән чыгуга таба атлый башлады.

— Тукта, Зоя, үзең теләгән киемнәрдән уйнарсың, спектаклебезне генә харап итмә.

Зоя, безгә эндәшмичә, сикереп, сәхнәдән төште дә, ашыга-ашыга атлап, мәктәптән үк чыгып китте.

Нишләргә белмичә, тирән аптыраашта калдык. Залда кул чабалар, аяк дөбердәтүләр көчәйгәннән-көчәя бара иде.

— Әллә Галиябану ролендә үзең уйныйсыңмы, Ильяс?— диде Гаяз.— Төскә-биткә артык ямьсез түгелсең, грим белән рәтләп булыр, бәлки.

Гаязның бу сорауны куюы миңа кызганыч тоелды. Ике елдан артыкка сузылган иптәшлек гомеремдә аның бу кадәрле таянычсыз хәлдә калуын беренче күрүем иде.

— Син, Гаяз, юләрләнәсең булса кирәк, миннән Галиябануны уйнату — адәм көлдерү бит.

Гаязның бу фикергә кушылмыйча чарасы юк иде.

— Ичмаса, Артыкбикәсе дә килмәде, шайтан!— дип куйды, өзгәләнеп.

— Болай булгач, аның килмәве хәерле булды инде,— дидем мин,— мондый хурлыкка калуыбызны аңа күрсәтү тагын да начаррак булыр иде.

— Бәлкем, ул безне мондый әшәке хәлдән коткарган булыр иде.

Без тагын нәрсә әйтергә белми сүзсез калдык. Котчыккыч хурлыклы аптыраш иде бу. Ул минутта Гаязның йөзенә чыккан өметсезлек, таянычсызлыкка карап елыйсым килә иде минем. Тик Гаяздагы бу ямьсез чырай озакка бармады. Ул каты итеп тешен кысты, кашларын җимерде дә, уң кулын каты йодрыклап, һавага кизәнеп куйды:

— Ярый!— диде. Тавышы нык, ышанычлы иде.— Булмаса булмас, «Галиябану»ны калдырабыз, концерт бүлеген башлыйбыз. Бар, син чыгып халыкка аңлат, мин монда, гримнарымны сөртеп, Зоя турында берәр нәрсә яза торыйм. Концерт бүлегендә үзем чыгып сөйләрмен. «Галиябану»ны ни өчен куймавыбызның сәбәбен әйтми тор. Бәгъзе сәбәпләр аркасында гына дип әйтерсең. Концертта аңлатырбыз без аны, бар, тынычландыр, син тынычландыра беләсең...

Мин пәрдә алдына чыгып басуга, кул чабу, аяк тыпырдату, сызгыру тавышлары басылды. Иң алдагы сафта утырган Низамыйның миңа карап мыскыллы елмаю күрсәтүе мине эсселе-суыклы итеп җибәрде. Коточкыч җинаять күрдем мин аның йөзендә. Ләкин түзүдән башка чара юк иде. Никадәр авыр булса да, сабырлыкны югалтмыйча, халыкны тынычландыру кирәк иде. Әйтәсе сүземне тиз генә күңелемнән барлап чыктым.

Минем нәрсә әйтүемне тирән тынычлык белән көтүче халык өстенә карап, «Иптәшләр!» дию
емә, урам як

ишек ачылып китте. Миңа таныш булмаган берничә башкорт кызы күренде. Күңелем нәрсәдер сизенде. Әйтәсе сүземне әйтмичә, күземне шул кызлар арасына юнәлттем. Ят кызлар арасыннан, аерылып, Артыкбикә күренде. Шулкадәр җиңел булып китте миңа, әйтә алмый торган авыр сүзләр башымнан бөтенләй чыгып киттеләр. Аз гына да уйлап тормыйча, кичәбезгә күрше авылдан килгән кунаклар турында хәбәр бирдем.

— Иптәшләр, көткән кунакларыбыз килде. Алгы сафтан урын хәзерләгез.

Үземне үзем белешмичә, сәхнәдән сикереп төштем дә Артыкбикәгә каршы йөгердем. Артыкбикә белән бергә алты-җиде башкорт кызы һәм биш-алтылап мәктәп малайлары килгән иде.

— Соңгарак калдык, Ильяс иптәш, ачуланмыйсызмы?— диде Артыкбикә.

— Бик вакытлы, бик вакытлы, әйдәгез.

Мин аларны йөгертә-йөгертә алгы сафка уздырдым. Алгы сафта Низамыйдан башкалар урыннарын бушатканнар иде. Ләкин ике кунакка урын җитми калды.

— Низамый, кунакларга урын кирәк,— дидем мин.

Низамый сүзсез кузгалды. Аның урынына кечкенә башкорт малаен утырттым да урын җитми калган кунакларның соңгысы булган Артыкбикәне сәхнәгә алып кердем.

— Гаяз кайда?

— Кием бүлмәсендә,— диделәр.

Гаяз сул кулының бармакларын чәч араларына тыгып, кашларын җимереп язып утыра иде. Без кергәч тә, күтәрелеп карамады ул.

— Гаяз, кунак килде, кузгал,— дип кычкырып җибәрдем. Гаяз кинәт безгә борылды. Артыкбикәне күрү белән сикереп торды. Исәнлек-саулык сорашып тормастан, Артыкбикәнең иңбашларына килеп тотынды:

— Иделбаева, әйтегез: «Галиябану»да уйнаганыгыз бармы сезнең?

Артыкбикә тыныч кына елмаеп куйды:

— Техникумда чакта мин аның героинясы идем.

Гаяз да, мин дә шатлыктан шашкан тавыш белән кычкырып җибәрдек:

— Шулаймы?

Үз-үзебезне онытып, икебез берьюлы кочаклап алдык без аны.

— Димәк, безне бу хурлыклы хәлдән котылдырдыгыз?

— Ни булды сезгә?— диде Артыкбикә. Бернәрсә аңламаган кара күзләре белән бер миңа, бер Гаязга карап сорау бирде.— Ни булды сезгә? Бернәрсә дә аңламыйм.

Эшнең нәрсәдә икәнен тиз аңлаттык. Шул ук минутта мин, яңадан пәрдә алдына чыгып, спектакльнең биш минуттан башланачагы, Галиябануролендә яңа артистка уйнаячагы турында хәбәр бирдем. Көчле алкышлар мәктәпне күтәрә яздылар...

Артыкбикә беренче җыры белән үк залны үзенә каратты. Андый көчле җырны, андый йөрәк җырын гомеремдә беренче тапкыр ишеткәнмендер. Шулкадәр дәртләнеп, шулкадәр бирелеп җырлый иде Артыкбикә, әйтерсең лә ул чын-чынлап Галиябану кичергәннәрне үз йөрәгендә кичерә. Аның вакытлыча гына Галиябану роленә кергән һәвәскәр артистка икәнлеген онытасың. Йөрәгең, үзеңә дә сиздермәстән, аның йөрәге белән кушыла. Ул куанганда куанасы, ул көлгәндә көләсе килә. Ул боекканда боегасы, ул елаганда аның белән бергә елыйсы килә. Бер күтәрелеп, бер төшеп сулый торган калку күкрәгеннән агып чыккан үтә саф тавышның кеше тавышы булуына ышанасы килми. Анда гади кешегә аңлашылмый торган ниндидер сер яшерелгәндер сыман тоела...

Бүгенге кичәнең җитәкчесе — үзенә күрә режиссеры булуым мине беразга айнытты. Бу сихерле музыка әсирлегеннән йөрәгемне тартып алып, үзен үзе оныткан залга карадым. Залдагылар, чын-чыннан, үзләрен үзләре онытканнар иде. Бик күпләрнең кыяфәтләре миңа көлке тоелды. Кем нинди хәлдә булса, гипноз белән йоклатылган шикелле, шул хәлендә катып калган. Күпләрнең аскы ияклəрен дә ябып тотарлык ихтыярлары калмыйча, авызлары ачылган, күпләр муеннарын тота алмыйча, көлке кыяфәтләргә кереп, башларын кыегайтканнар, һәрберсе үзенә бер төргә ия булган күзләр, барлык көчләренә киерелеп ачылып, сәхнәгә текәлгәннәр... Бөтен зал шулай катып калган.

Бу тиңе булмаган йөрәк көче алдында үзен үзе югалтмаган бер генә кеше күрдем мин — ул Низамый иде. Аның аптыраушта калган ачулы күзләре ниндидер авыр сорауга җавап эзлиләр. Ләкин мондый минутта кем аңа җавап бирсен. Аның барлыгын белүче дә юк... Ул, залда урнашкан йөрәк тынлыгын җимерергә теләмәгән сыман,

әкрен генә урыныннан кузгалды. Кепкасын кулына тоткан килеш, аяк очларына гына басып, ишеккә таба атлады. Аның чыгып китүен миннән башка берәү дә күрмәде дә, сизмәде дә. Мин, үземне зур көрәштә җиңеп чыгучы батыр кебек хис итеп, залдан күзләремне алдым. Йөрәгем яңадан Артыкбикә йөрәге белән тоташты.

Низамыйның чыгып китүе бер дә юкка гына булмаган, күрәсең. Аның нәтиҗәсе соңрак беленде. Шул ук спектакльдә безнең программабызда күрелмәгән яңа бер күңелсезлек көтә иде.

XVIII

Спектаклебез җимерелде дип торганда Артыкбикәнең килеп чыгуы, капризланып чыгып киткән Зояга караганда тиңләштермәслек дәрәҗәдә яхшы уйнавы, яхшы җырлавы безне чиктән тыш бәхетле итте. Әйтеп аңлатырга мөмкин булмаган дәрәҗәдә көчле алкышлар, көчле «ура» тавышлары астында беренче пәрдә төшерелгәч, без, сәхнә тирәсендәгеләр, барыбыз да Артыкбикә янына җыелыштык. Ничек итеп котларга, нинди сүзләр белән тәбрикләргә белми идек без аны.

— Хәйранга калдырдыгыз сез безне, иптәш Иделбаева,— дидем мин.— Беләсезме, сезнең җырыгызны ишеткәч, табигатьнең нечкә серләренә төшенә алмаган вәхши шикелле булдым мин. Сездәге ул акыл ирешә алмаслык дәрәҗәдәге көчле музыкага табынырга әзер мин. Кайдан алдыгыз сез ул матур тавышны? Кайдан килде сезгә ул кадәр моң?

Артыкбикә сөйкемле итеп елмайды:

— Мин сезгә хәйран калам: кайдан алдыгыз сез ул тәмле телне, кайдан килде сезгә ул кадәр комплиментлар?

— Сез, сез тудырдыгыз миндә аларны!

Артыкбикә кычкырып көлеп җибәрде:

— Сезгә җавап таба алмассың, сез шундый...

Аны бүлдерделәр. Сәхнәгә керә торган ишектән бер башкорт кызы дәште:

— Артыкбикә апай, сык әле.

— Әү, Алмабикә. Миңа чыгарга ярамый, акыллым, кер үзең.

Өстенә яшел бизәкле ситсыдан тегелгән яңа күлмәк кигән, башына кызыл яулык бәйләгән кыз — Алмабикә — кыю адымнар белән сәхнәгә менде.

— Артыкбикә апай, һине Күсәрбай агаең көтә, сыкмайһыңмы?

Артыкбикәнең йөзендә көчле шатлык уты кабынды:

— Күчәрбай агаем?..— дип кычкырып җибәрде ул.—Ул мондамы? Алып керегез аны.

Мин, аптырап, Артыкбикәгә сорау бирдем:

— Күчәрбайны беләсезмени сез?

— Бердәнбер абыем ул минем,— диде Артыкбикә, ни эшләгәнен белми, мине кочаклап алды.— Сигез абыемнан үлмичә калган бердәнбер абыем ул минем!

— Хәзер алып керәм мин аны,— дидем мин, машина җитезлеге белән залга атылып төштем.

Бу минутта минем хәтеремә Күчәрбайның ниндидер югалган иркәсе турында сөйләгән сүзләре килде: «Ул бүреләр минем иркәмне суеп ашадылар инде»,— дигән иде ул. Шушы микәнни аның югалган иркәсе? Шул ук минутта Артыкбикәнең безнең белән бергәләп Базарлыдан кайткан вакытта әйткән сүзе дә минем хәтеремдә терелде: «Сезнең авылда минем күрәсе кешем бар»,— дигән иде. Менә кемне күрәсе булган икән аның.

Күчәрбайны Кинҗә авылыннан килгән кунаклар уратып алган иде. Алар, берсеннән-берсе уздырырга тырышып, Артыкбикәнең Кинҗә авылында эшләгән эшләре турында сөйлиләр. Күчәрбай, аларга ни дип җавап бирергә белмичә, аптырашлы елмаю белән кызарып, тик тора.

— Әйдә, Күчәрбай,— дидем мин, сул як җиңеннән тотып, аны үзем белән өстерәдем.

Күчәрбай җәза астына алып барылган кеше төсле тартылды: «Оялам, Ильяс, куй бүгенгә, оялам»,— ди иде ул. Мин аның ай-ваена карамадым, җилтерәтеп, сәхнәгә алып мендем. Безне Артыкбикә белән Гаяз берьюлы каршы алдылар.

— Күсәрбай агаем, һинме был!— диде Артыкбикә.

Күчәрбай «мин» дияргә өлгермәде, Артыкбикә аның киң күкрәгенә капланды. Абыйсы аны сөеп чәчләреннән, иңбашларыннан сыпыра башлады:

— Артыкбикә иркәм, һин югалманыңмыни?— диде ул. Аның күзләрендә яшь бөртекләре ялтырадылар.

— Югалманым, агаем, комсомолецлар мине бүре аудыннан һуырып алдылар.

Ага белән сеңел арасында булган бу романтик очрашу каршында без, Гаяз белән, күзгә-күз карашып, ни

әйтергә белми калдык. Икенче пәрдәне ачарга вакыт җиткән иде. Тагын минем режиссерлыгым ярдәмгә килде. Ага белән сеңел йөрәгендә туган нечкә хисләрне тупас рәвештә җимермәс өчен, Күчәрбайга шаярып сүз кушкан булдым:

— Ай-һай, Күчәрбай, кайчаннан бирле бергә йөрибез, шушындый оста җырлый белә торган сеңлең барлыгын әйткәнең дә юк.

Бу сүзләрдән алар икесе дә айныдылар. Артыкбикәнең әүвәлге шаян чырае кайтты. Абзыйсы өчен үзе җавап бирде:

— Минем барлыгымны үзе дә белмәгән бит ул, шулай бит, агаем?

— Шулай шул,— диде Күчәрбай.— Мин һине дөнья йөзендә юкка һанап йөренем.

— А, Иделбаева югаламы соң, аны югалтырга ярыймы соң,— дидем мин.— Яшәргә кирәк бит аңа, җырларга кирәк, Галиябануны уйнарга кирәк.

Артыкбикә сискәнеп китте. Җәһәт кенә миңа борылды:

— Безгә пәрдәне ачарга вакыт җитәдер бит?

Аңа җавап урынында, залдан пәрдә ачылуны күптән көткәнлекләрен белдереп, кул чаптылар.

— Хуш хәзергә, агаем, бар, син безнең уйнаганны карай тор, безгә башларга вакыт.

— Ерла, иркәм, ерла, мин һине тыңлаем,— диде Күчәрбай, әкрен генә атлап, сәхнәдән төшеп китте...

Сораулар һәм биремнәр

1. Яшьләр спектакль уйнарга ничек әзерләнәләр? Галиябану ролен башкарырга тиешле Зоя ни өчен шәһәр мещанкалары кебек киенә? Ул спектакльне ташлап чыгып китүе белән хаклымы?

2. Галиябану ролен Артыкбикә ничек башкара? Аның хисчичерешләре турында сөйләгез.

3. Күчәрбай белән Артыкбикәнең очрашулары, туганлык мөнәсәбәтләре ничек сурәтләнгән?

XXV

Без бөтен күңлебез белән Рабига җиңгә сөйләячәк сүзләрне тыңларга әзерләндек. Ул, безнең алдыбыздагы яртылаш бушаган кечкенә чынаякларны кыстап эчертеп бетереп, яңадан чәй ясады да сөйләргә тотынды:

— Безгә килгән вакытта күргәнсездер,— мәчет әргәсендә бик матур буяулы йорт бар. Ул — Йомагыл байның йорты. Артыкбикә әнә шул Йомагыл байда тора иде...

Гаяз хикәянең болай якыннан башлануы белән канәгатьләнмәде, Рабига җиңгәнең тирән сулыш белән башланган сүзен бүлдереп, сорау бирде:

— Рабига җиңгә,— диде ул,— син безгә баштанрак сөйлә инде: Артыкбикә үзе кем кызы соң ул?

Рабига җиңгә, нинди генә сорау бирсәң дә, җавап бирергә иренә торган кеше түгел иде. Гаяз сораганча, баштан ук сөйләп бирергә рәхәтләнеп риза булды:

— Мин сөйлим, тыңларга гына җобанмагыз[1].

— Юк, юк, җобанмыйбыз, рәхәтләнеп тыңлыйбыз сине, Рабига җиңгә.

Рабига җиңгә хикәясен яңадан башлады:

— Артыкбикәнең ата-әсәләре безнең кебек үк ярлы кешеләр иде. Гомер буйларына ачлы-туклы яшәделәр, бахырлар. Аларның сигез балалары бар иде. Андый ярлы кешегә сигез баланы карауның ничаклы кыен булганын үзегез дә беләсез. Шундый ярлы тормышта тугызынчы бала булып, шушы кыз туды, бахыр.

— Шуңа күрә аңа «Артыкбикә» дип исем кушканнарынмыни?— диде Гаяз.

Рабига җиңгә көлеп куйды:

— Шуңа күрә дисәк тә хата булмас,— диде ул.— Әйе, тугызынчы бала булу өстенә, кыз бала да булгач, атасы әйткән: «Был нәмә безгә артык булып китте инде»,— дигән. Әсәһе әйткән: «Алай булгас, без аңа «Артыкбикә» дип ат кушаек дигән, бердәнбер кызым булгач, мин аны бөтенесеннән артык күрәм»,— дигән. Атасы да көлгән. «Ярар, мәелең»,— дигән. Югыйсә безнең башкорт халкы андый «Артыкбикә», «Артыкгали» сыман исемнәрне тиктомалга гына кушмый; йә тәнендә берәр артык җире — орысы-мазары, миңе-мазары булган балага куша, йә икенчеләй, матурлыгы белән кешедән артык күренгән балага да кушалар...

Җиңгә бу урында тирән көрсенеп куйды. Кечкенә тукталу ясап, безне чәй эчәргә кыстап алды да сөйли башлаган сүзен дәвам иттерде:

— Авыр, нужалы елларда түзә алмыйча үлеп беттеләр бахыркайларым. Аналары атылган үрдәк бәбкәләре

[1] Җобанмагыз — иренмәгез.

кебек, шушы ике ятим торып калды. Берсе — менә — Күчәрбай. Бу егет, аягына чабата кия белә башлаган чагында ук татар авылына чыгып китеп, көтү көтте, кулдан кулга, байдан байга йөреп, ачлык елны исән чыкты. Аның иркәсе Артыкбикә бәләкәйдән үк бик сылу кыз иде. Бала, ятим калып, кулдан кулга йөри башлагач, Йомагыл байның хатыны, үзенең кыз баласы булмаганга ямансылап, аны үзләренә алды. Мин үз гомеремдә Йомагыл байларга бик күп эшләдем. Алар йортында нинди кортлар уйнавы миңа яшерен түгел иде. Артыкбикә тәү мәлдә ул йорт эчендә иркә булды. Тора-бара бахырның үгәйлеге өскә калыкты. Ора-суга башладылар. Олы малайларына бичә алгач, ятим кызның тормышы тагын да караңгылана бирде. Киленнәре шул сылу баланы күрә алмый, аны мыскыллый, «бер хәерсенең артык балаһын асрап ятарга нимәң етмәгән» дип, иренә сөйли, сылтау юктан сылтау чыгарып, Артыкбикәне тукмый иде. Ятсытылып, кыерсытылып яшәгән ятим бала ямансылаган саен миңа елыша: «Рабига енгәм, мин нигә болай артык бала булып дөньяга туганмын, нигә мине берәү дә яратмый, минем кай ерем яман, әйт, Рабига енгәм, нигә минем әсәем юк?» — дип, сулыгып-сулыгып елый торган иде. Мин аны башыннан сыйпап юатам: «Сабыр ит, иркәм, без беребез дә рәхәт күреп үсмәгән. Һин өлкән булган сакта тормыш болай яман булмас, Күсәрбай агаең үсеп ир булгас, һине үдөнә алыр, һин бәхетле буларһың»,— дип тынычландыра торган идем. Шул чакларда үземнең дә йөрәгем сыкрый, югалган балаларым исемә төшеп, күзләремә яшь килә иде. Шунда да мин чыдый идем. Артыкбикәне куркытмас өчен еламый идем...

Елый-елый, сыкрана-сыкрана, байтак заман узды. Артыкбикә үскән саен сылулана барды. Унөч яшенә чыкканда, Эргәзенбай авылының Шәнгәрәй бае Артыкбикәне телгә алган, имеш, дип хәбәр чыкты. Шәнгәрәйнең Йомагылга килгәләп, кунак булып киткәләвен белә идем. Бер килүендә Артыкбикәгә күзе төшеп, үзенең тол малаена бичә итеп алырга уйлаган, имеш, дип сөйли башладылар. Бу хәбәрдән соң Йомагыл үзе дә, аның бичәсе дә Артыкбикәгә ата-әсә күзе белән караган сыман күренә башлады. Хәтта Йомагыл: «Үд кыдым күек карап үстердем, яхшы ердән яусы килһә, үд кыдым күек туй итеп бирүде дә бурысым һанаем»,— дип

әйткән, имеш, дип ишеттерделәр. Ил хәбәре ялганга чыкмый. Чынлап та, көзгә авышкан көннәрнең берендә Йомагылларга, читән арбага утырып, Эргәзенбай авылыннан бер карт башкорт килеп төште. Яшел читек эченнән сыңар балагын чыгарып куйган булгач, мин моның башкода икәнлеген сизеп алдым. Бу хәлне күреп, күңелем кузгалды, Йомагылның Шәнгәрәй белән кода булырга дәрте зур икәнлеген төшенә идем инде. Тик Артыкбикәне шул Шәнгәрәйләр йортына җибәрергә бер дә күңелем тартмый иде. Инде бер бичә аерган Әлимгулның яман кеше булуы турында ишеткәнем бар иде. Күңелемнең кузгалуы бер дә юкка булмаган, күрәсең, шул көнне билгеле булды: яучы Шәнгәрәй малаеннан килгән, Йомагыл, Артыкбикәнең атасы булып, биш йөз сум акча, дүрт баш эре мал, күлмәкләр, итекләр, инә туны, урын-җир мәһәренә сатарга ризалыгын биреп җибәргән.

Бу хәбәрне алу белән, коты чыккан Артыкбикә минем яныма йөгереп килде дә сулыгып-сулыгып елый башлады. «Рабига енгәм, мине нишләттеләр, кемгә һаттылар, мин бер намә лә белмәем. Куркам мин, Рабига енгәм, нишләем? Әсәем бул, Рабига енгәм, һөйлә миңа, мине нишләтәләр?» — дип өзелә бахыркай. Сөлек кебек зифа булып буйга үсеп килгән кыз бала бик яшь иде әле. Шундый ялләдем бахырны, кочагыма кысып, әнкәсе төсле чәчләреннән сыйпадым: «Курыкма, иркәм. Үдеңнең күңелең теләмәһә, һине бер намә лә эшләтә алмастар...» — дидем. Артыкбикә, минем әйтеп бетергәнемне дә көтмичә, үзенең кияүгә барырга теләмәгәнлеген сөйли башлады: «Енгәм, коткар һин мине. Минем кияүгә бараһым килмәй. Минем был илдән китәһем килә. Анау камсамул һөйләгән күек, укырга китәһем килә...» — ди.

Бу урында без Гаяз белән икебез бер авыздан Рабига җиңгәнең хикәясен бүлдердек:

— Тукта, Рабига җиңгә, нинди комсомол сөйләгән сүзне әйтте ул?

— Әй, аныһын әйтергә онытканмын икән,— диде Рабига җиңгә, яңадан артка кайтып, авылга комсомолецлар килеп китү вакыйгасын сөйләп бирде.— Шул елны безнең авылга волостьтан камсамуллар килеп, уен күрсәтеп киткәннәр иде. Бөтен авылыбыз белән җыелып карадык — зерә дә кызык булды инде шуларның уен-

нары. Шунда бер сылу гына егет, вәгазь сөйләп, яшьләрне камсамулга керергә, укырга барырга димләгән иде. Шуннан соң Артыкбикәнең күңеле талпына калды лабаса, әледән-әле миңа килә дә сукрана: «Рабига енгәм, мин был илдән китәр идем, анау камсамул һөйләгәнсә, калага барып укырга инәр инем»,— ди.

— Үз авылыгызда бер комсомолец та булмадымыни? — дип сорау куйды Гаяз.

— Булмады шул. Бер мөгаллимәбез бар иде барлыгын, спай гына татар кызы иде, укытып йөргән булды шунда. Болай яшьләр белән сөйләшергә бик яратмады, ахрысы, әледән-әле әллә кая китеп югала, берәр атна, унар көн йөреп кайта иде. Шунда да Артыкбикә шул мөгаллимәдән язу танырга өйрәнеп калды, бәләкәй чагыннан ук укырга һәвәс иде... Әй, сүземне бүлдердегез, ничек дип туктаган идем әле?

Без тагын Гаяз белән икебез бер авыздан аңа эзгә төшәргә ярдәм иттек:

— Артыкбикә сиңа килеп елаган иде, кияүгә барасым килми, анау камсамул сөйләгәнчә...

— Ә-ә,— диде Рабига җиңгә, безгә әйтеп бетәргә дә ирек бирмичә ялгап алып китте:— Әнә шул сүзен кияүгә биргәч тә исемә төшерде: «Минем бер дә кияүгә бараһым килмәй. Минем был илдән китәһем килә. Анау камсамул һөйләгән күек, укырга китәһем килә»,—ди бахырым, сызланып-сызланып елый. Үземнең дә җибәрәсем килми тора иде, кызның да күңелендә булмагач, мин аңа үз киңәшемне бирдем: син бер дә курыкма, Артыкбикә, батыр бул. Тау бөркете кебек кыю бул. Кыю булсаң, теләгән җиреңә китә алырсың, димен. Әгәр дә минем сүземнән чыкмасаң, теләгеңә ирешерсең, дидем. «Ни кушсаң да һүдеңнән сыкмаем, енгәм»,— ди бахыр. Шуннан соң мин аңа эндәшмичә генә барына да риза булып йөрергә куштым. Туйны да ясасыннар, кияү дә килсен, кияү куйнына керәсе көнне бары да син дигәнчә барып чыгар. Тик батыр булсаң гына, курыкмас булсаң гына. «Бер нәмәнән дә курыкмыйм»,— ди.

Шуннан башлап, ярәшелгән кыз булып китте: күрше-тирә кызлары белән җыелалар да сыңлайлар[1], җыелалар да сыңлайлар. Артыкбикә өйгә дә кайтып төшми... Безнең башкортның йоласы шулай инде. Кияүгә

[1] Сыңлайлар — елашалар.

ярәшелгән кыз кияү янына кергәнгә тиклем өйгә төшми, ахирәт кызлары белән елашып тик йөри. Ата-баба йоласы дип, кызның елавын искә дә алмыйлар.

Менә берзаман шаулап туй көне килеп җитте. Мичкә-мичкә баллар төяп, ту бияләр тагып, тугыз арба белән кодалар килеп төште. Безнең бәләкәй генә авыл бөтенләй тулып китте. Кодаларга тагылып килгән симез бияләрнең берсен, сөлге белән тотып алып, Йомагылның йорт уртасына егып суйдылар. Без, туй ашын кичкә өлгертергә дип, биянең итен, эчәкләрен, карталарын, карыннарын тизрәк бүлгәләп алдык. Кодалар туйга катнашучы күрше-күләнгә таралышып беттеләр. Төп йортта төп кода — Шәнгәрәй карт үзе генә калды. Ишегалдында малайлар, кызлар кичкә тиклем котырып чыктылар. Уйнамаган уеннары, җырламаган җырлары калмады. Кич булды. Күрше-тирәгә таралышкан кодалар Йомагыл йортына җыелдылар. Алып килгән баллар эчелә, пешерелгән ашлар ашала башлады. Һай-һуй кирәкме, җыр кирәкме, бию кирәкме — берсе дә калмады инде. Йомагылның урта малае белән кинҗә[1] малае кияүне каршы алырга киттеләр. Караңгы булып беткәч, атка атланып, кияү килеп төште. Капка төбеннән үк үзен малайлар туктатып, ишек бавы сорый башладылар. Әлимгул ул чакта ук хәзергедәй зур гәүдәле ир иде инде. Бер бичә аерып, яман аты чыккан булса да, кияү булып килгәч, ягымлы күренергә тырышты, күрәсең, елмаеп кына торды. Малайларга акчалар биреп, йортка кергәч, аны каршы як өйгә алып кереп ашата-эчертә башладылар. Бу вакытта Артыкбикә яшеренгән иде инде.

Сез беләсезме, безнең башкорт халкында ата-бабадан калган йола бар: кияү килгән вакытта кызлар качалар, аларны, бик озак эзләгәннән соң гына табып, кияү кулына тоттыралар. Качмаган кыз әдәпсез кыз санала. Шуңа күрә дә Артыкбикәнең яшеренгән булуы башта берәүне дә гаҗәпләндермәде. Кияү килү белән, без, өчдүрт җиңгә, кызны эзләргә чыгып киттек. Эзлибез, эзлибез, табып булмый да булмый. Өй саен кереп йөрдек, бер җирдән дә табып булмый. Аптырагач, кияүгә барып әйттек: «Кияү, дидек, эдләнек, эдләнек, инмәгән йорт калмады, менмәгән лапас башы калманы, карамаган

---

[1] К и н җ ә — кече, төпчек бала.

мунча калманы, кызды таба алмыйбыд. Әйдә үдең дә эдләшсе»,— дидек. Кияү моңа бер дә гаҗәпләнмәде. Ни өчен дисәгез, һәрбер туйда шулай, кияүдән бүләк алмыйча, кыз табылмый инде ул. Безнең кияү дә бүләк бирде: «Енгәләр, кызды тидрәк табыгыд, менә һедгә миннән бүләк»,— дип, безгә тәңкәләр өләште. Без, аның үзен дә ияртеп, тагын авыл буенча эзли башладык. Кыз бер җирдән дә табылмагач, кияү безгә тагын бүләк бирде:

— Бигрәк одакка һуздыгыд, енгәләр, бүләктә эш калмас, мәгед, тидрәк табыгыд,— дип, безгә тагын тәңкәләр өләште. Алай да табылмагач, кияү кесәсеннән җепкә тезелгән сумлык тәңкәләр чыгарды: «Табып биргән енгәгә менә ошы бүләкте бирәм»,— диде. «Табабыд, табабыд»,— диештеләр енгәләр.

Авылыбызның түбән очындагы иң читтәге йортның лапас астында кызлар шаулашканы ишетелә башлады. Без — кыз эзләүче җиңгәләр: «Таптык-таптык!» — дип кычкыра-кычкыра, кияү белән бергәләп, шул якка таба йөгерештек. Без килүгә, лапас астында тавыш басылды, барысы да шым булдылар. Лапас астына кертеп салган абзар ишеген тарттык. Ишек эчтән бикле булып чыкты:

— Кем бар анда, тавыш бирегед?— дип сорадык.

— Берәү дә юк,— дип җавап бирделәр.

Йомагылның килене ачулы тавыш белән Артыкбикәне куркытырга теләде:

— Артыкбикә, сык, би атаем әйтә, бик одак карышһа, көрәк ярылгансы тукмарым, ди.

Ишекне ачтылар. Без, фонарьлар тотып, абзарга кердек. Кыз чыгып йөгермәсен дип, кияү ишек төбендә торды. Абзар эчендә унлап кыз бар, тик Артыкбикә алар арасында юк иде.

— Артыкбикәне кая яшердегед?

— Эзләгед, езнәбед яхшылабрак эзләһен, эзләнкерәп алһа, кыз кадерлерәк булыр.

Абзар эчендә тагын бер кечкенә ишек барлыгы беленде. Ул ишекне ачып кердек. Анда да бер бозаудан башка җан иясе булмады. Тагын берәр ишек юк микән дип эзләнә торгач, кеше сыярлык читән тишеге таптык:

— Шуннан сыгып каскан икән, төлке,— диде бер енгә.— Каян гына табарбыд инде, Илаһым!

Йомагыл килене чын-чынлап авызын бүлтәйтте:

— Бигрәк тә килешмәгәнне кылына, суска, үзенә күрә түгел күрәһең, хәерсе...

Төн буе эзләсәк тә, Артыкбикә табылмады. Кияү зур-зур бүләкләр биреп карады. Йомагыл, ачуланып, кыз җиңгәләре аркылы кызга ишеттерергә кушып, каты-каты сүзләр әйтеп карады — берсенең дә файдасы булмады. Әлимгулның мыегы кабарды, йөзе кара янды. Кодалар да шактый күңелсезләнделәр. Шунда да бөтенләй үк өметләрен өзмәделәр әле. «Бүген табылмаса, иртәгә табылыр — яшьрәк кыз шул, куркып, ныграк качкандыр»,— дип тынычландылар. Бер яктан караганда, кызның тиз генә табылмавы аның дәрәҗәсен дә күтәрде. Безнең башкорт халкында була торган йола ул. Беренче көнне табылмыйча, кияүне ялгыз кундырулар да гаеп саналмый. Бүген дә шулай булыр дип уйладылар. Кияү һаман бүләкләрне кызганмады. Җиңгәләр белән аерым-аерым сөйләшеп карады. Тик җиңгәләр арасында, нindидер шомлы хәл барын сизенеп, борчылу башланган иде инде. Ул борчылулар юкка гына булмады. Артыкбикә икенче көнне дә табылмады. Аның кайда икәнен белүче дә булмады. Кодалар күңелсезләнеп таралдылар. Шәнгәрәй карт үзенең улы белән Йомагылга бик нык ачуланып кайтып китте. Йомагыл карт бөтен өй эчен туздырып шаулады-шаулады да үзенә үзе акыл биреп куйды:

— Бабайдар бик белеп әйткәннәр шул: ятим бодау асраһаң, авыдың-борының май булыр, ятим бала асраһаң, авыдың-борының кан булыр,— диде.

Өч көн уткәч, Кинҗә астындагы таллы яр кырыеннан Артыкбикәнең яулыгы белән башмакларын табып кайттылар. Шуннан башлап, Артыкбикә суга баткан дигән хәбәр таралды. Кыз бала безнең авыл өчен юкка чыкты. Тик аның дөньяда барлыгы, ни өчен югалуы, яулык белән башмакның, минем киңәш буенча, эз югалту өчен генә яр буена ташлап калдырылган булулары бер миңа гына ачык иде...

1935 ел

Сораулар һәм биремнәр

1. Артыкбикәнең серлелек пәрдәсенә төрелеп сурәтләнүе нинди картиналарда күренә? Аның язмышы, тормыш юлы ничек тасвирлана?

2. Артыкбикә образына характеристика бирегез.

«АГЫЙДЕЛ» ПОВЕСТЕ ТУРЫНДА

«Агыйдел» повестенда 1927 елда Башкортстан авылларында барган вакыйгалар тасвирлана. Әсәрнең үзәгендә җәйге каникулга кайткан студент яшьләр образы, яшьлеккә хас мөнәсәбәтләр, тойгы, кичерешләр сурәтләнгән. Бу хисләр әсәргә лирик аһәң бирәләр. Әсәрнең геройлары Ильяс та, Гаяз да сылу, ягымлы Артыкбикәне якын күрәләр, күңелләрендә аңа карата җылы хисләр саклыйлар. Артыкбикә дә боларга, бигрәк тә Гаязга, битараф, тыныч кына карый алмый, Гаяз дулкынландыра аны.

Әдип бу студентларны иҗтимагый актив итеп сурәтли. Тешсез Ибрай, Имәли, Күчәрбай кебек крестьяннарда, ялчыларда үз хәлләреннән ризасызлык, рәтлерәк тормышка чыгарга омтылу сизелә. Гаяз белән Ильяс әлеге омтылышка юнәлеш бирәләр, авылдашларын укырга-язарга өйрәтәләр, күзләрен ачалар, хокукларын, хөкүмәтнең тоткан юлын төшендерәләр. Алар авыл халкы алдында кыюлыклары, тынгысызлыклары, белемле булулары белән абруй казаналар, киеренке көрәштән ләззәт, рәхәтлек табалар, хезмәт ияләрен бәхетле тормышка таба алып баруларына керсез күңелләре белән ихлас ышаналар.

Әсәрдә шул дәвердә әдәбият, сәнгатькә, бөтен җәмгыятькә көчләп тагылган чор карашы, идеология дә чагылмый калмаган, әлбәттә. Әйтик, хәлле, таза тормышлы кешеләргә, сәүдәгәрләргә, дингә бер яклы мөнәсәбәт әнә шул хакта сөйли. Әмма автор авыл хуҗалыгын мәҗбүри, тоташ күмәкләштерү турында сүз алып бармый, бәлки теләк белдергән егерме дүрт гаилә хуҗалыгын артельгә берләштерү хакында яза.

Әсәрдә Артыкбикә образы бик сөйкемле итеп, серлелек пәрдәсенә төреп бирелә. Ул язмышын үз кулына ала, үз ихтыярына буйсындыра. Әсәрдә аның батырлыгы, киң тормыш юлына килеп чыкканлыгы сурәтләнә. Биредә, гомумән, кешеләрнең үзләрен ирекле, азат тоюлары, шуңа омтылулары бик җитди тасвирлана. Әдип уңай геройларда эчке-тышкы гүзәллек белән эш-гамәлнең ярашуын, көрәш дәртен чагылдыра.

Автор табигать күренешләрен, бигрәк тә Агыйделне, кеше рухына, яшьлеккә тиңләп сурәтли. Аны җанландырып тасвирлый, кешенең төрле халәте белән чагыштыра, җылы, якты төсләр белән хикәяли. Агыйдел, Дим, Ашказарларның халык күңеленә, җырларга үтеп кергәнлеген күрсәтә. Әсәрне хикәяләүче Ильяс табигать матурлыгын үз байлыгы, шәхси байлыкның бик мөһим бер өлеше итеп тоя.

Сибгат Хәким
(1911—1986)

Язмыш гүя үзе саклап бара,
Алып чыга аны Дугадан —
Халкым аны, газиз улы күреп,
Изге дога белән ураган.

Җирне барлап атлый акрын гына,
Чишмәләрне арчый, тукталып.
Күңелләре саекмасын диеп,
Кешеләргә бара, моң алып.

Ш. Маннапов

С. Хәкимнең язганнары беренче карашка бик гади кебек. Чөнки ул әллә нинди катлаулы җөмләләр, купшы сүзләр кулланмый. Аның әсәрләре шагыйрьнең үзе кебек гади, тыйнак.

Язар өчен илһам эзлә, диләр,
Урын эзлә, диләр, ямьлерәк.
Никтер минем шигъри хисләремә
Арышларның исе тәмлерәк!

Бу шигъри юлларда аның барлык әсәрләренә уртак булган хасиятне — гади генә итеп олы фикерләр, тирән хисләр белдерә алуын күрергә мөмкин. Чын шигърият нәкъ менә шулай гына була ала. Ул үзе болай дип язган иде: «Күңел туктаусыз эзләнә. Нәрсә җитми аңа, белмим. Үз-үзеннән канәгатьсезлек, шагыйрьне шул йөртәдер, мөгаен. Сугышны күрдем, тәмам арып, авырып кайттым. Бераз хәл керде, яңадан шул урыннарга сөйрәде җан. Нәрсә калган, нәрсәне әйтеп бетермәгәнмен — әйтеп бетерәсе иде. Туган якка күпме кайттым икән мин үз гомеремдә? Кешеләр бер кунак булып килү дип кенә уйлыйлар. Ә мине кайтып-кайтып та сөйләп бетереп булмаган изге хис газаплый. Шигырь дә, җыр да язып карыйм, юк, ул хис тирәндә, ә җир үзе гап-гади, кешеләре гади, яшәешләре гади. Шагыйрь

күңеле җирдәге изгелекне җырларга тиеш. Син тота алмаган хистән дә авыррак нәрсә юк дөньяда».

С. Хәким иҗаты турында уйланып, шагыйрь Наҗар Нәҗми дә мондый фикер әйтә: «Иҗади югарылыклар каян килә соң? Серләре нәрсәдә? Беренче сер — шагыйрьнең табигатеннән, аның тумышыннан, дияр идем. С. Хәким шигърияткә «мин дә шагыйрь булам әле» дип килгән шагыйрь түгел, миңа калса, аның күп әсәрләре шагыйрьнең үзеннән алда туган шикелле, ягъни ул шигырьләр, укучыга ирешер өчен, аның дөньяга килүен көтеп торганнар да шагыйрь йөрәге аша үтәсе генә калган кебек. Бөтен сер дә, бәлки, шушы үтүдәдер, чөнки С. Хәкимнең бөтен барлыгы — җаны, акылы, күз карашлары, сөйләшүләре, атлап йөрүләре, елмаюы — туган җиренә, басуларына, юл-сукмакларына, тауларына, урманнарына, чишмәләренә, шул җирдә яшәгән кешеләр күңеленә килеп кушылып, бербөтенгә әйләнә».

Әйе, менә болай дип бары тик С. Хәким генә әйтә ала иде:

Бөтенләем белән җирнекемен,
Минем барлык нәсел-нәсәбем —
Игенчеләр. Җирдән төртеп чыга
Һәрбер юлым, һәрбер әсәрем.

Нәкъ менә шулай әйтергә С. Хәкимнең тулы нигезе дә бар. Аның ерак бабаларыннан берсе Мәмкә исемле булган (бу — кушамат булырга тиеш). Патша хакимияте заманында берничә елга бер җир бүлү уздырылган. Гаделлеге өчен Мәмкә картны җир бүлүче, межа яручы итеп куя торган булганнар. Шагыйрьнең әтисе Таҗи абзый исә балта эшенә бик оста булган. Әнисен «туры Газзә» дип йөрткәннәр, чөнки үз уен, карашларын турыдан-туры әйтеп бирергә яраткан, гаделсезлекләргә түзеп тормаган. С. Хәким үзен аларның эш-гамәлләрен дәвам иттерүче итеп сизә. Шул рәвешле, туып үскән Күлле Киме авылына (Әтнә районы), нәсел-нәсәбенә булган ярату хисе, үсә-зурая барып, тулаем Татарстанны, бөтен дөньяга сибелеп яшәүче татар халкын, кешелекне якын күрү дәрәҗәсенә кадәр киңәя.

С. Хәким ихлас күңелдән халыклар дуслыгын хуплый, зурлый. Аның мәхәббәте бигрәк тә күрше мари халкына юнәлгән. «Мари ягы — урманлы як. Анда яңгыр күбрәк ява. 1921 елгы ачлыкта без шул мари авылларына сыендык. Шактый бәрәңге ташыдык без ул яктан.

Ачлык еллар... Өйдә ашарга бернәрсә юк. Әти марига йорт эшли. Балта осталары, көнгә кимендә ике тапкыр ашау хуҗадан дип, алдан ук сөйләшеп куялар. Ул вакытта тамак ялына

эшләтсәләр дә бик рәхмәт инде. Әти ара-тирә үзе белән мине дә алып баргалый. Алар эшли, мин йомычкалар арасында уйнап утырам. Алар көндезге чәйгә керә, мин ишегалдында калам. Андый кытлык елны һәр телем исәптә. Шуңа күрәдер инде әти чәй янына чакырырга кыймаган, ә хуҗалар, бәлки, онытканнардыр, бәлки...

Әмма әти тышта малае барын онытмаган. Онытса, ул миңа тәбикмәк алып чыгып бирмәс иде. Их, ул кайнар арыш тәбикмәге, ансат кына килеп кермәгән икән минем кулга. Әти чәй эчкәндә йорт хуҗасы читкә киткән арада яңа табадан төшкән кайнар тәбикмәкне такыр башына каплый да өстеннән тиз генә иске бүреген кия һәм минем янга йөгерә. Ул вакытта әти түзә, сиздерми. Әмма эштән бушап, балта осталары үзләре генә бергә җыелгач, ачлыкның бөтен газабын тоеп, шушы хәлгә төшүеннән гарьләнеп, кимсенеп елый».

Баласын саклап кала алса да, әтисе шул ачлык елында вафат була.

Боларның һәммәсе шагыйрьнең тормышны, сизгер тоеп, бөтен катлаулылыгы белән белүен, шулар нигезендә хисләренең дә бай һәм тәэсирле булуын тәэмин итә.

С. Хәким, барыннан да элек, лирик шагыйрь. Аның шигырьләрендә табигый моң ага, укучы аларны йөрәгенә якын алганын сизми дә кала. Композитор Рөстәм Яхин С. Хәким шигырьләре турында: «Аның шигырьләре лиризм белән шулкадәр сугарылганнар, алар үзләреннән-үзләре көйгә салуны сорап торалар»,— ди. «Таң атканда», «Чын йөрәктән», «Фазыл чишмәсе», «Юксыну», «Башка берни дә кирәкми», «Кем уйлаган» һәм С. Хәким шигырьләренә җырлана торган уннарча җырлар — моның ачык дәлиле.

С. Хәким — олы тормыш юлы үткән шәхес. Туган авылында җиде сыйныф тәмамлый, мәктәптә пионервожатый булып эшли. Казанда рабфакта укый. Аннан соң Казан педагогия институтының татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлый. Китап нәшриятында редактор, «Совет әдәбияты» («Казан утлары») журналында әдәби хезмәткәр булып эшли. Сугышның беренче аенда ук армиягә алына. Взвод, рота командиры була. Курск дугасындагы гаять каты бәрелеш уртасында сугыша. Батырлыгы өчен Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләнә. Сугыштан соң да ул халык язмышын кайгыртып яши, тормышның үзәгендә булырга тырыша. Мондый кешегә, күргән-белгәннәрен, кичергәннәрен язу өчен, бер гомер генә җитмидер, әлбәттә.

С. Хәким дә, бик күпләр шикелле, иҗатын төгәлли алмады. Әмма язылган кадәре дә аны күренекле шагыйрь итеп танытты. Ул Татарстанның халык шагыйре исеменә лаек булды.

Сораулар һәм биремнәр

1. С. Хәкимнең тормыш юлын искә төшерегез.

2. С. Хәким үзенең бабасыннан һәм әнисеннән нинди сыйфатларны кабул итеп алган? Сез үзегезнең шәҗәрәгезне беләсезме? Өйдә өлкәннәр белән бергәләп нәселегезне ачыкларга тырышыгыз.

3. Шагыйрь ни өчен «шигъри хисләремә арышларның исе тәмлерәк» ди?

4. 1921 елгы ачлык алар гаиләсенә ничек килеп кагыла? Ата кешенең баласына мәхәббәтен тасвирлап күрсәтегез.

5. С. Хәким иҗатының үзенчәлекле яклары нәрсәдә дип уйлыйсыз?

6. С. Хәким иҗаты турында күренекле кешеләрнең фикерләрен искә төшерегез.

7. «Халкы аны изге дога белән ураган» дигәндә, шагыйрь Шамил Маннапов нәрсәләрне күздә тота?

8. Сез С. Хәким сүзләренә җырлана торган нинди җырларны беләсез? Шуларны сыйныфта бергәләп тыңлауны оештырыгыз. Шигырь һәм көйнең тәңгәллеге, аваздашлыгы, яңгырашы турында фикерләрегезне әйтегез.

ЮКСЫНУ

Күз карашым нинди уйчанланды,
Син беләсең микән, юк микән?
Син киләсе юлдан күзем алмый
Сине көтәм, иркәм, кич-иртән.

Яратам мин, әйтмим генә аны,
Син йөрәкне минем белмисең;
Кошлар кайта безгә, син һаман юк,
Син һаман юк, никтер килмисең.

Сагынуымны төннәр утырып язган
Хатлар гына басар дисеңме?
Юк, басалмый, сөйгән җырларыма
Сыйдыра алмыйм хәзер хисемне.

Син укыган мәктәп буйларыннан
Моңсу гына карап үтәм мин;
Иптәшләрең белән шау-гөр килеп
Күренерсең дип өмет итәм мин.

Көзге яңгыр ява, таш урамда
Басып торам чатта шыкланып;
Берәр җирдән менә кинәт кенә
Син чыгарсың кебек шатланып.

Бәйрәм көннәрендә күзем алмыйм
Поход колоннасы өстеннән,
Күпме кеше агыла, ничек тә мин
Таныр идем, булсаң, төсеңнән.

Бакчабызда шомырт агачлары
Җәй буена сине көттеләр;
Син килмәдең, көзге җилләр инде
Яфракларны җиргә сиптеләр.

Бу вакытлы гына юксынуым,
Дусларымның исе китмәсен;
Тик ярата белгән кеше генә
Сагына шулай үзенең иркәсен.

1938 ел

Шигырьдә сүз бик гади нәрсәләр турында гына бара кебек — юксыну, сагыш, сагыну. Сагыну кешене борчылдыра, халык җырында әйтелгәнчә, «сарыларга сабыштыра». Шуның шикелле ярату дигән төшенчә дә бар. Юк, ул — төшенчә генә түгел, бәлки бик тирән хис, кичереш. Ярату төрле-төрле булырга мөмкин. Ата-анаңны, әби-бабаңны, туганнарыңны, дусларыңны һ. б. ярату. Туган илеңне, халкыңны, аның телен, моңын сөю дә шуңа керә. Болардан тыш, кеше тагын берәүне генә аеруча өзелеп яратырга мөмкин. Егет кешенең бик күп кызлар арасыннан берсен аерып сөя башлавы, шулай ук кызның берәр егеткә карата күңелендә җылы хисләр уянуы — табигый нәрсә. Бу хисләрнең тора-бара мәхәббәткә әверелүе мөмкин. «Юксыну» шигырендәге лирик герой да кемнедер ярата. Күңеле әлеге якын кешесен эзли, юксына.

Ярату булмаса, сагыну да булмас иде. Чөнки кемгә дә булса артык исең китмәсә, ягъни аңа битараф булсаң, ул кешене сагынмыйсың да бит. Ярату белән сагыну — бер үк халәтнең ике төрле чагылышы: яратканга сагына, сагынганга ярата. Ә яраткан кеше күңеле белән дә матур була. Андый зат башкаларны да аңлый, аларның хисләреннән көлми, тупаслыклар

кылмый. Сез әлеге әсәрдәге лирик геройның теленә генә игътибар итегез. Ул нинди нәфис, матур! Яраткан кешесен ул «иркәм» дип атый.

Лирик герой уйчан. Ник дигәндә, сөйгән кешесе каядыр югалган, күренми башлаган. Ул аны сагына, һәр җирдә сөеклесе килеп чыкмасмы дип көтә. Төн утырып, хатлар да язып карый, юк, күңеле басылмый, сагышы артканнан-арта гына бара. Дүртенче строфадан күренгәнчә, аның сөеклесе әле укый икән, аны очратмаммы дип өметләнеп, мәктәп тирәсендә йөрүе шул турыда сөйли. Көзге яңгырда ул, күрергә өмет итеп, урамда йөри. Җәй буе өзелеп көтсә дә, алар күрешә алмаганнар. Ихтимал, бу кыз яки егет җәйге ялга гына киткән булгандыр, чөнки лирик герой юксынуының вакытлы гына булуын әйтә. Яратмаган кеше сагына алмый, шигырьдән шушы төп фикер аңлашыла. Г. Кутуй да «сине сагынган саен, миндә көч-дәрт арта, рухым канатлана» дигән иде («Сагыну» нәсере). Бу очракта Г. Кутуй илне сагыну турында сүз алып бара. Бөек Ватан сугышы елларында композитор Шакир Мәҗитов «Юксыну» шигыренә бик матур көй яза, аны фронттагылар да, тылдагылар да яратып җырлыйлар. Андагы хис барысы өчен дә кадерле, якын була. Шулай да С. Хәкимгә сугыш вакытында бу җырны ишетергә туры килми. Сугышның иң хәтәр җирләреннән исәнимин кайткан шагыйрьгә аны танылган җырчы Зифа Басыйрова җырлап күрсәтә. Кешеләрнеке кебек үк, әдәбият-сәнгать әсәренең дә кызыклы тарихы була икән. «Юксыну»— моның ачык мисалы.

Сораулар һәм биремнәр

1. Нинди әсәрне без лирик шигырь дибез?
2. Кем ул лирик герой?
3. Шагыйрьнең холкы, эчке дөньясы белән аның әсәрләренең рухы арасында уртак сыйфатлар буламы?
4. Кешенең кәефе, рухи халәтенең тышкы һәм эчке сәбәпләр белән билгеләнүен шушы әсәр мисалында аңлатып буламы?
5. Ярату белән юксыну хисләре каршылыкмы әллә бер үк хиснең ике төрле чагылышымы?
6. Аерылышу сагышы көчле булмаса, очрашу шатлыгы да зур булмас иде дигән фикерне аңлатып бирегез. Шушы җөмләне кире мәгънә аңлашылырлык итеп төзегез.
7. «Көй — шигырьнең канаты»,— диләр. «Юксыну» әсәре мисалында моны күреп буламы? Тагын кайсы әсәрләргә карата шулай әйтергә мөмкин?

ӘНКӘЙ

Кая барсам, кайда йөрсәм дә мин,
Күңелемә шулай тоела:
Пар кулыңа пар чиләгең асып,
Син чыгасың, әнкәй, коега.

Су алганчы юлга бер карыйсың,
Чиләкләрең тулгач, тагын бер.
«Бала күңеле далада»,— дип, бәлки,
Үпкәләп тә йөргән чагыңдыр.

Изге теләк теләп үстердең син,
Бассыннар дип тизрәк аякка.
Шул сүзләрең синең искә төшә,
Юнәлсәм дә менә кай якка.

Кое янында син ишетерсең
Миннән сиңа хәбәр килгәнен,
Син һәркемгә очрыйсыңдыр, әнкәй,
Мөлдерәмә килеш чиләгең.

1954 ел

Әни — җирдә иң газиз, якын кеше. Чөнки ул сине тудырган, күкрәк сөтен имезгән, җыр көйләп бишектә тирбәткән, беренче елмаюыңны күреп куанган, туган телне өйрәткән, халык моңын күңелеңә сеңдергән... Әниләрнең сиңа кылган изгелеген санап бетерү мөмкинме соң?

Кешегә гомере буена әти-әнисе кирәк. Аларның кайгыртучан карашы, җылы сүзләре, акыллы киңәшләре җанга рәхәтлек бирә. С. Хәким дә әти-әнисенә гомере буе рәхмәтле булып яшәгән. Мәсәлән, аның әнисенә багышланган шигырьләре генә дә уннан артык. Аларда күпме ихласлылык, рәхмәт хисе! Менә шундыйларның берсе.

КЛИНДЕРЛӘР ЭЗЛИМ

Нәрсә салыйм икән әнкәйгә мин —
Аны, димен, чиксез сөендергән?
Хат ахырында гына әйтеп куя:
Онытa күрмә, улым, клиндерләр...

Картайды нык, тешләре дә төшкән,
Колакка да хәзер ул саграк...
Нигә инде шунда сорамаска
Берәр тәмле нәрсә, йомшаграк?

Кешеләрдән миңа бик уңайсыз:
Сине баккан ич ул, киендергән.
Зурдан кубып, имеш, күчтәнәчкә
Клиндерләр җибәр, клиндерләр?!

Ерактан ук барыбер күреп торам
Клиндерне чәйдә җебеткәнен.
Уйлыймы ул: арыш, бодай үскән
Басуларда озын юл үткәнен?

Бу дөньяда бары мин генә шул,
Мин генә шул аның көен белгән.
Буранмы ул, яңгырмы ул тышта —
Клиндерләр эзлим, клиндерләр...

1960 ел

Күргәнебезчә, лирик герой, әнисенә күчтәнәчкә җибәрү өчен, кибеттән кибеткә клиндерләр эзләп йөри. Тешләре төшеп беткән әнисенә йомшаграк әйбер җибәрергә кирәк тә бит (әлбәттә, андыйларын да алгандыр), әмма әнисе клиндер сораган. Чәйдә җебетеп ашаса да, аңа шәһәрнең шул ризыгы тансык. Шагыйрь әнисенең теләген үти.

«Әнкәй» шигырендә исә лирик герой әнисен коега суга чыккан вакытында сурәтли. Кое татар халык авыз иҗатында да, язма әдәбиятта да еш искә алына. Кол Гали «Кыйссаи Йосыф» әсәрендә коены тасвирлауга бер бүлек багышлый. Гадәт-йолаларыбызга да кое тыгыз бәйләнгән. Күп кенә авылларыбызда коеларны, сәнгать әсәре кебек итеп, бизәп, нәкышләп ясыйлар. С. Хәким дә әни образына бәйле рәвештә кое җисемен әсәрләренә табигый кертеп җибәрә.

«Әнкәй» шигыренә килгәндә, биредә кое образы, «Юксыну» әсәре кебек үк, сагыш, моң белән өртелгән. Баласын өзелеп сагынган ананың, кое янына чыккач, юлга күз ташлавы бик таныш, үтә табигый. Читтә баласы булган ана шул юлга карамый булдыра алмый: белмәссең, улы яки кызы кайтып киләдер. Бәлки, әле ул, су кирәк булмаса да, шул юлга күз төшерү өчен генә дип чыккандыр бу коега. Х. Туфан әйтмешли:

Юлларда күзе аның...
Ә юлда җилләр исә,
Иртәләр җитте исә.

С. Хәкимнең бу шигырен укыганда, Кол Гали сурәтләгән ана күз алдына килә. Коллыктан котылып кайтучы Бәшир дә картаеп беткән әнисе белән су янында очраша.

Кое яны, гадәттә, кешесез тормый. Аннан күрше-тирә су ала, юлаучылар да аның янында тукталмый узмыйлар. Шунда төрле хәбәрләр дә ишетергә мөмкин. Менә ни өчен анага баласы турындагы хәбәрнең кое янында ирешүе бик ихтимал. Шагыйрь моны бик уңышлы әйтеп биргән.

Буш чиләкләр белән очрасаң, имеш, сәфәрченең юлы уңмый дигән бер ышану бар. С. Хәким исә ананың кешеләргә мөлдерәмә сулы чиләкләр белән очравына шикләнми. Чөнки ананың күңеле гел яхшылыкта. Ул очрагач, кешеләрнең юлы уңмау мөмкин түгел. Күргәнебезчә, кечкенә генә шигырь дә укучыга күп нәрсәләр сөйләргә, аны яңа хисләр белән баетырга мөмкин икән.

Сораулар һәм биремнәр

1. Һ. Такташ: «Ана — бөек исем»,— дигән. С. Хәким шигыренә нигезләнеп, тормышта күргәннәрегезгә таянып, шушы темага сөйләшеп алыгыз.

2. С. Хәкимнең әнисенә булган мөнәсәбәтен сурәтләп бирегез. Сез үзегез әниләрегезне ничек итеп хөрмәтлисез?

3. Татар әдәбиятына кое, чишмә образларының килеп керүен сез ничек аңлатырсыз?

4. С. Хәким сурәтләгән ана образы нинди булып күз алдына килеп баса?

5. Сагыну, юксыну, әни, әти, кое, чишмә турында йә шигырь, йә хикәя язып карагыз. Сыйныфта яки әдәбият түгәрәгендә бергәләп укыгыз. Уңышлы табылганнарын матбугатка, радионың балалар өчен булган тапшыруларына тәкъдим итегез.

6. Урта гасырлар татар шагыйре Мәүла Колый: «Ата-ананы хөрмәт иткән, аларга хезмәт күрсәткән, күңелләрен хуш кылган уллар-кызлар — Аллаһы Тәгаләнең дустыдыр»,— дигән. Сез моны ничек аңлыйсыз?

ТЕГЕРМӘН СТЕНАСЫНДАГЫ ЯЗУЛАР

Яңгырга эләктем, яңгырга,
Кинәттән яварын кем белгән...
Борчак та кукуруз басуда,
Басуда иске бер тегермән.

Эчендә тын аның, шомлырак...
Җил күктә болытны кабартты;
Дуламый, котырмый тегермән,
Ул инде бер генә канатлы.

Мемориаль такта күк стена,
Укыйсың, кулларын таныйсың,
Бур белән һәм күмер белән дә
Язганнар авылның тарихын.

Кадаклап һәм потлап үлчәнгән...
Бик сирәк чалына центнерлар.
Авылның монда үз моңнары,
Юк, туган, юк монда чит җырлар.

Елларга ит әнә игътибар:
Кырык бер, кырык өч, кырык биш!..
Кайгыны, хет тарттыр ташларда,
Кайда ул, кай төштә тыныч кич?

Кызларга алкага яраглык...
Өзәмен борчакның кузагын.
Яңгырлар ыграк юсайде
Дөньяның җыелган тузанын.

Яңгырны җир ничек ярата:
Барлык җан иясе терелгән...
Борчак та кукуруз басуда,
Басуда иске бер тегермән.

1961 ел

Шагыйрь булу — сүзләрне тезеп рифмалаштыру гына түгел ул. Шигырь язу өчен, иң әүвәл фәлсәфәче булуың кирәк. Беренче карашка гади генә тоелган күренеш турында яңа бер фикер әйтү өчен, чыннан да, фәлсәфәче, ягъни төрле яклап тирән уйлау сәләтенә ия булу таләп ителә.

Күз алдына китерегез: кеше басу буйлап бара. Шулвакыт каяндыр болыт килеп чыга, коеп яңгыр ява башлый. Бәхеткә, шунда якында гына иске җил тегермәне бар икән. Кеше, яңгырдан качып, шул тегермәнгә кереп сыена. Яңгыр яумаса, бу кеше монда керергә уйламас та иде. Әмма ул кötмәгәндә табышка юлыга. (Башка берәү, ихтимал, монда үзенә берничә дә кызыклы әйбер тапмас иде.) Тегермән диварларын[1] кайчандыр авыл халкы төрле язулар белән сырлап бетергән. Кем кайчан ашлык тарттырган, кем кемгә күпме бурычлы, тегермәнчегә күпме кирәк оны бирелергә тиеш һ. б. Дөресен әйткән-

---

[1] Дивар — стена.

дә, монда авыл тарихы теркәлгән. Бик фәкыйрь елларны да хәтерләтә бу язулар. Кешеләр берничә кадак, бер пот, ике пот ашлыгын да шушында алып килгән. Уйлап карасаң, бер пот ашлык нәрсә инде ул тегермән өчен? Аның чиреге тегермән ташына гына ягылып калгандыр. Ә центнерлап тарттырырлык ашлыкны каян аласың? Колхозда эшләгәнгә бирмәгәннәр, бер кесә ашлык өчен дә нинди каты җәзага тартканнар. Сугыш елларының кытлыгы аңлашыла, халык булмаганны өмет итми. Тыныч вакытта да крестьянны буш хезмәт көненә эшләтү иң соңгы дәрәҗәдәге гаделсезлек иде. Тегермән ташына салу өчен, ашлык кирәк, аһ-зарны, кайгы-хәсрәтне тарттырып булмый анда. Шагыйрь моны бик төгәл итеп әйтеп бирә алган.

«Яңгыр» сүзенә шагыйрь олы мәгънә сала. Ул — игеннәргә шифа, яшәү көче бирүче табигать могҗизасы. Шул ук вакытта автор яңгырга дөньяның, җәмгыятьнең, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрнең ямьсез якларын юып төшерерлек көч итеп тә карый. Әлбәттә, яңгыр моңа сәләтле түгел. Әмма образлы фикер йөртүче шагыйрь болай дип әйтә ала.

Күкрәп иген үскән басу, «кызларга алкага ярарлык» нәфис борчак кузаклары. Шулар янында иске тегермән. Аның эчендә тынлык, шомлылык. Ләкин бу җимерек бина кирәкмәгән әйбер түгел. Ул — халык тарихы, үткән заманнарның сагышлы хатирәсе. Тарихның шушы күренеше белән очрашу шагыйрьне уйландыра, ул укучы белән шул хисләрен уртаклашмыйча кала алмый.

Сораулар һәм биремнәр

1. Очраклы рәвештә иске тегермәнгә юлыгу лирик герой күңелендә нинди хисләр тудыра?

2. Бер канаты гына калган җил тегермәне инде күптән файдаланылмый. Нигә аны сүтеп алмаганнар?

3. Иске тегермән һәм халык язмышы. Шул темага сөйләшү уздырыгыз.

4. Сезнең төбәктә борынгыдан калган шундый тегермәннәр, тимерче алачыклары һәм башка корылмалар юкмы? Өлкәннәр ярдәмендә аларның тарихын ачыклагыз.

ҺӘЙКӘЛ УРЫНЫНДА УЙЛАНУЛАР

Башка чакта гел кисәтеп килде
Безне заман: артык җәелмә...
Ә бу юлы бер дә икеләнми,
Һәйкәл кирәк, диде, Җәлилгә.

Ул кодрәтле, ул йөретә эшне,
Ул мең еллар буе биеткән...
Һәйкәл өчен урын сайлый заман,
Шагыйрьләргә — әйбәт, биектән...

Шәһәр Советының каршысында
Калку урын... чынмы, әйт әле;
Александр II нең, имеш,
Шул урында торган һәйкәле?

Биек урын, биш йөз гасыр тулган,
Тарихы да шунда, тирәндә...
Шул урында мәңгеләшсен шагыйрь,
Ичмасам, үч итеп тиранга...

Җыелыр беркөн Әхмәт Симаевлар,
Шабаевлар, Гайнан Курмашлар...
Читтә — бергә, үз илендә нигә,
Монда нигә бергә булмаслар?

Җыелыр алар Җәлил тирәсенә —
Безнең кешеләр, безнең илнеке...
Бер һәйкәлгә урын сайлый заман,
Ә күңлемдә минем — уникe...

1966 ел

Муса Җәлил һәм аның унбер көрәштәшенең исемнәре егерменче йөзнең иң күренекле кешеләре исемлегендә урын алды. Алар арасында шагыйрь М. Җәлил аерылып тора. Аның һәйкәленең Казандагы Кремль алдында салынуы табигый иде. Бу урында кайчандыр патша сыны торган. Хәзер исә анда татар шагыйренең һәйкәле урын алган. М. Җәлил һәм аның каһарман дуслары барлык халыкларның бәхете өчен гомерләрен дә кызганмадылар. Әлеге калкулык гаделлекнең, изгелекнең гәүдәләнеше булырга тиеш.

Шагыйрь С. Хәким язганча, без, һәйкәл салу өчен дә, ил җитәкчелегеннән рөхсәт сорарга тиеш идек. Кодрәтле бу көч бөтен эшне үзе генә «йөретте». Ә шулай да М. Җәлилгә һәйкәл салырга рөхсәт бирми кала алмады. Чөнки бу шәхес башкарган изгелекләр теләсә нинди «кодрәтнең» күңелен йомшартырлык иде.

Шунысын да ачык аңларга кирәк: бу һәйкәл бер генә кешене гәүдәләндерми. Бирегә килгән кеше, һичшиксез, тулаем милләтебезне, М. Җәлил белән бергә көрәшкән һәм үлемне тез чүкмичә, батыр йөрәкле булып каршылаган башка каһарманнарыбызны да хәтереннән уздыра. Алар арасында Абдулла Алиш, Рәхим Саттар, Әхмәт Симаев, Гайнан Курмаш кебек шагыйрьләребез дә бар. Фашистлар ярты сәгать эчендә татарның биш шагыйрен һәлак иттеләр. Фоат Булатов, Фоат Сәйфелмөлеков, Гариф Шабаев, Зиннәт Хәсәнов, Абдулла Батталов, Әхмәт Атнашев, Сәлим Бохаровларның исемнәре халык хәтереннән мәңге җуелмас. С. Хәким ышана: М. Җәлилнең мәһабәт сыны янәшәсендә аның унбер көрәштәшенә дә һәйкәл күтәрелер әле.

1995 елда каһарман шагыйребезнең һәйкәле янында аның көрәштәшләренең барельефлары куелды. С. Хәкимгә исә бу көнгә кадәр яшәү насыйп булмады.

Сораулар һәм биремнәр

1. Үзегез чыганаклардан эзләп табып белегез: М. Җәлилгә Казан Кремле янындагы һәйкәл кайчан куелды? Аның авторлары кемнәр?

2. Бу урында М. Җәлил һәйкәле торуын сез ничек аңлатырсыз? Ни өчен һәйкәл Казанның иң үзәгенә куелган?

3. М. Җәлил һәйкәле — бер үк вакытта Бөек Ватан сугышында катнашкан күп геройларга куелган җыелма сәнгать әсәре дә. Шуны төшендереп бирегез.

4. «Ә күңлемдә минем — унике...» — ди шагыйрь. Болай дигәндә ул нәрсәне күздә тота?

Фатих Хөсни
(1908—1996)

Фатих Хөсни — үзе бер дөнья... Без, язучылар, Хөснинең тел байлыгына сокланабыз.

Ибраһим Гази

Татарстанның Теләче районында Олы Мәтәскә авылы бар. Әдәбиятыбызның күренекле язучысы Фатих Хөснетдин улы Хөснетдинов — Фатих Хөсни 1908 елның 3 февралендә шул авылда туа. Башлангыч белемне авылда ала. Уналты яшендә Казанга килә һәм бирედә М. Вахитов исемендәге мәктәпнең бишенче сыйныфына укырга керә. Ул 1929 елда гына, ягъни 21 яшендә, урта мәктәпне тәмамлый. 1933 елда, институтны тәмамлап, югары белемле икътисадчы[1] була. Ләкин күңеле әдәби иҗат эшенә тартыла. Мәктәптә, институтта укыганда һәм армия хезмәтендә (1933—1935) шигырьләр, хикәяләр яза. Сугышка кадәр үк инде аның берничә хикәяләр җыентыгы басылып чыга.

Шулай да Ф. Хөснинең язучы булып танылуы «Йөзек кашы» повестен (1942) иҗат иткәч була. Әлеге әсәрен ул үзе дә ярата, китап укучылар белән очрашулар вакытында озын-озын өзекләрен яттан укый. Повесть үзбәк, рус, казакъ телләренә дә тәрҗемә ителде.

Бөек Ватан сугышында Ф. Хөсни фронтта газета чыгару хезмәтендә була, бу чорда күп кенә хикәяләр дә иҗат итә.

[1] Икътисадчы — экономист.

Ф. Хөснинең аеруча нәтиҗәле иҗат иткән вакыты илленче-алтмышынчы елларга туры килә. Аның «Җәй башы» (1950), «Авыл өстендә йолдызлар» (1952—1953), «Җәяүле кеше сукмагы» (1957), «Утызынчы ел» (1958—1962), «Гыйльмениса» (1968) һәм башка әсәрләрен укучылар бик яратып укый.

Ф. Хөсни — чын мәгънәсендә тел остасы. Аның теләсә нинди китабын алып, теләсә кайсы битен ачсаң, шундук бу әдипне танып аласың. Чөнки алардагы сүзләр, безне Фатих Хөсни язды, дип әйтеп торалар сыман. Әдип сүзне, беркем дә кулланмаганча, бары тик үзенә хас җиңеллек, шаянлык-шуклык, юмор белән файдалана белә. Бу исә аңа дөньяның, кешеләр күңеленең хисапсыз күп төсмерләрен, бизәкләрен оста ачу мөмкинлеген бирә. Тел йөгереклеге, аһәңлелеге әйтергә теләгән фикерен үтемле итеп җиткерергә ярдәм итә.

Бер үк вакытта ул, әдәбиятыбыз турында кайгыртып, күп кенә мәкаләләр дә язды. Аның драма әсәрләре буенча спектакльләр куелды.

Ф. Хөснигә 1972 елда Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге бирелде. Ул әдәбиятны үстерүгә керткән зур хезмәтләре өчен илебезнең орденнары һәм медальләре белән бүләкләнде. Ярты гасырдан артыкка сузылган иҗаты белән Фатих Хөсни талантлы әдипләребез арасында үзенең лаеклы урынын алды. Ф. Хөсни — Татарстанның халык язучысы.

ЙӨЗЕК КАШЫ

(Әсәр кыскартып алынды)

I

...Безнең Янбулат авылында Айдарлар бер мин генә түгел. Мине Кәҗә Шаяхмәт Айдары дип йөртәләр иде. Ни өчен Кәҗә Шаяхмәт? Анысын менә хәзер белерсез. Берчакны шулай минем әти Теләче базарыннан безнең авылның Гыймай Сәләхиләренә утырып кайткан (безнең үзебезнең атыбыз юк иде шул). Сүз иярә сүз чыккан, бәхәс киткән. Дуамалрак кеше иде минем әти:

— Их, ит ашыйсым килә, әгәр булса, бер кәҗә ашап бетерер идем,— дип әйтеп ташлаган.

Авызы ипигә туймаган ярлы кешене котыртырга күпме кирәк соң! Тегеләр тотыналар моны кыздырырга:

— Бетерәсеңме дә бетерәсеңме?

Әти:

— Бетерәм булгач бетерәм.

— Бетерсәң, сиңа бер кәҗә, бетермәсәң, син безгә бер кәҗә,— диләр тегеләр. Шалт та шолт. Кайталар да җиңел кулдан бисмиллаһи Аллаһы әкбәр... бер кәҗәне егалар да суялар. Башкасын белмим, әмма ләкин әйткән сүзеннән кайтмый торган ие минем әти. Бер кәҗә итен бер утыруда ашаган да бетергән шул. Әле җитмәсә, кичкырын кайдандыр алып тагын бер стакан аракы төшергән дә, Сәләхиләргә барып:

— Аның шулпасы да булырга тиеш, нигә миңа шулпасын бирмәдегез,— дип, дау кубарып йөргән.

Әнә шуннан бирле безне Кәҗәнекеләр, Кәҗә Шаяхмәтнекеләр дип йөртәләр. Хәер, төкерергә. Авылда кушаматсыз кеше буламыни? Кәҗә Шаяхмәт малае гына булсам да үскәнмен әле. Таякны ат итеп уйнауларны, мулла бакчасыннан алма чәлдерүләрне сөйләп тормыйм. Алма дигәннән, безнең Янбулат авылына берчакны шулай алма сатучы килде. Әллә шуннан башлап китәргәме? Әй, шуннан башлап китимче әле. Июль ахырлары микән, август башларымы, әйе, алма сатучы килде. Аты яхшы — тимгел-күк. Ялы — көлтә төсле, утырып кына тора. Шлеясы-йөгәне — барысы да тәңкәле. Арбасын карага буяган, тимерле арба. Ә арбада зур-зур әрҗәләр, ә әрҗәләрдә берсеннән-берсе эрерәк алмалар. Кыпкызыл. Ул исе, ул исе... бөтен авылга җәелде исе. Госман, безнең күрше малай, ис сизәргә дигәндә аннан да җәһәт кеше юк иде. Алма исе иң элек аның курнос борынына барып кергән, ул, читән өстенә басып, миңа кычкырды:

— Әй... Айдар, алма сатучы килгән. Әйдә киттек!

Әйтүе булды, шул якка элдерүебез булды. Алма сатучы, атын җай гына атлатып, урам буенча бара да бара, үзе: «Алма сатам, ал-ма!» — дип кычкыра. Кешеләр күбрәк җыела төшкәч, атын туктатып, сату итә башлый. Ә безнең авыл кешеләре, дөресен әйтим, алманы элек-электән бик яраталар. Карты-карчыгы, баласы-чагасы, килене-кызы — барысы да йөгерә. Кайсының кулында ике-өч йомырка, кайсысы чиләк төбенә салып ясмык алып чыга, ә кайбер шуграк малайлар әбиләренең садакага дип адарынып куйган ике тиенлек, өч тиенлек бакырларын чәлдереп чабалар. Әбиләре артларыннан капка төбенә чыгып кычкырып кала: «Садакага дигәнем генә ие, кая алып олактың...» Ә алма сатучы,

мондый шау-шуларга бер дә исе китмичә, товарын мактап-мактап сата да сата. Үзе дә бик көяз кеше иде шул, каһәр. Каракүл бүрекне кыңгыр салган, өстендә трико кәзәки, кәзәки кесәсеннән сәгать чылбыры салынып тора, ә телгә дисәң, товарын мактарга дисәң, авызына шайтан төкергән инде. «Бу алманы сез моңа чаклы күрмәдегез, моннан соң күрәчәк түгелсез, алып калыгыз»,—ди. Безнең авыл кешеләренә шул җитә кала, этешә-төртешә кабаланалар. Янәсе, миңа үлчә дә, миңа үлчә.

Без, малайлар, арба артыннан ияреп йөрибез. Алманың исен иснәгән өчен акча сорамыйлар, алманың үзен алырга акчабыз юк, арба артыннан да ияреп йөрмәгәч, безгә ни кала соң?

Атын күргәнмен, арбасын күргәнмен, алмасын күргәнмен, ә менә алма әрҗәләре арасында кысылып утырган кечкенә генә кызны, түгәрәк ак бәләкле, кап-кара күзле, башына салам эшләпә кигән кызны моңа чаклы күрмичә торганмын. Алма сатучының үз кызыдыр инде ул, шөпшә төслерәк икән. Алай дисәң, шөпшәнең күзләре кара булмый бугай. Нинди була соң әле шөпшәнең күзләре? Аты әйбәт, арбасы әйбәт, алмасы әйбәт, ә кызы барыннан да әйбәтрәк. Шөпшә төсле дип юри генә әйттем мин, бөтенләй шөпшә төсле түгел.

Бүтәннәр алма карыйлар, мин кыз карыйм. Кыланчык нәрсә икән, эшләпәсенә ал лента бәйләгән булган. Безнең авылныкы булса, мин аның эшләпәсен чәнчә бармак белән эләктереп алыр идем дә өй түбәсенә атып бәрер идем. «Алып бир дә алып бир»,—дип, соңыннан минем тирәмдә тик бөтерелеп йөрсен. Безнең авылныкы түгел шул. Әллә, алма караган булып, якынрак килеп карарганмы? Әтисе күрер каһәрнең. Алма чәлдерергә йөрисең дип, борынга чиртер. Шулай да арбага якынрак елышам, арт карамага тотынам. Бушаган әрҗәләргә поса төшеп, кызга якыннанрак карап торам. Шактый ук озак карап торам, ә ул күрми дә күрми. Ә күрсен иде, каһәр. Бер дә булмаса, әтисе күрсен иде. Ә болай берсе дә күрми. Әллә арба тәгәрмәченә басып карарганмы? Бастым. Кинәт үсеп киттем. Кызны хәзер колак йомшакларына чаклы күрә башладым. Әллә агач ботагында алма белән бергә үстеме икән ул? Битләре нәкъ алма төсле. Чәчен зәңгәр лента белән кушып үргән, маңгае ап-ак, күзләре түгелергә торган төсле. Ә үзе шул

кечкенә генә куллары белән үлчәү тәлинкәсе тирәсендә маташкан була. Герләр алып сала, алма тутырыша, мине ичмасам бар дип тә белми. Ачуымны китерсә, чәч үргеченнән тартырмын әле. Уйлавым булды, тартуым булды. Карамас җиреннән карады кызың. Карады, аннары көлеп җибәрде. Тешләре уенчык төсле ап-ак. Алма ашап шулай агарып беткәндер инде ул, дим эчемнән генә. Ә үзем күземне терәп, карап тик торам. Кыз үлчәү тәлинкәсе тирәсендә бераз маташты да тагын борылды, тагын миңа карады. Бу юлы инде мин аның бит очындагы кечкенә миңенә чаклы күреп калдым. Әйбәт кыз, әйбәт. Безнең авылныкы булса, мин аның хәйләсен табар идем, колак йомшагыннан гына тешләп алыр идем, безнең авылныкы түгел шул.

Дөресен генә әйткәндә, әллә нишләдем мин. Алманың исен сизми башладым, үземнең Кәҗә Шаяхмәт малае гына икәнлегемне оныттым, ә Госманнар әнә һаман шул тирәдә чуалалар. Берсе берәүгә дә сиздермичә эләктерде дә бугай. Алма сатучы килер дә китәр, иптәш малайлардан аерылырга ярамый. Ачык авыз дип, соңыннан үртәп йөдәтүләре бар үземне.

Мин арбадан бер читкә китәм, берсенә дә карамаган бер төс белән басып торам. Кыз күтәрелә дә карый, тешләрен күрсәтә. Үзем дә сизми калганмын, минем дә тешләр күренеп киткән тегеңә. Шуның артыннан озак та тормады, ул кыз бик зур, бик матур бер алманы сайлап алып, этисе күрмәгәндә генә, миңа атып бәрде.

Мин инде бик әйбәтләп кенә тотып алдым. Аннары нәрсә булган,— берсен дә белмим. Ник дисәң, кинәт башым әйләнеп китте минем, өйгә йөгердем. Малайларның әйтүенә караганда, аннары ул алма сатучы, атын җай гына атлатып, безнең авылдан чыгып киткән. Кая киткән? Берәү дә белми. Авылдан чыккан чакта аның кызы бушаган әрҗәләр өстенә утырып, арбадагы бөтен әйберләрдән, этисенең үзеннән дә, атның дугасыннан да биегрәк булып, озакка, бик озакка чаклы күренеп барган. Аның зәңгәр ленталары белән җил уйнаган, ә ул үзе басу капкасын чыкканнан соң да, каерылып-каерылып, безнең авыл ягына таба карап барган.

Ә Госман, курнос борын, мине мыскыл итмәкче була.

— Алма сатучының кызы алманы сиңа дип атмады, үлчәү тәлинкәсенә салам дигәндә, кулыннан ялгыш төшеп китте,— ди.

Мәтәштерми генә тор. Ялгыш кына төшеп киткәч, нигә соң ул минем кулга килеп эләккән, нигә Госман кулына эләкмәгән?

Дусын дус та син, Госман, шулай да әллә нәрсә генә бар синдә. Нигә инде кешене алай үртәргә. Бүген алма сатучы узган, иртәгә кыяр сатучы узар. Безнең Янбулат урамы киң ич ул. Шулай да, күп бәхәсләшеп тормыйча, әйдә су кереп кайтыйк әле. Әллә нәрсә, бик эсселәп торам мин бүген.

Күз ачып йомганчы без, Госман белән икәү, тегермән буасына су керергә йөгерәбез. Ә теге алма һаман кулымда.

II

Аннары ул менә болай була.

Кыш узып, яз җиткәч, сабан чәчүләре беткәч, безнең яктагы авылларда, борынгы гадәт буенча, җыеннар, Сабантуйлары башланып китә. Яшь киленнәр чүпләмле сөлгеләрен әзерлиләр, колмак турында, сыра утырту, бал әчетү турында сүз китә,— алары аның олы кешеләр эше. Ә бит Янбулат авылында безнең ише койрыксыз әтәчләр дә җитәрлек. Хәер, Госман белән без әллә кайчан ук сөйләшеп куйдык инде. Җыеннар башланса, ат чаптырырга барабыз. Тизрәк җитсен генә.

Көтә торгач җитте тагын. Элек безнең авылда җыен булды — бездә шауладылар, аннары күрше авылларда җыен булды — аларда без шауладык. Әти, ат чаптырырга барасы булма дип, алдан ук колак итемне ашап куйган иде дә...

Теләсә ни булсын, быел теләгемә ирештем. Җиңел сөякле малай дип, гел мине эзләп йөриләр. Рәхәт тә соң ат өстендә килү! Бөтен халыкның күзе синдә. Атның кайнар ялы синең битеңә сирпелә. Ә алда, биек колга башында, берсеннән-берсе матур булып сөлгеләр күренәләр. Кайдадыр кычкыралар:

— Куала, Айдар, куала!

Йөри торгач, без Мамалай җыенына ук барып чыктык. Ат җибәрер вакыт җиткән икән. Тизрәк мәйданга, халык арасына йөгердем. Госман инде бер атка менеп тә алган. Колагына яулык бәйләгән, ал күлмәген балкытып, атның аякларын кыздырып йөргән була. Ә күзләре халыкта. Янәсе, күрәләрме аны. Яратмыйм шулай болганып йөрүне. Йөреп-йөреп баш килсәң, тагын бер хәл.

Ә иң актыктан сөйрәлергә калсаң егыл да үл инде. Иң яхшысы — егетлекне кинәт күрсәтү, кеше көтмәгәндә күрсәтү. Язгы яшен төсле ялтырыйсың, аннары югалсаң да ярый.

— Кая, минем атны кем алып бара? — дигән бер тавыш ишетеп калдым. Икеләнеп торулар бөтенесе коелды: «Бир, абый, үзем»,— дип кычкырдым. Ике минуттан мин инде ат өстендә идем.

Атның аякларын кыздырып тормадым. Хуҗасы үзе дә таякны тиз сындырырга ярата торган кеше икән.

— Әнкәсен, бик чая мал, дип сатканнар ие. Йөрәгендә булса, аягында булыр. Әйдә атлан да кит,— ди. Аты болай җиңел күренә. Тояклары да түгәрәк, борын тишекләре дә парлы, бәлки нәрсә булса да чыгар.

Китә башлагач, атның иясе мине туктатып, колагыма тукыды:

— Кара аны, баш килерлек булмаса, хайванны юкка яндырма. Тот та аермадан ук сулга каер, авылның аргы башында мин үзем каршы алырмын.

Җавабым юк, дөрес сүз. Булмастайны камчылаудан ни файда? Киттек. Барыбыз җидәү: Госман, мин, калганнары ят малайлар. Атлар — барысы да күрер күзгә ягымлы маллар. Уйнаклап кына баралар. Арада бер озын торыклы байтал мине бигрәк тә куркыта.

Барып җиттек. Тезелдек. Чыктык. Башта бер-ике чакрым җирне барыбыз да тигез килдек дип әйтерлек. Бу араны атлар җиргә түгел, хәйләгә басып килделәр. Госман, чыгу белән дип әйтерлек, камчысын айкый башлады, ара-тирә йөрәксенеп кычкырып та җибәрә, тик шулай да ул берәүне дә куркытмый. Аның түшәмен без шунда ук күрдек. Моннан соң ул, ничаклы тырышса да, артык сикерә алмаячак. Ул бездән, бер җир буе дип әйтерлек, алда бара, тик шулай да мине ул түгел, арттан уйнаклап килүче теге кашка байтал шикләндерә. Үз атымның чамасы үземдә, камчы тидерергә ашыкмыйм — бар нәрсәнең дә вакыты була бит.

Ниндидер юл аермасын үттек, берәү шунда кинәт кенә:

— Һа! — дип кычкырып җибәрде, колагыма җил бәрелде, тояклар ярсу белән тупырдадылар. Күземне ачып-йомарга өлгермәдем — кашка байтал минем алга сикереп чыкты. Аның арт тоякларыннан балчык аты-

лып минем битемә бәрелде, бераз вакыт күземне ача алмыйча бардым, ә күзне ачарга вакыт бик җиткән иде.

Алда, берничә чакрым ераклыкта, колга башындагы сөлгеләр чагылып киттеләр. Күренделәр, аннары тагын югалдылар. Хәйлә бетте, безнең аяк астында хәзер җир, җитмәсә, тагын нинди җир! Йә күтәрә ул, йә башыңны яра. Мин, ике бармагымны тешемә кысып, сызгырып җибәрдем һәм беренче мәртәбә атыма камчы селтәдем. Уен түгел икәнлекне ат та сизенде булса кирәк, кинәт сикереп алды, мин чак кына артка очып калмадым. Күз алдымда нәрсәләрдер тиз генә яктырып киттеләр, кинәт сүнеп калдылар, битемә үз атымның әчкелтем пары килеп бәрелде. Тагын шул: теге аермадан узып, бер-ике генә сикердем, Госманның артына килеп бастым. Аның атының ухылдавы ишетелә, бу — дәртлелек түгел, хәлсезлек билгесе. Минем Госманнан көләсем килде, тик көлгәнче тагын бер сикерәсе бар иде әле. Атыма тагын бер селтәнеп җибәрдем — без хәзер аның белән тигез барабыз. Тагын бер селтәнсәм, мин аны артка калдырачак идем. Госманга бу ошамады. Атына шәп кенә пар өстәмәкче булып селтәнде дә минем атның алга сузылып бара торган борынына сукты. Күземә кинәт кан бәрелде,— күрә дә, уйлый да алмадым. Ачу белән ярсып, Госманның битенә камчым белән селтәп җибәрдем. Ул чайкалды, аты өстеннән очып төшеп калды. Соңыннан гына белдем, каты сугылган икән мескенгә, алты ай буена яңагын бәйләп йөрде, ә соңыннан гомерлек яра эзе калды.

Госманнан, тагын берничә ярканаттан җиңел генә узып китсәм дә, кашка байталдан узу ансат булмады. Ул сөлек төсле сузылган, ничектер агып бара. Өстендәге малае да бөҗыр күк. Кадакланган шикелле утырган да кулларын як-якка болгаштырып очып кына килә. Атны борчымый, телен белгән төсле, әллә нидә бер кычкырып кына җибәрә.

Сөлгегә килеп җитәргә ярты чакрым чамасы җир калганда, без икебез дә бер тигезлектә бара идек. Мәйдандагы халыкның умарта корты төсле гөжләве ишетелә башлады. Кемдер, ярсулы тавыш белән:

— Каула, Айдар! — дип кычкырып җибәрде.

Кауларга кирәк икәнен мин үзем дә бик яхшы белә идем, шулай да ул ярсулы тавыш ярап куйды, тартып алган төсле булды ул. Мин тешләремне кысып селтәнеп

җибәрдем, нидер аугандай булды, боҗыр күк малай артка шуды, сөлгегә ярты җир буе калды дигәндә, минем атым кашка байталның алдына сикереп чыкты. Күзләремә яшь килде,— үзем өчен түгел, кашка байтал өчен.

Мине ат өстеннән кочаклап алдылар, ә атның муенына бик озын сөлге эленде. Кайсыныкы булгандыр, әйбәт сөлге иде ул. Әле хәзер дә, авылны, балачакны искә төшергән минутларда, бүтәннәр белән бергә, күз алдымда һаман шул кызыл башлы озын сөлге җилфердәп тора кебек...

Әйтерсең лә әллә ни эшләгән, мине «рәхмәт» белән коендыралар гына. Атның хуҗасы — Исмәгыйль абзый дигән кеше — кайдадыр күргәнем дә бар күк үзен. Аема-ваема куймыйча, мине үзләренә кунакка алып китте. Бай гына кешеләр икән, өйләре калай түбәле, капкалары буяулы, идәннәре дә буяулы,— мин элек басарга да кыймый торган иsurvey дә, бераз кунак булганнан соң биеп тә җибәргәнмен тагын.

Исмәгыйль абзый үзе гаҗәп күңелле кеше икән... Ул җырлаганда, мин аның авызына карап утырам. Иреннәре әллә ничек, миңа таныш төслерәк селкенә, кайда гына күрдем соң мин бу кешене? Хәтерләп карыйм, юк. Берни дә искә төшми. Барысы да юылган.

Ашагач-эчкәч, мин инде, кайтып китмәкче булып, ишеккә карый башладым. Кунак булу рәхәт тә, шулай да ишек дигән нәрсә бар бит дөньяда. Кергән ишектән вакытында чыгып китә белергә дә кирәк.

Тик Исмәгыйль абзый минем сүзне ишетергә дә теләмәде. Бүген бездә кунарсың, иртәгә ихтыярың, теләсәң кая бар, ди. Әллә чынлап, әллә юри әйтә: кичен менә кызлар уенына барырсың, дип ычкындыра. Хәйләкәр төлке син, Исмәгыйль абзый... Кайдан белгән соң ул минем кызлар яратканны?!

Шулай да мин сүземне бирмим:

— Китәм булгач китәм,— дим.

Исмәгыйль абзый үзенекен:

— Җибәрмим булгач җибәрмим.

Ишегалдына чыгып киттем. Матур гына бакчалары бар икән. Алма, шомырт, миләш, карлыган, чия — баш тыккысыз. Шулай да кердем. Аптырап тик торам. Дөресрәге, бүрегем белән киңәш итәм: китәргәме, калыргамы? Китәр ием, кызлар уйнаган җиргә дә барасы килә. Китмәс ием, мин аларга кем? Коры бер тыпыр-

давык. Идән таптаучы. Шулай уйланып, бүрек белән киңәш итеп торганда, кинәт бер яфрак селкенеп китте. Аннары икенче яфрак селкенеп китте. Аннары куе булып, төптән чыгып үскән бер карлыган агачы дерелдәп куйды. Карлыган агачы белән бергә минем йөрәк тә дерелдәде. Ни булыр бу? Басып тик торам. Миннән киңәш шул: андый хәвефле минутларда басып тик торудан да файдалысы юк икән. Карлыган агачы тагын селкенде, мин ни дип әйтергә дә өлгерми калдым, бер кул күренде. Кечерәк кенә кул. Башта мин аны кош дип торам, кул икән. Кызлар кулы булса кирәк, йөрәгем шулай ди. Басып тик торам. Башыма бер карлыган ботагы килеп төште. Тагын берәү. Тагын.

— Шаярмагыз! — дип кычкырып җибәрдем. Ничек кычкырмаска ди соң, ул бит бөтен карлыган агачын сындырып бетерер. Ә теге кул шаяра да шаяра.

Калтырап тик торам, әй. Шулай да бераздан атладым. Үзенә таба якынлашуымны күргәч, теге кулның иясе агач төбеннән кинәт пырхылдап килеп чыкты. Ул карлыган куагының теге ягында, мин бу якта. Карлыган куагы безнең билебездән генә.

— Мин сиңа бервакытны алма белән бәргән идем, исеңдәме? — ди ул, вак кына тешләрен күрсәтеп көлә. Карлыган куагы безнең билебездән генә, кыз инде шактый ук үскән, күкрәге беленеп килә.

— Сез безнең авылга алма сатырга килгән идегез,— дим мин.

Ул арада баскыч төбеннән: «Вәсилә, син кайда? Өйгә кер»,—дигән тавыш ишетелә. Шулай итеп шул, кош дигәнем Вәсилә булып чыкты. Әйбәт, бик әйбәт.

Вәсилә китмәкче булды, китмәде, тагын посты. Ә бераздан пышылдаган тавыш белән:

— Син китмә! Кун бездә, кун,— дип, кыска-кыска гына әйтеп куйды. Үзе тагын карлыган куагы төбенә посты. Мин ни дип әйтергә дә өлгерми калдым, ул, агачларга поса-поса, бакчадан чыкты да йөгереп өйгә кереп китте.

Узган елдан бирле байтак кына су аккан, аз-маз гына акыл да кергән, шуның өстенә тагын Сабан туе вакыты; кош дигәнем Вәсилә булып чыкты. Вәсилә дигәнем минем төшемә кереп йөдәтеп бетергән алма сатучы кызы икән, болай булгач, коры идән таптаучы гына түгел инде мин.

Өйгә кердем дә Исмәгыйль абзыйны күреп әйттем:

— Бүген кунам инде мин сездә, Исмәгыйль абзый,— дидем.

Сораулар һәм биремнәр

1. Хикәяләүче малайны сез ниндирәк итеп күз алдына китерәсез? Ул нинди сыйфатларга ия?

2. Айдар белән Госман холкындагы аермалыкларны күрсәтегез.

3. Госманның кимчелекләре нәрсәләрдә күренә?

4. Хәрәмләшү, кешенең булдыклылыгыннан көнләшү кебек нәрсәләр белән сезнең тормышта очрашканыгыз бармы?

5. Айдар бары тик уңай сыйфатларга гына ияме?

6. Вәсилә Айдарны бер күрүдә үк ошата. Аның малайга булган уңай мөнәсәбәтен белдергән урыннарны искә төшерегез.

7. Ат чабышында катнашкан малайның халәте әсәрдә бик киеренке итеп бирелә. Сезнең үзегезнең ат чабышында катнашканыгыз бармы? Аның хисләре сезнең кичерешләр белән туры киләме, юкмы? Шуны сөйләгез.

III

Кундым. Ә кунмаган булсам яхшырак буласы икән. Вәсилә аш өе белән ике арада әле анысын, әле монысын ташыган булып чабулап йөрде дә, кич белән яңа күлмәкләрен киеп, ишегалдында бөтерелергә тотынды. Чандыр гына кыз, бу хәтле купшылык кайдан килгән диген. Чәчләрен ленталар белән күмгән. Өстендә аклы күлмәк. Җитен чәчәге төсле вак-вак кына бөрчекләр төшкән. Челтәрләп, иңбашларына каплавычлар салындырып теккән алъяпкыч.

Үзем унбиш яшьлек малай, ә эчемдә шайтан утыра. «Кысып карарга иде бу кызны, сыңар учка сыеп бетәр иде микән?» — дип уйлыйм эчемнән генә.

Аннары алар күрше кызлары белән, чыр-чу килеп, әллә кая чыгып киттеләр. Ишегалды бөтенләй бушап калды. Капка төбенә чыктым. Утырып тордым. Аннары әйләнеп кергән булдым. Ә Вәсилә күренми дә күренми. Йолдызлар күренә башладылар. Әллә нинди искитмәле йолдызлар. Үзләре яшькелт, үзләре баш очында гына диярлек, катырак җырлап җибәрсәң, өстеңә коелырга торган төсле. Безнең Янбулат авылында мондый йолдызларны һич күргәнем юк ие минем. Чынлап та, әллә нинди генә булды ул кич.

Шул кичне, иптәш кызлары белән уйнап кайтышлый, Вәсилә, минем янга туктап, миннән:

— Син ни атлы? — дип сорады.

Мин исемемне әйтеп өлгермәдем, ул, балаларча чытлыкланып, икенче сүзгә күчте:

— Безнең атны тәки баш китердең бит син. Ничек курыкмадың?

Мин ни дип тә әйтә алмадым, ат өстендә килү кызлар белән сөйләшүгә караганда чүп кенә икән. Вәсилә, үзе шулай чикерткә генә булса да, батыр булып чыкты.

— Ник сөйләшмисең, сөйләш, сөйләш инде! — дип, минем янымда таптангалап торды да ахырында, миңа кулы белән төртеп, ишегалдына йөгерде.

Сөйләшә алмасам да, кулга киткәч бирешмим инде мин. Песи төсле сикереп торуым булды, кызыйны капка баганасына китереп кысуым булды. Чырылдаган була, үзе шундый җиңел, шундый җиңел!

— Безгә тагын кил, яме, Айдар! — ди бу миңа.

Юк, мин аларга ул җәйне тагын бара алмадым. Ник дисәң, киемем әйбәт түгел минем, оялдым. Ул чук төсле, ә мин эти кәҗәкиеннән бозып теккән кыска җиңле камзулдан. Бөтерелеп йөрер-йөрер дә ахырында беркөнне әйтер: «Син, малай, этиеңнең камзулын киеп минем тирәдә йөрмә әле»,— дияр. Әйтмәсә дә, үзем беләм мин: кызлар сөйсен өчен, иң элек бер пар ялтыравыклы итек, бер тужурка, сатин күлмәк, хәтфә кәләпүш кирәк...

Җәйге эшләрне бетергәч, иң кимендә әнә шуларны эшләп кайту нияте белән, шахтага китәргә булдым. Әти белән әни каршы торып караганнар иде дә, авызларын тиз томаладым. Җилкәм үсте, синең искеңнән бозып теккән камзулга сыймый башладым, дидем. Шуннан үзләре аңладылар тагын. Эш хәзер конторда, пашпорт алуда. Баштан ук шикләнгән идем, дөрес шикләнгән икәнмен, конторда күземне дә ачырмыйлар. Яшелрәк әле син, диләр. Тагын бер-ике җәй Янбулат кояшы астында пеш, аннары шахта тишегенә таман гына булырсың, дип көләләр. Мәтәштермәгез, бар пешүем җиткән минем, китәм булгач китәм. Контор идәннәренә түкермәдем дә ичмасам, пашпортсыз-нисез киттем дә бардым.

Юлда Кәче авылы кешеләренә очрап, алар белән бардык. Безнең ярты авыл шахтада, үзебез урнашты-

рырбыз, диделәр. Яшькә яшь булсам да, буем бар минем, кулларым да бар. Кәче кешеләре ошатып ук куйдылар. «Молодец, йөрәгең җиткән»,— диләр.

Голубовка дигән шахтага килеп җиттек. Чынлап та, Кәче кешеләре баскан икән үзен. Мин, бердәнбер Янбулат малае, бөтенләй югалып калдым. Кәҗә оясы чаклы гына өйләр, стеналары балчыктан, тәрәзәләренең ватылган өлгеләренә иске мендәрләр тыгып куйганнар. Ул бала, ул чебен — ерып йөргесез. Нужаны мин безнең авылда гына дип уйлаган и　ем, монда да бар икән ул нужа, монда әле озынрак сакаллысы көтеп торган икән.

Беренче тапкыр клетька утырып шахтага төшкәндә, эти белән энине искә алуымны, ходокның түшәменә маңгаемны бәреп күземнән утлары күренгәнне, лавага кереп җиткәч, лампам сүнеп, нишләргә белмичә аптырап калуымны язып тормыйм. Карт шахтерлар әйтәләр, башта ул шулай була, диләр. Беренче көннәрдә үземне дә түгел, кешеләрне дә түгел, атларны кызганып йөдәдем. Сукыр атлар. Мескеннәр, гомерләре буена шунда җир астында вагонетка тартып интегәләр икән. Күзгә караган төсле мөлдерәшәләр җаннарым. Болар янында безнең җир өсте атлары кунак кызлары икән. Якты кояш астында рәхәтләнеп эшлиләр, яшел тугайларда утлап йөриләр. Ә Сабантуйларында инде үзләре дә ирек ача, кешене дә ирек ачтыралар. Кинәт Вәсиләләрнең чабыш атлары исемә төшә. Их, атланыр иде дә туганүскән җирләремә кайтып китәр ием.

Атландым атның биленә,
Киттем сахра җиренә...
Их!

Килүемә ун көннән артык түгел, әле беренче получканы да алмаган, ә күңел, читлеккә керәсе килмәгән кош төсле, әллә кайда очып йөри. Барысы да, барысы да синең өчен бит, Вәсилә! Аллы-зәңгәрле ленталар тагып, шомырт кара күзләреңне сирпеп, сикергәли-сикергәли, әллә кайдан гына килеп чыктың да мине менә монда, җир астына китереп тыктың.

Ялтыравыклы итекләр киеп кайтсам, үзеңнең дә үзәгеңне өзәрмен әле өзүен.

Өмет тә киң, кесә дә тирән,— акча гына аз. Беренче получкадан соң: «Бу нишләп болай гына?»— дип, телемне кузгатмакчы булган ием дә, арт яктан кемдер

килеп иңбашымнан тотып алды. Әйләнеп карасам: Рахман абзый тора. Минем белән бергә килгән Кәче кешесе. Көлә.

— Маңгаеңда тир, аяк астыңда җир исән булсын диген, тиле малай, акчаны монда санап кына бирәләр,—ди.

Кешене белмим, минем үз исәбем үземдә. Кием-салымны рәтләрлек акча җыеп булса, монда, җир астында тончыгып ятасым юк. Китәм, буразнама кайтам. Төннең төн буе йокламыйча, акчамны исәпләп чыктым,— мин дигәнчә түгел. Иртәгесен, бүтән бер кешене дә күрмәгәч, техникка бәйләнә башладым.

— Ни өчен болай? — дим. Шаркылдап көлә генә.

— Безнең җир астында ни өчен болай дигән сорауга җавап бирү гадәте юк ул,— ди.

Китте дә барды. Бары тик итекләре генә күз алдымда ялтырап калды.

Тырышсам, әнә шундый итекләргә тырышам инде мин. Басканда шыгырдап тора торган булсын, кунычында кояш нуры уйнасын. Тик менә җир астында «Ни өчен?» дигән сорауга җавап бирмәүләре генә хәтәр икән.

Эчмәдем, тартмадым, ике ай дигәндә саф унбиш сум акча җыйдым. Ә теге техникка һаман ачуым кабарып йөргән көн. Штраф дип, бөтенләй юк нәрсәләр өчен минем өстән язып чыгара икән. Астан шулай язып чыгаргач, өстә синең белән сөйләшеп тә тормыйлар, билгеле. Әгәр шул ләгънәт төшкән штрафлары булмаса, минем акчам егерме биш сум булыр иде инде. Получка саен кесәдә икмәклек-тозлык, чәйлек-шикәрлек калдырам да, калганын әйбәтләп кенә төреп, бүрек түбәсенә, эчкә тегеп барам. Кәче кешеләре — картрак шахтерлар — миннән көләләр.

— Синең төсле яшь бер егет, моннан элек тә шулай ашамыйча-эчмичә, акча җыйды-җыйды да, җыелган акчасы — җир өстендә, ә үзе, лава ишелеп, җир астында калды. Аша-эч, эти тапкан мал түгел, үзебез тапкан җәл түгел,— дип, дусларча җилкәмә кагып куялар. (...)

Шулай да Вәсилә искә төшә, каһәр. Теге чакны, аларның капка төпләрендә, үпми дә калдым бит үзен. Курку дисәм, юк, куркуның ни икәнен дә белмим мин. Әллә нәрсә генә булды шунда. Каушадым, ахры. Йолдызлар бик түбән төшкәннәр ие шул ул кичне, уңайсыз ие.

Табылмаган мал тау чаклы, диләр. Әтиләр дә, кайт та кайт дип, хат артыннан хат тупырдатып торалар.

Пашпортсызларны бик нык тикшерәләр икән, дигән хәбәр дә йөри. Василәне дә сагындым, кайтмый булмас, ахры. Алдагы получканы алгач, өс-башны бераз караштыргалыйм да — сәфәр.

Шундый яхшы ният белән йөргәндә, теге, безнең штольняның[1] техникы тагын аякка килеп чалынды бит. Имеш, мин терәүләрне дөрес салмаганмын. Терәүләр салырга җыенам әле мин сиңа, черек теш. Получканы алып, өзәсе эшләремне генә өзим. Үземә үзем ант итеп куйдым: арт сабагын укытам мин ул дуңгызның.

Җае да туры килде. Расчеттан соң, иртәгә китәсе дигән көнне, иптәшләр белән бераз төшердек тә урамга чыгып киттек. Байтак кына болганып йөрдек. Берчакны шулай, иптәшләрдән аерылып, тар гына урам буенча үзем генә килә идем, күземә күренәме дип торам, бу сөйрәлә. Кинәт антым исемә төште, уч төбем кычыта башлады. Каршына килеп бастым. Торам. Якасыннан каптырып алдым:

— Безнең Эт бистәсендә ни эшләп йөрисең син? — дим тегеңә. Шүрләде бу, ык та мык килә. — Берәр нәрсә чәлдерергә йөри торгансың әле,—дидем дә икенче кулым белән яңагына чалтыраттым да. Учымның кычытуы басылып ук китте. Теге кычкыра башлады, мин тагын берне. Кычкыра икән, туеп җитмәгән дигән сүз. Нигә бирмәскә?..

IV

Кайтып бер-ике көн тормадым, Кәҗә Шаяхмәт малае кайткан икән, баеп кайткан икән дигән хәбәр бөтен авылга таралып та өлгерде. Мыек астыннан гына көлеп тик йөрим, әйдә, дан китсен, дим. Мыек дип юкны сөйлим, кайда әле мыек. Шәп-шәрә малай. Ә чынлап та, борын астында сызылып киткән кара мыек булса начар булмас ие,— кара мыек, ялтыравыклы итекләр, сатин күлмәк, кесәле чалбар, куллар чалбар кесәсендә. Урамнан узасың, бөтенесенең күзе синдә: «Әнә, әнә Айдар узып бара!»

Башкасы бар, мыек кына юк. Хәер, төкерергә. Болай да бик әйбәт йөрим әле. Кичә Сабир кызы Хәдичәдән хат алдым. Кәгазьне чәчәкләп тутырган. «Әльхат,

[1] Штольня — шахтерларның күмер чаба торган урыны.

нисфел-мәлакать, кабул күрсәң укып бак кабул күрмәсәң, утка як» дип теленә салынган. Утка якмадым ягуын, шулай да ертып ташладым. Хәдичә торып торсын әле, анда мине, яшь тай төсле, ефәк чукларга күмелгән Вәсилә көтеп тора торгандыр.

Әйдә Мамалайга, синең апаңнарга кунакка барабыз дип, Госманга әйтеп караган ием, риза булмады.

— Ни атна, ни шимбә, килешми ул, без эш кешесе,— дигән була.

Ә мин әйтәм, килешә, дим. Киттем дә бардым.

Авылдаш дигән булып, Госманның апасына, Ниса түтигә төштем. Бер яулык белән бер исле сабын тоттырдым — эреде дә китте. Аяк астыңа ятып үлимсәнә дигән төсле йөри. «Ул чаклысы кирәк түгел, шулай да менә бу «кош теле»дәй хат кисәген Вәсиләнең үзенә генә илтеп бирче, Ниса түти».

Ярты сәгать тә узмады, Ниса түти шундый ук «кош теле» тотып, әйләнеп тә кайтты. «Кичкә чишмә янында очрашырбыз, шунда кил»,— дигән.

Түзә алмыйм, сезнең Мамалайда кич тиз буламы соң ул дип, Ниса түтидән сорашасым килә. Ә ул, наян хатын, үзе кыбыр-кыбыр эшләп йөри, үзе сөйләнә:

— Чәчен тарап утыра, чәче биленә төшкән... Хатны укыгач, бөтенләй аптырап калды, чәчен дә үрмәкче була, хат та язасы бар. Ишекле-түрле йөгереп йөри кызың. Ә үзенең биле сыгылып тора, буе-сыны коеп куйган төсле. Каушау килешә икән тагын үзенә: ике бите алма төсле булып кызарды. Күтәрелеп карамый да үзе, шулай да күреп торам: сөрмәле күзләреннән дәрт ява.

Җитәр, Ниса түти! Синең сүзләреңне тыңлап бетерә алмам, сезнең кичегезне көтеп тәкатем җитмәс. Аякка ялтыравыклы итекләрне киеп, өскә зәңгәр сатин күлмәкне элеп, күлмәк өстеннән билгә чук асып, урамга чыгып киттем. Урамның нәкъ уртасыннан барам — булды, урамның читеннән күп йөрдек, уртасыннан йөреп карыйк әле.

Вәсиләләрнең өй турыларына якынлашам, йөрәгем дөп-дөп тибә. Күрә микән, юк микән? Кичен очрашырбыз без, ул турыда сүз дә юк, көндез, кояш яктысында күреп кал син мине!

Узып киттем, бераз чиркәнчек алган төсле булды. Матур кыз дигәннәре кызык кына нәрсә икән,— йөрәккә кереп утыра да чыкмый да чыкмый.

Шулай да кич җитте тагын. Итекләремне ялтыратып, сатин күлмәк өстеннән пиджак элеп чыгып киттем. Чишмә буена барып бастым,— кызлар су китерергә тотынганнар гына. Бераздан, гармун уйнатып, берничә егет тә килде. Рәтлерәкләрен сугышка алып бетергәннәр, ахры, болары — корырак сөякләр. Шулай да, эт оясында батыр дигәндәй, миңа таба кырын күзләрен салгалыйлар. Кайдан килгән чыпчык бу, янәсе. Исем дә китми, басып тик торам. Яшькә яшь булсам да, гәүдә бар миндә. Күләгәм коточкыч озын булып сузылган. Тегеләрнең күләгәләре минем күләгәм янында чебеш кенә.

Бераздан ак чиләкләрен асып килүче Вәсилә дә күренде. Әллә кайдан ук таныдым,— төшемә кереп йөдәткән кыз. Нык кына үскән, тулыланган, аяклары җиргә әллә тия, әллә юк — шул, нәкъ шул үзе.

Дөньядагы бөтен нәрсәне онытгым, сикереп каршысына чыгып бастым. Әлек икебез дә телсез калдык, аннары икебез дә берьюлы сөйләшергә тотындык. Мин аңа нәрсә әйттем, ул миңа нәрсә диде,— берсен дә белмим. Шахтада күргән азаплар онытылды, ялтыравыклы итекләрем дә онытылды, ахрысы, Вәсилә аларны бөтенләй күрмәде дә бугай.

Аннары ул, озак торырга ярамый, әнкәйләр ачулана дип, чиләкләренә су алып кайтып китте. (...)

Айдар чишмә янында Вәсиләнең кабат килүен көтеп торганда, аңа Мамалай авылы егетләре бәйләнәләр. Айдар алар белән сугыша, староста малаеның битен яралый. Аны ябып та куялар. Айдарны бик астыннан Вәсилә коткара. Кыз Айдарның авылдан тизрәк китәргә тиешлеген әйтә.

Киттем. Шул китүдә авылдан ук киттем. Таң атып килә. Ә ай һаман батмаган. Юл яп-якты булып сузылып ята... Әкрен генә атлап кайтып барам. Вәсиләгә әйтергә дип уйлап та, әйтелмичә калган сүзләр берсе артыннан берсе искә төшәләр. Аңа дип, әллә ничә йөз чакрым җирдән саклап алып кайткан бүләгем дә кесәмдә онытылып калган.

Ә мин аны инде кайчан күрәм? Күрәмме, юкмы?

Ачуым да бик килгән иде, шул китүдән мин үз авылыма кереп тә тормыйча, җәяүләп, Урал ягына киттем. Итекләрем чыдарлык, калганы турында уйлап та бирмим.

V

Шул китүдән ике елга якын йөрдем. Әтиләргә дә, Василәгә дә бер хат та язмадым. Әтиләргә ник язмадым? Буләсе малым булганнан түгел, үзем акча җибәрә алмаудан хурланып язмадым. Ике имана җирне сөрдерү өчен, яз саен байлар алдында бишкә бөгелгәнен белеп торам бит мин аның. Ә мин йөрим-йөрим — тапканым үземнән артмый.

Василәгә ник язмадым, үзем дә белмим. Әллә нинди кеше булып барам мин. Кемнәрдәндер үч аласы килү, билгесез ачу кайный миндә. Китсен, җәһәннәмгә олаксын Василәсе, дим кайчакта.

Шулай да Василә, магнит төсле, яңадан мине авылга тартып кайтарды. Йә солдатка алып куярлар, күреп калырга кирәк, дип уйладым.

Кесәмдә әллә ни рәтем юк, шулай да өс-башым рәтләдем. Кайтуым ярап куйды тагын, Мамалайда гөрләтеп туй итеп яталар, Василәне Сатыш авылының кибетче Зариф малаена кияүгә биреп куйганнар. Менә хат язмый йөрсәң. Ачуымнан нишләргә белмим. Эчтә бертуктаусыз кайнап йөргән билгесез ачу хәзер әзрәк билгеле була башлады инде. Чәйнәп ташларга кеше дә бар — кибетче Зариф малае.

Шулай да иң элек Василәнең үзен күреп сөйләшергә кирәк. Ниса түтине җибәреп чакырттым, килде. Агарып калган кызый. Күз карашлары авыр, керфекләре тагын да озыная төшкән төсле, балачактагы ялкыны эчкә киткән, эчтән яна белә башлаганга охшый. Үзе башлап бер сүз дә дәшмәде, үпкәләгән булса кирәк. Иреннәре әйтеп тора. Ә үзе шундый матур, шундый матур,— каршымда май ае төсле балкып тора. Эчемнән генә әйтеп куйдым:

— Ни туры килсә, шуны эшлим, ә сине кешегә бирмим.— Болай үзем шактый ук усал кыланам: — Туеңа кайтып өлгердем тәки, Василә, әйе бит,— дим.

— Кайтып өлгергәч яхшы инде,— ди ул, күтәрелеп карамыйча гына. Салкын итеп, ачу китерә торган итеп әйтә. Мин юри кызны үчекләргә теләп телемә салынам:

— Кибетче Зариф малае бөтен яктан кәеф булыр инде ул. Хәзер үк авызыңны прәннек белән тыгылдырган, сөйләшә дә алмый башлагансың.

Вәсилә кинәт яшеннән курыккан төсле сискәнеп куя, нидер әйтмәкче була, әйтми, бер читкә карап тагын тынып кала.

Нәрсәдер бар кызда: куркырга да, кире кайтырга да уйламый. Барып ике иңбашыннан тотам. Шундый рәхәт, салкын күмер тотып катып беткән кулларым йомшап ук киткән төсле булалар. Кулларым гына түгел, күңелем дә эри. Әллә нинди яхшы сүз әйтәсем килә, тел очыма гына килми.

— Их, Вәсилә, Вәсилә. Тагын әзрәк көтмәгәнсең бит. Мин сине үзем белән алып китмәкче булып кайткан идем.

— Бернинди хат-хәбәр җибәрмичә тагын әзрәк йөрер идең,— ди бу, һаман шулай күтәрелеп карамыйча гына. Аннары кинәт күтәрелеп карый, күзләрендәге җәһәннәм очкыннары барысы да берьюлы минем өскә чәчелгән төсле булалар.

Ә мин кем? Акчасыз кесә. Менә кем мин. Андый җәһәннәм утларына ничек чыдап торыйм:

— Ярый, хуш, алайса,— дидем дә ишеккә таба атлый башладым.

Вәсилә кинәт үзенең балалыгына кире сикергән төсле булды. Кузгалды, җиңел гәүдәсе белән очып минем муеныма килеп асылынды. Кочаклый, үбә, үзе елый-елый сөйләнә:

— Айдар, бәгырем, бәхетсез итмә башымны. Алып кит моннан. Иртәгә кияү килергә тиеш, ә син бүген алып кит. Синнән бүтән кеше юк минем өчен. Булмады, булачак түгел. Китик, җанкисәгем!

Болай булгач шатланырга, көләргә кирәк, ә ул, тинтәк кыз елый. Күзеннән тозлы су агыза. Яратмыйм мин күз яшен.

— Ярый, авызың прәннек белән тыгылмаган булгач, бик яхшы. Бүтәнен рәтләрбез. Иртәгә кичкә әзерләнеп тор. Атка салам да, алам да китәм.

Кызны шулай тынычландырдым да үзем, кешегә-карага күренмичә, тиз генә авылга кайтып киттем.

Икенче көнне, Сәфәргали җизнинең күк айгырын төпкә, Госманнарның кара туры алашаларын прәшкәгә җигеп, пар ат белән киттек тә бардык. Әни:

— Кая болай җенләнеп йөрисез? — дип төпченмәкче булган иде дә:

— Кайткач күрерсең, җыеныбрак торыгыз,— дигәч, үзе шуннан аңлады бугай инде.

Госман, мин, атларны тотып торырга тагын бер малай алдык. Кирәк-ярак булса дип аракы алып тыккан идем, авылны чыккач та аны бүлеп салдык. Әйбәт үк булып китте,— атлар икенче төрлерәк элдерә башлаган күк булдылар. Караңгы төшеп килә, йолдызлар калка башлады, әкрен генә булып кичке җил исә, биткә рәхәт, ә күңелгә аннан да рәхәтрәк. Әйбәт тә соң безнең як! Төннәре куе, караңгы, кыз урлаучыларны да, ат каракларын да яшерә. Шулай уйланып, дәшми-тынмый гына барам, колагымда тояк тавышлары, ә күктә малайчакны искә төшерә торган йолдызлар...

— Исән-сау ерып чыгып булса, кызның менә дигәненә тиенәсең инде син, малай,— дип, эледән-эле минем салпы якка салам кыстыра Госман. Исән-сау ерып чыксак, имеш. Пычагым булсынмыни безгә!.. Мине икенче нәрсә борчый. Әни аңлап калган булса ярый, хәзерләнеп торыр. Аңламаган булса, эш харап,— яңа кеше алдында сынатабыз. Хәер, төкерергә. Мәңге торасымыни ул монда.

Барып та җиттек. Әле ярый Ниса түтиләрнең өйләре басу капкасы төбендә үк. Атларны ишегалларына кертеп, туармыйча гына куйдык. Теге малайны атлар янына бастырып, Госман белән без бакча артлатып кына киттек.

Исмәгыйль абзый — минем иске таныш, ничек йөрергә кирәк икәнен азрак беләм. Аннары тагын Василә белән кичәнәк сөйләшенгән. Сәгать ун белән унберенче ярты арасында, яңа өйнең бакчага таба карый торган тәрәзәсендә, түбәнге өлгедә, рамда минем ак саплы пәке кадалып торырга тиеш. Шул пәкене күрүгә, Вәсилә, комган тоткан булып, тышка чыга. Бакчага керә, карт шомырт агачлары, карлыган куаклары, безнең иске танышлар, алар безне яшерәләр. Без, бакча коймасы аркылы төшеп, элек Ниса түтиләргә, ә аннан безнең авылга китәчәкбез. (...)

Минем пәке тәрәзә рамына кадалган килеш тора да тора. Аның үткен йөзе тәрәзә аша төшкән ут яктысында тагын да ялтырый төшә, койманың теге ягында Госманның куркынып мышнаганы ишетелә, ә Вәсилә чыкмый да чыкмый.

Бераздан, кайдандыр ерактан, эреле-ваклы кыңгырау тавышлары ишетелә башлады. Исерек авазлар күтәрелде, юлга тупырдатып баскан тояк тавышлары урам

өстендә яңгырап калды. Кияүне алып киләләр, кияү кайдадыр шушында, якында гына. Йөрәгем дөп-дөп тибә, әгәр Вәсилә чыкмаса...

Юк, чыкты. Әнә бакчага таба килә. Нәкъ сөйләшенгәнчә, кулында комган. Әнкәсе, баскыч төбенә чыгып, йомшак кына итеп нидер дәште дә кереп китте. Кереп китмәсә дә, барыбер алып китәчәк идем кызын. Тудырган, үстергән — аның эше бетте, үскәч алып китү — безнең эш.

Вәсилә нечкә генә итеп тамак кырып куйды. Күз ачып йомганчы, ул минем кулымда иде инде. Күтәреп алып бардым да җайлап кына бакча коймасының өстенә куйдым, койманың теге ягыннан Госман кулын сузган.

Кызның уңганлыгына тагын бер кат иман китердем — очынып кына тора. Ник кенә куркып карасын. Ә бит без аны киявенең авызыннан диярлек тартып алып китәбез.

Кыңгырау тавышлары колак төбенә үк килеп җитте инде. Кемдер, урамны яңгыратып: «Киләләр!» — дип кычкырып җибәрде. Ишек тавышлары, хатын-кызларның үзара пышылдаулары ишетелде: «Вәсилә! Син кайда, Вәсилә?»

Вәсиләгез койманың аргы ягында инде, аны тиз генә таба алмассыз. Ишегалдында ыгы-зыгы, ә мин, Вәсилә белән булышып, тәрәзә рамына кадалган пәкемне онытып калдыра язганмын.

— Йә инде, Айдар, калсын инде,— дип, куркынып дәшә Госман.

Нишләп пәке калдырырга? Ишегалдында кияү егетләре, хатын-кызлар, малайлар. Ишегалдында чыр да чу. Ә мин коймадан тавышсыз-тынсыз гына сикереп керәм дә, агачлар арасыннан кача-поса килеп, тәрәзә рамына кадалган пәкемне алам.

Ун минуттан без инде юлда идек. Атлар пыр тузып чабалар, чаба бирсеннәр, шулай рәхәтрәк.

Сораулар һәм биремнәр

1. Башка чакта бик сөйләшүчән, кыю малайның, Вәсилә белән ялгыз калгач, теле тоткарлана. Сөйләшер сүз таба алмый интегә. Ни өчен дип уйлыйсыз?

2. Айдар — тәвәккәл. Шахтага киткәндә, аның бу сыйфаты нәрсәдә чагыла?

3. Айдарның авыл малае булуы шахтада да күренеп тора. Күзәтүләрегез белән уртаклашыгыз.

4. Айдар — дуамал холыклы егет. Бу уңай сыйфатмы әллә тискәреме?

5. Айдар бераз мактанчык та. Бу сыйфат аны бизиме әллә киресенчәме?

6. Ни өчен Айдарда кешеләргә карата ачу хисе үсә бара? Гомумән, кешеләргә үчләнү дөресме?

7. Вәсилә дә тәвәккәл. Аның тәвәккәллегенең сәбәбен аңлатып бирегез.

8. Сезнең кыз урлау турында тагын нинди әсәрләр укыганыгыз бар? Аларның кайсыларында бу эш уңышлы тәмамлана, ә кайсыларында хәтта фаҗига белән бетә? Ни өчен? А. Шамовның «Кыз урлау» дигән хикәясен табып укыгыз. Аның буенча сөйләшү уздырыгыз.

VI

Бүген инде безнең өйдә ыгы да зыгы. Әни йөри чабулап, Зөһрә апа йөри чабулап, мәче йөри чабулап. Иртәдән бирле мич яна, чаж да чож таба тавышы, минем тавышка урын да юк. Мәш киләләр. Килен үзе дә җиңнәрен сызганып алган, итәк кыстырулы, кулы кулга йокмый. Әнинең авызы колакта, бер тиенсез өйгә килен кайткан, янәсе.

Хәер, үземнең дә кәеф күтәренке — өйләнәм дигән сүз бит. Әлек карт-коры, күрше-күлән, туган-тумача җыелып үзләре генә утырдылар, безне кертмәделәр. Кич белән без утырдык, картларны кертмәдек. Мулла никахны укыды, Вәсилә хәзер минеке инде, теге вакыттагы төсле, алма белән атып кына китә алмас.

Әни ак келәткә бик әйбәтләп урын җәеп куйган, узганда-барганда кырын күзне салып йөрим. Шулай да кызны алып кайтышкан иптәшләрне, аннары тагын җәйнең эсселегеннән авызлары кибеп йөри торган барлык авылдашларны бер сыйламыйча ярамый бит...

Әти миннән качырып әзерләгән булган, мин әтидән качырып — аракы су урынына ага. Егетләр телләренә салына башладылар, болай сыйлагач, иртәгә без сиңа тагын бер кыз урлап алып кайтып бирәбез, диләр. Ул мине мактау, ул әтине мактау, фәрештә сөтеннән оешкан кешеләр булдык та калдык. Тамак төбе кычытуын кычыта, сүзләрем дә бар, дәшеп кенә булмый. Үз туеңда үзең тавыш чыгару күңелле түгел.

Үземне мактауга чыдап та утырган булыр идем, бервакытны Госман Вәсиләне мактый башлады. «Кызга

тиендең инде, Айдар, кадерен белеп кенә тор, билен сындыра күрмә. Кичә койма өстеннән күтәреп алганда, ялгышлык белән кулым биленә тиеп киткән ие, малай, ай бил үзендә, ай бил, җанкисәгем»,— ди. Тагын әллә ниләр лыгырдый. Түзмәдем, өйалдына чакырып чыгардым тегене.

— Йә теленә салынмыйча гына утырасың, йә мин сине тәрәзәдән атам,— дидем.

Җебүе җиткән каһәрнең, шаркылдап көлә генә.

— Мактаганга нигә кылтаясың, кәләшеңне мактыйм ич. Мактарлык җире булганга күрә мактыйм,— ди.

— Сүзеңне үлчәп сөйләмәсәң, күр дә тор, телеңне суырып алып, колак тишегеңә тыгып куярмын.

Һаман тыелмый бу, ә күзләре шундый хәтәр ялтырый.

— Телемне өзеп алганчы, әйтәсе сүземне әйтеп бетерим дип тырышкан ием, ярый инде алай булгач, әйтәселәрен дә әйтми калдырам.

Өйалдында сукыр ут кына, шулай да күрәм: башын исереклеккә салып кылануында ниндидер шик бар аның. Эчемдә нидер кайнап уяна, бервакытта да болай булганым юк иде. Мин хәзер аңа тик тор дип түгел, сөйлә дип бәйләнәм. Ә ул, юри минем ачуымны китереп, күзгә карап тик тора.

— Мин сине сөйләтермен. Әйтмәгән сүзләреңне бугазыңны буып әйттерермен.

Госман селкенми дә, минем кунагым булганга күрә шулай батыр кылана ул. Шулай да теленнән ычкынып китте:

— Нигә миннән әйттерергә, иялә шә төшкәч, Вәсиләң үзе дә әйтер аны.

Сулышым эчемә сыймый, йөрәгемдә мең төрле елан берьюлы кузгала, ә аларның берәвесе чыкса да эшең харап синең, Госман! Мин Госманның якасыннан каптырып алам, күзләрем аның күзләрендә.

— Син ни дидең, курнос танау? Әйт, син ни дидең?

— Вакыты җиткәч, Вәсиләң үзе дә әйтер, дип әйттем ич инде.

— Тел төбеңдә нәрсәдер бар синең. Әйт, Вәсилә турындамы?

Минем йөрәгемдә мең төрле шик кайный, ә ул ыржаеп тик тора. Тешләрен күрмәс ием, каһәрнең. Якасы кулымда, нишләтергә дә белмим.

Күзне күзгә терәп күпме торганбыздыр, берчакны бу, берни дә булмаган төсле, уен-көлке белән кушып әйтеп тә ташлый:

— Нигә ул чаклы ярсырга аңа. Үзең дә тик кенә йөрмәгәнсеңдер әле... Васыйләнең дә җаны бар ич. Син булмасаң, монда без калдык.

Моннан да артыгы кирәк түгел. Йә ул моны ничек булса да күрсәтеп бирә, йә мин үземнең бөтен еланнарымны берьюлы аның өстенә җибәрәм.

Эшнең шуңа таба баруын ул үзе дә сизде, ахрысы, кулын минем нәкъ күзләрем алдына китереп терәде. Аның чәнчә бармагында кашы йөрәк төсле итеп коелган көмеш йөзек ялтырый иде.

— Укы! — диде ул, миңа йөзек кашын күрсәтеп.— Монда нәрсә дип язылган?

Чынлап та, йөзек кашында кечкенә генә булып «واسیله» («Васыйлә») дигән исем янып тора иде.

Кинәт айнып киттем, кулымны Госманның якасыннан ычкындырдым. Янган баганадай тик басып торам, кайдан тотынырга, нәрсәдән элеп алырга икәнен белмим. Ә Госман, йөрәкне бозып, һаман сөйләнә:

— Ихтимал, ул сине кайтмас дип уйлагандыр, ике елга якын берниндИ хәбәрсез йөрдең бит. Көтмәгәндә генә кайтып төштең, ул чагында йөзек минем бармакта иде инде. Син юкта бер-ике тапкыр Сабан туе булып алды, ә Сабантуйларында Мамалай кызларының ничек кыланганын үзең беләсең. Бигрәк тә кунак егетләре белән...

Бер сүз дә дәшмим, басып тик торам. Каршымда сукыр ут яна, әллә шул сукыр уттан тотыныргамы?

Күпме басып торганмын, чайкалып, башымны күтәреп җибәрдем. Өйдә шаулашалар, ник шунда асты өскә килми. Госман кереп китте. Ә мин нидән тотынырга белмичә торам да торам. Васыйлә чыкты. Чыкканда кояш төсле иде, мине күргәч, бөтенләй коелып төште.

— Нишләп болай үзең генә торасың, Айдар? Башың авыртамы әллә? — ди бу.

Куллары белән минем башыма сузыла. Кулларын кире этәрәм.

— Бар, кереп кит,— дим.

Ул кереп китми, минем янымда басып тора, үзе дерелдәгәннән-дерелди.

— Кереп кит, диләр сиңа! — дип кычкырып җибәрәм.

Тавышымнан өйалдындагы сукыр ут сүнә. Без караңгылык эчендә күмелеп калабыз. Василә хәзер үзе күренми, бары тик калтырап чыккан тавышын гына ишетәм:

— Нигә болай үпкәләдең, Айдар? Әйт, ни булды сиңа?

Кулларым белән капшап аның кулларын табам,— җылы, ачуны баса торган йомшак куллар. Ул арада Госманның теге сүзләре исемә төшәләр,— куллары салкын бакаларга әйләнгән кебек була. Җилкәсеннән этеп, Василәгә келәтне күрсәтәм:

— Синең белән сүз соңыннан булыр, бар, келәткә кер дә көтеп утыр.

Ул, һичбер каршылыксыз, келәткә кереп китә. Бераздан аның келәт ишегенең элгечен эчтән төшереп бикләнгәнлеген ишетеп калам. Ярый, ныклап исәпләшәсе кешем хәзер минем кулда. Калганын әкренләп сүтәрмен әле.

Бөтенесен бозып ташлау өчен берничә юл бар. Берсе — башны исерекләккә салып өйгә керергә дә Госманны тәрәзәдән тотып бәрергә. Ошамый. Госманның ни гаебе бар монда? Кыз үзе кочакка атылып кергәч, Госман кочагын җәйми нишләсен? Аннары тагын, ни генә димә, ул бит минем кунагым. Үз кунагыңны үзең тәрәзәдән ташлау безнең Янбулатта булган хәл түгел. Икенче юлны беләм, ансы да ошап бетми.

Бөтен бәлам дә шунда: мин эшне уйлап эшли алмыйм. Өченчесе ошыймы-юкмы дип тормадым, йөгереп урамга чыктым да, зур гына бер таш табып, шуның белән үз тәрәзәбезгә — ялт. Пыяла чалтырап коелды, калганын мин күрмәдем. Өйгә әйләнеп кергәндә, мәҗлес тузгыган, кешеләр ташны кулдан кулга йөртеп берсенәберсе карашалар, тәрәзәгә каршы якта утырган Саттар башын тотып изалана, аның бармаклары араларыннан кан бәреп чыккан. Таш бөтенләй гөнаһсыз кешегә эләккән икән, чамаламыйчарак җибәргәнмен шул.

Пыяла куючы безнең үзебездә, безгә унбиш тиен зыян, аңа унбиш тиен файда, ә шулай да мәҗлесне тузгыту өчен ярап куйды бу таш.

Кешеләр үзара буталышкан арада, мин тиз генә таеп өлгердем. Келәткә, Василә янына кереп бикләндем.

Ул келәттә ялгыз елап ята-ята шешенеп беткән, сүзләрен дә рәтләп әйтә алмый, ә миңа ничек кенә булса да аның сүзләрен ишетергә кирәк.

Йомшак тәнле ул кыз тырнак өчен зур, йодрык өчен кечкенә, ә гаебе аның ни эшләсәң дә торырлык. Шулай да мин аңа тырнак белән дә чиертә алмадым, кулым күтәрелмәде, ир кеше кулы өчен артык юка иде шул ул. Аннары тагын кыйнашу өчен кызлардан бүтәннәр дә җитәрлек ич.

Үч алуның икенче юлын да беләм мин. Көйдерә торганрагын да.

Ләм-мим сүз кузгатмыйча, янына килдем. Биленә кулымны салдым — янып тора кыз. Келәтнең кечкенә тәрәзәсеннән ай күренеп китте, эти ясап куйган юкагач кроватьның ак аягы чагылды. Дөньяда ачу килү бар, үч бар, шуның белән бергә тагын дөньяда кроватьның ак аягы, юаш кына ай, сулышын еш-еш алып сине көтеп утыручы дәртле кыз бар.

Башымда шундый уйлар буталып киткәнен беләм, бүтәнен белмим. Бөтенләй җебеп кала язганмын, утка янсын кроватъ аягы. Күпме вакыт узгандыр, ай болыт астына кереп качты, келәт эче караңгыланып калды. Бая, утка баскандай чабулап йөргәндә, итегем белән ташка бәрелгән идем, ертылмаганмы дип, шырпы сызып итекләремне карадым. Шунда, шырпы яктысында, ялгыш кына күзем төшеп китте: Вәсилә, куркынып, кроватька ятар-ятмас аптырап калган, аның куе-кара чәчләре, ак мендәр өстенә яртылаш тузгып, таралып төшкән иде.

Ичмасам күзләрем күрмәсен дип, шырпыны тиз генә сүндереп ташладым. Бер сүз дә дәшмичә аягымны салып киендем.

— Син нишләп болай торасың, Айдар? — дип, нидер сизенеп, борчылган тавыш белән дәшеп куйды ул. Мин тәмам киенеп бетмичә җавап бирмәдем.

Киенеп беттем, чыгып китәсем генә калды, аягым атламый да атламый. Теге йомшак тавыш тагын кабатланды:

— Син нишләп болай... Айдар?

Аңлаша башласам, озакка китәр, йә тагын, мәлҗеп куеп, кочагына егылып төшүең бар, үч булгач үч булсын, үзенә түгел, кроватена да борылып карамадым.

— Мин хәзер әйләнеп керәм,— дидем дә келәттән чыгып киттем. Бу минем Вәсиләгә беренче мәртәбә ялганлавым булды, икенче мәртәбә ялганларга да, дөресен сөйләргә дә туры килмәде.

Шул чыгып китүдән, беркемгә дә әйтмичә, мин тагын Донбасс ягына юл тоттым.

1942 ел

Соңыннан билгеле булганча, кызны урлап койма аша чыгарганда, Госман Вәсиләнең йөзеген аңа сиздерми генә үзе салдырып алган икән. Вәсиләнең Айдар алдында бернинди дә гаебе юклыгы, кызганыч, бик соң ачыклана.

Сораулар һәм биремнәр

1. Айдар үзе турында: «Мин эшне уйлап эшли алмыйм»,— ди. Әсәрдән моңа мисаллар табыгыз. Аның мондый гадәтенә сезнең мөнәсәбәтегез ничек?

2. «Акылы алдан йөри, эше арттан йөри», «Эше алдан йөри, акылы арттан йөри». Бу җөмләләр белән белдерелгән фикернең кайсысы Айдарга туры килә? Чынында кеше боларның кайсысы белән яшәргә тиеш?

3. Госманның мәкерлелеге әсәрдәге вакыйгаларның кайсы урынында үзенең иң югары ноктасына җитә? Әгәр Айдар урынында бүтән берәү булса, вакыйга башка эздән китмәс идеме?

«ЙӨЗЕК КАШЫ» ПОВЕСТЕ ТУРЫНДА

Йөзек кашын бик матур җемелдәп торган асылташлардан ясыйлар. Андый таш гади ташлар арасына ташланса да югалмый, кояш нурларында җемелдәп, әллә каян күренеп тора. Фатих Хөснинең бу әсәре белән дә шулай булды. Әлеге повесть әдәбиятыбызның гаять зур байлыгы эчендә югалып калмады. Ул туган көненнән алып әлегәчә яратып укыла, анда сурәтләнгән образлар укучыларның күңелендә йөри. «Бу лирик-романтик повесть — авторның иҗатында, чыннан да, йөзек кашы төсле ялтырый торган әсәр. Татар әдәбиятында аның тиңдәше юк, дисәк тә ялгыш булмас»,— дип язды повесть турында икенче бер күренекле әдибебез Ибраһим Гази.

Повесть ни өчен укучыга якын соң? Аның сәбәбе нидә? Бу сорауга төрлечә җавап бирергә мөмкин: язучының тормышны дөрес итеп сурәтләвендә, җор телендә, вакыйгаларны кызыклы итеп күрсәтеп бирүендә... Шулай да төп сәбәп — анда сурәтләнгән Айдар белән Вәсилә образларының, аларның күңел дөньяларының, язмышларының бөтен ачыклыгы белән, җанлы кешедәй гәүдәләнүендә. Укучыны алар кичергән хәлләр борчый, тетрәндерә, биләп ала.

Әсәр үзәгендә, әлбәттә, Айдар образы тора. Баштан ук ул үзенең сөйкемлелеге, шаянлыгы, шуклыгы, җорлыгы белән җәлеп итә. Айдар укучы күз алдында үсә, җитлегә бара. Еллар үткән саен, аның холкына яңа сыйфатлар өстәлә: тәвәккәллек, кызып китүчәнлек, дуамаллык, хезмәт сөючәнлек, әти-әнисенә карата җылы мөнәсәбәт, гаделлек... Күрәбез: аңарда уңай сыйфатлар булган кебек, тискәреләре дә җитәрлек. Ф. Хөсни үзе дә, бу герое турында уйланганда, болайрак фикер йөртә: «Үрнәк булырлык язмышмы бу диярләр. Алдан ук әйтәм, түгел. Киресенчә, аның күп кенә яклары минем үземә дә ошамый. Ләкин тормыш — шуның өчен дә тормыш ул, аның законнары минем яки синең кәеф белән генә исәпләшеп тора алмый. Әйе, тормышта Айдарлар да бар. Үрнәкме алар, түгелме? Ләкин андыйлар бар һәм, димәк, тормышның бүтән яклары белән бергә аларның да җырга кереп калырга хаклары бар. Ә дөрес нәтиҗәне укучы үзе ясый алыр, дип уйлыйм мин, авызына чәйнәп салганны көтеп утыра торган яшьтә түгел ул хәзер».

«Йөзек кашы» повесте Бөек Ватан сугышының иң куркыныч елында язылган. Бу вакытта язучылар күбрәк фронттагы, тылдагы хәлләр, дошманга каршы көрәш турында, ул чактагы юлбашчыларны мактап яздылар. Аларга бары тик югары идеяле уңай геройларны гына сурәтләргә туры килә иде ул елларда. Ф. Хөснинең шул чорда мәхәббәт лирикасы белән сугарылган, җыр шикелле җиңел укыла торган әсәр язуы, анда Айдар кебек уңай һәм тискәре яклары булган кеше образын сурәтләве үзе бер зур яңалык булды. Чөнки сугыш вакытында кырысланган күңелләр матурлыкка нык сусаган иде.

Айдарның баштан ук күренгән уңай сыйфаты — матурлыкны бәяли белүе. Василәнең гүзәл кыз булуын ул беренче күрүдә үк чамалый. Аңарда бу чибәр кызчык белән сөйләшеп китү теләге туу табигый. Ул аны кыз авылдан китеп баргач та оныта алмый. Кыз биргән алманы да ашамый, кулында йөртә, чөнки ул аңа бик кадерле. Алманың кызыллыгы кызның бит алмасын хәтерләтә, кулының җылысын саклый сыман.

Әсәрне мәхәббәт турында җыр дип әйтергә була. Мәхәббәт ул — бик матур, җылы, рәхәт хис. Өзелеп яраткан кеше матур була. Ул матур уйлый, матур сөйләшә, матур гамәлләр кыла. Василә белән Айдар — бер-берсен ихлас яратучы егет белән кыз — укучыга нәкъ менә шуның өчен якын, кадерле.

Матурлыкка бөтен күңеле белән гашыйк кеше ямьсез күренешләрне бер дә яратмый. Айдарның холкында килеп чык-

кан үзгәрешләр әнә шул ямьсез күренешләргә җавап буларак барлыкка килә дә. Күз алдына китерегез: вакыйгалар менә болай барырга мөмкин идеме? Айдар Сабан туендагы ат чабышында бернинди каршылыксыз беренче булып килә, Вәсилә белән шунда чын-чынлап танышалар. Шахтада эшләп, өстенбашын рәтләп кайткач, кыз белән өйләнешәләр дә бәхетле гомер кичерәләр. Әлбәттә, мөмкин иде. Моңа нәрсә комачаулый? Көнчелек, кешенең өстенлеген күралмау, башкаларның бәхетсезлегеннән тәм табу. Госман — үзендә менә шушы тискәре сыйфатларны туплаган сөйкемсез егет. Аның мондый яклары кечкенәдән үк күренә башлый. Башта ул Айдарга: «Кыз алманы сиңа атмады»,— дип хәрәмләшә. Ат чабышында Айдарның атына суга. Айдар да җавапсыз калмый. Әмма Айдарның бу гамәле укучы тарафыннан гаепләнми, чөнки ул әшәкелеккә җавап кына бирә. Госман ахырда Вәсилә турында яла сүз әйтә, аны Айдарга тугры булмауда гаепли. «Вәсилә» дип язылган йөзекне күрсәтә. Бу — бернинди әхлак киртәсенә сыймый торган эш. Шуның белән ул ике яшьнең бик матур буласы тормышын чәлпәрәмә китерә.

Госман ни өчен мондый адымга бара? Ул Вәсиләне ярата мы? Юк. Әллә кызны үзенә алырга телиме? Юк. Аның теләге бер: ул кеше бәхетсезлегенә куана, шуннан тәм таба. Госман — күңеле белән ямьсез кеше. Ул Айдарны гомере буе эзәрлекли. Шундыйларга җавап итеп Айдар да үзгәрә бара. Үсеш, үзгәреш каршылык булган җирдә күзгә күренебрәк, тизрәк барлыкка килә. Айдар әсәрдә бик кискен хәлләрдә кала. Һәм ул мондый кискенлеккә каршы дуамалланып җавап та бирә.

Әсәрдәге вакыйгаларның әнә шулай өермәле булып баруының сәбәбе — Айдарның холкы. Әгәр ул сабыр, җиде кат үлчәп, бер кат кисә торган кеше булса, Госманның бу әшәкелекләренә исе дә китмәс иде. Госман да аның бу гадәтен үз мәнфәгатьләрендә оста файдалана. Димәк, сюжетны барлыкка китерүче төп көч — Айдарның холкы, табигате, дип әйтә алабыз. Күргәнебезчә, ул аңа бик күп бәхетсезлекләр алып килә. Минем холкым — минем язмышым дигән сүз бу очракта тулысынча аклана.

Шуңа күрә, үскән саен, үз холык-фигыленә игътибарлырак булырга, андагы тискәре башлангычларны киметә барырга, матур сыйфатларның артуына ирешергә кирәк. Әйләнә-тирәндәге кешеләрнең асылын танырга өйрәнү — шулай ук бик мөһим.

Госманның кара эчле булуын вакытында күрә алмавы Айдарга бик кыйммәткә төшә.

Ф. Хөснинең бу әсәре сезгә, кадерле укучылар, тормышны, кешеләрне тагын да яхшырак аңларга ярдәм итәр.

Сораулар һәм биремнәр

1. «Йөзек кашы» повестеның укучыны җәлеп итү көче нәрсәдә?

2. И. Гази каләмдәше Ф. Хөсни иҗатына нинди бәя бирә?

3. Айдар урынында булсагыз, сез бу әсәр эчендәге вакыйгаларда нәрсә эшләр идегез?

4. Айдар холкында нинди сыйфатлар өстенлек итә: уңаймы әллә тискәреләреме?

5. Мәхәббәт — иң нәфис хис. Ул кешегә ничек тәэсир итә? Вәсилә мәхәббәте хакына нинди адымнарга бара?

6. Бу әсәрдә Госман образын сурәтләү язучыга нигә кирәк булган?

7. «Йөзек кашы» повестеның сугыш вакытында язылуының нинди әһәмияте бар?

8. Түбәндәге темаларга инша языгыз:

а) «Егерме беренче гасыр егетеннән (кызыннан) Айдарга хат».

ә) «Вәсилә! Мин дә синеңчә эшләр идем».

б) «Минем холкым — минем язмышым».

в) «Мин Айдардагы нинди сыйфатларны үземдә булдырыр идем?»

г) «Минем Госман образына мөнәсәбәтем».

Типиклык төшенчәсе. «Типиклык» сүзе грек теленнән алынган. Ул образ дигән мәгънәне аңлата. Бу атама ярдәмендә уртаклык, охшашлык дигән төшенчә белдерелә. Әйдәгез, тирә-юньдәге кешеләрне күзәтик әле. Аларга хас уртак яклар күп. Болар — кешеләрне берләштерүче гомуми яклар, ягъни типик сыйфатларны тәшкил итә. Кешеләрнең типиклыгы алар яши торган заманга да бәйле.

Әдәби образ типиклык белән индивидуальлекнең кушылмасыннан гыйбарәт була. Вәсилә, мәсәлән, авыл кызларына хас булганча, сабыр, саф, эчке гүзәллеге белән ачыла. Аның бу сыйфатларын башка бик күп татар кызларында да күрергә мөмкин.

Фатих Кәрим
(1909—1945)

Фатих Кәрим — һәр шигырь юлы белән Ватанга фидакарь хезмәт иткән җырчы һәм солдат. Аның Казан музеенда саклана торган шинеле генә түгел, кулъязмаларының соңгы битләренә кадәр пулялар белән тишкәләнеп беткән.

Луи Арагон, француз язучысы

Фатих Кәрим — татар шигъриятенең горурлыгы. Аның әсәрләрен халкыбыз яратып укый. Ул гомеренең теләсә кайсы чорында да үзенең шагыйрь икәнен, халкына тугрылыклы булырга тиешлеген онытмады.

Аның беренче шигыре 1927 елда Мәскәүдә чыга торган «Кечкенә иптәшләр» журналының 2 нче санында басыла. Ул «Хәзер сезнең белән» дип атала. Әсәрдә сурәтләнгән көтүче малайга әтисе курай бүләк иткән. Малай аны ямьле җәйге урман буйларында уйната, аның кураена сандугачлар кушылып җырлый. Ата-анасыз малайга бу — зур юаныч. Малай хәзер «ярдәмләләр[1]» булышлыгы белән укырга килгән. Бирәдә дә кулыннан яраткан кураен төшерми. Әтисе элек, курайда моңлы көйләр уйнап, тыңлаучыларны елаткан, ә малай шатлык көе уйный.

Без бу шигырьдә кечкенә Фатихның үз язмышын күргәндәй булабыз. Тугыз яшендә вакытта аның әтисе үлеп китә. Әтисе, сукыр булса да, үзе өчен генә шигырьләр чыгара, аларны балаларына сөйли торган була. Апасы Мәрьям дә лирик ши-

[1] Авыл халкы, акча җыеп, аңа укырга мөмкинлек тудырган.

гырьләр яза. Аларның Ает авылы яныннан гына гүзәл Дим елгасы ага. Шигырьләрендә апасы күбрәк әнә шул матурлыкны җырлый. Абыйсы Ярлы Кәрим исә (чын исеме Габдулла) ул елларда шагыйрь булып таныла, аның әсәрләре еш кына газета-журналларда басылып килә. Боларның һәммәсе Фатихны да иҗатка дәртләндерә. Татар әдәбиятына якынрак булырга омтылуы аны Казанга тарта. Дөрес, ул әдәбият-сәнгать уку йортына түгел, бәлки, абыйсы тәкъдиме буенча, җир төзү техникумына укырга керә. Һәм менә шул елларда (1925—1929) ул даими яза да башлый. Сигез ел эчендә (1929—1937) яшь шагыйрь ун китап чыгара. Ләкин шәхес культы шаукымы Ф. Кәримгә дә кагыла, байтак вакыт аңа тоткынлыкта интегергә туры килә. Ул шигырьләрен төрмәдә дә яза. 1941 елның декабрь башында аны азат итәләр.

Фатих Кәрим 1941 елның 30 декабрендә сугышка китә. Аның каләм көче бу елларда аеруча ныгый. Шагыйрьнең госпитальдән тылга җибәргән хатында мондый юллар бар: «Язам. Окопта да яздым, сугышта да яздым, монда да язам. «Совет әдәбияты» белән «Кызыл Татарстанга» күп әйберләр җибәрдем. Тик язган әйберләремә анда ни бәя бирәсездер? Ә мин язам да язам. Кирза итекнең кунычын өстәл итеп, шыгрым тулы товарный вагон полный ходка барганда да язам. Шигырь язарга өйрәнү өчен, кичергән елларның файдасы күп булды. Тик менә кәгазь юк».

Чыннан да, Ф. Кәрим Бөек Ватан сугышы елларында күп һәм сәнгатьчә югары дәрәҗәдәге әсәрләр иҗат итте.

Мин рядовой солдат бу сугышта,
Тик бер нәрсәм белән аерылам:
Рядовойлар төнен йоклаганда,
Мин йокламыйм шатлык, кайгыдан.

Бер минут та башка тынгы бирми,
Окоп почмагында утырам,
Аламын да куен дәфтәремне,
Янып, җыр язарга тотынам.

Ут булмаган җирдә ай яктырта,
Җыр хакына кала йокылар;
Окопларда язган хатларымны
Хөрмәт белән дуслар укырлар,—

дип язды ул. Әнә шулай йокы, ял исәбенә шагыйрь унга якын поэма, баллада, йөзләгән шигырьләр, ике повесть һәм бер пьеса иҗат итте. 1943 елда, мәсәлән, ул «Мәхәббәт һәм нәфрәт»

исемле шигырьләр һәм поэмалар җыентыгын, «Разведчик язмалары» повестен, ә тагын бер елдан «Моң һәм көч» дип аталган шигырь китабын нәшер итә. Сугышның соңгы елында исә «Язгы төндә» повесте басыла. Алар укучыларның яраткан китапларына әверелә, әлеге китапларга карата матбугатта уңай бәяләмәләр басыла. Ф. Кәрим моңа бик куана, нәтиҗәле иҗат итүенең сәбәбен бик гади генә аңлата: «Минем язган әйберләрем уңышлы санала икән, моның төп сәбәбе шушы: канымны коеп сугышам, шуның турында шул хис белән язам».

Рус халкында шундый сүз бар: «Туплар гөрселдәгәндә, җыр тынып тора». Әмма Ватан сугышы елларында илебез халыкларының, шул исәптән татар шигъриятенең тавышы тагын да ышанычлырак яңгырады, җиңүгә якынайган саен, аның халыкка тәэсире көчәя генә барды.

Ф. Кәрим һәм М. Җәлил иҗаты сугыш елларында иң югары биеклегенә күтәрелде. С. Хәким әйткәнчә, «шагыйрь берзаман ачыла, һәм син үзең дә соңыннан аптырап каласың. Тукта, бу ничек икенче баскычка, иҗатында бөтенләй икенче баскычка күтәрелә алды, менә алды? Фатих Кәримнең Ватан сугышы лирикасын укыганнан соң, шул фикергә киләсең. Күп еллар буена эчке бер хәзерлек, уйлануларында туктаусыз эзләнүләр барган, аларга ниндидер вакыйгаларның бәрелүе кирәк булган. Менә шушында шагыйрь йөрәге икенче төрле көчкә әйләнә, һәм җанының тынычлыгы бетә. Алдында ил азатлыгы, халык азатлыгы, үзенең ирке, туган җире, туфрагы. Шушы нәрсә аны Фатих Кәрим иткән, шигырьләрен икенче баскычка күтәргән чор — бу Бөек Ватан сугышы чоры. Сугыш, һөҗүм, азатлык».

Өлкән шагыйрь хаклы. Чыннан да, Ф. Кәрим кеше һәм гражданин буларак та, сугышчы һәм шагыйрь буларак та гомеренең соңгы дүрт елында аеруча өлгерде, ачылып китте, ялтырап алды. Моның шулай икәнлеге каләмдәш дусларының хатларыннан да ачык күренә.

«Вак-төяк турында язарга булыр иде дә, шигырьләрең турында әйтми калырмын дип куркам. Барысыннан да бигрәк, миңа «Сибәли дә сибәли», «Кайгы», «Таң», «Окоп» дигән шигырьләрең ошады. Менә, ичмасам, чыннан да настроение шигырьләре[1]. Укыйсың, җан чистарып, сафланып киткән төсле

---

[1] Настроение шигырьләре — кешенең хис-кичерешләрен, эчке халәтен аңларга ярдәм итә торган шигырьләр.

була. Авыр да, моңсу да, ләкин ерак түгел «тавис кошы төсле» булып кояшның җилкенеп торганын күрәсең. Рәхәт булып китә» *(Фатих Хөсни)*.

«Сәламәтлек һәм озын гомер телим сиңа! Шигырьләреңне укыдым һәм бик яраттым. Яраттым гына түгел, блокнотыма күчереп алдым. Син чын мәгънәсендә адәм балаларының йөрәген айкый торган лирик шигырьләр язгансың. Мин бик шат, чын күңелдән, саф күңелдән шат» *(Ибраһим Гази)*.

Шагыйрь һаман дәртләнеп иҗат итә. 1944 елның май аенда язган хатында, мәсәлән, ул болай ди: «Минем яза башлаган бик кызыклы әйберләрем бар. Алар сыйфатлары белән моңа чаклы язылган әйберләрдән югары булырлар дип нык, нык ышанам. Мин үземдә тагын да ныграк үскән иҗат көченә нык ышанам. Әле сокланырлык әйберләр язармын мин».

Әйе, сугыш араларында никадәр күп һәм берсеннән-берсе гүзәл әсәрләр язган шагыйрь Ф. Кәрим тыныч елларда нинди генә әдәби җәүһәрләр бирмәс иде! Тик гомере кыска булган икән шул. Нинди үкенеч, сугыш бетәргә ике ай ярым калганда, 1945 елның 19 февралендә ул батырларча һәлак була. Шагыйрь сугышкан частьның политбүлегеннән Татарстан Язучылар берлеге идарәсенә хат килә. Анда мондый сүзләр бар: «Безнең часть немец-фашист илбасарларына каршы авыр сугышлар алып барды. Ф. В. Кәримовка фашистларны 37,8 биеклегеннән бәреп чыгарырга һәм шунда ныгып калырга дигән бурыч куелды. Бу бурычны үтәүнең бөтен сугыш нәтиҗәсе өчен зур әһәмияте бар иде. Кече лейтенант Ф. Кәримов үзенә төп хәрби бурычны үтәү йөкләтелгәнне яхшы аңлады, ул үзенең взводы белән көчләре күп өлеш артыграк булган дошманга каршы кыю рәвештә сугышка ыргылды. Фашист бандитлар, бу аз санлы кыюларны биеклектән куып төшерергә теләп, биш тапкыр каршы һөҗүмгә күчтеләр. Ләкин зур югалтуларга дучар булып, артка тәгәрәделәр».

Шушы бәрелештә һәлак булган Фатих Кәримгә батырлыгы өчен «Беренче дәрәҗә Ватан сугышы» ордены бирелә. Әлеге орден Казанга 1966 елда гына килеп җитте. Ф. Кәрим язган шигъри юллар аның үзенә бик тә туры килә:

Шулай үлде Ватан улы
Сугыш барган кырларда:
Сагынган саен, без аны
Бик биеккә, зәңгәр күккә
Күтәрербез җырларда.

Сораулар һәм биремнәр

1. Фатихка шагыйрь булып тәрбияләнергә нинди шартлар ярдәм итә?

2. Ф. Кәрим Ватан сугышы елларында аеруча күп һәм уңышлы иҗат итә. Ул үзе моны ничек аңлата?

3. Луи Арагон, Фатих Хөсни, Ибраһим Гази, Сибгат Хәким кебек каләмдәшләре шагыйрь шәхесен һәм иҗатын ничек бәялиләр?

4. Фатих Кәрим, Муса Җәлилләрнең язмышларындагы һәм иҗатларындагы уртак һәм аермалы якларны күрсәтегез.

5. Ф. Кәримнең «Сибәли дә сибәли», «Кайгы», «Таң», «Окоп» һәм башка шигырьләрен табып укыгыз. Аларда кешенең хис-кичерешләре, эчке дөньясы ничек гәүдәләнә? Кеше күңелендә тагын нинди хисләр була? Шуларны аңлатыгыз.

6. «Мин рядовой солдат бу сугышта» дип башланган шигырьнең өч строфасына да рәсем ясарга тырышып карагыз. Уңышлы дип табылган рәсемнәрдән сыйныф бүлмәсендә күргәзмә оештырыгыз.

7. «Шагыйрьнең иҗаты аның гамәлләреннән аерылмый» дигән фикерне Фатих Кәрим үткән тормыш юлы белән дәлилләгез.

АНТ

Юлбасарлар таптый җиребезне,
Ватан сугышына мин китәм.
Менә — балам. Син — әнкәсе аның,
Балабызны тотып ант итәм:

Синең өчен, шушы балам өчен,
Нәселем өчен, Туган ил өчен
Мылтык тотып баскан җиремнән
Бер адым да артка чигенмәм...

Бәлки, соңгы тапкыр күрештек,
Кочаклаштык, озак үбештек.
Сизә бала, карый күзләремә:
«Сакла безне!» — ди ул күңеленнән,
Ана күкрәгеннән суырып алган
Сөт тамчысы алсу иренендә.

Шушы балам өчен, синең өчен,
Нәселем өчен, Туган ил өчен
Мылтык тотып баскан җиремнән
Бер адым да артка чигенмәм!

1942 ел

Хөрмәтле укучылар, сез «Ант» шигырен укып чыктыгыз. Анда сурәтләнгән күренешләр күз алдыгызга килеп басты. Тыныч кына, матур гына яшәп яткан илебезгә фашистлар басып кергән. Алар кешеләрне үтерә, йорт-җирләрне яндыра, байлыкны талый. Шундый вакытта ир кеше нишләргә тиеш? Әлбәттә, ул, әлеге вәхшилекләрне булдырмас өчен, көрәшкә ташланырга бурычлы. «Ант» шигыренең лирик герое да, хатыны, баласы белән саубуллашып, сугышка китә. Мондый вакытта ул дошманнарга нәфрәт белән менә болайрак та әйтергә мөмкин иде:

Таптыйк дошманны,
Тере калмасын;
Немец каскасы
Җирдә аунасын.

Бу елларда моңа охшаш шигырьләр дә күп язылды. Алар Ф. Кәримдә дә бар. Әлеге дүртьюллык — патриот-шагыйребезнең «Кулымда кылыч» дигән шигыреннән бер өзек. «Ант» шигыре исә бөтенләй башка рухта язылган.

Бер шигырендә Ф. Кәрим үзе турында болай дигән иде: «Мин бер шагыйрь — тойгы, хис кешесе». «Ант» шигырендә Ф. Кәрим нәкъ менә күңеле назлы хисләр белән тулган кеше буларак күзаллана. Бу урында шуны онытмаска кирәк: әсәрдә сурәтләнгән фронтка китүче солдатны шагыйрь үзе дип кенә аңларга ярамый. Ул — җыелма образ. Тик шунысы бәхәссез: Ф. Кәрим бу очракта үз хис-кичерешләрен дә язган. Фронтка китүче ирнең йөрәгендә баскыннарга карата нәфрәт тулы. Ул аларны «юлбасарлар» дип атый. Илнең ятлар итеге астында тапталуы — ир кеше өчен гарьлек. Ул чит байлыкларга кызыгучы бу хәшәрәтләрне илдән сөреп чыгарырга тиеш. Мондый хәлдә, гадәттә, иң кадерле нәрсә белән ант итәләр. Мәсәлән, икмәк, кояш, күз һәм башкалар (икмәктер, кояштыр, күзем чәчрәп чыксын). Безнең сугышчы исә баласын тотып ант итә. Чөнки, Ф. Кәрим әйткәнчә,

Бала —
Киләчәкнең хыялы ул,
Һәм бездән соң бу яшь балалар
Без кузгаткан көрәш ташкыннарын
Көчәйтүче булып калалар.

(«Аникин» поэмасыннан)

Бала — ата-ана өчен иң газиз, кадерле җан иясе. Юкка гынамы аны сөйгәндә «күз нурым», «бәгырь кисәгем», «алтын алмам» димиләр. Баланың исән-иминлеге илнең тыныч, азат булуы белән генә тәэмин ителә ала. Менә ни өчен лирик герой ант итүне хатынын, баласын телгә алудан башлый. Баланың әнисе — лирик геройның сөеклесе. Шул ук вакытта баланың (киләчәкнең дә дип аңларга кирәк) яшәве-яшәмәве аның янында әнисе булу белән бик нык бәйле. Чөнки күкрәк баласына ана сөте, ана назы, ана тәрбиясе кирәк. Сабыйның күз карашы да «Сакла безне!» дип әйткән төсле булып тоела кешегә.

Игътибар иткәнсездер, шагыйрь башта баланы телгә ала, аннан соң — хатынын, нәселен, Туган илен. Шулай итеп, баладан башланган сүз бик табигый рәвештә үсә, киңәя бара.

Безнең ил солдаты — бу очракта бары тик үзенең газиз җирен яклаучы, саклаучы. Кулына мылтык тоткан килеш чигенү — аның өчен мөмкин булмаган эш.

Шигырь 1942 елның 11 гыйнварында язылган. Димәк, Ф. Кәрим аны сугышка китеп ике атна тулыр-тулмас вакыт узгач иҗат иткән. Әле аның хатыны, ике кызы белән саубуллашкан хисләре яңа, алар, хәтеренә төшеп, тагы да үткенәяләр, шагыйрь күңеленә тынгылык бирмиләр.

«Ант» шигыре кыска гына — бары унсигез юл. Әмма ул үзенә никадәр фаҗигане, гомергә хәтердә уелып калырлык күренешләрне һәм хисләрне сыйдырган. Шагыйрь әнә шулай аз сүз ярдәмендә үз әсәрендә ил язмышын, кешеләрнең берберенә мөлаем мөнәсәбәтен үтемле итеп сурәтләп бирә алган. «Ант» — Бөек Ватан сугышы чорында иҗат ителгән иң уңышлы шигырьләрнең берсе.

Сораулар һәм биремнәр

1. Шигырьнең лирик герое нинди хисләр кичерә?
2. «Ант» шигыреннән файдаланып, «Ил язмышы — ир язмышы» дигән мәкальнең эчтәлеген аңлатыгыз.
3. Сугышка китүче солдат ни өчен баласын тотып ант итә?
4. Безнең солдат 1941—1945 елларда гаделлек өчен көрәште, немец фашистлары исә илебезгә явызларча һөҗүм итте. Шуңа нигезләнеп, «Гаделлек һәм явызлык» турында кечкенә әңгәмә үткәрегез.
5. Шигырьне башта сәнгатьле итеп укырга өйрәнегез, аннары ятлагыз.

* * *

Сөйләр сүзләр бик күп алар,
Иренмичә сөйләсәң;
Озын сүзнең кыскасы шул:
Күп яшәргә теләсәң,
Үлем турында уйлама,
Илең турында уйла,
Илең турында уйласаң,
Гомерең озын була.

1942 ел

ВАТАНЫМ ӨЧЕН

Бәлки, бу хат соңгы хатым булыр,
Иң дәһшәтле утка керәмен,
Шулай була калса, кояшны да
Бүген соңгы тапкыр күрәмен.

Мин сугышка керсәм, дошманымның
Йөрәгенә төзәп атамын;
Үзем үлсәм, балаларым кала
Минем гомерем булып, Ватаным.

Кала дөнья, кала бар матурлык,
Ал чәчәкләр кала болында,
Чәчәкләргә төренеп эзем кала,
Җырым кала үткән юлымда.

Үләм икән, үкенечле түгел
Бу үлемнең миңа килүе.
Бөек җыр ул — Бөек Ватан өчен
Сугыш кырларында үлүе.

1942 ел

Күләмнәре белән кечкенә булсалар да, кайбер шигырьләрдә олы һәм тирән фикерләр үтемле итеп әйтеп бирелгән була. Мәсәлән, «яшәү» дигән төшенчәне алыйк. Барыбыз да озак һәм бәхетле яшәргә тели. Һәркем белә: бар — җисми яшәү, бар — рухи яшәү. Җисми яшәү,— димәк, кешенең туганнан алып үлгәнчегә кадәр булган яшәве. Ә рухи яшәү — кеше үзе үлгәннән соң да исеменең, бигрәк тә кылган эшләренең халык телендә, халык аңында саклануы. «Ат үләр — мәйдан калыр, егет үләр — дан калыр», «Егетлек белән үлгән — үлем түгел», «Ир-егетнең кадерен агасы белмәс, ил белер», «Батыр бер үләр, куркак көн дә үләр» кебек мәкальләрне халык бик туры һәм үткен итеп әйткән.

Муса Җәлил, Газинур Гафиятуллин, Хәйретдин Мөҗәй, Бари Шәвәлиев, Мәгубә Сыртланова, Гази Заһитов һәм халкыбызның бик күп батыр уллары-кызлары үлемнең күзенә туры карап сугыштылар, үзләренең шәхси мәнфәгатьләрен ил язмышы белән бергә үрделәр, шуңа күрә алар, үлгәч тә, халык хәтерендә яшиләр.

Фатих Кәрим дә алар сафында. «Минем сугыш барган вакытта мылтыгым белән дә, каләмем белән дә туктаусыз илемә, халкыма хезмәт итәсем килә»,— дип язган шагыйрьнең иң әүвәл үзе турында түгел, бәлки ил кайгысы белән яшәгәнлеген аңлыйбыз. Ләкин бу әле илен сөйгән, аның өчен гомерен дә кызганмаган патриот-шагыйрьнең шәхси омтылышлары, борчулары булмаган дигән сүз түгел. Хатыны Кадриягә язган хатларыннан аның ихлас ярата белүче ир, балаларын өзелеп сагынучы ата икәнлеген күрәбез. «Сөекле Кадриям, күз нурларым — кызларым» дип башлап китә ул үзенең бер хатын. Гаилә башлыгы, ут эчендә йөрсә дә, һәрвакыт өйдәгеләре турында борчыла. «Мин тиз көндә сезне особый

паекка[1] беркетү турында бик җитди сүз кузгатып хат язам. Нинди нәтиҗә бирер. Инде бәрәңге утыртуың ничек бара? Син аны, кызлар белән бергәләп, мөмкин кадәр күбрәк утыртырга тырыш инде. Синең тормышка, күз нурым, шушы язган киңәшләрдән тыш, башка бертөсле дә ярдәм итә алмыйм инде хәзергә».

Ф. Кәрим менә шушы кадерле кешеләренең киләчәктә азат, бәхетле булулары өчен сугыша. Ил чит баскыннардан тазартылган чакта гына, алар бәхетле булачаклар. Димәк, шагыйрьнең үтә шәхси мәнфәгатьләре ил алдындагы бурычы белән бергә туры килә. Бу исә аның көрәшен тирән мәгънә белән сугара.

«Сөйләр сүзләр бик күп алар...» дип башланган шигырь ике генә строфадан тора. Халык җырларындагыча сигез һәм җиде иҗектән торган шигырь юлларында бер генә артык сүз дә юк. Икенче строфаның беренче ике юлын һәм икенче ике юлын аерым-аерым мәкаль итеп карарга да була. Строфаны рифмалашкан «уйла», «була» сүзләре генә түгел, юл башларында килүче «үлем», «илең» сүзләренең аваздашлыгы да ныгытып тора. Шигырь юлларының нечкә сузык авазлардан торган сүзләр белән башланып, калын сузык авазлар ярдәмендә төзелгән сүзләр белән тәмамлануы да үзенә күрә бер матур яңгыраш тәэмин итә.

Әмма игътибарны тартып торган төп әйбер — ул, әлбәттә, шигырьнең эчтәлеге. «Үлем» һәм «яшәү» төшенчәләре бирелә капма-каршы куела. Шул мәңгелек каршылык әсәрнең кызыксындыру көчен тәшкил итә. Үлем — аяусыз. Күпме яшәсә дә, аннан котылып калган кеше юк. Әмма үлемне вакытлыча җиңгән кешеләр дә бар.

Табигый, ил турында уйлау гына гомерне озайтмый әле. Бусы аңлашыла. Уйдан ният, ниятән эш-гамәл туа. Бу соңгысы кешене тулысынча биләп ала, аның бөтен барлыгын үзенә буйсындыра. Халык, ил, кешеләр, якыннарың өчен файдалы эшчәнлектә гомернең озынаюы да мөмкин хәл. Чөнки болар кешегә канәгатьлек тойгысы, уңай хисләр һәм куаныч китерә. Мондый күңел күтәренкелеге кешегә, әлбәттә, өстәмә көч бирә.

Ф. Кәрим дә шулайрак фикер йөртә. «Сөйләр сүзләр бик күп алар...» һәм «Ватаным өчен» шигырьләрендә ул нәкъ

---

[1] Шундый паекка беркетелгән кешегә азык-төлек әйбәтрәк, тотрыклырак бирелгән.

шушы карашын әйтеп бирә. Дөньяда якты кояш, барлык гүзәллекләр, чәчәкләр, балалар кала, әмма Ватан өчен үлүне шагыйрь «бөек җыр»га тиңли. Шулай булмаганда, кеше, көн саен үлем белән очрашып торып, үзендә рух ныклыгын, күңел күтәренкелеген һәм җинүгә ышанычын саклап кала алмас иде. Фатих Кәрим өчен дә көч чыганагы әнә шул ук хисләр, уйлар һәм омтылышлар иде.

Сораулар һәм биремнәр

1. «Сөйләр сүзләр бик күп алар...» һәм «Ватаным өчен» шигырьләренә уртак булган төп фикер һәм хис нәрсәдән гыйбарәт?

2. Халык егетлек, батырлык турында ниләр дигән? Шул турыдагы мәкальләрнең эчтәлеген ачыклагыз. Тагын шуңа охшаш нинди мәкаль-әйтемнәрне беләсез?

3. Нәрсә ул җисми яшәү? Нәрсә ул рухи яшәү? Аларның берберсен тулыландыруын күрсәтегез.

4. Ф. Кәрим — иле өчен дә, якыннары өчен дә кайгыручы, борчылучы, аларның икесен дә яклап көрәшүче. Бу турыда сез нәрсәләр әйтә аласыз?

5. «Сөйләр сүзләр бик күп алар...» шигыренең сәнгатьчә эшләнешендәге үзенчәлекләрне аңлатып бирегез.

6. «Яшәү» һәм «үлем» — капма-каршы төшенчәләр. Шагыйрь аларның мәгънәсен ничек итеп ача?

7. Үлем — фаҗига, аны «бөек җыр»га тиңләү дөрес буламы, ышандырамы? Мондый үлем нинди шартларда гына мөмкин?

8. Шигырьләрне сәнгатьле итеп укырга өйрәнегез.

9. «Шулай үлде Ватан улы» дигән темага инша языгыз.

КЫҢГЫРАУЛЫ ЯШЕЛ ГАРМУН

Бакча эчендә госпиталь,
Ишекләре язулы.
Госпитальдә кемнәр генә
Белми икән Фазылны?!

Сугышка кадәр эшләгән
Донбасс шахталарында,
Эшләгән, исеме төшмәгән
Мактау такталарыннан.

Егетнең дә егете ул,
Ул сугышта сугышкан.
...Берчак шулай өч танкка
Төялеп килгән дошман.

Гранаталар тоткан Фазыл,
Шаккатырган халыкны:
Чүлмәк кебек чәлпәрәмә
Китергән өч танкны...

***

Бакча эчендә госпиталь,
Кәрнизләре челтәрле.
Фазыл бер кызга хат яза,
Хаты барып җитәрме?

Хатының соңгы юлларын
Җырлар белән тутыра.
Без дә берсен язып китик,
Җырлары ла ни тора:

«Ал кадыйм түшләреңә,
Гөл кадыйм түшләреңә,
Былбыл булып, гөлгә кунып,
Керәсең төшләремә...»

Язып бетерә ул хатын,
Башын кулына салып.
Язган җырларын укый да,
Бик тирән сулыш алып:
— Иптәшләр, берегез,— ди,—
Әнә шул гармунны, зинһар,
Китереп бирегез,— ди.

Ала кулына гармунын,
Ача тәрәзәләрне,
Җилпеп җибәрә кичке җил
Ал челтәр пәрдәләрне.

Карый Фазыл зәңгәр күккә,
Күктә — алтын йолдызлар,
Ә бакчада, чәчәк тотып,
Ял итеп йөри кызлар.

Вак-вак атлап килә берсе,
Шәһәр кызыдыр үзе,
Чирмешән буенда пешкән
Шомыртлар кебек күзе;

Бакча эченнән килә ул,
Бөдрә чәчләрен тарап;
Үзе уйный, үзе җырлый,
Фазыл бу кызга карап:

«Агыйделнең ярларында
Чәчәк микән, гөл микән,
Бер әйләнеп күз дә салмый,
Әллә ул түгел микән?»

Кем белсен: улмы, түгелме?
Тик кыз карый әйләнеп;
Бу чибәр кызның кулында
Язгы чәчәк бәйләме.

Шаярып көлә егетләр:
«Шул үзе... үзе икән!
Зәңгәр крепдешин күлмәген
Нинди килешле теккән!»

Бөдрә чәчен артка сирпеп,
Кыз да куанып көлә,
Көлеп кенә калса ни хәл,
Борылып якын килә;

Зәңгәр крепдешин күлмәге,
Белмим, егет бүләге,
Ничек басып килә бит ул,
Дулкынлана итәге.

Текәлеп карый Фазылга,
Күзләре лә, күзләре!..
Онытмас Фазыл бу кызның
Назлап әйткән сүзләрен:

— Яшел гармуның өстенә
Сандугачлар кунсын,—ди,—
Батыр егеткә охшыйсың,
Миннән бүләк булсын,— ди.

Елмаеп суза Фазылга
Язгы чәчәк бәйләмен;
Китә... китеп бераз баргач,
Тагын карый әйләнеп.

Пәрдәләрне җилпи-җилпи,
Тәрәзәдән җил бәрә.
Күз текәп киткән бу кызга
Фазыл сызып җибәрә:

Саратский яшел гармун,
Көмеш кыңгыраулары,
Бу көмеш кыңгырауларның
Кичке яңгыраулары
Әллә нишләтә күңелне,
Үксеп елыйсы килә...
Елау егет эшемени?! —
Эх, бер җырлыйсы килә!..

* * *

Җырлыйлар гармунга кушылып
Госпиталь егетләре,
Канын кызганмый сугышкан
Ватанның бөркетләре:
«Утырдым яшел вагонга,
Карыйм тәрәзәсеннән,
Шат, бәхетле киләчәгем,
Күгәрченем, гөл чәчәгем,
Хатлар көтәрмен синнән.
    Ватаным өчен —
    Гомерем, көчем.
    Төзәлде ярам,
    Данлы сугышка
    Яңадан барам!

Мин китәм, иркәм, сугышка,
Син сагынып җырларсың,
Үлсәм, хәбәр итәр дуслар,
Мактап хат язар комиссар,
Үкси-үкси еларсың...

Авыр булса да әйтәмен
Якын иткәнгә күрә:
Мин үлсәм, башка берәүне
Миңа тиң итеп яратып
Салырсың йөрәгеңә.
Сайлаганың минем кебек

Иркәли, сөя белсен;
Кирәк чакта Ватан өчен
Аямыйча яшьлек көчен
Көрәшә, үлә белсен.

Батырны үлем алмый, ди,
Бер күрешербез әле;
Күгәрчен кебек гөрләшеп,
Күзләрне күзгә текәшеп,
Бер үбешербез әле.
    Ватаным өчен —
    Гомерем, көчем.
    Төзәлде ярам,
    Данлы сугышка
    Яңадан барам!»

Тын калып тыңлый бу җырны
Күктә алтын йолдызлар,
Һәм бакчада, чәчәк тотып,
Ял итеп йөргән кызлар.

* * *

Саратский яшел гармун,
Көмеш кыңгыраулары,
Бу көмеш кыңгырауларның
Кичке яңгыраулары
Әллә нишләтә күңелне,
Тирән сулыйсы килә,
Тирән сулыш алып, дуслар,
Ярсып җырлыйсы килә!

1942 ел

«Кыңгыраулы яшел гармун» поэмасы,— Ф. Кәрим иҗатында гына түгел, гомумән, сугыш чоры татар шигъриятендә күтәренке рух, киләчәккә ышаныч белән сугарылган иң уңышлы әсәрләрнең берсе. Халыкның ныклыгын, фидакарьлеген, сөйкемлелеген, мәхәббәт хисенең бөтен авырлыклардан өстенлеген раслау ул вакыт өчен бик тансык иде.

Әсәрнең үзәгендә Фазыл образы. Шагыйрь бу егеттә татар сугышчысының бик матур гәүдәләнешен тапкан. Фазыл сугышка кадәр алдынгы шахтер булган, сугышта да кыю, батыр

егет булып танылган. Җитмәсә, гармунчы, җырчы. Чибәрлеге өстенә шаянлыгы да бар. Шуңа күрә кызлар да аңа яратып карыйлар. Госпитальдәге егетләрнең дә Фазылны үз итүләре сизелеп тора. Бу образны А. Твардовскийның «Василий Тёркин» әсәренең герое белән тиң куясы килә.

Поэмада бик матур бер бизәк бар, ул — гармун. Үзе кыңгыраулы, үзе яшел, бик матур тавышлы. Оста Фазыл сыздырып җибәргәндә, ул солдатларның күңел дөньясын тибрәтә. Егетләр түзмиләр, гармунга кушылып җырлыйлар. Йөрәкләрендә йөрткән иң кадерле хисләрен, җырга салып әйткәннәрен сизми дә калалар. Шулай итеп, җыр поэмада бик әһәмиятле хезмәт башкара. Ф. Кәрим җырның халыкчан яңгырашлы булуына нык игътибар итә. Алай гына да түгел, әсәр тукымасына табигый рәвештә халык җырларын да кертеп урнаштыра.

Яраланган шагыйрь 1942 елның язында Казан госпиталендә дәвалана. Әсәр шул вакытта (май аенда) иҗат ителгән. Сәламәтләнеп сугышка китүче Фазылның хисләре Ф. Кәрим күңеленә бик якын. Шуңа күрә алар аеруча җылы итеп бирелгәннәр дә.

Поэма турында төшенчә . Шигырь белән язылган катлаулы төзелешле әсәрләргә поэма диләр. Мәсәлән, шигырьдә бер күренеш, бер хис сурәтләнергә һәм фикер йөртү шулар тирәсендә барырга мөмкин. Поэмада исә хисләр дә, вакыйгалар да дәвамлырак һәм күбрәк була. Анда лирик чигенешләр, сюжетны яхшырак ачарга ярдәм итәрдәй аерым кисәкләр дә булырга мөмкин. Хисләр, кичерешләр генә сурәтләнсә, мондый әсәрне лирик поэма дип, вакыйгалар, кеше образлары да килеп керсә, лиро-эпик поэма дип тә атыйлар. Ф. Кәримнең «Кыңгыраулы яшел гармун» әсәре — лиро-эпик поэманың матур үрнәге.

Әмирхан Еники
(1909—2000)

Әмирхан Нигъмәтҗан улы Еникиев 1909 елның 2 мартында Башкортстанның Благовар районы Яңа Каргалы авылында таза хәлле крестьян гаиләсендә туган. 1911 елда аларның гаиләсе моннан кырык чакрым ераклыктагы Дәүләкән дигән авылга күченә. Әмирханның яшьлек еллары шушы төбәктә — Дим буенда үтә.

1925 елның җәендә ул сәнгать мәктәбендә уку теләге белән Казанга килә һәм китап кибетенә курьер булып эшкә урнаша. Бер елдан Казан университеты каршындагы рабфакка укырга керә. 1927—1931 елларда Донбасста наданлыкны бетерү курсларында укыта. Казан мех фабрикасында эшли, бер үк вакытта төп эшеннән аерылмыйча, 1931—1933 еллар арасында Казанда Хезмәтне фәнни оештыру институтында укый. Шуннан соң ул 1934—1941 елларда Казандагы җирле промышленность өлкәсендә техник укыту буенча методист булып, кинофикация трестында инструктор, Бакудагы «Азеркино» студиясенең районлагы махсус вәкиле, Казанның икенче номерлы тегү фабрикасы каршындагы стахановчылар мәктәбендә һәм Үзбәкстанның Маргелан шәһәрендәге мәктәпләрнең берсендә укытучы булып берәр-икешәр ел эшләп ала. 1941—1945 елларда Ватан сугышында катнаша.

Армиядән кайткач, Ә. Еники берникадәр вакыт «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») журналында — әдәби хезмәткәр, Татарстан радио комитетында әдәби тапшырулар бүлеге редакторы булып эшли, 1950—1952 елларда Казан авиация техникумында татар теле укыта. 1953 елдан ул тулысы белән язучылык хезмәтенә күчә.

Ә. Еникигә Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге бирелде. Ул — Татарстанның халык язучысы.

Ә. Еники 2000 елның 16 февралендә Казан шәһәрендә вафат булды.

ӘЙТЕЛМӘГӘН ВАСЫЯТЬ

(Әсәр кыскартып алынды)

I

Йомшак кына җәйге җил исә... Дала буйлап кылганнар йөгерә, кылганнар йөгерә. Ефәк чукларын еш-еш кына селкеп, акрын гына кыштырдап, бик тырышып һәм бик кабаланып йөгерә кебек алар... Колын булып уйнаклап, шул кылганнар артыннан чабасы да чабасы килә. Дала буш, дала киң, җир җылыкай, шаян җилкәй биттән сөя... Рәхәт, һәй, рәхәт тә соң!.. һәм ямансу. Нигәдер бик ямансу да шул! Шагыйрь әйтмешли, йөгереп уйныйсы, ятып елыйсы килә бу тын, буш, моңсу башкорт даласында!

Әнә көмешләнеп дулкынланган кылганнар арасында ак яулык бөркәнгән, алъяпкыч бәйләгән, күлмәген ыштан бөрмәсенә кыстырган кечкенә буйлы арык кына бер әби кизәк җыеп йөри. Сул беләгендә аның иске чиләк, уң кулында нечкә таяк. Шул таягы белән ул кизәкне чирәмнән куптарып әйләндерә дә аннары иелеп алып чиләгенә сала. Тагын як-ягына каранып эзләп китә. Тагын кизәкне, чирәмнән куптарып, чиләгенә алып сала... Шулай да бу авыл кырындагы чирәмлектә хәзер кизәк аз табыла. Колхоз терлекләре монда йөрмиләр, ә бәләкәй генә авылның үз бозаулары салып калдырган «беленнәр» күпме генә соң ул! Далада утын дигән нәрсә бик кадерле булгач, ялгыз әби, ике-өч көндә бер чыгып, иске чиләге тулыр-тулмас шул «беленнәрне» җыеп кайта. Борыннан килгән бер гадәт. Аннары кизәк казан астына бик килешә, ашны әкрен генә кайната, ә үз җае белән әкрен генә кайнап пешкән аш бик тәмле була ул. Әйтерсең чирәм исе керә ашка.

Тик соңгы вакытта әбинең хәле бик үк әйбәт түгел әле. Картлыгы җиткәнме, берәр чир зәхмәтеме шунда, ләкин гел менә бөтен тәне авыраеп, кул-аяклары сызлап, йөрәгенең хәле китеп тора. Ара-тирә өшетеп тә җибәрә

яки тиктомалга яндыра да башлый. Үзенчә мәтрүшкәсен-ниен эчкәләп, ятып караса да, бер дә юнәеп китә алмый. Менә бүген дә, кояш шактый нык кыздыруга карамастан, аның зәгыйфь тәне, эчендә боз яткандай, гел туңып тора; аркасы буйлап әледән-әле салкын кымырҗу йөгереп уза, шул ук вакытта күз төпләре яна, иреннәре бөрешеп кибә, һәм ул гер таккандай авыраеп киткән аякларын көчкә генә сөйрәп йөри... «Булмас, ахрысы, кайтырга кирәк»,—ди ул үз-үзенә иренеп кенә һәм, чиләге кизәк белән тулмаса да, авылга таба борыла.

Читән буйларында котырып кычыткан үскән тар тыкрыктан узып, бәбкә үләне түшәлгән киң урамга килеп чыккан чакта гына аңа Миңлебай карт очрый. Торна шикелле нечкә озын аяклы, какланып беткән бу чандыр бабайны авылның иң карт кешесе диләр. Туксанның өстендә үк түгел микән? Хәер, тәгаен ничә яшьтә булуын ул үзе дә белми. Былтыр гына аның җитмештән узган Миңлегәрәй исемле улы үлеп киткән иде. Хәзер бабай Миңлегәрәйнең зур улы Миңлегалидә тора. Миңлегалинең дә өйләнгән улы, кияүгә чыккан кызлары бар. Миңлебай карт менә шуларның балаларын, ягъни үз токымының дүртенче буынын күрде. Дүртенче буын әкәмәт икән ул, бер дә бабай дигәнчә түгел. Ул хәтта аларның исемнәрен дә отып ала алмый. Вилне Вилдан дип, Эммаы Әсмабикә дип тик йөртә шунда...

Дөньяда чамасыз озак яши торгач, кайчандыр паровоз тавышын да ишетмәгән бабай тракторын да күрде, автомашинасын да, самолетын да, радиосын да күрде; ләкин картның берсенә дә исе китмәде. Чөнки бу заманның барышына ис китеп өлгерерлек түгел иде.

Ләкин былтырмы икән, өченче ел микән, кемнәрнеңдер бу тирәләргә очып килеп, самолеттан бүре атып йөрүләрен ишеткәч, картның моңа шулай да исе китте. Кара син аны. Бүрене самолеттан гына «сугалар» диген, ә?.. Кайчандыр, бик күптән инде, ул үзе ир-егет чагында камчат бүрек, ак чикмән киеп, билен кызыл билбау белән буып, камыт күрмәгән сөлектәй яшь айгырга атланып, далага чыгып китә иде дә, йөри-йөри бүренең эзенә төшкәч, аны уктай сузылып очкан бурзаеннан өсләтеп һәм ун-унбиш чакрым куа барып, озын саплы чукмары белән сугып ала торган иде. Менә бу ичмасам бүре сугу иде! Ә хәзер һавадан атып йөриләр, имеш.

Моның ни кызыгы да, ни комарлыгы бар? Юк, әллә нишләде бу замана! Машина да машина, ә кешенең үз йөрәгенә, үз кулына ни кала?!

Миңлебай картның дөньяда да, колхозда да хәзер бер эше дә юк. Ул какланып беткән тәнендә бары җан асрый. Алдына куйганны утырып ашый, ястыгын тәгәрәтә дә ятып йоклый, шулай итеп гомерен суза да суза. Аның хәзер бер генә эше бар — ул ялан таптарга ярата, һәр көнне иртәнге чәйдән соң ул, озын карагай таягын тотып, торнаныкыдай нечкә аякларын сыгылдырып кына буш урамнан уза, кырга чыга һәм күзе караган якка таба китеп бара. Берәр түбә җиргә менгәч, озын таягын ике учлап, ерак кырларга тик кенә һәм озак кына карап тора. Бу күз җитмәс Юлкотлы яланының бөтен ягын, андагы түбәләрнең, үзәннәрнең, чокырларның бөтенесен исемнәре белән белә. Хәзер инде ул исемнәрнең күбесе онытылып бара. Хәзер, мәсәлән, Каракош басуы яки Атчабар кыры дип түгел, ә фәләненче бригаданың да тегәненче бригаданың участогы дип кенә йөртәләр. Юлкотлы яланнарын тоташтан сөреп бетерделәр. Иске чикләр, иске исемнәр барысы да күмелеп калды шунда...

Карт түбәдән төшеп китә, үзәнлекләрдән уза, иген басуларын буразна буйлап кисеп чыга, шулай итеп әллә никадәр җир әйләнеп, күп вакытта авылның икенче очыннан кайтып керә. Юлында очраган кешегә үзе башлап дәшми, ә берәрсе: «Саумы, Миңлебай бабай?» — дип дәшсә, «Ару әле» яки «Шөкер!» дип кенә узып китә. Ни уйлап, нәрсә карап йөри торгандыр карт — белүче юк.

Менә бүген дә карчык, йөзгә-йөз очрашкач, дәшмичә китүне килештермичә, үзе башлап аңа:

— Нихәл, арумы, Миңлебай агай? — диде, авызын учы белән генә каплый төшеп.

— Ә, синмени әле бу, Акбикә килен? Шөкер! — диде карт, тукталып. Җитмештән узган карчык аның өчен һаман да килен иде әле. Һәм Акбикә дип тә бары ул гына дәшә, югыйсә авыл халкы карчыкны күптән инде Акъәби дип кенә йөртәләр.

— Каян кайтып киләсең болай?— диде карт.

— Менә кизәк җыярга чыккан идем.

— Ә, ярый, ярый... Казан астында утның өзелмәве яхшы! Йә, үзең ару гынамы соң?

— Шөкер иде әле, тик менә бу көннәрдә генә әллә нишләп хәлем китеп тора,— диде карчык һәм тирләгән битен яулык очы белән сөртеп алды.

— Авырма инде, син — ялгыз кортка, карар кешең юк.

— Алладан вакыт җитмәгән булса үтәр әле.

— Үтәр, Алла боерса, үтәр, бик күпне үткәрдек,— диде карт, ияк очында гына ябышып торган берничә бөртек ап-ак кылдай сакалын селкетеп.— Ярый, кортка, юлыңда бул! — Һәм карт озын аякларын сыга биреп китеп тә барды. Ул карчыклар белән күп сөйләшеп торырга яратмый иде.

Акъәби, үзенең җил капкасына җиткәч, туры читән алачыкка узды. Бу эчтән балчык белән сылаштырылган җир идәнле алачыкта аның барлы-юклы савыт-сабасы да тора, шунда аш-суы да пешә иде. Җирдән аз гына күтәртеп салынган, калай морҗасы туры гына кыектан чыгарылган учагы алдына карчык кизәкләрен бушатты. Казанына өч-дүрт чүмеч су салды да учагына күп кенә итеп чыбык-чабык сындырып тыкты, ут төртеп җибәрде. Чыбыклар күмерләнеп төшкәч, алар өстенә иплəп кенә кизәкләр өештереп куйды. Аның исәбе башта су җылытып, табак-савытын юу, аннары әзер казанда үзенә бер-ике генә уҗау буш умач пешереп алу иде. Нигәдер күңеле бүген сызык йөгерткән буш умачны корот катып кына ашарга теләп тора иде. Ләкин карчык сизә: пешерә дә, ашый да алмас төсле; хәле бөтенләй бетеп бара, көчкә генә йөреп азаплана, гәүдәсе менә гел ятарга гына сорап тора... Ахырда түзмәде, казан астыннан кизәкләрне алгарак тартып, учагын сүрелтә төште дә бераз ятып торырга булды. Алачыктан өенә узышлый күрше ишегалдында йөргән яшь хатынга читән аша гына дәште:

— Гарифә кызым, минем казан астын гына кереп караштыра тор әле, әз генә ятып алмакчы булам, бер генә дә хәлем юк.

— Ә, ярый, ярый, Акъәби, карармын, борчылма, ят! — диде уңган хатын, әбинең төсе качкан чыраеннан авыру булуын шунда ук чамалап.

Акъәби урам тәрәзәләре ябык, әрем себеркесенең исе аңкыган салкынча өенә керде, сәке түренә бөкләп куйган ястыгын җәйде дә, бисмилласын әйтеп, сырган юрган белән ябынып, бөгәрләнеп кенә ятты. Аның бик

җылынасы килә иде. Ятып күзләрен йомуга, ул, салкын бер чоңгылга баткандай, башта туңып китте, кымырҗып, акрын гына калтырана башлады. Күпмедер вакыттан соң бераз гына җылынган кебек булды, ләкин тәмам эреп, изрәп китә алмыйча, ярым уяу, йокылы хәлдә һаман бөрешеп кенә ята бирде. Бераздан Гарифә кереп хәлен белде, ашыйсың-эчәсең килмиме дип сорады. Әби: «Локма да кабасым килми, кайнар чәй генә эчәр идем»,— диде. Гарифә алачыктан утлы көл өстендә генә пешергән куе чәй китереп, чынаягына карлыган кагы салып, шуны сыек бал белән генә аңа эчерде. Әбинең җыерчыклы ябык куллары һәм кипкән иреннәре калтырый иде. Шулай да ул тәлинкәне үз кулы белән тотып эчте. Гарифәгә күп итеп рәхмәт әйтте, тирләп бер йокласам, иртәгә, Алла боерса, аякка басармын, диде, тик бүген инде көтү кайткач, кәҗәсен савып, сөтен баз өстенә генә куярга кушты. Гарифә барысын да эшләргә булды, тыныч кына ятарга кушты һәм карчыкның өстен әйбәтләп ябып чыгып китте.

Ләкин карчык икенче көнне дә, өченче көнне дә аягына баса алмады. Күршеләре кереп аның хәлен һаман белә тордылар, Гарифә исә ашау-эчүен кайгыртып, йорт-җирен һаман карый йөрде. Шулай да карчыкның хәле бер дә алга бармагач, аңа әллә улларыңа, кызларыңа хәбәр итикме, болай яту ярамас бит дия башладылар. Ләкин Акъәбинең өмете зур иде әле, ерак каладагы балаларын бер дә борчыйсы килми иде. Аннары болай да берәрсе кайтып китмәсме дигән өмете дә юк түгел иде. Кайткалыйлар иде әле аның уллары яки кызлары, инәләрен онытып бетермиләр иде, исән генә була күрсеннәр инде.

Карчыкның соңгы елларда гомере шул балаларының кайтып китүләрен көтеп яшәү белән генә уза башлады. Дөрес, моннан ун ел элек, карты үлгәннән соң, балалары карчыкны калага тартып караганнар иде каравын, ләкин Акъәби гомер иткән нигезен ташлап китәргә теләмәде инде. Шушы Юлкотлыда туган ул, үскән ул, шушы Каһарман карт өенә килен булып төшкән, шушында илле биш ел яшәгән, уллар-кызлар үстергән. Шушы Юлкотлы туфрагында аның атасы, анасы, күпме туганнары, яшьли үлгән сабыйлары, гомер иткән карты ята — йә, ничек шуларның барысын да ташлап китәсең?..

Күп торасы да калмагандыр, ят җирнең туфрагына барып ятканчы, шушында үзенең ата-анасы, карты, сабыйлары янында булыр — шулай уйлаган иде карчык ул чакта, һәм, һичнигә карамастан, хәзергә чаклы ул шушы ниятендә нык торды.

Шулай да карчыкка җиңел түгел иде. Туган туфрак никадәр генә үзенә бәйләмәсен, авыл артындагы канау белән әйләндереп алган зиратта ятучы әрвахлар нихәтле генә якын булмасын, әмма болар гына аның тормышын тутыра, ялгызлыгын җиңеләйтә алмыйлар иде. Ялгыз башын монда асраса да, күңеле белән ул һаман шул балалары янында иде. Шуларны уйлап, шуларны сагынып, шыксыз озын көзләрне дә, салкын кышларны да уздырып җибәрә: сабыр гына җәйне көтеп ала, ә җәен берәр улымы яки кызымы балалары белән кайтып китәргә тиеш аның... Бигрәк тә оныкларын бик сагына карчык. Шулар кайтса инде, куанычы эченә сыймый, бөтен дөньясын оныта, үзе дә бер бәйрәм итеп кала, бичара. Тик бу бәләкәчләрнең әти-әниләре карчык янына, гадәттә, бик кыска вакытка гына кайталар. Алар, ни хикмәттер, гел ашыгалар. Кайсының эше көтә, кайсының курортка китәсе була, аннары балаларыбыз авыл җирендә авырып-нитеп китә күрмәсен дип куркалар да булса кирәк, кыскасы, бер атна торгач та, карчыкның бик тилмереп соравына карамастан, юатыр өчен кулына мул гына акча тоттырып, вәгъдәләр биргән булып китеп тә баралар. Шулай итеп, ел буе көтеп алган санаулы көннәр төш кебек кенә үтә дә китә.

Нишлисең, заманасы шулай туры килде инде. Акъәбинең сабый чактан исән калган балалары үсә тордылар, күрше авылның урта мәктәбен бетерә тордылар, һәркайсы, канат чыгарган кош кебек, Юлкотлыдан еракка оча торды. Хәзерге вакытта бер улы белән бер кызы Өфедә яшиләр. Тагын бер кызы, врач булып чыкканы, Пермь өлкәсендә тора, ә иң кече малае, институтны бетергәч, Казакъстанга җибәрелгән иде, шунда, исеме дә билгесез бер шәһәрдә, кемдер булып эшли.

Өфедәге иң зур улы Суфиян — хәзер инде отставкага чыккан полковник, ә кызы Гөлбикә фәнни институтларның берсендә гыйльми эштә, кияве исә аның, Чакмагош башкорты, зур, җаваплы урында утыра. Кыскасы, барысы да зур кешеләр булып беттеләр. Кайсы галим, кайсы инженер, кайсы врач... Борын заманда бер ата-

анадан түгел, бөтен өязеннән бу кадәр укымышлы башкорт чыкмагандыр. Акъәби үзе кыз чагында башкорттан яки татардан доктор барлыгын ишеткәне дә юк иде. Әле дә хәтерли: элек авылда берәрсенең теше сызласа, моннан унсигез чакрымдагы чуваш авылына, тәмәке алып кайтыр өчен, ат мендереп кеше чаптыра торганнар иде. Булган заманнар. Юк, аның балаларына килде инде бәхет, килде, әйтәсе дә түгел!

Тик менә бик бәхетле булып киткән балалары аңардан ничектер шактый ераклаштылар шикелле. Зарланса язык булыр, карыйлар, ярдәмнәреннән ташламыйлар, рәхмәт үзләренә, тик шулай да карчык борчылып уйламыйча булдыра алмый: туган җирләрен дә, кечкенә Юлкотлыны да, аталарыннан калган нигезне дә алар бөтенләй онытып баралар кебек. Уйлары да, күңелләре дә бүтәндә булса кирәк... Менә зур улы Суфиян. Күпме ил гизде, нинди зур дәрәҗәгә ирешә, олайды, үзенең дә ул-кызлары үсеп җитте, инде хәзер беркайда да эшләми, зур пенсия ала, машинасы бар — аңа бит Юлкотлыга ешрак кайтса да була хәзер... Ләкин нишләтәсең аны, һаман вакытым юк дип зарлана, ниндидер комиссияләрдә эшләп йөри, кышын бер-ике айга курортка китә, йә булмаса үзе кебек погоннарын салган полковниклар белән төннәр буе карта сугып утыра, ә җәйгә чыккач, машинасына хатынын, балачагаларын утырта да йә Кырымга, йә хатынының урыс туганнарына — Саратовка китеп бара. (Суфиян сугышка чаклы ук әле, Саратовта хезмәт иткән чагында, марҗа кызына өйләнгән иде, һәм Акъәбинең ул чакта моңа күңеле бик тә сыкранган иде.) Ә каладан йөз егерме чакрымда гына торган Юлкотлы читтә кала, әнисе-карчыкның алар өчен генә дип саклаган казлары келәтендә шул килеш эленеп тора. Полковникның кереп туган авылын күрергә һәм әнисен куандырырга вакыты да, җае да табылмый. Ничек моңа күңел сыкранмасын, ди.

Шулай да былтыр җәй Суфиянның җиткән улы Геннадий үзләренең машинасында «бабушка»ны күрергә дип кайткан иде. Өч көн торды, өч көн Акъәби бер кәлимә башкортча белмәгән оныгы алдына барлык сыйларын куйды, сүзсез генә аңа моңсу һәм назлы итеп карап утырды. Егет җирән чәчле иде, таза иде, физкультурник иде; урам буйлап чыгып киткән чакларында карчык аның чуар күлмәк кигән киң аркасына читән

аша гына карап кала иде. Егет бер көн эчендә Юлкотлының бөтен тирә-ягын йөреп чыкты; машинасына ыбыр-чыбыр балаларны төяп, әллә кайлардан үзләрен йөртеп кайтарды, аннары колхоз келәтендә аунап яткан ике потлы гер ташын табып кайтты да иртә-кич гел шуны күтәреп-чөеп уйный башлады.

Кечкенә авылда егеткә аралашыр өчен үз тиңнәре бөтенләй юк диярлек иде — кызлар җәйләүдә яталар, егетләре каядыр таралышып беткәннәр — һәм Акъәбинең моңа бик эче поша иде. Оныгының күңелен табар өчен, ул әледән-әле аңа башкортча нидер әйткән була, ләкин Геннадий, берни аңламыйча, «бабушка»сына бик юмарт елмаеп карый, җавапсыз калмас өчен генә:

— А, да-да, точно! — дип, башын кагып куя иде. Әби белән онык арасында бер кызык хәл дә булып алды. Шулай иртәнге чәй янында оныгын сары майда гына йөзгән әче коймак белән сыйлаган чакта, Акъәби «безнең башкорт халкы...» дип нидер сөйли башлаган иде, Геннадий, шуны үзенчә аңлап булса кирәк, көтмәгәндә генә баш бармагы белән күкрәгенә төртеп:

— Я — башкирин, бабушка, башкирин! — диде һәм, җитмәсә әле «борчылма!» дигәндәй, әбисенә күз дә кысып куйды.

Акъәби уйчан гына аңа карап торды, үзалдына гына көрсенгәндәй итте, аннары моңсу-назлы итеп кенә елмайды: нишлисең, бу җирән чәчле егеттә аның каны, башкорт каны ага иде шул!

Менә шулай Акъәби ялгыз башы шушы көнгә кадәр улларын, кызларын көтеп, оныкларын сагынып, алар турында үзенең күңелле һәм күңелсез уйларын эченнән гел уйлап, исән-имин генә яшәп килде. Әмма быел, Ходайдан вакыт җиткәнме, җәйгә аяк басу белән, үзен начар сизә башлады һәм бирешмәскә тырышып йөрде-йөрде дә ахыр чиктә менә урынга ук ятарга мәҗбүр булды.

Башта торып китәрмен дигән өмет белән ятты, күршеләренең калага улларына хәбәр итик дигән сүзләрен дә кире какты, әмма ләкин хәле аның отыры начарлана барды. Биш-алты көн эчендә ул күзгә күренерлек булып суырылды, саргайды, ашаудан калды. Күршеләре, карчыкның болай начарлана баруын күреп, хәвефкә төштеләр, нишлик икән дип, үзара киңәшеп тә алдылар, ахырда Юлкотлыдагы колхоз бригадиры Сәетгалигә хәбәр итәргә булдылар.

Гарифә барып әйткәч тә, Сәетгали икенче көнне үк, Сыртланга узышлый, үзенең мотоциклында пырылдап, Акъәбинең капкасы төбенә килеп туктады. Акъәби шунда ук кем килгәнен белеп алды һәм ни өчен икән бу дип борчылып уйлап куйды. Ул арада ишектән, иелә биреп, тузанлы күн итекләрдән, бригадир белән председательләр өстендә генә очрый торган, капчыкланып беткән зәңгәр пинжәктән Сәетгали үзе дә килеп керде.

— Саумы, Акъәби? — диде ул, таза кешегә дәшкәндәй юри кычкыра биреп.— Бәй, ни булды, әллә авырып калдыңмы?

— Авырыйм шул, Сәетгали,— диде карчык, гаепле кеше сыман итеп.

— Куй, юкны сөйләмә, гомердә авырмаганны... Синең кебек корткага килешәмени ул!

Сәетгали, килеп, сәке кырыена гына утырды, карчык юрганын үзенә таба җыя төште.

— Килешми дә бит, нишлисең. Ходайдан вакыт җиткәч...

— Җиткән, ди, сиңа... Болай гына, салкын-фәлән генәдер әле... Кай җирең авырта соң?

— Авырткан җирем дә юк кебек... Тыным кысыла, сулавы авыр...— диде Акъәби, бугазын һәм күкрәген сыйпап.

Сәетгали карчыкның суырылган, саргайган йөзенә беравык сынап карап торды.

— Йә, нишлибез, Акъәби, доктор чакыртыйкмы?

— Кирәкмәс, Сәетгали улым, иншалла, болай да үтәр әле...

— Үтә күрсен! — диде Сәетгали, карчыкка тагын да сынабрак карап. Юк, шулай да карчыкның хәле бер дә шәпкә охшамый, йөзе лимон кебек сары, күзләре тоныкланып тора.— Әллә, мин әйтәм,— диде бригадир сак кына,— калага хәбәр итикме? Суфиян агай, йә булмаса Гөлбикә апай килеп китсә, зарар итмәс... сөйләшерсез...

— Юк, кирәкмәс, сабыр итик әле, алар да эшле кешеләр,— диде карчык, эченнән генә үзенекен уйлап.

— Анысын куй,— диде Сәетгали, урыныннан торып,— бер әсәйләре өчен вакыт табарлар әле. Ярый, идарәгә баргач, мин Гыйльман агай белән сөйләшермен. Берәр чарасын күрербез. Ә син, әбекәем, тыныч кына ят. Терел.

Сәетгалигә ияреп, Гарифә дә өйалдына чыкты. Алар анда пышын-пышын гына нидер сөйләшеп тә алдылар.

Ә берничә көннән соң Сыртлан ягыннан Юлкотлыга таба тузан уйнатып килгән өр-яңа яшел «Волга» машинасы күренде. Һәм озак та үтми, киң урамның күк үләнендә ярылып яткан кара эз калдырып, Акъәбинең капкасы төбенә килеп тә туктады. Машинадан җәйге габардин пальто, күк эшләпә кигән зур, таза гәүдәле бер ир белән ефәк плащ кигән, зәңгәр косынка бәйләгән озын буйлы ябык кына бер хатын чыктылар. Болар Акъәбинең кызы белән кияве иделәр.

Алар урам тәрәзәләре ябык караңгырак өйгә килеп кергәч һәм кызының: «Әсәем!» — дип дәшүен ишеткәч, йокылы-уяулы хәлдә яткан Акъәби сискәнеп күзләрен ачты, бермәлгә өнемме, төшемме бу дигәндәй аптырап, каушап калды, аннары куанычыннан онытылып китеп, капыл гына урыныннан тормакчы булды.

— Кызым, Гөлбикә! — диде ул, өзелеп.

Кызы, шунда ук килеп, аның өстенә иелде, маңгаеннан үпте, һәм алар тотынышып икесе дә елап җибәрделәр. Мәһабәт кияве дә, килеп, карчыкның кипкән ябык кулын зур, таза кулларына алды, иелә төшеп, күтәренке тавыш белән: «Нихәл, әби җаным, авырып киттеңмени? Ничево, ничево, берни дә булмас!» — диде һәм, пальто чабуын кайтарып, аз гына читкәрәк, сәке кырыена утырды. Кызы да чажлап торган плащы белән әнисенең аяк очына чүкте. Алар икесе бертавыштан карчыкка кузгалмаска куштылар. Ләкин карчыкка кияве белән кызы алдында болай авырып ятуы гаҗәп уңайсыз иде, һичнигә карамыйча, аның тизрәк торасы, кадерле кунаклары өчен әүвәлгечә бөтерелеп йөрисе килә иде, әмма тик, нишләсен, ятарга чарасыз мәҗбүр иде. Шулай да ул түшәк өстенә торып утырды һәм Гарифәгә урам тәрәзәсен чыгып ачарга, тизрәк самовар куярга кушты.

Тәрәзә капкачы ачылгач, өй эче яктырып китте. Акъәби шәһәрчә бик пөхтә киенгән кадерле кызы белән кадерле киявенең чиста, шома йөзләрен күрде. Күрде дә үз хәленнән тагын бер уңайсызланып, елыйсы килеп, авыр сулап куйды. Үз нәүбәтләрендә алар да бик ябыккан, тәмам кечерәеп калган әниләренең зәгъфрандай саргайган, сулган йөзен күрделәр. Күрделәр дә, сүзләрен оныткандай, бермәлгә тынып калдылар һәм яшерен

генә карашып алдылар. Болай ук булыр дип көтмәгәннәр иде алар. Эшләре тыгыз, вакытлары юк, шуңа күрә сүзне озынга сузмыйча, карчыкка шул ниятләрен әйтергә булдылар.

— Әсәем,— диде кызы, әнисенә үрелеп.— Без сине үзебез белән алып китәргә дип килдек. Калада докторларга күрсәтербез, әйбәтләп карарбыз, анда тизрәк терелерсең.

Кияве дә шунда ук өстәде:

— Дөрес, әби,供 бездә сиңа әйбәтрәк булыр, монда доктор да юк, караучы да юк, ялгызың нишләрсең?

Карчык тиз генә җавап кайтара алмады, аның кинәт күңеле тулды, шул ук вакытта нигәдер бик борчылып та куйды.

— Рәхмәт инде, балалар! — диде ул бераздан әкрен генә.— Юкка мәшәкатьләнгәнсез, үз өемдә дә терелер идем әле, Ходай насыйп итсә.

— Юк, әсәем, сине хәзер монда калдырып китеп булмый,—диде кызы, кабаланып.—Алып китәбез. Яхшылап дәваларга кирәк сине...

— Өй ялгыз кала бит.

— Калсын, берни дә булмас, күршеләрең карый торырлар.

Карчык бүтән бер сүз дә әйтмәде, авыр сулап кына куйды, монда доктор каравыннан башка, мәтрүшкәфәлән эчкәләп кенә терелеп китмәсен үзе дә аңлый иде булса кирәк. Аннары япа-ялгыз яту да аны шомландыра иде. Ә тегендә, калада, бөтен балалары диярлек, Ходайдан вакыт җитеп, алай-болай булып китсә, алар аның янында булачаклар. Әмма шул ук вакытта нәкъ менә шушы «алай-болай булып», ягъни үлеп китүен уйлап, ул үзенең гомер иткән почмагыннан чыгып китәргә дә теләми иде. Чит җирдә үлү, чит җир туфрагында ятып калу аны һәрвакытта куркыта иде. Юк, аның шушында, карты җан биргән кечкенә өендә үләсе, авылдашлары кулы белән кечкенә авыл зиратына — карты һәм яшьли үлгән сабыйлары янына куеласы килә иде. Ләкин ничек итеп менә хәзер ул алырга дип килгән кызы белән киявенең ихтыярына каршы тора алсын? Чыкмаган җанда өмет бар дигәндәй, бәлки, алып китеп, чынлап та терелтеп, аякка бастырып кайтарырлар, шуның өчен килгәннәр бит. Юк, авыр иде карчыкка бу төенне чишү, бик авыр иде!

Чәй урынын карчык янына, сәке өстенә әзерләделәр. Карчык, яткан җиреннән генә Гарифәгә кушып, үзенең сыйларын — баздан сөтен, маен, чоланнан кәрәзле балын, каклаган казылыгын табынга китертте. Ярлырак та бит, нишлисең, таза чагы булса, үзе тиз генә берәр кайнар аш та өлгертер иде, ә болай кешегә кушып кына буламыни ул. Аннары кызы белән кияве дә: «Борчылма, әсәй, бик әйбәт, бик җиткән»,—дип кенә торалар. Ашыгалар, күрәсең. Алып китәргә дип килгәч, алар үзләре дә бу юлы күчтәнәчләр төяп кайтмаганнар иде. Шулай да кызы берничә лимон белән бер кап шоколад конфетлар китергән икән, шуны табынга чыгарып куйды. Лимон авыру карчыкның нәфесе бик теләп торган нәрсәсе иде, ул аңа бик сөенде, хәтта кулына алып иснәп-иснәп тә карады.

Табын әйләнәсенә утырыштылар. Гарифә чәй ясый башлады. Карчыкка берьюлы рәхәт тә, күңелле дә булып китте. Менә, Ходаның рәхмәте, көтмәгәндә генә ул иң кадерле якыннары белән бер табында утыра бит әле. Аның өчен елына бер генә килә торган бәхет бит бу, гел шуны көтеп яши иде бит ул, тик менә, кызганычка каршы, урын өстендә каршы алырга туры килде үзләрен. Шуңадыр, ахры, бу минутта аңа никадәр генә рәхәт булмасын, нечкәргән күңеле нидер сизенгәндәй ирексездән ямансулап та, шомланып та куйгалый иде. Хәерлегә була күрсен иде...

Чәй янында сүз дә гел китү белән бәйләнгән эшләр турында барды. Карчыкка авыр иде бу сөйләшү, китүенә бер дә ышанасы килми иде шикелле, шуңа күрә күбрәк кызы бу турыда кайгыртып утырды. Ахырда түзмәде, өзелергә торган тавыш белән еламсырап әйтте:

— Ходаем, гомер иткән өемә йозак салып китәрмен дип уйлаган идеммени мин...

— Әсәем, бу ниткән сүз? — диде кызы, гаҗәпләнгән булып.— Бөтенләйгә ташлап китмисең бит, менә тиздән терелеп, үзең дә кайтып җитәрсең.

Карчык: «Юат инде, кызым, юат!» — дигәндәй, үзалдына моңсу-зәгыйфь кенә көлемсерәп куйды, әмма кайтарып бүтән бер сүз дә әйтмәде.

Чәйдән соң юлга да әзерләнә башладылар. Кияү кеше ашыга иде. Ул машинасы янына чыгып китте. Тузан кунган яшел «Волга»ны бала-чага сырып алган иде. Аягына чак тәпи басканы да ава-түнә килеп җиткән.

Зурраклары машинаның бөтен ялт иткән нәрсәләрен тотып-сыйпап, әйләнеп йөриләр, тик түбәсенә генә менеп китмиләр. Зур, таза абзый чыккач, алар башта куркып читкә сибелделәр, ләкин тиз үк яңадан машина тирәсенә җыела башладылар. Аларның тынгысыз елтыр күзләре бу шәп агайга, машинасында бер йөртеп килмәсме дигән яшерен өмет белән, гел чекерәеп карап кына торалар. Хәтта бер кап-кара башлы малай әрсезләнеп һәм юмаланып сорап та куйды:

— Агай, ә, агаем, безне анавы очтан гына бер йөртеп килсәң ине!

Мәһабәт агай, башын кагып, телен шартлаткан булды:

— Юк шул, малайлар, булмый хәзергә, ашыгабыз. Менә Акъәбиегезне китерә килгәч, мин сезне рәхәтләнеп бер йөртеп кайтарырмын, ярыймы!

Малайлар, Акъәби дигәнне ишеткәч, шунда ук тындылар, артык бәйләнеп тормадылар. Кайчагында алар мәсьәләнең җитдилеген зурларга караганда да тизрәк аңлый беләләр иде.

Шул арада читтәге капка төпләрендә җыелышып торган корткалар, хатын-кызлар да акрынлап килә башладылар. Акъәбине алып китәләр дигән хәбәр кечкенә авылга бик тиз таралып өлгерсә дә, хатын-кызлар каладан кайткан кадерле кунакларга ашап-эчкәндә комачауламас өчен, шулай әдәп саклап, көтебрәк торганнар иде. Хәзер инде менә килделәр, олыраклары өйгә үк кереп киттеләр. Акъәби — аларга бик якын кеше, гел бергә яшәгәннәр, аңа бик ияләшкәннәр, шуңа күрә аны ерак юлга, билгесез сәфәргә озату алар өчен шактый зур вакыйга иде. Йөзләре дә аларның җитди-уйчан иде, нидер сизенәләр иде, ахрысы, һәркайсында корткабызны яңадан инде күрә алмабыз дигән уй ята иде шикелле... Гаҗәп бит ул — кеше берәүнең дә үлүен теләми, әмма шул ук вакытта ничектер ихтыярсыздан шул үлемнең буласын сизеп, көтеп тә тора кебек.

Бераздан кара бишмәтен, оек-калушын кигән, чәчәкле зур шәлен ябынган Акъәбине кызы белән Гарифә ике ягыннан култыклап, акрын гына өйдән алып чыктылар. Алар артыннан бер хатын зур мендәр күтәреп чыкты.

Кияү машина ишеген ачты. Карчыкны иплэп кенә утырттылар, мендәрен, таяныр өчен, янтыгына салды-

лар. Кызы янәшәсенә кереп утырды. Машина тәрәзәсенә хатын-кыз башлары иелде.

— Акъәби җаным, хуш, сау бул инде!

— Акъәби бәгырем, терелеп кайта күр!

— Хуш, безне онытма, без көтәбез сине! — диделәр аңа. Ә таякка таянган бер кортка:

— Хуш, яшьтәш, бәхил бул, ахирәттә күрешергә насыйп итсен! — диде, бик тыныч, әмма чын күңелдән бик ихлас итеп.

Гөлбикә иренә тизрәк кузгалырга кушты. Машина алдында торучыларга кыска гына бер гудок бирде дә шома гына кузгалып китте.

Аз гына китүгә, Акъәби, кинәт урыныннан кузгалып:

— Һай, кәфенлегемне оныткан мын лабаса! — диде, нишләргә белмәгәндәй бик борчылып.

Кызы бу көтелмәгән сүздән сискәнеп киткәндәй булды һәм, чыраен сытып:

— Куйсана, әсәй! — диде, үпкә катыш рәнҗү белән.— Таптың искә төшерер нәрсә!

Карчык дәшмәде, күзләрен йомып, хәлсезләнеп башын гына иде.

Яшел машина, йомшак кына тирбәлеп һәм тузан уйнатып, Юлкотлыдан зур калага таба чыгып китте. Кечкенә өйнең капкасы төбендә җыелышып калган хатын-кызлар бөтерелеп тузан сузылган юл буена, машина күздән югалганчы, тик кенә карап тордылар.

Сораулар һәм биремнәр

1. Беренче бүлектә Акъәбинең кәефе, уй-фикерләре ничек тасвирлана? Аңа нинди сыйфатлар хас? Мисаллар китереп сөйләгез.

2. Миңлегали карт образына характеристика бирегез.

3. Акъәбинең балаларга, балаларның Акъәбигә мөнәсәбәте әсәрдә ничек яктыртыла?

4. Автор әсәрнең башында табигатьне ни өчен ягымлы-моңсу итеп сурәтли?

II

Менә Акъәби ялгызы кечкенә бер бүлмәдә, сиртмәле тар караватта, ак түшәмгә карап һәм каяндыр түбәннән тоныкына ишетелгән зур кала гөрелтесенә колак салып, тыныч кына ята. Урыны йомшак, астында чипчиста ак җәймә, өстендә сатин юрган — ипле, рәхәт аның арык-җиңел гәүдәсенә... Рәхмәт инде киявенә дә,

кызына да, аны менә шулай кадерләп, аерым бүлмәгә урнаштырдылар. Дөрес, аларны бер дә тыгызлыйсы килмәгән иде килүен, ләкин кияве белән кызы бу хакта авыз да ачтырмадылар. Хәтта элек бу бүлмәдә торган асрау кызларын да кухняга чыгардылар. Тик бераздан гына сизде карчык: монда авыру кешенең яткан җире генә түгел, ашаган-эчкән савыт-сабасы да аерым булырга тиеш икән.

Гомумән, карчыкка башта игътибар бик зур булды. Беренче көнне үк шәһәрнең икенче читеннән отставкадагы полковник улы белән килене дә аны күрергә килеп җиттеләр. Чүкечтәй нык, базык гәүдәле, зур йомры башлы, кыска имән муенлы полковник Суфиян, әйтергә кирәк, кәкре аякларындагы тар кунычлы хром итекләре белән генә түгел, бөтен кыланыш-гадәтләре белән дә чын «янарал» булырлык, беткәнче хәрби бер кеше иде. Кычкырып, кырт кисеп сөйләшә ул, берәүдән дә тартынмыйча, киерелеп, шаркылдап көлә һәм, иң мөһиме, үзен бик хаклы рәвештә дөньяның хуҗасы санап, бернигә исе китмичә, рәхәтләнеп яши иде. Квартир менә дигән, машина бар, пенсия җитәрлек, шуның өстенә аучылар җәмгыятендә нидер эшләп тә шактый акча төшергәли, кыскасы, әле чак иллесен тутырган полковникның тормышы бал да май, ал да гөл иде.

Әнисе карчык янына күрешә килгәч тә, ул карлыкканрак тавышы белән бүлмәне яңгыратырга тотынды:

— Һай, әсәй, әсәй, әсәем! — диде, әнисенең кипкән кулын каты учларына алып.— Ни булды сиңа, авырып киттеңмени, ике күзем?.. Ну, ничево, түлке син паникага бирелмә. Безнең генерал әйтә торган иде: солдатны пуля түгел, паника үтерә дип...

— Нәрсә соң ул... пәникә дигәнең, улым?

— Улмы, ул ни... курку, әсәем!

— Мин бер дә курыкмыйм, улым,— диде карчык тыныч кына.— Тәкъдирдән узмыш юк, барысы да Алла кулында.

— Һи, әйттең тагын! Барысы да безнең кулда! — диде полковник, һаман шаулап.— Менә мин сиңа докторның иң шәбен үзем алып килермен, әсәй!..

— Рәхмәт, улым, рәхмәт!

Карчыкның килене, өч башкорт бичәсенә торырлык юан, мәһабәт, ап-ак Мария Васильевна, каенанасы белән ике куллап, бик җитди итеп күреште. Карават кырыена

урындык алып утырды да, авыруның хәленә керергә теләгәндәй, аңа чын кызгану белән карап тора башлады. Юрган астында бала шикелле сизелер-сизелмәс кенә яткан бу каенана дигән сап-сары йөзле карчыкка аның нидер әйтәсе дә, кайгыртып нидер сорыйсы да килде, ләкин, гөнаһ шомлыгына каршы, тел юк — карчык бер кәлимә русча, ә килен бер авыз башкортча белми иде. Шулай да Мария Васильевна, ире аркылы булса да, берничә сорау бирде.

— Әсәй, киленең менә синнән кай җирең авырта дип сорый.

Карчык уйчан-моңсу гына әүвәл улына, аннары килененә карады.

— Тыным кысыла,— диде ул, күкрәген күрсәтеп.— Хәлем бер дә юк.

— Күптәнме?

— Тыным бетүен кыштан ук сизә башладым. Ә хәлсезләнүем күптән түгел.

Суфиян карчыкның сүзләрен русчага әйләндергәч, Мария Васильевна иреннәрен мәгънәле генә кысып, башын селкеп торды. Аннары ашыкмыйча гына нидер әйтте.

— Әсәй, киленең әйтә,— диде Суфиян,— опасный берни дә булмас, бронхлары ниткәндер, борчылмасын, ди.

Карчык дәшмәде, тик күзләре белән генә рәхмәтен белдереп, килененә бер тутырып карап алды.

Икенче көнне карчык янына, күрешергә дип, Суфиянның зур улы Геннадий да килде. Геннадий инде Юлкотлыга барып, әбисендә кунак булып кайткан егет, шуңа күрә ул карчык белән бик үз булып: «Ха, бабушка!» — дип, шатланып күреште һәм, урындык алып, караваты янына утырды. Акъәби, сөенеп-яктырып, башкортча: «Улым, килдеңмени, рәхмәт төшкерем!» — диде, ә егет, аның ни әйткәнен аңлагандай, елмаеп башын какты. Әйе, карчык бу дәү, сары егетне, үз нәселенә һич охшамаса да, чынлап ярата иде — барыбер аның токымы ич, аның каны!.. Нишлисең, якын шул, бик якын!.. Тик егет үзе «бабушка»сының йөрәгендә аңа карата нинди тирән һәм газаплы мәхәббәт ятканын сизәме икән?.. Юк, сизәргә тиеш, әнә килгән бит әле ул, әнә елмаеп әбисенә нидер әйтә дә бит әле... Ах, бу тел юклыгы!.. Карчыкның тел өйрәнер вакыты күптән

үткән шул инде, әмма ник бу Суфиян, юньсез, балаларына, ичмасам, әбиләренә дәшә алырлык кына үзебезчә берничә дистә сүз өйрәтмәде икән соң?!

Егет әдәп кушкан кадәр утырганнан соң кузгала башлады, торып, әбисенең кипкән ябык кулын сыйпады һәм: «Пока, бабуся!» — дип баш какты да чыгып китте. Карчык аңардан бик шат, риза булып калды.

Шул ук көнне тагын Суфиянның өч кызы: Татьяна, Светлана, Рита белән кече малае Борис та әбиләре янына килделәр. Кызлары да «суеп каплагандай» әниләренә охшаганнар, әниләре кебек барысы да эре сөякле, җирән чәчле, зур соры күзлеләр... Тик Боря (Борис) гына атасына охшаган, атасы кебек зур башлы, зур битле, арыш чумарыдай кап-кара бер малай иде. Бусын инде, бер дә икеләнмичә, Суфиян малае Шәяхметов дип йөртергә була.

Кызлар әбиләрен сырып алдылар, шаулап: «Здравствуйте, дорогая бабушка!» — дип күрештеләр, алып килгән чәчәкләрен карават янындагы тәрәзә төбенә утыртып куйдылар, урындыгына шоколад конфетларын салдылар һәм, инде ни әйтик дигәндәй, күзләрен елтыратып, әбиләренә карап тора башладылар. Шушы икән инде ул папаларына мама тиешле әби-карчык! Үзе кечкенә, үзе арык, өстенә киң, җиңел әкәмәт кенә күлмәк кигән, башына вак кына чәчәкле сары яулык бәйләгән, в общем, типичная башкирка икән.

Ә Акъәби үз нәүбәтендә буй җитеп килгән таза, зифа кызларга уйга калып, исе китеп, селкенмичә карап ята. Аннары зәгыйфь кенә елмая, иреннәрен кыймылдатып куя — нидер әйтергә тели, ахрысы... Менә ул күзләрен Боряга төби, әкрен генә кулы белән ымлап, аны якынрак килергә чакыра. Боря курыккандай башын сөзеп, каш астыннан гына карап, кузгалмыйча тора, тик апалары: «Иди, иди», — дип, аркасыннан этәргәч кенә, әбисенә якынлаша. Карчык, бердән яктырып, малайның аркасыннан сөеп: «Бәбкәчем, — ди, — зур егет бул, Алла тәүфыйк бирсен үзеңә!» — ди... Малай, берни аңламыйча, кызарып, әбисе яныннан тизрәк китә, ә кызлар нидер әйтеп, шаулап көлешәләр... Карчык исә һич үпкәсез, әмма боек-сагышлы итеп, тирән генә бер сулап куя. Әйе, бу балалар, никадәр ят-сәер күренмәсеннәр, аның үзенеке шул, үзенеке!.. Улының кемгә өйләнүенә, ничек яшәвенә бәгыре күпме генә сызланмасын, әмма онык-

лары аңа бик якын, бик газиз шул!.. Минем байлыгым дип кенә йөртә ул аларны...

Бер-ике көннән соң кызы Гөлбикә доктор чакыртып китерде. Урта яшьләрдәге таза, мөлаем хатын доктор Акъәби белән бик ачык сөйләште, күп сорашты, аннары күкрәген алдан да, аркасыннан да әйбәтләп тыңлады, тик ни өчендер карчыкның үзенә авыруы турында бер сүз дә әйтмәде. Кызы белән залга чыгып, шунда икәүдән-икәү генә сөйләштеләр.

Тагын берничә көн үтте, һәм менә шул ук хатын доктор олы яшьтәге озын, чандыр, күзлекле бер ир кешене ияртеп китерде. Моны шәһәрнең бик атаклы профессоры дип әйтәләр. Үзе татар икән... Шул профессор карчыкны игътибар белән тыңлады, сорашты, вакыт-вакыт иреннәрен кысып, авыруга озак кына уйланып карап та торды, аннары яңадан сорашты, яңадан тыңлап карады. Карап беткәч, тураеп һәм сүзләрен үлчәп кенә: «Әби, үпкәгездә авыру бар, ләкин ул картлык белән бәйләнгән булырга тиеш, без биргән даруларны эчеп, тыныч кына ятыгыз!» — диде. Шуннан соң барысы да, залга чыгып, үзара тагын нидер сөйләштеләр.

Акъәби, күңеленә ни генә килсә дә, сабырлыкка өйрәнгән гадәте буенча артык борчылмыйча, шомланмыйча, тыныч кына ята бирде. Ләкин докторларны озатканнан соң, янына кергән кызының бик җитдиләнеп киткән йөзенә карап, ул эшнең серен сизенгәндәй булды. Дөрес, кызы аңа берни әйтмәде, әмма бу киеренке хәрәкәтсез чырай, бу юри аңа карамаска тырышкан борчулы күзләр хәлнең ничек икәнлеген һәртөрле сүздән дә ачыграк әйтеп торалар иде кебек... Ә хәлләр, чынлап та, бик шомлы-куркыныч иде: докторлар карчыкның үпкәсендә яман шеш (рак) таптылар. Алар фикеренчә, җитмештән узган карчыкка операция ясап торудан мәгънә юк, иң яхшысы, үзенә әйтмичә, юатып, тыныч кына яткыру да авыру газабын төрле дарулар белән җиңеләйтергә тырышу — бары менә шуны гына эшләргә мөмкин. Хәер, үзенә әйтмәсәләр дә, карчык бу авыруның әҗәленә тигән авыру булуын күптән инде сизеп тора иде. Күпме яшереп маташмасыннар, монда ул бары вакытлы мөсафир гына...

Докторлар килеп киткәннән соң, карчыкка игътибар һәм тәрбия тагын да көчәя төште. Кызы белән кияве генә түгел, улы белән килене дә башта әсәйләренә бик

йомшак булдылар, гел кайгыртып кына тордылар. Кирәк даруларын да табып китерделәр, күңеле теләгән ризыкны да алдыннан өзмәделәр. Гүя алар көннәре санаулыга калган әсәебез алдында соңгы бурычыбызны үтик дип тырышалар иде. Һәм шушы хәл үзе генә дә инде карчыкка күп нәрсә турында сөйли иде кебек... Билгеле, ул балаларыннан бик риза, күңеленнән аларга рәхмәтен укып кына тора, әмма шулай да аларның бу соңгарак калган яхшылыклары вакыт-вакыт карчыкка аны фани дөньядан юатып озатыр өчен генә эшләнгән шикелле булып тоела, шуңа йөрәге сызланып куя, һәм чыкмаган җанда өмет бар дигәндәй, иң элек бер Алласына сыенып, тыныч кына ята бирә иде.

Акъәби калага килеп урынга яту белән, Казакъстандагы кече улын һәм Пермь өлкәсендәге зур кызын чакырып язуны үтенә башлады. Аны менә язабыз, инде язабыз дип, гел юатып тордылар, ләкин шулай да язарга ашыкмадылар. Бу шактый читен мәсьәлә иде. Карчыкның кече малае кайтып-китеп йөрмәслек бер җирдә эшләгәнгә күрә, аны, гомумән, чакырып маташудан мәгънә юк иде. Ә зур кызы Пермь өлкәсенең эчкәре бер районында балалар врачы булып эшли, җәй көне эше аеруча тыгыз була, шуңа күрә аны да вакытлы-вакытсыз борчырга ярамый иде. Кыскасы, карчыкның хәле бер көерәк торган чакта чакыру белән ашыкмаска булдылар.

...Көннәр үтә, гүя алар зур каланың түбәндәге шаушуы кебек тонык кына гүләп, читләтеп үтә. Колакка сеңгән бу шау-шуның башы-ахыры булмаган кебек, үтеп торган көннәрнең дә исәбе һәм билгесе юк. Ә рәхимсез авыру карчыкны астыртын гына кимерә, акрынлап кына ул эри-сыза...

Озакка сузылган өметсез авыруның бик күңелсез бер ягы бар: авыручы үзе дә, аны караучылар да акрынлап ялыга башлыйлар. (...)

Карчыкның берәүгә дә зары юк, ул барысын да аңлый, һәммәсеннән риза-канәгать, тик ул көне буе ялгыз ятудан бик туя һәм берәрсенең кайтып керүен зарыгып көтә. Кеше тансык, кеше кирәк аңа. Бигрәк тә кызының ике баласын — алты яшьлек Равиле белән дүрт яшьлек Гүзәлне бик сагына иде ул. Аларны балалар бакчасына йөртәләр: иртән илтеп куялар, кичкә таба алып кайталар. Алар кайткач, зур квартир тулып,

җанланып киткәндәй була. Бүлмәдән бүлмәгә йөриләр, такы-токы нидер сөйләнәләр, һәм Акъәби, ишектән күзен алмыйча, аларны көтеп ята. Равиле — малай кеше — әбисе тирәсендә күп чуалырга яратмый, керсә дә, тизрәк чыгып китү ягын карый, әмма Гүзәле, кыз бала булганга ахры, авыру әбисеннән бер дә ятсынмый, аңа гел сырпаланып кына тора. Бары шушы бала гына аңа бик матур, бик мөлаем итеп: «Әбекәем!» — дип дәшә. Бичара карчыкның күзләре яшь белән тулып китә бу җанга якын, тансык, кадерле «Әбекәем»не ишеткән чакта. Бик ярата, өзелеп ярата ул шушы түм-түгәрәк битле, кап-кара күзле йомшак, пакь, татлы оныгын! Үз йөрәгедәй якын ул аңа.

Хуҗаларга кунаклар да еш кына килгәлиләр иде. Өйдә, билгеле, ыгы-зыгы башлана. Гөлбикәнең кадак үкчәле туфлиләре белән шак-шок басып, ашыгып йөргәне ишетелә, тәлинкә, чәнечке-пычак, рюмкалар чыңлавы ишетелә, шуннан залдагы кунакларның шаулап сөйләшүләре, көлүләре ишетелә башлый. Карчык шуларның барысын да ничектер балаларча кызыксынып тыңлап ята.

Кызы Гөлбикә, вакыты тыгыз булса да кергәләп: «Әсәй, хәлең ничек, берәр нәрсә кирәкмиме?» — дип сорап чыга. Карчык, күңеле булып:

— Рәхмәт, кызым! Кунакларыңны кара, кунакларыңны! — ди аңа.

Ә залда мәҗлес матур гына дәвам итә. (...)

Кунакларның күбесе читтәге кечкенә бүлмәдә авыру карчык ятканны белмиләр дә иде шикелле... Һәрхәлдә, авыру бар дип борчылучы яки аның хәлен белергә керүче булмый диярлек — утыралар, көләләр-шаулыйлар, ашыйлар-эчәләр дә таралышалар... Шулай да ешрак килеп йөрүче бер кунак Акъәби янына кергәли торган иде. Бу тәбәнәк буйлы, ашыкмыйча, елмаеп кына сөйләшүче, исеме шактый билгеле булган олы яшьтәге бер шагыйрь иде.

Залда кунаклар шаулап утырган чакта гына, ул карчык янына мыштым гына килеп керә дә: «Саумы, әбекәем!» — дип, ике куллап күрешә, аннары урындык алып, караватт кырына утыра. Ул күп сөйләшергә яратмый иде, күбрәк тезләренә таянып тик кенә утыра һәм ара-тирә берәр хикмәтле сорау гына биреп куя торган иде. Карчык аның эчкәнме-түгелме икәнен дә аера

алмый, чөнки шагыйрь һәрвакытта гел бертөсле була торган иде. Ләкин, ничек кенә булмасын, ул бу уйчан, сәер кешене көтеп ала иде. Ничектер алар, аз сөйләшсәләр дә, бер-берсенә бик тиз ияләшеп киттеләр.

— Акъәби, Акъәби! — ди шагыйрь, үзалдына әйткәндәй әкрен генә.— Ә ни өчен Акъәби, ни өчен Кара әби түгел?

— Минем исемем Акбикә,— ди карчык, бу көтелмәгән сорауга бераз пошынып.— Кыз чагымда мине Аксылу дип йөртәләр иде, кияүгә чыккач, Аккилен булдым, аннары Акҗиңгә, ә хәзер менә Акъәби...

— Димәк, син гомерең буена ак кеше булгансың икән. Ак күңелле, пакь күңелле кеше... Менә миңа да шундый әсәй кирәк иде.

— Ни сөйлисең, улым, синең үз әсәең бардыр бит?!

— Юк шул, юк... Күптән оҗмахта инде ул... Ә әсәйсез авыр, әсәй сабый балага гына түгел, менә минем кебек сакалы агарган кешегә дә кирәк икән ул!

— Рәхмәт, улым! — ди карчык, нигәдер ирене калтырый башлап.

Шагыйрь, тезләренә таянган килеш, бераз уйланып утыра, аннары тагын сорап куя:

— Юлкотлыны сагынасыңмы?

— Сагынам, улым!

— Әйе, халык матур уйлаган, авылына, җиренә, суына матур исемнәр бирә белгән. Юлкотлы! Юлың котлы булсын, Акъәби! — дип әйтәсе килеп тора.

— Безнең ерак бер бабаебызның исеме Юлкотлы булган диләр. Аның кышлавын «Юлкотлы кышлавы»[1] дип йөрткәннәр. Тора-бара авылга да шул исем күчкән.

— Ә, шулаймыни? — ди шагыйрь, кызыксынып, һәм карчыктан иплән кенә аның кыз чакларын, кайчан, ничә яшендә кияүгә чыгуын, туйларның ул заманда ничек узуын, шул чактагы йолаларны, уеннарны, җырларны сорашырга тотына. Акъәби, еш кына тыны кысылса да, үзенең истәлекләрен, күргән-белгәннәрен иренмичә сөйли, ә шагыйрь аны бик игътибар белән тыңлап утыра... Карчык сөйләп беткәч тә әле, ул ни дә булса әйтергә ашыкмый, тик бераздан гына үзенең берәр әчке уен раслагандай әйтеп куя:

---

[1] Кышлау — күчмә башкортларның җәйләүдән соң кыш уздырыр өчен тукталган җирләре.— *Ә. Е.*

— Ийе... узган гомер кире кайтмый, сулар үргә акса да!.. Шулай ди җыр, сулар үргә акса да, ди, усал әйтә! Берсе дә — узган гомер дә, үтеп киткән тормыш та кире борылып кайтмаячак. Син дә, әбекәем, моның белән килешә торгансыңдыр?

— Килешмичә нихәл итәсең инде...

— Юк, син дөресен әйт, син олы кеше, бәлки борынгы тормыш сиңа кадерлерәктер, син аны сагына торгансыңдыр?..

— Хәзергесе начар булса сагыныр идем,— ди карчык, уйланып кына.— Хәзергесе, Аллага шөкер, әйбәт бит.

Шагыйрь аңа күзләрен тутырып карый.

— Шулаймы?.. Син дөньяны таный беләсең икән, әбекәй, яшә, яшә!.. Ләкин сагыныр нәрсәләр дә юк түгел бит. Әнә шул син сөйләгән халыкның матур йолалары — бәйрәмнәре-туйлары, уеннары-җырлары — берсе дә онытылмаска тиеш, минемчә... Халыкның буыннан буынга күчеп килгән рухи байлыгы бит алар барысы да... Дөрес, яңа заман яңа байлыклар тудыра, ләкин искенең дә яхшысын саклый белергә кирәктер ләбаса!

— Борчылма, улым,— ди карчык сабыр гына.— Халыкныкы халыкта саклана, югалмас, Алла бирсә!

— Гаҗәп сүз әйттең, әсәй бәгырем, гаҗәп сүз!..— Һәм шагыйрь, кинәт кенә тураеп, бер аягы белән идәнгә акрын гына суга-суга җырлап җибәрә:

Аппак микән, йомшак микән йәнкәемнең куллары,
Салават күпере кү-ү-үк суга барган юллары.

Онытып кара син бу җырны, онытып кара, мөмкинме соң!.. Шагыйрь, тавышы өзелгәндәй, шулай ук кинәт кенә тынып кала, башын артка чөя һәм күз төбендә аның тәгәрәп төшә алмаган яшь бөртекләре күренә. Тик бераздан тынычлангач кына, гафу үтенгәндәй әйтеп куя:

— Син мине тилегә санама инде, яме!.. Нишлим, мин шагыйрь кеше, халык җырын, бөек Тукай әйтмешли, рәсүлнең тырнагыдай йөрәгемдә саклап йөртәм.

— Ә мин Тукайны беләм,— ди карчык, һич көтмәгәндә.

— Китче! — ди шагыйрь, шаккатып.— Кайдан беләсең син аны?

— Суфияннар мәктәптә укыган чакларында: «И туган тел, и матур тел»,— дип, бер җыр ятлап йөриләр иде, шуннан хәтеремә кереп калган.

— Суфиян агай туган телне җырлап йөрдеме?.. Кызы-ык! — Һәм шагыйрь, бөгелә төшеп, тавышсыз гына күләргә тотына: — Их, генерал, генерал!..

Ләкин Акъәбинең җитдиләнеп китүен күргәч, ул көлүеннән шунда ук туктый, иелеп чәчләрен сыпыра, аннары баладай юаш кына әйтә:

— Син мине кичер инде, әсәй, синнән бернәрсәмне дә яшерә алмыйм шул...

— Бик яхшы, улым,— ди карчык тыныч кына.— Күңелең кешеләргә көзгедәй һәрвакыт ап-ачык булсын!

— Рәхмәт, әсәй, рәхмәт!.. Җиңел, рәхәт миңа синең янда... Тик күп лыгырдап ялыктырам бугай үзеңне... Ярый, кузгалыйм булмаса, син дә ял ит инде, ял ит, безгә карама, без — әрсез кунаклар!..— Һәм шагыйрь, торып, карчыкның юрган өстендә яткан сап-сары кулын йомшак кына сыйпый да, исерә төшкән кешедәй, аз гына чайкала биреп чыгып китә.

«Сәер кеше,— дип уйлана карчык аның артыннан,— ләкин әйбәт кеше үзе, кече күңелле, тик күңелендә ниндидер сызлавыгы бар шикелле, җанына урын таба алмыйча, шуңа сызланып йөри, ахрысы, бахыркаем!» Һәм күп вакытта ул аны ятим баладай күреп, чын ихластан кызганып кала торган иде.

...Бер ике-өч атна үтүгә, карчыкның хәле шактый авыраеп китте. Бик ябыкты ул, тамагына бернәрсә капмас булды, шуның өстенә тавышы да бетә башлады. Яңадан врачлар килде, карадылар, юаткан булдылар, тагын ниндидер яңа дарулар язып калдырдылар. Хәер, карчык өчен боларның берсе дә кирәкми иде инде. Ул барысын да белеп ята. Шулай ук аның хәлен уллары-кызлары да бик яхшы белеп торалар... Һәм эчләреннән генә куркып, шомланып үлемне көтәләр. Карчык, хәер, моны үзе дә сизә, карчыкның сизгәнен алар да беләләр.

Ләкин шуңа карамастан һаман: «Әсәй, борчылма, үтәр, терелерсең!» — дип, аны да, үзләрен дә алдарга тырышалар.

Карчык соңгы көннәрдә бик уйлана башлады. Көндезләрен барысы да хезмәтләренә китеп беткәч һәм асрау кыз да, карчыкның өстеннән бикләп, базарга китеп баргач, Акъәбигә ялгызы ак түшәмгә карап, теләсә күпме уйланып ятарга мөмкин иде. Уйлар күп, уйлар төрле-төрле, өзлексез килә торалар, китә торалар... Башта ул,

чынлап та, Юлкотлысын сагынып йөдәде. Бөтенесе: яланы-кыры, авылы-урамы, кешеләре, маллары бер генә минутка да исеннән чыкмый... Бөтенесе: өе, алачыгы, келәте, кәҗәсе, тавык-чебешләре — күз алдында тора, бөтенесен ап-ачык ишетә, күрә... Менә кәҗәсе, көтүдән кайткач, ишек төбенә килеп, Акъәбине дәшкәндәй, тавышын калтыратып кычкыра торгандыр. Җавап булмагач, тык-тык басып, өйалдына ук керә башлыйдыр... Тавыклары да, тибенеп йөргән җирләреннән туктап: «Нигә әле безнең әбиебез күренми?» — дигәндәй, башларын кырын салып, җелт-җелт карана торганнардыр. Казлары да, күл буеннан кайткач, ишегалдында озак кына каңгылдаша торганнардыр да, чыгучы, дәшүче булмагач, боек кына чирәмгә чүгәләшеп, башларын сыртларына салып йокыга талалардыр... Әйе, алар барысы да әбинең юклыгына гаҗәпләнә торганнардыр, күңелсезләнеп, боегып, моңаеп йөри торганнардыр... Шуларны уйлагач, Акъәбигә гаять авыр булып китә, алар да, үзе дә аңа бик кызганыч булып тоела һәм ихтыярсыздан кайнар яшьләре мөлдерәп төшә... Юк, күрмәс инде ул аларны — туып үскән Юлкотлысын да, гомер иткән өен дә, күршеләрен дә, терлекләрен дә — берсен дә яңадан күрә алмас инде!

Шушы котылгысыз аерылышуны сизеп торганга күрә дә булса кирәк, карчыкның күңеленә еш кына башка уйлар — җитдирәк, тирәнрәк уйлар да килә башлады. Әйе, аның көннәре санаулы, соңгы сәгате якынлаша... Ул курыкмый, ул тыныч көтә бу серле, рәхимсез сәгатьне, тик бер Ходаеннан җан бирү газабын җиңеләйтүне генә сорый... Ул әзер булып торырга тиеш, әйе, зиһене ачык, теле бар чакта ул үзенең соңгы теләген, соңгы васыятьләрен әйтеп калырга тиеш. Аннары инде... китәргә дә була.

Сораулар һәм биремнәр

1. Акъәбинең шәһәрдә үткәргән көннәре ничек хикәяләнә?

2. Хикәядән Акъәбинең сабыр холкын, язмышы белән килешүчән табигатен чагылдырган урыннарны табып укыгыз.

3. Балалары, оныклары Акъәбинең авыруына нинди мөнәсәбәт белдерәләр?

4. Шагыйрьнең Акъәбигә булган кешелекле мөнәсәбәте, нечкә күңеле турында сөйләгез.

Иң элек аның уен, билгеле, үлгәннән соң ничек итеп күмәрләр дигән нәрсә гел борчып тора. Ул белә: кайда, кемнәр кулында ятуын, әмма ул, гомере буена башыннан яулыгын салмаган мөселман карчыгы, Алла хозурына барам дип ышана, шуңа алдан әзерләнеп килгән һәм бөтен керсез күңеле белән үлгәннән соң гәүдәсен бары мөселманча итеп җирләүләрен тели: «Инде, муллла-мәзин чакырып, тәхлил әйттерү кебек зур мәшәкатьле эшне сорамыйм да, анысын эшләмәсәләр дә ярый. Әмма ләкин гәүдәмне әйбәтләп юып, ак кәфенгә төреп, ләхетле кабергә куйсыннар иде. Аннары, берәр карттан гына булса да, баш очымда Коръән укытсыннар иде...» Авылында булса, аны шулай күмәрләр дә иде, аның алып куйган кәфенлеге дә, чәчеме өчен җыеп торкан тәңкәләре дә, гәүдәсен ләхеткә куючылар өчен саклап килгән сөлгеләре дә бар иде, ләкин, нихәл итмәк кирәк, барысы да сандыгында торып калды шул... Ничек кенә булмасын, улы-кызы аның бу үтенечен тыңларга тиешләр. Үзләре ышанмасалар да, кирәксез нәрсә дип тапсалар да, ул кушканча эшләргә тиешләр — бу бит газиз аналарының соңгы васыяте! Васыятьне үтәмәү мөмкинме соң?!

Һәм кызы бер кичне аның хәлен белергә кергәч, Акъәби аңа якынрак килеп утырырга кушты.

— Гөлбикә кызым, сиңа сүзем бар,— диде ул, чак ишетелерлек зәгыйфь тавыш белән.— Алладан вакыт җитә шикелле, шулай сизәм... Менә исемдә чакта әйтеп каласым килә...— Аңа сөйләве авыр иде, әледән-әле тыны кысыла, авызы белән көчкә генә өзеп-өзеп сулышын ала.— Ух, ух, Тәңрем, җиңеллек бир... Э-э, әйе... кызым, ишетәсеңме, мин үлгәч, гәүдәмне берүк...

Гөлбикә, кызганудан йөзен чытып, шунда ук аның сүзен бүлде:

— Әсәй, әсәем, нигә ул хакта сөйлисең әле... Куй, кирәкми, борчылма, уйлама ул турыда...

— Һай, кызым, ничек уйламыйсың ди, килә бит ул әҗәл, килә, күрмисеңмени?.. Ух, уф... Соңгы сүземне әйтеп калыйм...

— Әсәем бәгырем, ярамый сиңа сөйләшергә,— диде кызы, кат-кат башын селкеп.— Хәлең юк, тавышың беткән, нигә үзеңне азаплыйсың... Тыныч кына ят, кирәгеңне генә сора!..

Карчык бераз күзен йомып торды, аннары ничектер хәл кергәндәй тыныч кына әйтте:

— Мин, кызым, нәкъ менә иң кирәген сорыйм да шул... Сез, яшьләр, шәригать йолаларын белмисез, үзем әйтеп калдырмасам, кем мине мөселманча җирләр?.. Яшьнеккә салырсыз да илтеп куярсыз...

Кызы урыныннан ук торды, ул, гадәтенчә, каядыр ашыга иде.

— Юк хәсрәт төшкән башыңа, әсәй!.. Ярар, бу хакта сүзне бетерик... Врачлар киңәшен тыңларга кирәк. Хәзер менә шушы даруыңны эч, бераздан Фатыйма кайнар чәй кертер... Онытма, ямьсез уйларга бирелеп яту синең өчен бик зарарлы ул... Ярый хәзергә, сөйләшербез, минем барып киләсе җирем дә бар иде...

Карчык дәшмәде, тик «бар!» дигәндәй башын гына каккандай итте. Һәм бик озак күзләрен йомып, берни уйламагандай, тын гына ятты. Әмма аның зиһене бер генә секундка да эшләүдән туктамаган иде. Нәрсәнедер, үзе өчен бик мөһим, бик яңа бер хакыйкатьне аңларга тырышып ята иде кебек... Алай, әнә ничек икән ул!.. Үләсе кеше белән каласы кеше тиз генә уртак тел таба алмыйлар икән! Бик кыен икән аларга сөйләшүе... Ни өчен соң бу шулай? Бөтенләй кирәксез, юк нәрсә турында кайгыртып ятамыни ул — дөньядан китәсе ана кеше? Балалары белән аның арасы шулай бик ераклашты микәнни? Алай дисәң, карыйлар, дәвалыйлар, кызганып, борчылып та торалар кебек, ә менә әсәйләренең соңгы сүзен, соңгы үтенечен тыңларга, йөрәген аңларга теләмиләр. Нидән соң бу болай?

Әлбәттә, карчыкка моның җавабын табу бик читен иде. Тик ул күңеле белән генә сизенә: балалары аның — бүтән кешеләр, бик нык үзгәргән кешеләр. Авыр аңа, ямансу аңа, ничектер, кинәт бик ятим, бик ялгыз калгандай хис итә ул үзен... Ләкин шулай да аның балаларына үпкәлисе, рәнҗисе килми. Җәнлек үзенең ярасын ялап төзәткәндәй, ул да җәрәхәтле йөрәген сабыр акылы белән тизрәк тынычландырырга, юатырга ашыга: ярамый болай, язык булыр, ди, балаларымны бәхилләп, ризалыкларын алып китәргә тиешмен, ди. Шәт, алар да мине аңларлар, сүземне тыңларлар, кадерләп озатырлар... Әйе, аның өмете зур һәм әйтер сүзе дә күп әле, күп...

Җитмеш алты ел буе дөньяда яшәгән карчык бит ул. Гомер иткән нигезе бар, нужа белән тапкан күпме-азмы мал-мөлкәте бар, яшь килен чагыннан ук саклап килгән

үзе өчен бик кадерле кием-салымнары бар — шуларның барысын да ул бик теләп, бик куанып балаларына калдырып китә. Өен, абзар-курасын, кәҗә-сарыкларын соңыннан теләсә нишләтсен — колхозга бирәләрме, сатып акчасын бүлешәләрме — алар эше.

Ләкин кайбер бик кадерле нәрсәләрен ул балаларына исемләп, атап биреп калдырырга тели. Сатар өчен дә түгел, чит кешеләргә бирер өчен дә түгел, ә аның төсе итеп, саклап тотар өчен бүләк итәргә тели. Мәсәлән, үзенең ак ука тоткан, якут каптырмалы сары бәрхет камзулын Гөлбикәсенә, вак мәрҗәннән җыеп эшләнгән, әдрәс астарлы кашмау белән чәчкабын Пермьдагы олы кызы Сылубикәсенә, картыннан калган камчат бүрекне улы Суфиянга билгеләп тора. Аннары бик борынгы тәңкәләр һәм төрле төстәге ташлар белән бизәлгән бөяте (хәситәсе) бар, шуны, кабул итсә, марҗа килененә бүләк итәр иде. Улының хатыны булгач, ул аңа да якын бит, бәлки, Мария килен дә каенанамның төсе дип бөятне үзендә саклар иде.

Билгеле, кызы — кашмауны, килене бөятне киеп йөрмәсләр, ул кадәресен генә Акъәби аңлый инде. Ләкин бит аларны бер әсәйләре генә түгел, әсәйләре кебек бик күп башкорт кызлары, башкорт җиңгәләре кигәннәр. Шуның өчен генә булса да, алар ул киемнәрне ничектер сакларга тиешләр. Югыйсә бетә бит инде барысы да, югала, онытыла... Ярый, шушы көнгә кадәр ул, Акъәби дигән кортка яшәп килде. Ул менә аларны моңарчы туган җирләре белән, андагы тормыш, андагы кешеләр белән бәйләгән бердәнбер җеп булды. Хәзер шушы бердәнбер җеп тә өзелә инде... Нишлисең, тәкъдирдән узып булмый шул, узып булмый!.. Ләкин, ни кызганыч, тере җеп өзелү белән бергә туган-үскән илгә юл да киселәчәк. Кылганлы далада утырган Юлкотлы үзе дә, аның кешеләре дә акрынлап онытылачак. Әмма киселергә тиешме соң, Ходаем, туган илкәйгә юл, онытылырга тиешмени соң ата-бабадан килгән андагы тормыш, андагы кешеләр? Юк, Акъәби үзе мондый хәл белән һич тә килешә алмый. Аның өчен туган ил — туган туфрак дигән сүз. Шул туфракта ата-бабаларының сөякләре ята, шунда аның гомердәшләре Миңлебай картлар, Минҗиһан корткалар, шунда аның күз алдында үсеп җиткән яшь ирләр, яшь киленнәр, шунда аның тирәсендә чуалган бала-чагалар, һәм ул аларны, кая

гына китмәсен, актык сулышына чаклы онытачак түгел. Менә шул хакта аның үз балаларына да бик нык әйтеп каласы килә: «Суфиян улым, Гөлбикә кызым, балакайларым! Сез икегез дә укыган, белемле, дәрәҗәле, зур кешеләр булдыгыз. Икегезнең дә түгәрәк кенә тормышыгыз бар, бер-бер артлы балаларыгыз үсеп килә, үзегез дә инде олыгаеп барасыз. Хак Тәгалә барыгызга да тигез гомер биреп, шул балаларыгызның игелеген күрергә насыйп итсен! Амин!.. Ләкин сезнең дә сабый чакларыгыз бар иде. Сез Аслы күл әйләнәсендәге киң, тигез далада утырган Юлкотлы дигән кечкенә башкорт авылында тудыгыз. Сөттәй йомшак, көмештәй саф сулы Аслы күл Юлкотлыдан өч кенә чакрымда... Аның шифалы суында коендырыр өчен, атагыз мәрхүм сезне, арбага тезеп утыртып, еш кына шунда алып бара иде. Ә Аслы күлнең Нора тавына менсәң, шуннан инде еракта ялгыз утырган, нәкъ түбәсенә кушкаен үскән Балкан тавы да күренә. Сезнең «Зyятүләк белән Сусылу» әкиятен ишеткәнегез бар инде, шул көзгедәй уйнаклап яткан күл белән еракта басып торган биек таудан туган әкият ул, ә тауның түбәсендәге кушкаенны Зыятүләк белән Сусылуның кабере диләр, каеннар төбеннән бәреп торган чишмәне Сусылуның озын кара толымнарыннан саркып чыккан су диләр. Әнә шулай әкиятләргә кергән гаҗәеп якты, иркен, матур җирләр бит ул безнең Аслы күл яклары! Һи, ниләр генә сөйләп булмас иде безнең башкорт илләре, башкорт җирләре турында!..

...Мин бераз читкәрәк киттем шикелле, балалар! Әйтәсе килгәнем бүтән иде... Зиһенемне азрак җыйыйм әле... Әйе, менә шул... Сез Юлкотлыда тудыгыз, аның киң урамында чабышып йөрдегез, чирәмендә ятып аунадыгыз... Үсә төшкәч, сез Юлкотлының ак кылганлы яланнарында, тау-чокыр буйларында йөрдегез, бозау көттегез, кизәк җыйдыгыз, әрлән кудыгыз... Бүтәннәрдән бер аермагыз да юк иде, бүтәннәр шикелле үк сез дә ситсы күлмәк, бөрмәле ыштан киеп, ялантәпи йөрүче кап-кара балалар идегез, үскәч кенә менә кем булып киттегез!

...Җиде-сигез яшегездән Юлкотлының кечкенә мәктәбенә сабакка төштегез. Шунда тел ачкычы таптыгыз, шунда күңел күзегез ачылды... Икешәр-өчәр көн рәттән котырган кышкы бураннарда үзем сезне җитәкләп

мәктәпкә илтә торган идем... Атагыз Әлшәй базарыннан, куенына кыстырып, сезгә китаплар, дәфтәрләр алып кайта торган иде... Бик ипле, бик бала җанлы кеше иде ул, мәрхүм!..

Юлкотлы мәктәбен бетергәч, Сыртлан мәктәбенә йөреп укыдыгыз... Аны да бетергәч, калага китәбез дидегез, каршы тормадык. Гәрчә сезне бер-бер артлы яныбыздан җибәреп тору авыр булса да, уку — изге эш, без күрмәгәнне балаларыбыз күрсеннәр, безгә насыйп булмаган аларга насыйп булсын дип, хәлебез җиткәнчә һәркайсыгызның өс-башын юнәтеп, акчасын да аннан-моннан табып, сезне ерак юлга озаттык. Сездән аерылгач, безгә бик ямансу була иде, атагыз, ир кеше, сиздермәсә дә, минем, ашарга утырган саен, кашыгыма яшьләрем тәгәрәп төшә иде... Сез киттегез, әмма ул чакларда әле сез Юлкотлыны онытмый идегез, Юлкотлыны сагына идегез, бала кошлар шикелле очып-очып кайткалый идегез... Ләкин ни өчен сез аны соңыннан оныттыгыз? Чакырып-дәшеп тә еллар буе кайтмый башладыгыз?.. Ике сүзнең берендә «туган ил» дисез, ә Юлкотлы нәрсә соң? Туган илнең сезгә иң якын, иң кадерле бер өлеше түгелмени ул?

...Сез бик еш кына «халык» дисез, ләкин Юлкотлыдагы кешеләр дә халыктыр бит инде. Бер тамырдан чыккан, бер ыруглан үрчегән халык, шуңа күрә ул сезгә якынрак та, туганрак та булырга тиештер ләбаса!.. Кайчандыр сезнең башыгыздан сыйпап узган агайларның, апайларның кайберләре хәзер дә әле исәннәр. Менә кайтып, шулар белән ике куллап бер күрешсәгез, олылап бер җылы сүз әйтсәгез, сез аларны күпме сөендерер идегез. Һәм күпме рәхмәт, күпме изге теләк сез алардан ишетер идегез. Һай, ярата безнең халык зур укыган кешенең кече күңелле булуын, мактап бетерә алмый, ә тәкәббердән кача, тәкәббергә бервакытта да йөзен дә, телен дә ачмый ул...

Яки атагыз мәрхүмне исегезгә төшерегез. Ул да бит халыкның бер бөртеге... Сезгә җан биргән, сезнең өчен тир түккән, сездән күпме өметләр көткән ата кеше бит әле ул сезгә! Йә, сез аның алдында бер дә бурычлы түгелмени соң?.. Авыл читендәге канау белән генә әйләндереп алган кечкенә зиратта аның гәүдәсе ята. Баш очында ташы юк... Аның каберен мин дә, тагын берничә авыл карты гына белә. Бездән соң белүче булмаячак,

кабер җир белән тигезләнәчәк... Йә, сезнең җаныгызны бер дә борчымыймыни бу нәрсә?.. Машиналар сатып алырга хәлегездән килә торып, атагызның каберенә бер таш кына яздырып куярга сезнең кулыгыздан килмимени? Килә, бик килә, тик күңел саранлыгыннан котылырга кирәк, тик кемгә бурычлы булуыгызны онытмаска кирәк!.. Имештер, яшь чагында көтү көткән, соңыннан бик баеп киткән Өфенең бик зур бер куписы үзенең шул кайчандыр киеп йөргән иске чабаталары белән озын чыбыркысын намаз бүлмәсендә генә элеп тоткан, ди. Күрәсез, ул да, бахыр, намаз укыган саен шуларга карап, элек кем булуын онытмаска тырышкан. Менә сезгә гыйбрәт!

Әйе, сез зур кешеләр булдыгыз, илгә, дәүләткә кирәкле, файдалы кешеләр булдыгыз, хәзер шуның әҗерен күрәсез, рәхәтен чигәсез!.. Ләкин сезне менә без, Сәлимҗан белән Акбикә дигән гади башкорт кешеләре, дөньяга китердек, Юлкотлы дигән кечкенә башкорт авылы сезне үзенең туфрагында үстерде, башкорт халкы сезне бүгенге югарылыкка күтәрде — сез шуны онытмагыз, балаларым, ишетәсезме? Сезнең онытырга хакыгыз юк, аңлыйсызмы?.. Бу минем күңелем төреннән чыккан иң кайнар, иң зур, иң соңгы васыятем сезгә!»

Һәм шушы васыятен әйтеп калырга Акъәби берничә тапкыр омтылып карады. Бу аның өчен бик тә кирәк иде, әйтмичә китәсе килми иде, хәтта үлгәннән соң да әйтә алмыйча калган васыяте өчен кабере́ндә борчылып ятар кебек иде. Ләкин ул авызын ачты исә, аңа: «Һай, әсәй, юкка борчылма әле син, кирәкмәгән нәрсәләр уйлап ятма әле»,— диделәр. «Сиңа күп сөйләргә ярамый, врачлар кушмый»,— дип, гел тыйдылар һәм аны юатыр, тынычландырыр өчен тамчылап даруын эчерделәр, лимонлап чәен китерделәр, тәлинкә тутырып алмасын, чиясен китереп куйдылар.

Аптырап-уйланып ята торгач, кайчагында Акъәбинең үзе янында сырпаланган кечкенә Гүзәлгә нидер әйтәсе килә, бик сак кына, бик гади сүзләр белән генә күңелендәге шул сабыйга аңлатасы килә. Шул ук вакытта баланың йөрәгенә шом салмыйм дип тә курка ул... Ничек кенә дип әйтергә аңа? Бераз икеләнеп ятканнан соң, баланың аркасыннан сыйпап, гүя болай гына әйтеп куйган була:

— Бәләкәчем, мин тиздән китәрмен инде...

— Китәсең... Кая китәсең? — ди бала, зур күзләре белән әбисенә тутырып карап. (Ә берни сизә, берни төшенә белмәгән, бары тик ышана яки курка гына белгән сабый күзләреннән дә бәгырьне телгәләрлек нәрсә бар?!)

— Ни инде... үзебезнең Юлкотлыга,— ди карчык, көчкә генә телен әйләндереп.

— Юк, китмисең, китмисең!..— ди бала, шунда ук үпкәли дә башлап.

Акъәби, үксеп җибәрмәс өчен, иреннәрен кыса һәм озак кына дәшә алмыйча ята. Бары бугазына килгән төер кире киткәч кенә, тагын әйтеп куя:

— Мин сиңа, кошчыгым, аннан бүләк җибәрермен.

— Бүләк? Нинди бүләк, әбекәем?

— Сиңа билгеләп куйган бик матур чулпыларым бар, шуларны җибәрермен.

— Ә нәрсә ул чулпы? Нигә син аны алып килмәдең?

— Онытканмын.

Бала, ышаныргамы-юкмы дигәндәй, әбисенә карап тора-тора да, нидер сизенгәндәй, башын селкеп куя.

— Син алдыйсың,— ди ул, сузып кына.— Бездән китәр өчен генә әйтәсең...

Акъәби йөзен тизрәк читкә бора. Юк, булмый, сөйләү мөмкин түгел... Сабыйның күңеленә кагылырга ярамый, ярамый, аярга кирәк аны, аярга!.. Кем белә, бәлки соңыннан бу әйткәннәрне исенә төшереп, әнисеннән: «Әбекәем кая китте, нигә миңа чулпы җибәрми?» — дип сорап йөдәтер. Һәм карчык, сабыйны тынычландырыр өчен, аның күңелендә бернинди шик-шомлану калдырмас өчен, көлгән булып, баланы юатырга ашыга:

— Юри генә әйттем, бәбкәчем, юри генә! Сине калдырып китәмме соң?.. Юк, юк, беркая да китмим, күз нурым!..

...Гаҗәп хәл! Бала белән шушы гөнаһсыз гына сөйләшүдән соң, Акъәби, гомумән, васыятьләрен кемгә дә булса әйтергә тырышудан шактый вакыт тыелып торды. Әллә ничек шунда һичнәрсәгә исе китмәстәй, һичнәрсә турында уйлыйсы килмәстәй булып калды. Тик өзлексез җанын борчыган бер генә нәрсә аны һаман уйландыра иде. Һәм бары шуны гына ул үз янына ашыгып кына кереп чыккан улы Суфиянга ишетелер-ишетелмәс тавышы белән тагын бер тапкыр әйтеп карады.

— Улым, үтенәм сездән, мине зинһар үзебезчә, мөселманча җирли күрегез инде.

Улы Суфиян, уйлап та тормыйча:

— Һи, әсәй, обязательно шулай эшлибез аны! — диде, гаҗәеп бер җиңеллек белән: — Менә әйтте диярсең, мөфти хәзрәтнең үзен чакыртам яныңа... Только син, әсәем, үләргә ашыкма әле, яме! Торыйк әле, торыйк, Алласына, мулласына үч итеп дигәндәй...

— Көфер сүз сөйләмә, улым! — диде карчык сабыр, җитди генә.

Ләкин Суфиян авыру кешегә бердәнбер кирәк нәрсә, ул да булса (үз сүзе белән әйтсәк) бодрость дип белә иде. Шуңа күрә ул һәр сүзне уенга бора, үзенчә шаяртмакчы-көлдермәкче була. Һәм күп вакытта утырып та тормыйча, авызына ни килсә шуны сөйләп, бүлмәне бер шаулатып, тизрәк чыгып та китә иде. Ә карчык, бичара, ни уйларга да белмичә, аның артыннан башын гына чайкап кала. Чынлап әйттеме ул, юри генә әйттеме, нигә утырып, әйбәт кенә сөйләшмәде соң, кая ашыга, кая чаба ул? Гаҗәп бу шәһәр халкының гадәте — барысы да каядыр ашыгалар, ашыгалар, ашыгалар!..

Үлем дә ашыга иде шикелле. Соңгы көннәрдә карчыкның хәле бөтенләй начарланып китте. Тын алуы бик авырлашты, кислород мендәреннән бер дә аерылмас булды. Бала шикелле тәмам кечерәеп калды, күзләрен дә инде йөртә алмый башлады.

Врачлар кызы белән киявенә карчыкның тиздән өзелеп китү ихтималын әйттеләр — торса, тагын бер атнаун көн генә тора алыр, диделәр. Бу хәбәр аларда зур борчылу тудырды. Димәк, әсәй карчык китә!.. Һәм бик ачык, котылгысыз булып алларына килеп баскан бу гаять авыр, хәсрәтле үлем аларны тәмам аптырауга төшерде. Хикмәт шунда: үлем дигән нәрсә аларның өенә беренче мәртәбә керә әле, моңарчы аларның мондый фаҗигале хәлне күргәннәре дә, кичергәннәре дә юк иде әле... Борчылмыйча, уйланмыйча һич мөмкин түгел. Иң элек карчыкның үлеме балаларга бик авыр тәэсир итәчәк, куркытачак бу нәрсә аларны... Аннары мәетне юу бар, җыештыру бар, озату бар, ә алар үзләре бу эшләрнең тәртипләрен һич тә белмиләр. Кемнән эшләтергә, ничек эшләтергә боларны? Түбәндәге дворник хатыны Сәрбиҗамал апага әйтсәң, ул бик теләп боларның барысын да оештырыр иде... Юарга, кәфенләргә карчыкларын да табар иде, бәлки мулласын да чакырып китерер иде. Ләкин болар барысы да гаять мәшәкатьле

эш бит, әллә ничек күңелсез эш. Кияве, бу хакта сүз чыкса, теше сызлагандай, чыраен сыта башлый. Мөселманча булсын дип әллә нинди карчыкларны, муллаларны үзенең квартирасына бер дә китерәсе килми аның... Килешми аның хәлендәге кешегә бу нәрсәләрнең берсе дә. Ничектер бүтән юл, бүтән чара табарга кирәк бу положениедән чыгар өчен...

Кияве белән кызы арасында шушы хакта берничә көн буена сүз барды. Гаять четерекле мәсьәлә турында алар мөмкин кадәр әдәп, такт саклап сөйләштеләр, ләкин шулай да ара-тирә үпкәләшеп, талашып та киткәләделәр. Хәер, асылда, аларның фикерләре бер иде: карчык квартирада үлсә, бик авыр, бик күңелсез булачак.

Ахырда кияве әйтте: «Гөлкәй, бүтән чара юк, әбине больницага салырга кирәк,— диде.— Больницада әле аңа яхшырак та булыр, урын-җире чиста, врач көн дә карап тора, сестралар һәрвакыт янында, үзебез дә чиратлашып янына баргалап торырбыз... Нишлисең инде, үләргә булгач, кайда да барыбер... Аның каравы балалар кадерле әбиләренең үлемен күреп, тетрәнеп калмаслар, куркып елашмаслар... Аннары больницада мәетләрне әйбәтләп юындырып, киендереп озатучы махсус кешеләр дә бар. Ә без үзебез монда нишли алабыз?.. Юк, иң яхшысы больницага салу инде...»

Гөлбикә, бу эшнең күңелгә авыр, оят, килешмәгән ягын белсә дә, уйлый-тора ахырда риза булды. Шулай сөйләшеп килешкәннән соң, алар үзләренең бу карарларын, уңайсызланыбрак булса да, Суфиян белән Мария Васильевнага да әйттеләр. Башта Суфиян бик кайнарланып каршы төште.

— Што сез,— диде, кычкырып,— кадерле әсәебезне өйдә үлмәсен өчен генә больницага илтеп салмакчы буласыз? Оятын ничек күтәрерсез, хурлыгын кая куярсыз?.. Юк, юк, мин моңа асла риза түгел!

Ләкин кияү кеше кызмыйча гына, әйбәтләп кенә аңа төшендереп бирде:

— Каенагай, оят мәсьәләсендә синең безгә бер сүз әйтергә дә хакың юк. Әсәебезне авылдан без барып алдык, без аны өебездә ай ярым буена кулыбыздан килгән кадәр тәрбияләдек, карадык, терелмәсме дип бөтен чараларны күрдек... Әсәй үзе моның өчен безгә рәхмәтен әйтер, дип ышанабыз. Инде больницага салу мәсьәләсенә килгәндә, бу синең өчен авыр икән, тота-

сың да үзеңә аласың... Сиңа да ана бит ул!.. Әмма мин әсәйнең үлгән чагын балаларга күрсәтеп, аларның йөрәкләрен җәрәхәтләргә теләмим.— Һәм шунда ук, каенагай тагын дулап китмәсен дип булса кирәк, ипләп, йомшартып кына әйтте: — Без, Суфиян, дәү кешеләр, мәсьәләгә айнык карарга тиешбез. Авыруны больницага салуның һичбер гаебе юк. Беркем бер сүз әйтмәячәк. Инде анда үлеп китә икән, без әсәебезне шуннан гына бик әйбәтләп, бөтен шартын җиткереп, соңгы юлына озатырбыз. Ә өйдән мәет озату — бик авыр, бик мәшәкатьле эш ул, син безнең хәлебезне аңларга тиешсең, Суфиян!

Бу сүзләрдән соң Суфиян, шактый аптырауга төшеп, үзенә терәк эзләгәндәй, алмашлап, бер сеңлесенә, бер хатынына карады. Ире артына посыбрак, бөрешеп кенә утырган сеңлесе гүя бөтен кыяфәте белән: «Миңа карама, мин арыдым, мин берни дә эшли алмыйм»,—дип әйтеп тора иде. Ә юан ак беләкләрен зур күкрәкләре өстенә кушырып салган хатыны, бу мәсьәлә аңа һич кагылмагандай, йомык бер битарафлык саклап утыра иде. Суфиян акрын гына җилкәсен кашырга тотынды.

— Шулай, каенагай! — диде кияве, аның хәлен җиңеләйтергә теләгәндәй. — Борчылырлык урын юк, барысы да бик әйбәт булыр, менә күрерсең!

Һәм Суфиян бу мәсьәләдә үзенең ялгыз калуын гына түгел, бигрәк тә көчсез булуын сизеп, ниһаять, килеште.

Инде моны карчыкның үзенә җиткерергә кирәк иде. Кияү, билгеле, бу эштән читтә калырга теләде, чөнки ул, нинди генә якын кеше булмасын, карчыкның үз баласы түгел... Шуңа күрә улы белән кызы әйтергә тиеш булдылар: «Әсәй җаным,— диделәр алар аңа ипләп кенә,— докторлар сине бер атна-ун көнгә больницага салып торырга куштылар, анда дәвалап карамакчы булалар. Син борчылма бер дә, хәлең яхшыргач та, кире алып кайтырбыз үзеңне...»

Акъәби моның чын сәбәбен сизгәндерме-юктырмы, әмма «болнис» дигән сүз үзе генә дә аның котын алды. Тәмам куркып, рәнҗеп һәм ялварып, ул: «Балакайларым, зинһар, кузгата күрмәгез, шушы җылы урынымда тыныч кына үлим, миңа берни дә кирәкми, вакытым җитте, аңлагыз шуны!»— диде.

Ләкин улы белән кызы, ташка әйләнеп булса да, аны үгетләп, юатып, хәтта азрак кына көчләп тә урыныннан кузгаттылар, киендереп чыгардылар һәм «Волга» ма-

шиналарына кырын яткырып, алдан кияве сөйләшеп куйган бер больницага илтеп салдылар.

...Өч тәүлек үтүгә, төнлә белән Акъәби шул больницада вафат та булды. Җан биргәндә, янында кеше булмаган. Берәүне дә борчымыйча, күбәләктәй тавышсыз тынсыз гына киткән дә барган. Әйтерсең үзенең Юлкотлысына...

Иртән иртүк әбинең үлгәнен телефон аша кызына хәбәр иттеләр. Кызы белән кияве, шунда ук машинага утырып, больницага киттеләр. Алар килгәндә, Акъәбине үлекләр ята торган цемент идәнле таш бүлмәгә төшереп куйганнар иде инде. Тиздән улы Суфиян белән килене Мария Васильевна да килеп җиттеләр. Ак җәймә астында яткан әсәйләренең йөзен ачып карадылар. Йөзе бер дә бозылмаган иде, киресенчә, ничектер авыр газапларыннан котылып, тынычланып калган кебек иде. Әмма күзләрендә ни торып калгандыр, анысын күрмәделәр — күзләрен кемнеңдер бармагы сак кына йомдырып куйган иде.

Аннары больница бакчасына чыгып, шунда гына карчыкны ничек итеп җирләү турында үзара киңәш корып алдылар. Мулла чакыру, җеназа укыту кебек нәрсәләрне эшләмәскә булдылар. Шулай да әсәйләренең Аллага ышанган карчык кеше булуын исәпкә алып һәм аның үзенең дә бик үтенеп соравын исләренә төшереп, гәүдәсен кәфенгә төреп күмәргә булдылар. Ләкин, гөнаһ шомлыгына каршы, больницадагы мәетне юып, киендереп озатучы марҗалар кәфен дигән нәрсәне бөтенләй белмиләр дә икән. Ә читтән кеше чакыртып, дини йолага бәйләнгән нәрсәләрне эшләтү монда рөхсәт ителми икән. Шулай итеп, чарасыздан Акъәбине «заманча гына» әзерләргә мәҗбүр булдылар. Бер чиста күлмәген, китереп, өстенә кидерделәр, башына «мөселманча» итеп ак батис яулык бәйләделәр, шуннан соң гәүдәсен кечкенә кызыл табутка салдылар. Табут әйләнәсенә чәчәкләр тезделәр, күп итеп ислемай сиптеләр, һәм Акъәбиебез хәйран матураеп китте. Ул, бичара, хәтта көлемсерәп яткандай күренә башлады.

Зиратка табутны машинага куеп илттеләр. Озата баручылар күп түгел иде; иң якыннары да аларның кайбер дус-ишләре һәм шулар арасында әлеге кечкенә буйлы шагыйрь дә бар иде. Ләкин ул бүген дә кызмача иде шикелле.

Табутны кабергә төшергәндә, кызы Гөлбикә бик каты елады, килене Мария Васильевна да елады, аның кызлары да «бабушка»ларын кызганып елашып алдылар. Ләкин ирләр түзделәр... Кияве, иреннәрен кысып, читкәрәк китте. Ә улы Суфиян әсәен озату шәрәфенә бөтен орден-медальләрен өр-яңа кителенә тагып килгән, башына соры папахасын сындырыбрак кигән полковник кабер кырыенда таш сыңдай басып торды. Үлемне күп күргән, елауны күптән оныткан кеше булуына карамастан, аңа бу минутта яшьләрен йотып калу гаять авыр шикелле.

...Күмеп бетергәч тә борылып китү ничектер кыен иде, шуңа күрә шагыйрь, ак балчык өеме янына басып, мәрхүмә турында берничә сүз әйтергә булды:

— Кадерле дуслар, без менә шушы биек тау башындагы инде үләннәре дә корыган, чәчәкләре дә шиңгән җир куенына Акъәбиебезне бирдек,— диде ул, ашыйкмыйча, салмак кына.— Ак күңелле, пакь күңелле әсәебездән мәңгегә аерылдык... Әйе, ул барыбызның да уртак әсәебез иде. Алай гына да түгел, мин, һич икеләнмичә, аны башкорт халкының изге җанлы анасы дияр идем... Әмма нәрсә беләбез без аның хакында?.. Күрә белдекме без аның шул изге җанын, пакь күңелен, ак уйларын!.. Менә сез, аның уллары, кызлары, кияүләре, нәрсә генә әйтә аласыз гомере буе сезнең өчен өзелеп яшәгән бичара әсәегез турында?.. Юк бит, әйтә алмыйсыз бит...

Шунда ук Суфиян, кычкырып, аның сүзен бүлде:

— Син ни сөйлисең, ә?! Ташла, кирәкми...

— Безобразие бу! — диде кияве дә, кызарып-бүртенеп.

Шагыйрь аларга һич игътибар итмичә тагын нидер әйтә башлаган иде, шул чакта кемдер аны беләгеннән эләктереп, кабердән, җилтерәтеп, читкә алып китте. Телгә батыр булса да, гәүдәгә бик җиңел иде шагыйрь...

Бу күңелсез тамаша аркасында озата килүчеләр яңа гына кабергә куелган Акъәбине ничектер онытып җибәрделәр. Берәүләр шагыйрьне тиргәргә тотындылар, икенчеләр, киресенчә, аңа әһәмият бирмәскә, сүзне уенга борырга тырыштылар. Һәм үзара сөйләшә-шаулаша кабер яныннан тарала да башладылар. Иң ахырдан кузгалган Гөлбикә зират капкасы төбендә утыручы картхорыларның учларына тиз-тиз генә акча салып чыкты...

Киттеләр... Агыйдел, Дим буйларына караган биек тау башында Акъәби берүзе генә торды да калды.

Әмма ләкин Акъәби, биек тау башындагы зиратта әнә шулай ялгызы гына торып калса да, үзенең фани дөнья белән аерылып бетмәвен тагын бер тапкыр балаларының исенә төшерде. Хикмәт шунда: кызы Гөлбикә, Юлкотлыда карчык өен карап торучы әлеге күрше хатыны Гарифәгә кыска гына хат язып, әсәйләренең август ахырында вафат булуын хәбәр иткән иде. Озак та үтми, Гарифәдән дә Акъәбинең үлүенә бик хәсрәтләнеп, күршетирәнең аны бик кызганып елауларын әйтеп, инде бахырның өе ятим калды, аны нишләтергә уйлыйсыз, дип борчылып язган хат килә. Хат артыннан ук карчыкның колхоз машинасына салып җибәргән иске яшел сандыгы да килеп төшә. Күрәсең, яхшы күңелле Гарифә үзенчә бер изгелек эшләргә теләгәндер инде, ләкин монда ул сандыкны берәү дә әле көтми иде. Яңа гына кичергән кайгы-мәшәкать аркасында, гомумән, Юлкотлыда калган өй-нигез турында да, башкасы турында да уйлашырга өлгермәгәннәр иде. Инде менә әсәйләренең үзе белән бергә картайган, буявы да уңып беткән иске сандыгы: «Мин сезнеке, мине нишләтәсез?» — дигәндәй, Гөлбикә квартирына килде дә керде. Гөлбикәгә бу сандык бик таныш иде, кайчандыр аның шушы сандык өстендә курчак уйнаган чаклары да бар иде, кинәт күргәч, әллә нишләп китте, бермәлгә аптырап-каушап калгандай булды. Аннары исенә килеп, тиз генә агасы Суфиянга шалтыратты. Шул ук кичкә таба агасы белән җиңгәсе Мария Васильевна, зур уллары Геннадийны да ияртеп, аларга килеп тә җиттеләр.

Барысы да җыелып беткәч, сандыкны идән уртасына куеп ачтылар. Ачып тибәрүгә, алар өстә генә яткан ак бәз кәфенлекне күрделәр. Һәм, күреп, берәр сүз әйтү түгел, хәтта бер-берсенә күтәрелеп карарга да ничектер кыймадылар, тик ак материяне сак кына бер читкә алып куйдылар. Аннары бөкләп салган кием-салымнарны чыгарырга тотындылар. Менә әсәйләренең тәңкәле кара җиләне, читләренә ука тоткан сары хәтфә камзулы, алтынга манган тәңкәләр һәм төрле ташлар тагылган бөяте (хәситәсе), вак мәрҗәннән эшләнгән кашмавы белән чәчкабы, беләзек, муенса, чулпылары, кыз чагында үз кулы белән чүпләп суккан кызыл башлы сөлгеләре килеп чыкты. Шулай ук аталарының кызыл сәдәпле

кара казакие белән камчат бүреге дә килеп чыкты — карчык шушы көнгә кадәр аларны да саклап торган икән, бичара!.. Актарына торгач, тагын бер хикмәтле әйбер табылды, бу аталарының яшь чагында тотып йөргән кыска саплы, күн чуклы, өч җәпле, һәр җәбенең очына көмеш пластинка бөкләп кидерелгән бик шәп камчысы иде.

Хикмәтле камчы шунда ук барысын да бик кызыксындырды.

— Һай, атаемның төлке куганда тотып чапкан камчысы бит бу! — дип кычкырып ук җибәрде Суфиян һәм элмәгеннән киеп селтәнеп тә, бот буена сугып та карады.

— Да-а, менә бу ичмасам реликвия! — диде кияве дә, сокланып.— Тик кем саклар аны?

— Ә аның хуҗасы бар,— диде Суфиян катгый рәвештә һәм улы Геннадийга борылып, тантаналы итеп әйтте: —Мә, улым, Гена, ал бабаңнан калган чуклы камчыны... Белеп тот, Шәяхметовлар кулында йөргән камчы булыр бу!..

Һәм Геннадий Шәяхметов баш кагып, елмаеп кына өч җәпле камчыны кулына алды.

...Инде калган әйберләрне нишләтү, ничек бүлешү мәсьәләсе кузгалды. Белгәнебезчә, әсәйләренең бу хактагы теләген алар тыңламыйча калдылар. Шулай да һәркайсы үзенә ошаган нәрсәне алырга хаклы иде. Ләкин бу тәңкәле җилән, хәтфә камзул, бөят, кашмау, чәчкаплар белән алар нишләрләр икән?.. Төс итеп кенә саклаудан башкага ярамый инде боларның берсе дә, аунап йөри торгач, череп-тузып кына бетәрләр... Шул чакта кияүләренең башына бик шәп бер идея килде. Ул болай диде:

— Менә нәрсә, Гөлбикә, каенагай! Без бу әйберләрне бүлешеп, әрәм-шәрәм итеп бетермик. Барыбер файдаланып булмаячак бит... Без лучше тотыйк та бөтенесен театр гардеробына тапшырыйк. Анда мондый нәрсәләрне саклый беләләр, борынгы тормышны уйнап күрсәткәндә киеп файдаланырлар, ә безнең тарафтан театрга бу бик әйбәт бер бүләк булыр. Чын, уйлагыз әле!

Бу фикергә шунда ук Мария Васильевна да кушылды:

— Бик дөрес әйтәсез, Сәхип Карамович, безгә нигә алар, артистлар кисеннәр.

Ләкин Суфиянга да, Гөлбикәгә дә мондый тәкъдим белән тиз генә килешүе авыррак иде. Ничектер күңелләре тартып бетерми иде. Әллә ничек менә, әсәйләреннән яхшы түгел кебек — алар өчен саклаган, аларга дип калдырып киткән бит әле ул... Инде тот та бөтенесен кочагы белән театрга илтеп ташла! Килешерме, оят булмасмы?

Шул ук вакытта кияүләренең сүзендә дә дөреслек бар: бүлешеп алсалар, әрәм-шәрәм булып кына бетәчәк, нишлисең, тәңкәле җиләннәр, укалы камзуллар заманы үтте шул инде!.. Ахырда, уйлаша торгач, башта Суфиян, аннары Гөлбикә дә яшел сандыктан чыккан бөтен киемсалымны театрга илтеп тапшырырга риза булдылар. Гөлбикә шулай да әсәенең төсе итеп, уртасына кызыл якут куеп, саф көмештән челтәрләп эшләнгән ике зур чулпыны үзенә алып калды.

Көннәр уздылар. Хәсрәт иртәнге томандай бик тиз таралды. Эш, мәшәкать белән тулы иркен, мул тормыш үзенең иске эзеннән ашыгып һаман алга таба тәгәрәде. Акъәбинең балалары өчен бу кызу чапкан тормыш бик тансык та һәм бик мавыктыргыч та иде.

Дала буйлап кылганнар йөгерә, кылганнар йөгерә... Куыша-куыша йөгергән кылганнар арасыннан, озын карагай таягын җир үлчәгәндәй алга ташлап, Миңлебай карт кайтып килә. Ыштан балагын эчкә тыгып кигән ак оекбашларына чәчәк тузаны кунып, билчән уралып, бакра сырышып беткән, әйтерсең Юлкотлы яланнарын үзе белән ияртеп кайта ул...

Авылга кереп, Акъәбинең тәрәзәләре кагылган өе янына җиткәч, карт күрше Гарифәдән гел кычкырып сорап уза:

— Аккилен кайтмадымы әле?

Гарифә ни дип җавап бирергә дә белми — ул бит инде аңа былтыр ук берничә мәртәбә Акъәбинең калада вафат булуын әйткән иде. «Балалар акылы керә башлаган ахрысы бу картка»,— дип уйлый ул эченнән генә һәм, аптырагач, ачулана биреп әйтә:

— Куй, Миңлебай бабай, үлгән кеше кайтамыни, ничек телең барып сорый?

Ләкин карт аның сүзләрен гүя колагына да элми.

— Алдама,— ди ул, таягының башын селкеп.— Аккилен үлмәде ул, китте генә... Китте генә... Кайтыр, насыйп булса кайтыр... Ә син учагын карый тор, учагын... Учагында ут сүнмәсен.

Һич аңламассың, әллә чынлап, әллә үчекләп, әллә саташып әйтә бу бернигә исе китми торган, әҗәлгә дә күптән кулын селтәгән, ялан таптаучы йөз яшәр Миңлебай карт!

1965 ел

Сораулар һәм биремнәр

1. Акъәби туган ягын, Юлкотлы авылын, үзенең хуҗалыгын, мал-туарын ничек итеп күз алдына китерә?

2. Акъәби балаларына васыять итеп нәрсәләр әйтеп калдырырга тели?

3. Аның туган туфракка, милләткә, туган теленә мөнәсәбәте ничек? Ул мөнәсәбәт ни рәвешле белдерелгән?

4. Ни өчен ул борыннан килгән истәлекләренең балаларында саклануын тели? Балалары бу әйберләргә карата нинди мөнәсәбәттә?

5. Балалары Акъәбинең васыятен ишетә алмыйча калалар. Сәбәпләрен аңлатыгыз. Моның нәтиҗәсе ничек булып бетә?

6. Автор бу әсәре белән нәрсә әйтергә теләгән?

7. Акъәби образы турында инша языгыз.

ӘМИРХАН ЕНИКИ ИҖАТЫНЫҢ ҮЗЕНЧӘЛЕГЕ

Әмирхан Еники безнең әдәбиятта кеше күңелен бик тирәнтен, мавыктыргыч итеп тасвирлый белүе белән аерылып тора. Ул кичерешләрнең үтә йомшак тибрәнешләрен, хисләр агышын, борылышларын, эчке каршылык, бәрелешүләрне үзенә бертөрле зирәклек белән тоя. Әдип катлаулы чынбарлыкны, кешеләр яшәешен гүяки эчке яктан яктырта, тышкы хәл-әхвәлләрне геройлар күңеле аркылы үткәреп сурәтли. Бәлки шуңадыр каләмдәшләре аның иҗатын музыкага тиңлиләр. Әсәрләренең моңы, матур җыр кебек, соңыннан колакта яңгырап тора, күңелгә йогып кала.

Ә. Еники ашыкмый-кабаланмый, тирән уйланып, һәр сүзен үлчәп яза, ювелир төгәллегенә омтыла. Аның прозасында психологик тирәнлек белән сәнгатьчә камиллек бергә кушыла.

Ә. Еники тема, характерларны китаптан алмый, тормышның үзеннән таба. Аның «Саз чәчәге», «Рәшә», «Вөҗдан», «Без дә солдатлар идек», «Гөләндәм туташ хатирәсе» повестьларындагы, «Әйтелмәгән васыять», «Җиз кыңгырау», «Тынычлану» хикәяләрендәге табышлары чынбарлыкны рәссам һәм философ буларак җентекләп өйрәнү җирлегендә туганнар. Партия җитәкчеләрен мактап кына язарга яраган бер дәвердә ул «Саз чәчәге»ндә аларның мещанлык сазлыгына бата баруын, «Рәшә» повестенда совет сәүдәгәрләренең халыкны имеп яшәүләрен, «Вөҗдан» повестенда колхозлашу елларының рухи драматизмын күрсәтте. Хәзер хәл ителә торган мәсьәләләрнең байтагын Ә. Еники күп еллар элегрәк кыю күтәреп чыкты, аларга җәмәгатьчелек фикерен юнәлдерде. Шуңа күрә аның әсәрләре үзгәреш рухын чагылдыралар, бүген язылган кебек укылалар. Әдипнең һәр яңа әсәре әдәбиятыбызда һәм укучы күңелендә үз урынын алды. Аның һәр язганы көтеп алына, яратып укыла.

«ӘЙТЕЛМӘГӘН ВАСЫЯТЬ» ХИКӘЯСЕ ТУРЫНДА

Ә. Еники маҗаралы, җитез хәрәкәтле, кискен борылышлы сюжетлар белән мавыкмый. Ул еш кына үтә гади, гадәти, ләкин шуның белән бергә бик кешелекле, тирән мәгънәле, кешеләргә якын, кадерле хәл-әхвәлләрне ала. Һәм шуларның хәрәкәте дәвамында кеше күңеленең моңарчы без белмәгән якларын чигеп, нәкышләп бирә, рухи гүзәллекне яктырта.

«Әйтелмәгән васыять» хикәясенең үзәгендә Акъәби образы, аның тойгы-кичерешләре, үтә кешелекле һәм җитди уй-фикерләре тасвирланган. Бу образда халык рухы, борын-борыннан килгән гореф-гадәтләре чагылган. Акъәби гомере буена хәләл көче белән көн күргән. Берсеннән-берсе уңган, илгә файдалы, кирәкле балалар үстереп биргән. Ул — киң күңелле, хезмәт яратучы, зур хөрмәткә лаек ана. Акъәби балаларының олы дәрәҗәгә ирешүләренә ихлас күңелдән куана, ләкин шул ук вакытта туган туфрактан читләшүләренә, туган халкыннан аерыла баруларына җаны әрни. Олы улы Суфиянның рус кызына өйләнүен бик авыр кичерә. Ул моны туган халкыннан йөз чөерү, нәсел-ыруыннан аерылу дип кабул итә. Һәм, чыннан да, әсәрдән күренгәнчә, Суфиянның балалары Татьяна, Светлана, Рита, Геннадий, Борис «бабушка»ларына дәшәрлек башкортча бер авыз сүз белмичә үсәләр. Суфиян гаиләсендә башкорт милләтенең теле, гореф-гадәтләре югала, хатыны Мария Васильевна йогынтысы гына табигый үсешен, яшәешен дәвам иттерә. Акъәби балаларына газиз туган телне күз карасыдай кадерләп сакларга кирәк дип васыять әйтеп калдырырга тели.

Моннан тыш, халыкның талантын, матурлыкка мөнәсәбәтен, яшәү рәвешен аңлаткан, ата-бабаларның төсе итеп буыннан буынга күчеп, сакланып килгән ядкарьләр була. Акъәби дә үзе өчен бик кадерле кайбер нәрсәләрен балаларына төсе итеп калдырырга тели. Мәсәлән, «ак ука тоткан, якут каптырмалы сары бәрхет камзулын Гөлбикәсенә, вак мәрҗәннән җыеп эшләнгән әдрәс астарлы кашмау белән чәчкабын Пермьдагы олы кызы Сылубикәсенә, картыннан калган камчат бүрекне улы Суфиянга билгеләп тора. Аннары бик борынгы тәңкәләр һәм төрле төстәге ташлар белән бизәлгән бөяте (хәситәсе) бар, шуны, кабул итсә, марҗа килененә бүләк итәр иде».

Ләкин балалары Акъәбинең соңгы теләген тыңларга вакыт та таба алмыйлар, кирәксенмиләр дә. Хәтта ананың соңгы васыятен — аны үзебезчә җирләүне дә тиешенчә оештыра алмыйлар. Акъәби вафат булгач, бу әйберләрнең күбесен театр гардеробына тапшыралар. Ата-бабаларның истәлеге өзелеп калгандай була.

Рухи байлык, әлбәттә, үткәннәр, үлгәннәр өчен кирәкми, исәннәр, бүгенге һәм киләчәк өчен кирәк. Әсәрдәге йөзьяшәр картның «учагында ут сүнмәсен» дигән сүзләре халыкның рухи байлыгы бервакытта да саекмасын, кимемәсен, милләт

үткәнен хөрмәт итсен дигәнне аңлата. Акъәбинең васыятьтеләкләре халык тормышын рухи төссезләндерүгә каршы юнәлгән. Бу гади генә авыл карчыгы киләчәк буыннар тормышын мәгънәле, матур итеп күрергә тели.

Хикәя табигать күренешен сурәтләү белән башланып китә: «Йомшак кына җәйге җил исә... Дала буйлап кылганнар йөгерә, кылганнар йөгерә. Ефәк чукларын еш-еш кына селкеп, акрын гына кыштырдап, бик тырышып һәм бик кабаланып йөгерә кебек алар... Колын булып уйнаклап, шул кылганнар артыннан чабасы да чабасы килә. Дала буш, дала киң, җир җылыкай, шаян җилкәй биттән сөя... Рәхәт, һәй, рәхәт тә соң!.. Һәм ямансу. Нигәдер бик ямансу да шул! Шагыйрь әйтмешли, йөгереп уйныйсы, ятып елыйсы килә бу тын, буш, моңсу башкорт даласында!» Бу юллар, кереш музыка кебек, әсәрнең бөтен аһәңен, моңын билгелиләр.

Проблема. Проблема күтәрү — тормыштагы хәл ителәсе мәсьәләне кузгату, җәмгыять игътибарын шуңа юнәлтү дигән сүз. Бу очракта әдип яшәешне философ буларак өйрәнә, аны халык ихтыяҗлары ноктасыннан карап бәяли. Ул тормыштагы нинди дә булса каршылыкларны тотып ала, аның шул конфликт хәлендә дәвам итәргә тиеш түгеллеген күрә, каршылыкны чишү, хәл итү өчен инде шартлар өлгергән дип саный.

«Әйтелмәгән васыять» повестенда Ә. Еники халыкның рухи хәзинәсенә хөрмәт белән карау кирәклеге мәсьәләсен күтәрде, рухи бушлыкны, әхлакый, мәдәни мирастан читләшүне тәнкыйтьләде.

Нури Арсланов
(1912—1991)

Нури Арсланов — чын шагыйрь. Әдәби осталыгын чарлый барып, актив иҗат итеп, үзен яңа, зур поэтик мәдәниятебезне тагын да баету өчен көрәшүче итеп танытты.

Мөхәммәт Садри

Тугандаш Казакъстан җире татар әдәбиятына Ибраһим Салахов, Мәхмүт Хөсәен, Бари Рәхмәт, Миркасыйм Госманов кебек әдәбият эшлеклеләрен биргән. Бу игелекле җир татар шигъриятенә Нури Арслановны да бүләк итте.

Нури Газиз улы Арсланов 1912 елның 12 сентябрендә Кызылъяр (хәзер Петропавел) шәһәрендә эшче-көнлекче гаиләсендә туган. Күкчәтау шәһәрендә җидееллык татар мәктәбен тәмамлый. Аннан соң, Казанга килеп, сәнгать техникумында рәсем ясау осталыгына өйрәнә. «Пионер каләме» (хәзер «Ялкын») журналында һәм «Яшь ленинчы» (хәзер «Сабантуй»), «Совет Татарстаны» (хәзер «Ватаным Татарстан») газеталарында рәссам булып эшли.

Рәссам булса да, ул кырыгынчы еллар башыннан әдәбиятка тартыла һәм гомеренең соңгы көннәренә кадәр кулыннан каләмен төшерми. 1964—1972 елларда «Казан утлары» журналында шигърият бүлегенә җитәкчелек итә. Ул үзенең бер робагыенда[1] болай ди:

---

[1] Робагый — дүрт юллы мөстәкыйль шигырь. Гадәттә аның беренче, икенче һәм дүртенче юллары рифмалашып килә.

Балачактан күңел сәнгатькә тартты,
Зәвыкны сәхнәдә, җырлауда тапты;
Рәсемнәр дә төшерде... Әмма шигъри
Гомергә тынгы бирми аптыратты.

Нури Арсланов ике сугышта — фин сугышында һәм Бөек Ватан сугышында катнаша. Ржев шәһәре янында каты яралана, Кызыл Йолдыз ордены һәм «Батырлык өчен» медале белән бүләкләнә.

Ир — ирмени, ил яклап,
Яуга каршы тормаса?! —

ди шагыйрь һәм бу сүзләрен үзенең шәхси эш-гамәлләре белән раслый.

Шагыйрьнең иҗаты алтмышынчы елларда аеруча чәчәк атты. Әсәрләренең лирик-фәлсәфи ягы, тәэсир итү көче артты. Аның байтак шигырьләрен композиторларыбыз көйгә салдылар. Мәсәлән, «Республикам минем» (Н. Җиһанов), «Казан кызы», «Нәсимә» (З. Хәбибуллин), «Гәрәбә» (Р. Гобәйдуллин), «Үрдәкләрем-дүдәкләрем» (И. Хисамов) һәм башка җырлар. Н. Арслановка «Иделем — илем» исемле шигырьләр һәм поэмалар җыентыгы өчен 1985 елда Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге бирелде.

Н. Арсланов 1991 елның 14 апрелендә Казан шәһәрендә вафат булды.

Сораулар һәм биремнәр

1. Казакъстан җиреннән чыккан күренекле әдәбият эшлеклеләренең исемнәрен атагыз. Аларның нинди әсәрләрен беләсез?

2. Рәссам белән шагыйрь арасында нинди аермалар һәм уртак яклар бар? Ничек уйлыйсыз: Н. Арслановтагы бу ике сәләт бер-беренә комачауладымы әллә, киресенчә, ярдәм иттеме икән?

3. Шагыйрь илен өзелеп яратучы, аның өчен утка-суга керергә әзер торучы булырга тиеш. Моны Н. Арсланов тормышы мисалында да дәлилләп буламы?

4. Шагыйрь Мөхәммәт Садри каләмдәшен, иҗат кешесе буларак, ничек бәяли?

5. Н. Арсланов — Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек булган шагыйрь. Әдәбият-сәнгать эшлеклеләреннән шундый бүләк бирелгән тагын кемнәрне беләсез? (Әсәрләрен дә атагыз.)

АТЛАНТИДА[1]

Атлантида булды микән чынлап?
Тынгы бирми сорау һич кенә:
Әллә кайдан, ерак-ераклардан
Һәлакәтле бер моң ишетелә.

Кинәт юкка чыккан бөтен кыйтга,
Тау-дулкыннар күккә ашканнар:
Бер мизгелдә илләр, шәһәрләрне,
Һәйкәлләрне сулар басканнар.

Океан упкан кебек Атлант җирен,
Дәүләтләрне монда җир упкан:
Дәшти-Кыпчак, Болгар, Алтын Урда...
Бер-берсенең тамырын корыткан.

Ничә тапкыр килгән монда яулар,
Кичергәннәр илне кылычтан[2]...
Калдыгын да көлгә дүндерергә[3]
Миссионерлар[4] күпме тырышкан.

Сәхифәләр тузган, юкка чыккан...
Ә без — менә, без — бар, булганбыз!
Фал ачабыз[5], ләкин баш ватабыз;
Әллә кыпчак, әллә болгар без?

Кем булгандыр бабам: кыпчакмы ул,
Болгармы ул? Нинди аерма?!
Татар дигән исем йөртәбез без —
Татар каны ага тамырда!

---

[1] А т л а н т и д а — борынгы грек риваятьләренә караганда, Атлантик океанда Гибралтар бугазыннан көнбатышта урнашкан утрау. Имеш, ул моннан ун мең елдан артык элек җир тетрәү нәтиҗәсендә юкка чыккан. Атлантиданың чыннан да булу-булмавы мәсьәләсен хәл итү буенча күп гасырлар буена бәхәсләр барса да, нинди дә булса уртак бер нәтиҗәгә киленгәне юк.

[2] К ы л ы ч т а н к и ч е р ү — кешеләрне кылыч белән чабып үтерү.

[3] Д ү н д е р е р г ә — әверелдерергә.

[4] М и с с и о н е р л а р — башка диндәге кешеләрне үз диненә күчәргә үгетләп йөрүчеләр, мәҗбүр итүчеләр.

[5] Ф а л а ч у — фалнамәгә (шундый махсус китапка) карап, үткәнне яки киләчәкне әйтү, ягъни күрәзәлек итү.

Атлантида! Атлантида баткан.
Эз калмаган бөек халыктан...
Ә без — менә, без — бар, эз бар җирдә —
Без батырган саен калыккан.

Атлантида язмышы юк безгә [1],
Оныкларның анык бабасы:
— Нәселең кем? — дип сорасалар әгәр,
Әйтерләр: — Без — татар баласы!

Татарстан дигән Ватаным бар,
Татар дигән халкым бар минем.
Узганнардан түгел, мин халкыма
Киләчәктән урын барлыймын.

1969 ел

Менә ничә гасырлар инде Атлантида чыннан да булганмы, булса, кайда булган, аннан нинди эзләр, истәлекләр калган дип баш ваталар, бәхәсләшәләр. Н. Арсланов та шигырьнең беренче юлында ук шундый сорау куя: «Атлантида булды микән чынлап?» Тулы бер илнең су басудан һәлак булуы бик кызганыч, әлбәттә. Шагыйрь дә моңа борчыла.

Әмма Н. Арслановның әйтергә теләгән төп фикере бу түгел әле. Әлеге легенданы искә төшереп, ул ерак үткәндәге шул фаҗигагә карата укучыда билгеле бер хис тудыра. Шуннан соң гына үзе әйтергә теләгән төп мәсьәләгә килә — халкыбызның язмышы турында уйлана. Иксез-чиксез Дәшти-Кыпчак далаларында, Болгар дәүләтендә, Алтын Урда берләшмәсендә, Казан ханлыгында яшәү баскычларын узган татар халкы нинди генә авырлыклар кичермәгән дә, нинди генә кайгы-хәсрәтләр күрмәгән. VI гасыр азагы һәм VII гасырның беренче чирегендә Кара диңгез һәм Кавказ буйларында төзелгән Бөек Болгар дәүләтенә кемнәрнең генә күзе кызыкмый? Хәзәрләр басымы астында дәүләт җимерелә башлый. Болгарларның зур бер өлеше, Идел — Чулман буйларына килеп, хәзерге Татарстан урнашкан җирдә Идел буе Болгары дип аталган дәүләт төзи. Истәлекләргә караганда, Идел буе Болгары көчле, алга киткән ил була. Шуңа күрә күрше илләр дә аны таныйлар, бу ил белән исәпләшергә мәҗбүр булалар. 984 һәм 1006 елларда тигез

---

[1] Атлантида язмышы юк безгә — бу очракта шагыйрь безнең үткәнебез билгесез түгел дип әйтергә тели.

хокуклы болгар-рус килешүләре төзелү шуны күрсәтә. Әмма 1236 елда Идел буе Болгары дәүләтен татар-монголлар яулап ала, аны Алтын Урда берләшмәсенә көчләп кертәләр. Бу империя җимерелгәч, биредә Казан ханлыгы төзелә. Әмма 1552 елда күрше рус дәүләте Казан ханлыгын сугышып ала, аны көч ярдәмендә үзенә куша. «Бер-берсенең тамырын корыткан» дигәндә, Н. Арсланов менә шуларны истә тота.

Болгарлар — безнең борынгы әби-бабаларыбыз — 922 елда ислам динен кабул иткәннәр. Ләкин 1552 елдан соң аның халкын көчләп чукындыру сәясәте алып барылган. Миссионерлар — әнә шул эшне тормышка ашыручы кешеләр. Алар моның өчен нәрсә генә эшләмиләр (әнә шагыйрь дә «миссионерлар күпме тырышкан» ди). Әмма халыкның бик аз өлеше генә бу басымга бирелә. Көчләп чукындырылганнарның да бик күбесе яңадан мөселманлыкка кайта.

Татар халкының килеп чыгуында, үсешендә болгарлар һәм кыпчакларның өлеше аеруча зур. Шуңа күрә хәзер кемнең шәҗәрәсе кайсысыннан — болгарданмы әллә кыпчактанмы булуы артык әһәмиятле түгел, иң мөһиме — татар булуыбыз. Татарлар, фаҗигаләргә юлыккан саен, көчле рухлырак була барганнар. «Без батырган саен калыккан халык»,— ди шагыйрь бу хакта. Үткәне олы, бай, хәвефле һәм фаҗигале, шул ук вакытта горурланырлык булган халкыбызның киләчәге дә өметле, матур булырга тиеш. Без башка халыклардан өстенлек алырга түгел, бәлки аларга тигез булырга гына телибез. Чөнки чын дуслык, хезмәттәшлек, тигезлек һәм дустанә мөнәсәбәтләр бары тик шул шарт үтәлгәндә генә мөмкин.

Сораулар һәм биремнәр

1. Нәрсә ул Атлантида? Аның турында сез нәрсәләр беләсез?

2. Татар халкының үсү тарихы һәм язмышы турында белгәннәрегезне сөйләгез.

3. Шагыйрь ни өчен татар халкын Атлантида белән чагыштыра?

4. Атлантида баткач, «эз калмаган бөек халыктан» ди шагыйрь. Татар халкы турында исә «без — бар, эз бар җирдә» диелә. Г. Тукай да «эзле без, тарихында бер дә тапсыз көзге без» дигән. Халкыбызның тарихта калдырган эзләре — игелекле эшләре турында сез нәрсәләр әйтер идегез?

5. Шигырьдәге «без батырган саен калыккан» дигән фикерне киңәйтеп, ниләр әйтергә була?

6. «Оныкларның анык бабасы» дигән темага фикер алышу уздырыгыз.

7. Татар халкының киләчәген сез ничек итеп күз алдына китерәсез?

8. Шагыйрь әсәрдә чагыштыру алымын уңышлы кулланган. Сәнгатьлелек алымы буларак, чагыштыруның шигырьдә тоткан урынын күрсәтегез.

ЯЗ

Матур чаклар!
Өстән энҗе тамып тора,
Ерганаклар,
Кар сулары агып тора,
Дымлы, салкын
Җирне нурга манып кына
Кояш алтын
Литаврасын[1] кагып тора.
Китте кышлар,
Мамык тунын салып кына,
Кайтты кошлар,
Канатларын кагып кына,
Карда посып,
Умырзая калкып чыга,
Килсә гыйшык[2] —
Урын калмый вак борчуга.

Тирәмдә ямь, —
Мин шул хәят[3] тәмен беләм!
Шуңа сөям
Сезне җаным-тәнем белән.

1986 ел

Кайсы гына шагыйрь яз турында шигырь иҗат итмәгән икән? Ник дигәндә, елның бу фасылы кеше күңелен аеруча нечкәртеп, канатландырып җибәрә. Озын, салкын кыштан соң табигатьнең уяна башлавын күрү кемнең генә күңелен нечкәртми? Иҗат кешесен бигрәк тә. Нури Арсланов та яз күренешләрен әнә нинди нәфис итеп сурәтли!

---

[1] Литавра — бәреп уйный торган музыка коралы.
[2] Килсә гыйшык — гашыйк булсаң.
[3] Хәят — тормыш.

Сораулар һәм биремнәр

1. Шигырьдән чагыштыруларны табыгыз. Аларның яз күренешен тулырак, җанлырак итеп күз алдына китерүдәге хезмәтен аңлатыгыз.

2. Шигырьнең төзелешен күзәтегез. Ул өч строфадан тора. Игътибар итегез: строфаларда юл саны тигезме? Шигырь юллары бер-берсе белән ничек рифмалашалар?

3. «Яз» шигыре — лирик әсәр. Ни өчен шулай әйтәбез? Сез тагын нинди лирик әсәрләрне беләсез?

4. «Тәмен беләм», «сөям җаным-тәнем белән» дигән сүзтезмәләрне сезнең тагын кайсы шагыйрьнең нинди әсәрендә укыганыгыз бар? Шул шигырьне дә сыйныфта укыгыз.

ТӘЛГӘШ-ТӘЛГӘШ МИЛӘШ

Миләшләрем минем тәлгәш-тәлгәш,
Оешканнар кызыл мәрҗәннән.
Баш ияләр алар мине күргәч,
Якын алар миңа бар ямьнән.

Тәрәзәмнән карап көндез-кичен,
Сүзсез генә нидер серләшеп,
Җыр чыгара алар минем өчен...
Башка таллар тора көнләшеп.

Миләшләрдән кызлар колагына
Ике бөртек алып тагасы! —
Янсын иде алка булып кына...
Кызык та син адәм баласы! —

Миләшне дә, назлы кызларны да,
Яратканга бөтен хәятны —
Гел төшәсең бәхет тозагына.
Бүтәннәргә әллә бу ятмы?

Ят түгел! Бар тормыш кадерен белеп
Яшәүчеләр, Хәйям[1] шикелле:
Аларга җир җәннәт булган кебек,
Алар белән җир дә сөйкемле.

1988 ел

Хәйям — атаклы фарсы шагыйре, 1048—1131 елларда яшәгән. Н. Арсланов, аның робагыйларын (дүртьюллыкларын) тәрҗемә итеп, 1986 елда аерым китап итеп чыгарды.

Кеше — табигатьнең бер өлеше. Әмма ул башка җан ияләреннән табигатькә тәэсир итә алу көче белән аерылып тора. Шул ук вакытта үзе яшәгән мохиттәге гүзәллекләргә соклана алуы — аның иң зур өстенлекләреннән берсе.

Миләш — безнең якларда гадәти җимеш агачы. Ул үзенең матур яфраклары белән болай да күзне иркәли. Әмма шул ямь-яшел яфраклар арасында тәлгәш-тәлгәш, чуклы-чуклы кызыл җимешләре дә асылынып торса, аннан карашыңны ала алмыйсың. Балланып пешкәч, бигрәк тә кырау төшкәч, миләш авыздан сулар китерә. Миләшне элек-электән дәва итеп тә кулланганнар. Кич утырганда чикләвек, көнбагыш, алма янына миләш тә куела торган булган.

Нури Арсланов та миләшкә сокланып карый, аның гүзәллеген бик яратып бәяли, укучыга шул уй-хисләрен җиткерә дә, нәтиҗә ясап: «Якын алар миңа бар ямьнән»,— ди. Миләшне кызлар колагын да бизәрлек затлы әйбер белән тиңли.

«Тәлгәш-тәлгәш миләш» шигыре менә шундый уй-хисләр белән сугарылган. Аны укыгач, тирә-ягыбызга яңача, икенче күз белән карый башлыйбыз. Мәгълүм җырдагы «үз илемдә якын миңа бәрәңге бакчасы да» дигән сүзләрнең мәгънәсе яхшырак аңлашыла төшә.

Сораулар һәм биремнәр

1. Шагыйрь күңелендә миләш нинди хисләр уята?

2. Миләшләр «җыр чыгара минем өчен» ди шагыйрь. Сез моны ничек аңлыйсыз?

3. Ни өчен лирик герой «гел бәхет тозагына» төшә? (Тозакка төшү, туры мәгънәсендә алганда, күңелле эш түгел, бу очракта лирик герой моның белән ләззәтләнә. Ник? Шуны аңлатыгыз.)

4. Шулай тормышны, табигатьне яратып яшәү — күпләр өчен уртак сыйфат. Сез дә чәчәкләргә, үсемлекләргә, агачларга, җәнлекләргә, кошларга сокланып, яратып карыйсызмы? Шул тәэсирләрегезне, күзәтүләрегезне шигъри яки чәчмә рәвештә язып карагыз. Аларны бергәләп укыгыз.

ХАЛКЫМА

Борынгыма якыная барам,
Төшсәм ерак еллар артына.
Сәхифәләр саен хәйран калам
Зур тарихлы батыр халкыма.

Ил егылган саен күтәрелгән,
Үрмәләгән өскә — калкуга,
Торып баскан хәрабәдән-көлдән,
Хөрмәтем зур шуңа халкыма.

Болгар иңгән... Казан үсеп чыккан
Казан суы, Идел чатында:
Озак еллар буе дәүләт тоткан
Төп оясы булып халкыма.

Көнчыгышның хикмәтләрен алган,
Көнбатышның җиткән акылына,—
Үз теленә тугрылыклы калган,
Хөрмәтем зур шуңа халкыма.

Үрнәк алыр милләтләр күп җирдә,
Иярсәм дә алар артыннан,—
Иң җылы, иң нечкә хисләр миндә
Үз халкыма, туган халкыма.

Сугышларга үзем теләп киттем,
Быргычылар быргы тартуга;
Бөтен барлыгымны фида[1] иттем
Мин фидакарь җанлы халкыма.

Киң күңелле диләр татарларны,
Лаек булыйм димен затыма,—
Бөтен рухы интернационаллы [2],
Кешелекле, тугры халкыма.

Чыксам юлның ерак-якынына,
Сагышлардан җаным талпына,—
Сагынып кайтам изге туфрагыма,
Казаныма, сөйгән халкыма.

1981 ел

Нури Арсланов, шагыйрь һәм рәссам булу белән бергә, халкыбызның һәм әдәбиятыбызның тарихын яхшы белүче, аны үзенең әсәрләрендә оста чагылдыручы иҗатчы иде.

---

[1] Фида иттем — багышладым, корбан итәргә әзер.
[2] Интернационаллы — башка милләтләрне дә яратучы мәгънәсендә.

Шагыйрь Көнчыгыш халыклары сүз осталарының фикерләү рәвешен дә бик нечкәләп төшенгән. (Көнчыгыш халыклары дигәндә, без гарәпләрне, фарсыларны, төркиләрне, ягъни үзбәкләрне, азәрбайҗаннарны, казакъларны, уйгурларны, кыргызларны, төрекмәннәрне, татарларны, кырым татарларын, каракалпакларны, башкортларны һәм башка халыкларны күздә тотабыз.) Н. Арсланов борынгы Иран шагыйре Гомәр Хәйям (XI йөз) робагыйлары белән милләтебезне таныштырды. Үзе дә робагыйлар язып калдырды. Борынгы шагыйребез Сәйф Сараиның (XIV гасыр) «Сөһәйл вә Гөлдерсен» дастанын хәзерге татар әдәби теленә күчерүе дә игелекле эш булды. Халык шагыйре Сибгат Хәким аның турында болай дигән иде: «Бу шагыйрьнең көче, осталыгы кыска фәлсәфи шигырьләрдә дә бик нык чагыла. Минем фикеремчә, Гомәр Хәйям, Сәгъди, Хафиз, Дәрдемәнд, Тукайлардан килә торган бу традиция безнең бүгенге татар поэзиясендә бик нык үсеп китә алмады шикелле. Күңел кайвакыт кыска, ләкин тирән мәгънәле, заман белән бергә баручы фәлсәфи дуртьюллыкларга сусый. Нури Арслановта мин шуларны күреп сөенәм».

Кыска шигырьләр тудырып, осталыгын арттырган шагыйрь сүзнең кадерен бик сизгер тоя. Озынрак әсәрләрендә исә фикерләрен тагын да киңәйтебрәк, тирән итеп бирә. «Халкыма» шигыре — моның матур үрнәге. Мондый шигырьне татар халкының тарихын, язмышын, үткәнен, бүгенгесен бик яхшы белгәндә һәм үз милләтеңне өзелеп яратканда гына иҗат итәргә мөмкин.

Шигырь лирик герой, ягъни «мин» исеменнән язылган. «Мин» — хәзерге заман кешесе. Әмма туган халкының ерак үткәннәре белән горурланучы шәхес. Халкыбыз бүген дә үз гореф-гадәтләре белән яшәү өчен көрәшен дәвам иттерә. Н. Арсланов шигыреннән дә бу ачык аңлашыла. «Ил егылган саен күтәрелгән» диюе әнә шуларны күздә тотып әйтелгән.

Халкыбыз үзе дә акыллы, зирәк, уңган. Шулай да ул үзенә файдалы булырдай нәрсәләрне Көнчыгыш һәм Көнбатыш халыкларыннан ала килгән. Әмма үз телен, динен, гореф-гадәтләрен саклап калган. Шагыйрь халкыбызга зур хөрмәтен белдерә. Туган җирен, сөйгән халкын дөньядагы иң кадерле, иң газиз нәрсәләр дип исәпли. Ләкин, ди ул, татар халкы бервакытта да башкаларны кыерсыту исәбенә бәхетле булмаган. Аның «бөтен рухы интернационаллы», ягъни башка халыкларга тигез, туган һәм хезмәттәш итеп караучы. Бары шул юл

белән генә татулык, тигезлек, дуслык һәм иминлек тәэмин итәргә мөмкин. Зур тарихлы батыр халкыбызның әнә шундый уңай сыйфатларны буыннан буынга тапшыруы татар милләтенең киләчәктә дә яшәячәгенә, чәчәк атачагына ныклы нигез булып тора.

Әсәр Н. Арсланов иҗатына хас булганча төгәл һәм камил. Шагыйрь чагыштыруны, сынландыруны урынлы кулланган. Ерак юллар артына төшү, ил егылу, халыкның өскә — калкуга үрмәләве, хәрабәдән-көлдән арынып торып басуы, Болгарның иңүе, җан талпынуы кебек чагыштырулар шигырьдә сөйләгәннәрне җанлы итеп күз алдына бастырырга ярдәм итә. Казан шәһәрен «халкымның төп оясы» дип атау да бик отышлы. Ул — тарихыбыз көзгесе, борынгы бабаларыбызның изге рухын саклаучы шәһәр. Яше меӊ елдан арткан башкалабыз белән горурланабыз.

«Халкыма» шигыре милләтебезгә мәхәббәт белән сугарылган. Нури Арсланов шигырьләре милләттәшләребез тарафыннан яратып укыла.

Сораулар һәм биремнәр

1. Халкыбыз нинди тарихи юл үткән? Н. Арсланов шигыре буенча шуны аңлатып бирегез.

2. «Болгар иңгән... Казан үсеп чыккан»,— ди шагыйрь. Болай диюе белән ул халкыбыз тарихының кайсы чорларын искә төшерә?

3. «Дәүләт тоткан халкым» дигән җөмләнең мәгънәсен аңлатып бирегез.

4. Н. Арсланов халкыбызның матур сыйфатларын нинди сүзләр белән атый?

5. Шагыйрь туган халкына мәхәббәтен ничек белдерә?

6. Лирик геройны без нинди шәхес итеп күз алдына китерәбез?

7. Татарстан, Казан лирик герой өчен бик кадерле. Ул моны ничек итеп әйтеп бирә?

8. Көнчыгыш һәм Көнбатыш дигәндә, сез кайсы илләрне, халыкларны күздә тотасыз?

9. Шигырьдән чагыштыру, сынландыруга мисаллар табыгыз.

10. Әсәрдән гарәп, латин сүзләрен аерып алыгыз. Шул ук мәгънәләрне татарның үз сүзләре ярдәмендә әйтергә тырышыгыз.

Гариф Ахунов
(1925—2000)

Гариф Ахуновның татар әдәбиятына күрсәткән хезмәтләре санап бетергесез. Ул — менә дигән тәрҗемәче. Ул — ялкынлы публицист. Ул — драматург. Ул — хикәяче. Ул — очеркист.

Аяз Гыйләҗев

Кайберәүләр әдәбиятка урау юллар аша килә. Г. Ахунов исә сүз сәнгатенә шактый туры сукмаклардан юл салды. 1951 елда беренче хикәясе басылган Гариф тагын алты елдан Язучылар берлеге әгъзасы булды. Арча педагогия училищесында һәм Казан университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укыган елларда ул бигрәк тә әдәбият, тел, тарихка багышланган хезмәтләрне йотлыгып укый. Әмма ул тагын бер әйберне яхшы төшенә: язучы булу өчен табигый талант, теоретик белем генә җитми икән, шуның өстенә тормышның үзен дә яхшы белү таләп ителә.

Арча районы Өчиле авылында (хәзер инде бу авыл юк) туган Гариф авыл кешеләренең мең төрле мәшәкатьләр белән тулы яшәү рәвешен яхшы белә. Ә менә эшчеләр, аеруча республикабызда яңа тармак булган нефть эше кешеләренең нинди уйлар, борчулар, мәшәкатьләр белән көн итүен ул әле якынча гына күз алдына китерә. Менә ни өчен Гариф 1956 елда Татарстанның нефть чыга торган төбәгенә — Әлмәт шәһәренә күчеп китә. Бер генә елга дип барган яшь язучы бу якларда ун елдан артык яши. Нефтьчеләрнең эшен, тормышын, аларның күңел дөньясын өйрәнә. Алар турында «Юллар чатында», «Хыялый

Хәйрүш егетләре», «Канатлар кая илтә?» повестьларын, күп санлы очерклар һәм хикәяләр иҗат итә. Аның нефтьчеләр тормышын сурәтләгән «Хәзинә» романы аеруча зур уңыш казанды. Әсәр буенча 1977 елда нәфис фильм төшерелде. Язучы романның дәвамын да язды, ул «Хуҗалар» дип атала.

«Яшьлек яме», «Чикләвек төше», «Ардуан батыр», «Идел кызы» әсәрләре белән дә Г. Ахунов әдәбият сөючеләрнең ихтирамын казанды. Аңа 1973 елда «Чикләвек төше» повесте һәм «Хәзинә» романы өчен Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге бирелде. Әсәрләре илебездәге унбишләп халык теленә тәрҗемә ителгән.

Г. Ахунов ун ел буе Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе булып эшләде. Ул — Татарстанның халык язучысы, Г. Исхакый исемендәге бүләк лауреаты.

Г. Ахунов 2000 елның 4 июнендә кинәт вафат булды. Кабере — Арча эшчеләр бистәсе зиратында.

Сораулар һәм биремнәр

1. Язучы булу өчен, нинди сыйфатларга ия булу кирәк дип уйлыйсыз?

2. Аяз Гыйләҗев каләмдәшенең нинди сыйфатларын хуплый?

3. Гариф Ахунов язучы булып җитлегү чорында нинди юллар үтә?

4. Язучының тагын нинди әсәрләре бар? Сез аларның кайсыларын укырга өлгердегез? Шулар турында сөйләгез.

5. «Публицист», «драматург», «хикәяче», «очеркист» сүзләренең мәгънәләрен ачыклагыз. Татар әдәбиятында бу жанрларда тагын кемнәр эшли? Аларның әсәрләрен искә төшерергә тырышыгыз.

6. Арча ягыннан чыккан тагын кайсы язучыларны беләсез? Исемнәрен һәм алар язган әсәрләрне атагыз.

7. «Минем яраткан атым», «Минем яраткан Сөтлебикәм», «Минем яраткан песием» һәм башка темаларга дәрестә кечкенә генә хикәя яза башлагыз. Аны өйдә дәвам иттерегез. Укытучы катнашында бергәләп укыгыз, әйбәт дип табылганнарын мәктәптәге кульязма әдәби журналыгызга урнаштырыгыз. Укытучыгыз тәкъдим итсә, «Сабантуй» газетасына, «Салават күпере», «Ялкын» журналларына, радио һәм телевидение тапшырулары редакцияләренә, район газетасына җибәрегез.

АРТЫШЛЫ ТАУ БУЕНДА

(Әсәр кыскартып алынды)

Чын исеме Хәсән булса да, аны Кәлимәт малайлары «Ат чебене» дип йөртәләр иде. Ун яшеннән ул ат янында чуала башлады. Кәнүшнидә яңа бер колын туса, иң элек ул килеп җитә. Урамда берәр кырыкмышны җигеп чыксалар, тәртә яныннан ул чаба.

Унике яшеннән инде ул олы кешеләр ярдәменнән башка ат җигәргә өйрәнде. Атның ялына ябышып йөгәнен, арба өстенә басып, камытын кидертә. Тик камыт чөелдереген[1] тартырга гына көче җитми аның. Эш шуңа килеп терәлгәч, борынын тартып, ат-арба тирәсендә әйләнә башлый.

Агайлар, мыекларын сыпыргалап, аңардан көләләр:

— Бар инде, Нигъмәтулла, чөелдереген тартып бир!

Нигъмәтулла абзый, уч төбенә төкереп, чөелдерекне кулына чорный һәм сул тезен камыт агачына китереп тери. Шомарып беткән агач шыгырдый, камыт бавы кыл кебек тартыла.

— Әти, булды. Җитте дим инде, әти! Муенын сукмасын...

Җәй көне Хәсән болында — атлар янында. Чакырып алмасаң, ул ашарга да кайтмый.

Артышлы тау буенда йомшак мүк үләне үсә. Үлән өстеннән мүкәләп барсаң, күзне камаштырып, җир җиләге килеп чыга. Кып-кызыл!

Артыш арасында йөреп туйгач, Хәсән, этисе кебек, кулларын баш астына куеп, йомшак мүк үләне өстенә сузылып ята. Рәхәт болай ятуы. Колак төбендә генә чикерткәләр сайраша, бал кортлары оча, үлән башларын сыйпап, җил исеп китә.

Хәсән күтәрелеп атларына карый. Әнә Чикылтык бия Чаптарның муенын кашып тора.

Нигә болытлар да ат төсле була икән? Кара, тегесе ничек ялларын тузгыткан. Чикылтык биядән бер дә ким түгел. Тау артындагысы бөдрә. Ферма тәкәсенең йоны кебек. Ә күк зәңгәр.

Бик озак карап ята Хәсән. Күк әкрен генә әйләнә. Атлар пошкырганы ишетелә.

---

[1] Чөелдерек — камыт бавы.

Хәсән, сискәнеп, күзләрен ача. Артышлы тау ягыннан кара болыт чыккан икән. Кулына йөгән тотып килгән әтисен күреп ала.

— Атларны апка-а-айт! Ат-лар-ны-ы! Яңгыр ки-лә-ә!

Хәсән үлән арасыннан камчысын эзләп тапты. «Давыл»ның аягыннан тышавын ычкындырды, муеныннан йөгән тезгенен сүтеп алды. Кечкенә хуҗасының ялгызы гына атлана алмавына гадәтләнгән акыллы ат башын сузды да ялына килеп ябышкан кечкенә көтүчене югары чөйде. Хәсән күз ачып йомганчы ат сыртына килеп төште.

Кинәт күк йөзендә яшен телгәләнде. Атлар бер күчкә өелделәр. Тик Чикылтык бия генә бер читтә кешнәп йөри, әнә авылдан икенче якка таба чаба да башлады инде. Ах, имансыз! Якын килсәң тешләшә дә башлар әле. Килеп карасын, менә камчы!

Хәсән «Давыл»ның ялына ныграк ябышты. Ә Чикылтык, аны күрү белән, колакларын шомартып, аңа таба омтылды.

Хәсән камчысын селтәргә дә өлгерә алмый калды. Чикылтык, кисәк кенә борылып, артын куйды һәм

шартлатып «Давыл»га тибеп тә җибәрде. «Давыл» аягүрә басты, шашынып алга сикерде.

Хәсән, таш кебек очып, җиргә килеп төште һәм шул секундта ук кемнеңдер тимерче чүкече белән башына бик каты бәргәнен тойды. Колак артыннан ниндидер җылы нәрсә агып муенга, күлмәк эченә тула башлады. Каяндыр, су эченнән, әтисенең тавышы ишетелде, аннары дөнья караңгыланды, йөзтүбән капланып, төпсез упкынга очты.

Келәт чаклы машина

Хәсәнне район больницасыннан бер ай узгач кына алып кайттылар. Малайның йөзендә кан әсәре калмаган, сул як каш турысыннан колак артына кадәр бармак яссылыгы кызыл җөй сузылган иде.

Авыл урамына килеп кергәч, Нигъмәтулла абзый арба яныннан йөгерүче малайларны куарга тотынды:

— Көшегез, көшш! Тәгәрмәч астына керәсез бит!

Габделхәй — сары пошлак — арба өстенә менеп тә өлгергән инде.

— Терелдеңме, малай? Ай-яй каты утырткан икән... Авыртамы? Ә без Чикылтык бияне саттык. Персидәтел сатып җибәрде. Беләсеңме нәрсә алдык? Барабансон! Айгыр ул, тояклары — баш чаклы.

Капкадан әнисе йөгереп чыкты.

— И балакаем, терелдеңме, күз нурым?..

...Хәсәнне атна буе беркая да чыгармадылар. Әнисе аңа иртә-кичен сөт савып эчерде, чәйне бөтнек һәм мәтрүшкә салып кайнатты.

Беренче көннәрне җылы, мәтрүшкәле чәй исләре чыккан өйдә яту күңелле булса да, тора-бара туйдырды. Хәсәннең урамга чыгасы килә башлады. Әнисе нигә урамга чыгармый икән инде? Юкка курка ул: башы да әйләнми, ярасы да сызламый инде...

Хәсән шуларны уйлап торганда, тыны беткән Габделхәй килеп керде.

— Кичәгенәк кермәдең дә, алдакчы!

— Әйдә, Барабансонны карарга барабызмы?

— Әни күрмәс микән?

— Күрми. Әлмәш күленә таба китте. Бозау апкайтырга.

— Ә әти?

— Чаптарны җигеп, вика чабарга китте.

Алар шыпырт кына бакча ягына сикерделәр...

Хәсәннең күзе ут булды. Ак бәкәлле кара айгыр утар эчендә йөри. Хәсән, дөньясын онытып, утар киртәсенә менеп китте.

— Мин хәзер аның янына керәм.

— Кит, юләр, тибеп җибәрсә...

Хәсән, курыкмавын күрсәтер өчен, ипләп теге ат янына керә башлаган иде, абзардан Нигъмәтулла абзый килеп чыкты.

— Каяле, кем ул анда Камыр батыр? Хәсән! Син нишләп йөрисең монда? Кем кушты сиңа өйдән чыгарга?

Малайлар кире йөгерделәр.

Хәсән, дустына үпкәләп:

— Синең белән йөрсәң шул,— диде.— Әти вика чабарга китте дип алдалаган буласың...

— Кояштыр газим, киткәние. Ике күзем чәчрәп чыксын.

— Син гел ант итәсең, үзең гел алдалыйсың.

Габделхәйнең ачуы чыкты. Хәсәнгә «Ат чебене» дип әйтеп салырга да уйлаган иде, колак янындагы ярасына күзе төште дә әйтми калды. Хәсәннең дәшми баруына эче пошып, ул сүзен икенчегә борды:

— Хәсән, малай, Чикылтык типкәч, башың авырттымы?

— Безрик тә авыртмады, ичмасам. Мин әле еламадым да. Табиб та мактады әле мине. Аркамнан сөйде.

Хәсән инде өйләренә кереп китәргә дә уйлаган иде, клуб тыкрыгыннан тракторныңмы — нәрсәнеңдер бик каты үкереп килгәне ишетелде. Ул да түгел, коточкыч зур машина, җир селкетеп, урамга килеп керде.

Габделхәй белән Хәсән дә машина артыннан чаптылар.

— Карале, малай, келәт чаклы бар! — диде Габделхәй, йөгерүдән тыны бетеп.

— Әйттең! Кәнүшни абзары чаклы диген!

— Ай-яй! Тузанны туздырып та карады.

Машина күл буена төшеп туктады. «Келәт» эченнән өч кеше сикерде. Малайлар эһ итәргә өлгерә алмый калдылар: җир өстендә зур яшел палатка барлыкка килде, күл буенда учаклар кабынды.

Беренче факел

Кәлимәт кешеләре җәйге авыл кичен бакалар сайравыннан башка күз алдына китермиләр иде. Көн буе арып кайтканнан соң, алар, кичке ашны ашап, капка төпләренә чыгалар, тормыш хәлләре турында, басудагы игеннәр турында сөйләшәләр. Бака тавышларына колак салып:

— Көннәр җылы булыр, бакалар туй ясый башлады,— диләр.

Күп еллар буена яшәп килгән бу тәртип быел бозылды. Менә өченче җәй инде су буйларын икенче бер музыка үз канаты астына алды:

— Дөп-дөп-дөп! — дип, йөрәк кага ул, пошкырына; вакыт-вакыт тимерләрен чыңлатып куя. Артышлы тау буена берөзлексез машиналар килә, кешеләр агыла. Кәлимәтнең һәрбер өендә хәзер яңа өйдәшләр: тракторчылар, шоферлар, бораулаучылар яши.

Ноябрь башларында Зәй елгасы тоташ боз белән каплангач, яңа хәбәр тарала:

— Факел кабызалар!

— Бер дә сүнми торган ут!

Халык Әлмеш күле буена агыла.

Хәсән, тыны бетеп, күл буена килеп җиткәндә, Габделхәй күптән анда иде инде. Хәсәнне күрү белән:

— Хәзер кабызалар! Якын барырга ярамый, шартлый! — диде.

Халык гөжли башлады. Кулына озын колга тотып, бер егет килеп чыкты. Колга башына чүбек чорнады, чүбеккә ниндидер май сибеп ут кабызды һәм, утлы колгасын баш очына күтәреп, торбага таба китте. Менә егет килеп җитте. Туктады. Утлы колгасы белән торба башына үрелде. Кинәт гөлт итеп һавага чаклы ут чәелде. Торба очында гаять зур ялкын теле айкалырга тотынды...

Шул көннән башлап Кәлимәт өстеннән төн качты.

Хыял

Тормыш — бик кызык нәрсә: кешенең планнарына әллә нинди үзгәрешләр кертә. Әгәр Кәлимәттә нефть тапмаган булсалар, Хәсән кайчан да булса бер нефтьче булу турында уйлап карар идеме икән? Хәсәндә инде

байтактан бирле ат кайгысы китеп тора, аны хәзер нефтьчеләр әмеренә буйсына торган корыч айгырлар кызыксындыра.

Хәсән тырышыбрак укырга тотынды. Нефтьче булу өчен, нәрсәне күбрәк белергә кирәк? Әһә! Иң беренче — математика. Торбаның диаметры күпме? Вышка ничә метр озынлыкта? Хәсән, инде боларны җиде төн уртасында уятып сорасалар да, күзен дә йоммый әйтеп бирә: вышка кырык ике метрлы. Пайморза абыйсы биргән китапта ачык язылган.

Ләкин җиденче класста уку аның өчен ифрат авыр булды. Юк, уку авыр түгел, кышның узып киткәнен көтеп алу авыр. Менә кыш көне йокыга китеп торсаң иде ул. Яз җиткәч кенә уянып китәсең дә укырга тотынасың. И укыйсың, и укыйсың! Уку белән, вакыт узганын сизми дә каласың. Аннары беркөнне кулыңа җиденче классны бетергәнгә таныклык алып, бораулау конторына, директорның үзе янына барып керәсең. Ул чагында: син белемсез, нефтьче булыр өчен, белем күп кирәк, дип әйтеп карасыннар.

Болытлар янында

Артышлы тау артында күк чите алсуланып килә, кояш чыкмаган әле. Кармакларга җим киертеп, су өстенә ташладылар. Габделхәй шундук калкавычка төбәлде һәм, тын да алмыйча, Зәй өстенә карап утыра башлады. Ничек армый икән ул? Ичмасам, бер генә тапкыр, һич югы, күңел өчен генә чиртсен иде. Юк бит, сукыр балык та килми. Әллә нефтьчеләр килгәннән бирле бөтен балык куркып су төбенә качып беткән инде...

Тамырлары белән су эченә кереп үскән иләмсез зур өянке төбенә, аның баштүбән әйләнеп су өстенә төшкән шәүләсенә карап, Хәсән озак уйланып утырды. Әле күптән түгел генә нефтьче булу, буровойга кереп эшләү турындагы ашкынулы хыяллары аның күңелен үзәк өзгеч бер сагыш белән тутырдылар. Юк инде алар, нефтьче булулар! Җиденче классны бетергәч, аны буровойга алмадылар, син яшь әле, укы әле, диделәр. Ә буровойда Хәсән юк дип тормыйлар, бораулыйлар да бораулыйлар. Бораулаучыларның башлыгы усал микән, буровой эченә керсәң, йөрмәле, малай актыгы, дип куып чыгармас микән?..

Хәсән, буровой ягына әйләнеп тә карамыйча, болын буйлап китте.

— Әй парин, туктале...

— Нәрсә бар?

— Кил әле, кил!

Хәсән теләр-теләмәс кенә кире борылды.

— Без бит әле синең белән танышмадык та,— диде нефтьче егет, зур кулы белән Хәсәннең кулын эләктереп алды.

Хәсән күрешкән арада кап-кара булып буялган уч төбен, үзе дә сизмәстән, чалбарына ышкырга тотынды.

— Кулың каты икән синең парин... Ә исемең ничек?

— Җиһангиров Хәсән...

— О, без адашлар икән ич: минем дә Хәсән. Әни Сәетхәсән ди. Сиңа ничә яшь инде?

— Миңамы? — Хәсән чак кына икеләнде. Ләкин шундук күңеленә килгән хәйләкәр уйдан сөенеп, яшен ике яшькә арттырды.— Быел майда уналты тулды.

— Укыйсың дамы?

— Юк, укуны бетердем инде.

— Ничәнчене?

— Җиденчене ... быел.

Егетнең сул кашы очынып югары күтәрелде:

— Күчми калдыңмыни?

— Юк, күчми калмадым...

— Ничек була инде ул: үзең уналтыда, үзең быел җиденчене бетердем дисең?

Хәсән ул хәтлесен уйлап җиткермәгән иде, ялганы тотылганга уңайсызланып, авыз эченнән ботка пешереп алды. Ә нефтьче егет, адашын уңайсыз хәлгә куюын аңлап, сүзне икенчегә борырга ашыкты:

— Ә нефтьче буласың киләме синең?

Хәсәннең ике күзе дүрт булды. Уйлап-нитеп тормастан ярып салды:

— Килә, абый! Кояштыр газим! Ышанмыйсызмы?

— Ышанам, ышанам! — диде нефтьче егет, елмаеп, һәм Хәсәнне, җиңеннән тотып, буровой эченә алып керде: — Әйдәле, мастер янына керик әле.

Буровой эчендә аларны өч кеше каршылады.

— Дөньяңны онытып йөрмә әле син, Абдуллин! — дигән усал тавыш Хәсәнне сискәндереп, уйларыннан айнытып җибәрде. Тавышның иясе, күн тужуркалы, мыеклы бер карт үзе дә каршыга килеп чыкты.

— Чыгырның чылбыры өзелде. Ялгарга кирәк. Ә сине эт белән дә эзләп табарлык түгел! — диде ул, гүя баштагы усал сүзләренең сәбәбен аңлатып бирергә теләгәндәй. Ләкин куркыныч ул хәтле зур түгел иде, ахрысы, егет мыеклының сүзләреннән коелып төшмәде, киресенчә, иркенәеп бер елмайды да кулы белән Хәсән ягына күрсәтеп сөйләргә тотынды.

— Таныш булыгыз, буровойга яңа кадр алып килдем. Минем адаш — Хәсән. Дөрес, хәзергә әле ул яланаяк. Ну анысы әллә ни зур бәла түгел. Беренче эшләп тапкан акчадан күн итекнең менә дигәнен алып кияргә була.

Өч-дүрт кешенең үзенә төбәп карауларын күтәрә алмыйча, Хәсән башын түбән иде, кызарды. Ә бераздан бу кешеләрнең үзенә ничектер бала-чага итеп карауларын аңлап, кинәт үчлекле бер уй белән, үзен таныту уе белән кабынды. Ул яхшы ат кебек башын югары чөйде, тураеп басты, биленә таянып торган кара мыеклыга һәм машиналар артыннан чыккан «мунча пәриләре»нә күзләрен тутырып бер карап алды. Шул ук минутта аның уңайсызлану хисе әллә кая китте. Чыннан да, нигә куркырга аңа? Ул барысын белә. Күрсәтеп бирергәме? Рәхим итегез: менә бу станок — элеватор, әнә теге аягүрә басып торган торбалар шәм дип атала. Вышка түбәсендә — тали блогы, баш өстендә чайкалып торганы — кран-блок!

Менә күрегез: йөгереп буровойдан чыкты, маймыл җитезлеге белән вышка баскычына асылынды. Икешәр басмачаны берьюлы сикереп, югарыга — баш әйләнгеч биеклеккә атылды. Тыны беткәнче, сулуы капканчы йөгерде. Верховой бишегенә менеп җитәрәк, иелеп аска карады, куркуыннан чак кына кычкырып җибәрмәде: аста упкын, аста тимерләр өеме иде.

Кыл кыймылдатырга куркып, беравык өнсез басып торды, йөрәге шашып тибәргә тотынды.

Кинәт баскыч шыгырдап китте, шушы коточкыч шыгырдау аны киеренкелектән чыгарды.

— Аска карама! — дип кычкырды аның артыннан менеп килгән егет.

Үзе белән янәшә адашының барлыгын тою, аның хәлсезләнгән аякларына хәл кертеп җибәрде, һәм ул баскыч буйлап сак кына югарыга таба атлады.

Бераздан ул вышканың очына ук менеп җитте. Ул хәзер болытлар янында ук басып тора, күлмәген җил

кабарта, җил муеннарын кытыклый иде. Кәлимәтне, Зәй елгасын, болыннарны, Артышлы тау буйларын аның әле беркайчан да мондый биеклектән күргәне юк иде. Астагылар аны шаулап каршы алдылар.

— Егет икәнсең!

— Укырга кер син!

— Техникумга!

Бер сүз дә әйтерлек хәле калмаган, күңеле ашкыну белән тулган Хәсән буровойдан чыгып чапты.

Сораулар һәм биремнәр

1. Хәсәнне сез ниндирәк холыклы малай дип күз алдына китерәсез?

2. Атлар да, кешеләр кебек, һәрберсе үз холкына ия. «Давыл» һәм «Чикылтык» исемле атларның холыкларын капма-каршы куеп чагыштырыгыз.

3. Хәсән белән Габделхәйне холык ягыннан аерып торучы сыйфатларны табыгыз.

4. Нефтьчеләр Кәлимәт авылына зур үзгәрешләр алып киләләр. Бу үзгәрешләрнең уңай һәм тискәре булганнарын аерып күрсәтегез.

5. «Кәлимәт өстеннән төн качты» дигән җөмләдәге мәгънәне аңлатып бирегез, аның тар һәм киңрәк мәгънәләрен ачыклагыз.

6. Хәсәннең иң матур сыйфатларыннан берсе — хыялга бай булу. Әсәрдән аның хыялланган урыннарын искә төшерегез.

7. Повестьның без укырга өлгергән өлешендә Габделхәй дә, Хәсән дә алдашалар. Ни өчен алар мондый алдашуга баралар?

8. Сәетхәсәнне сез нинди кеше буларак кабул иттегез?

9. Сәетхәсән адашы Хәсәнгә ярдәм кулын ничек суза?

Шаблон

Яңа вахта эшкә җыелганда, буровой эшчесе Шәйхинең авырып эшкә чыкмый калуы билгеле булды. Бу хәл бораулаучы Сәетхәсән Абдуллинны борчуга салды. Инде нишләргә? Контордан да артык кеше юк дип җавап бирделәр.

Шул турыда кайгырып утырганда, кыяр-кыймас кына атлап килүче Хәсән күренде. Бүген ул яланаяк түгел.

Адашы Сәетхәсән аны кичәгедән дә яктырып каршы алды.

— Килеп җиттеңме, адаш? Бик яхшы! Алдан ук сөйләшеп куйыйк, тәртип бозмаска! Эшкә соңга калмаска!

Мастер бик усал безнең: тәртипсез егетләрне бер дә яратмый. Килештекме?

Хәсән, чатнап чыккан тавыш белән:

— Килештек! — диде.

Адашы аның янына бик җитди чырай белән ике тимер китереп куйды. Тимерләр икесе дә бертөсле, урта бер җирендә йодрык сыярлык тишек бар иде.

— Күтәреп карале шуларны!

Хәсән күтәреп карады. Тимерләр шактый авыр, уникешәр килограмм бар иде.

— Оһо! Так-так-так! Болай булгач була. Инде бер нәрсәне хәтерләп кал: без боларны шаблон дибез.

Сәетхәсән, токны тоташтырып, бер рычагны күтәрде. Буровой әкрен генә гөрелди башлады. Егетләрнең берсе шаблонны торба авызына салды. Торбаның тураеп басуы булды, шаблон торба эченнән гүләп узды да чаңгылт итеп җиргә килеп төште.

— Яхшы карадыңмы? — диде Сәетхәсән.— Бүген менә синең эшең шул булыр: торба эченә шаблон салып торырсың. Только, кара аны, шаблоннар обязательно торба эченнән төшкән булырга тиеш. Без аның белән торбаларның брак түгелме, яньчелмәгәнме икәнен тикшерәбез. Брак торбаны забойга төшердекме — бетте баш! Бөтен эшләгән эш вәссәлам, юкка чыга.

Шул гынамы? Аңа бары шундый гына эш кушалармы? Буровойга эшкә кереп, торба эченнән тимер үткәзеп торыргамы? Ләкин ул боларны күңеленнән генә әйтте. Кая ул әйтү! Әле монысына да рәхмәт — ышанып алуларына да. Тизрәк эшне башлап җибәрүләрен көтте. Торба авызына үз кулы белән беренче шаблонны китереп салгач, ул инде үзе белән шаярмыйлар икәнен аңлады, шаблонның җырлаган сыман шуылдап, гүләп төшеп китүеннән күңеле булып, икенче шаблонга килеп тотынды. Шаблон артыннан шаблонны күтәрде, торба авызына китереп салды, торба башыннан күтәреп алды. Ахырга чаклы берәр ял итәләр микән? Ял итмәсәләр, аның көче җитәрме? Аның инде хәзер үк күз аллары караңгылана башлады. Ичмасам, маңгайдан аккан тир күзне ачыттырмасын иде.

Бермәлне йөрәге жу итеп, аркасыннан кайнар сулар коелып китте. Шаблонның берсе юк иде.

Әйтергәме?

«Әйт, хәзер үк әйт!» — диде күңелендәге эчке бер таләпчән тавыш.

«Әйтмә, әйтмә, әйтмә»,—дип гөрелдәде буровой.

Ул арада яңа торба килеп җитте. Хәсән, нишләгәнен онытып, торба авызына шаблонны салып җибәрде.

Вакыт күбрәк узган саен, торбалар забойга күбрәк төшкән саен, аңарда хатасын яшереп калу фикере арта, куркуы көчәя барды. Башы шаулады, колаклары чыңлады, чишмә булып маңгаеннан тир акты; ул вакытның күпме узуын да, үзенең кайда эшләвен дә чамалый алмас хәлгә килде.

Шаблонның берсе юк икәнен буровойдагы егетләр һәм Сәетхәсән белеп алганда, торбаларны забойга төшереп бетерә язганнар иде инде.

Буровой эчендә кинәт шомлы тынлык урнашты.

Вахта машинасы белән килеп җиткән мастер Афанасий Иванович буровойда нидер булганны бер күз сирпүдә аңлап алды, шомлы тавыш белән сорады:

— Аварияме?

Сәетхәсән, бер агарып, бер кызарып, шаблон турында сөйләп бирде.

Афанасий Иванович, бармакларын тырпайтып, учын җәйде дә шап итеп тезенә китереп сукты:

— Ну и дурак! Бала-чагага кем инде шундый эш тапшыра?!

* * *

Торба эченә кысылып калган шаблонны һәм таш булып каткан цементны бораулау атна буена сузылды. Атна буена Хәсән, йөрәгенә кан савар дәрәҗәгә җитеп, җан тиргә баткан нефтьчеләр янында болганды. Сәетхәсән аны күрмәмешкә салынды, Афанасий Иванович, җае чыккан саен әкрен генә, үткәзеп-үткәзеп кенә, нефть эшендә гамьсезлекнең, бала-чагалыкның никадәр зур фаҗигагә алып баруын аңлатты.

Ниһаять, бер атна тулды дигәндә, нефтьче егетләрнең, шул исәптән Сәетхәсәннең дә йөзе ачылып китте. Нефтьчеләр культбудка алдында җыелып, озаклап тәмәке тарттылар.

Афанасий Иванович Хәсәнне үзләре янына чакырып китерде, утырган җиреннән торып, Хәсәннең каршысына басты, кулын аның җилкәсенә китереп салды һәм туп-туры күзләренә карады.

— Йә, туганкай, синең белән саубуллашырга туры килә инде хәзергә. Техникум! Аңлыйсыңмы? Синең урының хәзер техникумда! Тик бер шарт белән: укып бетергәч, үзебезгә! Чөнки син беренче чыныгу мәктәбен бездә уздың.

Хәсәннең күңеле тулды, мыеклы, трубкалы бу абзыйның күкрәгенә башын куеп елап җибәрәсе килә иде.

1958 ел

Сораулар һәм биремнәр

1. Повестьтагы вакыйгаларның иң киеренке урыны «Шаблон» дигән бүлек. Ни өчен?

2. Хәсән үзенә тапшырылган эшне җитдигә санамый. Ул хаклымы?

3. Бер шаблонның торба эчендә кысылып калуын Хәсән ни өчен өлкәннәргә әйтми?

4. Малай күңелендә бу вакытта уйлар көрәше бара. Ләкин ул дөрес карарга килә алмый. Сәбәп нәрсәдә? Гаеп Хәсәндә генәме?

5. Мастер Хәсәнне түгел, Сәетхәсәнне шелтәли. Ни өчен?

6. Хәсәндә, җанлы кешегә хас булганча, уңай яклар да бар, холкындагы төзәтеп җибәрәсе кимчелекләр дә юк түгел. Аның башта уңай, аннан соң кимчелекле якларын күрсәтегез. Ул сыйфатлар сезнең үзегездә бармы?

7. Ир-егет булган Хәсәнне сез ничек итеп күз алдына китерәсез?

8. Әсәрдә табигать матурлыгының югала баруына, нигездә, олы кешеләр борчыла, яшьләрнең моңа битараф булуы дөресме?

«АРТЫШЛЫ ТАУ БУЕНДА» ПОВЕСТЕ ТУРЫНДА

Әсәр 1958 елда язылган. Язучы нефть төбәгендә гаять зур үзгәрешләр баруын күреп алган һәм шуларны, балалар күңеле аша уздырып, бәяләргә теләгән.

Повестьның төп герое — Хәсән. Ул да, сезнең кебек, унөчундүрт яшендә. Җиденче сыйныфта укый. Хәсән — авыл малае. Әтисе ат караучы булып эшли. Шуңадыр Хәсән атлар ярата. Атлар да аны үз итәләр. Ләкин «Чикылтык» дигән бия генә беркөнне малайны харап итеп ташлый. Әмма Хәсәннең атны яратуы шулкадәр көчле, хастаханәдән терелеп кайткач, беренче мөмкинлек булу белән, ул атлар янына чаба. Шул рәвешле, яшел чирәмле авыл урамында тәгәрәп, Әлмәш күле бакаларының тавышын тыңлап үскән малай табигатьнең бер

могҗизасы булган атка күңеле белән тартыла, бу бик ачык аңлашыла. Чөнки ат — авыл кешесе өчен хезмәттәш тә, дус та, юлдаш та. Хәсән дә бу хайваннарны яратмыйча булдыра алмый. Авылда аны юкка гына «Ат чебене» дип атамыйлар. «Башына ат тибеп тә кәнүшни юлыннан туктамады бит»,—дип гаҗәпләнәләр.

Кешенең омтылышлары, кем булырга хыяллануы әйләнә-тирәлеккә дә нык бәйле. Хәсән кечкенә чагында, уенчык паровоз белән уйнаганда, поезд йөртүче булам, ди. Аннан бригадир булырга тели, колхоз рәисе булу да кызыктыра. Алар авылына нефтьчеләр килгәч, күзе шушы һөнәр иярәренә төшә. Авыл малае өчен эшче һөнәренә күчү кайбер кыенлыклар белән бәйләнгән. Бигрәк тә аңа күңел каршылыклары комачаулый. Ник дигәндә, ат белән эш иткәндә барысы да гади, аңлаешлы, күңелгә якын кебек. Ә менә техника, тимер-томыр куркыта, шикләндерә. Авыл баласы терлек-туармы, кош-кортмы — җанлы әйбер белән эш итәргә күнеккән. Иген-таруга, җиләк-җимешләргә дә ул җанлы затларга караган кебек карый. Ә нефтьчеләрнең биек манаралары, озын-озын торбалары матурлык дөньясына бигүк ятышмый кебек.

Шулай да тора-бара Хәсән күңелендәге шушы киртәләрне атлап чыга һәм нефтьчеләр белән аралашып китә. Бу эштә аңа үзләрендә фатирда торучы чуваш Пайморза ярдәм итә. Нефтьчеләр аны әлеге һөнәргә өйрәтүче техникумга укырга җибәрәләр.

Повестьның үзәгенә куелган төп мәсьәлә — авыл малае яшүсмер Хәсәндә нефтьче һөнәренә мәхәббәт уянуы, шул юлга кереп китүдә үз-үзе һәм тирәлек белән каршылыкны җиңә баруы. Тормыш аны бик кыен хәлләргә куя. Ләкин Хәсән җебеп төшми, ничек итсә итә, әмма үзенең максатына туры бара. Олылар да аның омтылышларын аңлыйлар һәм малайга хөрмәт белән карыйлар. Күргәнебезчә, аның хыялы чынга ашар кебек.

Г. Ахунов әсәрендә тагын бер әһәмиятле мәсьәлә күтәрә. Аны, кыска гына итеп, нефтьчеләр һәм авыл табигатенә мөнәсәбәт дип атап булыр иде.

Артышлы тау буенда бер авыл бар. Табигате матур, суында балыгы, тирә-юнендә җиләк-җимеше мул. Кешеләр дә тыныч кына, булганына куанып көн итәләр. Көннәрдән бер көнне, беркемнән сорап тормастан, иләмсез зур машиналарга төялеп, нефтьчеләр килеп төшә. Матур гына яшәгән авылның тыныч-

лыгы югала. Су пычрана, балыклар бетә, урамда чирәм актарыла, ашлык таптала. Авыл халкыннан беркем дә рөхсәт тә сорамый, китергән зыян өчен гафу да үтенми. Г. Ахуновны бу хәл борчый, ул урыны-урыны белән табигатькә саксыз карауның зарары турында кисәтеп-кисәтеп бара.

Г. Ахуновның «Артышлы тау буенда» повесте — бездә нефть чыгару эшенең башлангыч чорын сурәтләүгә багышланган әсәрләрнең берсе. Балаларның шушы яңалыкларга мөнәсәбәтен бирүдә, аларның үзләренә генә хас күңел дөньясына үтеп керүдә язучы оста эш иткән.

Сораулар һәм биремнәр

1. Хәсән — сезнең яшьтәшегез. Аның уйлары, кичерешләре сезне дулкынландырдымы? Сез автор булсагыз, әсәрнең ахырын ничек итеп тәмамлар идегез?

2. Хәсән — моннан илле-алтмыш еллар элекке чор үсмере. Бүгенге унөч-ундүрт яшьлек малай андый җавапсызлык күрсәтер идеме? Тормышыгыздагы шундыйрак хәл-әхвәлләр турында искә төшерегез.

3. Хәсәннең нефтьче булырга омтылышы әсәрдә тиешенчә аңлатылганмы? Ул ни өчен бу һөнәр кешесе булырга тели? Әлеге повестьта моңа җавап бармы?

4. Һәр республика үз җиренә, байлыкларына үзе хуҗа булырга тиеш булган кебек, авылның басулары, күлләре һәм башка байлыклары да шунда яшәүчеләрнеке булырга тиеш. Кәлимәт авылында без моның шулай икәнен күрмибез. Сез моның белән ризамы?

5. «Хәсән — минем яшьтәшем», «Кешенең холкы — аның язмышы», «Нефть безнең Татарстаныбызга нәрсә бирде?» дигән темаларның берсенә инша язып карагыз.

Хәсән Сарьян

(1930—1978)

Бу җитди, таләпчән әдиптән күпне көтәргә була иде әле. Бик вакытсыз өзелде аның ачылып кына килгән иҗаты.

Әмирхан Еники

Хәсән Сарьян (Сарьян Салихҗан улы Хәсәнов) Башкортстанның Илеш районы Иске Аю авылында туа. Бөре татар педагогия училищесын, Уфа педагогия институтын тәмамлый. Шундагы төрле газета-журналларда әдәби хезмәткәр булып эшли. Башкорт дәүләт университетында татар теле буенча лекцияләр укый. Аннан соң егерме елга якын Казанда яши. Нәкъ менә Казанда аның язучылык таланты ачылып китә.

Х. Сарьян хәзерге әдәбиятта хикәя язу остасы буларак танылды. Кыска гына әсәрдә олы сүз әйтү, күңелдә тирән уелып калырлык образлар тудыру җиңел эш түгел. Әмма язучы татар хикәясен камилләштерүгә, баетуга үзеннән зур өлеш кертте.

Ул бигрәк тә яшьләр өчен язды. Кайсы гына китабын алып карасаң да, аларда төп геройлар — ярсу йөрәкле яшьләр. Аларның күңел дөньясын, борчу-сагышларын, эш-мәшәкатьләрен, матурлыкка омтылуларын ул зур мәхәббәт белән сурәтләде.

Һәр язучының төп китабы була. Х. Сарьян үзенең андый әсәре, гомер булса, киләчәктә язылыр дияргә ярата иде. Әмма аның гомере, кызганыч, шактый кыска булып чыкты. Х. Сарьян каләменнән төшкән «Әткәм һөнәре», «Егет язмышы», «Бер ананың биш улы» повестьлары әдәбиятыбызда үз урыннарын таптылар.

Х. Сарьян язу өчен вакыйгаларны әллә каян эзләмәде. Туган төбәген җанына газиз Башкортстан җиренең гүзәллеген, шул якларның кешеләрен үзенә бер осталык белән сурәтли торды. Озак еллар Казанда яшәсә дә, күңеле белән Агыйдел егете булып калды. Х. Сарьян сылу Агыйдел турындагы бихисап халык җырларына үз моңын кушарга яратылган кеше иде. Аның әсәрләрен шигъри проза дип атарга мөмкин.

Х. Сарьян тел остасы иде. Ул гап-гади әйберләрне дә образлы итеп әйтә белде. Талантлы каләм остасы туган телебез, әдәби тормыш хакында язылган мәкаләләре белән дә рухи мәдәниятебезне үстерүгә өлеш кертте. «Уеңны уйдырып сал» дип исемләнгән җыентыктагы хезмәтләре шул турыда сөйли.

...Кешеләргә үзеңнән соң шундый игелекле эшләр калдыру — үзе бер бәхет бит ул!

БЕР АНАНЫҢ БИШ УЛЫ

(Өзекләр)

...Без әтидән биш малай калдык: зурыбызга унҗиде, кечебезгә җиде яшь иде. Бишебез бергә ашарга утырсак, биш минут эчендә олы бер түгәрәк ипидән валчыгы да калмас иде. Шулай да без сугышка чаклы ипидән өзелмәдек — әни эшли, ике абый эшли. Абыйлар, әти тирәсендә чуалып үскәнлектән, шул юлданрак киттеләр. Әтидән соң үзебезнең күрше авылдан килеп ялланган Степан абый белән өчәүләп март башыннан ремонтка керештеләр. Аннары сабаны башланып китә. Болыны уракка килеп ялгана. Лобогрейкага янә безнең ике абый утырыр иде. Аннары инде — кара көздән акмантукманга хәтле — ашлык сугалар...

Очы да, кырые да юк иде ул чактагы колхоз эшенең.

Әни безгә кием генә җиткерә алмады. Абыйлар эшләп туздыра, без уйнап туздырабыз.

Әни башта ике зур абыйны карый, безгә шул кыскарткан да әйләндергән генә кала. Ләкин безнең ай-һайда да юк, язын тау битләре ачылу белән, өстән салып атабыз да көзен җир туңмыйча кимибез. Мунчадан да без чабынгач карда аунап, яланаяк, яланөс, табаннардан ут чәчрәтеп, җилеп[1] кенә кайта идек. Безнең бөтен нәсел җиде бабадан бирле мәйдан тоткан көрәшчеләр булган.

[1] Җилеп — йөгереп.

Әти мәрхүм безгә кул тидерү түгел, каты сүз дә әйтмәде. Кышкы озын кичләрдә, уйный торгач кызып китеп, сәндерәләрдән сикерә башласак та, көндез тимер чаңына мие кайнаган әтиебезнең шелтәсе:

— Ай-вай-вай-вай! Җәмәлән җавы[1] да бу төслүк булмагандыр, һай! Өйне күтәреп алып китәсез инде тамансы[2]! — дип әйтүдән узмас иде. Хәтта ул, без котырганда, ишек катындагы кече сәкедә аркасын ястыкка терәгән килеш, рәхәтләнеп ял итә сыман иде.

Без түгел, абыйлар да әле уйнап уеннан туймаган бервакытта әтиебезнең үлеп китүе күкрәкләрдә мәңге бетмәс әрнү калдырды. Арабызда иң моңлы бала диелгән Хәвадис абый, зиратка барсак, кабер читләрен тырнап елый торган иде. Кабер өстеннән алып изү эченә койган вак ташлар салкыны да бу хәсрәткә дәва түгел иде.

Ләкин вакыт үткән саен, әкрен генә кайгы да басылып, күз яшьләре кибә барды. Сугыш чыкканда инде эти үлеменә дүрт ел гомер узып, күңелләр дә ятимлеккә күнгән иде. Хәзер бу кайгы ил белән бүтәннәргә килде.

Зур абый Раббани беренче мобилизациягә үк эләкте. Кырык икенче елның көзендә Мирза абыйны да сугышка алдылар.

Сугыш бер безнең өйгә генә, кем теләкләре кабул булгандыр, үлем кайгысы китермәде. Тик Хәвадис абыйга гына чирен салып китте.

Хәвадис абый бездән бик нык аерылып тора иде. Без дүртебез этигә охшаган: җәенке каш, киңчә борын, коңгырт йөз; хәтта тавышыбыз да бердәй — ачылып ук җитмәгән күк иде. Без гәүдәгә дә бердәй таза, калын җилкәләрдә кайвакыт каннарны язып җибәрәсе килгән ят бер көч бар иде. Хәвадис абый гына берүзе әни ягына тартым: зәңгәр күзле, озынча матур йөзле, аксыл җитү чәч; ул буйга да Ниязкул камышыдай төз, шуның аркасында, бездән озын булмаса да, безнең янда ничектер калкып торган төсле иде. Әни яклары җырчы да, гармунчы да булып, Хәвадис абый да шулар ягына китте. Клубның сигез телле саратский гармуны бар иде, шуны кай арада өйрәнгәндер, өздереп бер уйнап җибәрсә, бармакларын җен йөртәдер моның, диерләр иде.

---

[1] Җәмәлән җавы — Емельян Пугачев явы дигәннән калган.

[2] Тамансы — тәмам.

Менә шул абыем сабышты инде үпкә чиренә. Үпкә чире нәселдә юк — без кайда үпкә, кайда бавыр икәнен дә белмибез; күршеләргә килгән башка чир дә безнең өй турыннан кырын-кырын гына карап үтә иде. Салкын тию генә екты абыйны, салкын тию генә... Күңеле генә түгел, тәннәре дә йомшак булган икән...

Кырык икенче елның игенен без кырык өчнең кышына тикле суктык. Кыш кыш инде, кары бар, бураны бар,— кибән төпләрен арчып бетерә алмадык: ачканы беренә тигезләп кенә кар салып китә иде. Шулай калдылар. Яз җиткәч, шулар буланып ачыла башлады — карты-яше кар өстеннән башакка ябырылды.

Апрель башларына инде үзебезнең басудагы кибән төпләрен чистартып чыгып, аръяктагы күрше колхоз басуына күчтек. Бу — аларның юл өзегендә өзелеп кала торган иң ерак басулары, ә безгә буа аша гына иде. (...)

Ул көнне без энебез Әдрәнне алмадык, Хәвадис абый белән икәү генә киттек. Башланмаган кибән төбе эзләп без бик ерак киткәнбез. Капчыкларыбызны төя-төя тутырып, авызын бәйләп торганда, кояш төшлеккә җитә язган иде инде. Шунда кыйбла тарафтан, иңрәп кенә кар эрегәне ишетелеп торган тын һаваны икегә ярып, колагыбызга шомлы бер аваз килеп керде. Без беләбез: бу иң усал Ниязкулның ярып төшүе иде.

Димәк, иртәгә боз да китәчәк. Без бата-чума тизрәк кайту юлына төштек. Ләкин өлгерә алмадык, кара тиргә батып яр буена килеп туктаганда, бер метр биеклеге тоташ ак күбек, йомгактай уралып, безнең өскә килә иде. Без ихтыярсыз артка чигендек. Ташу кайнап-чәчеп турыбыздан үтеп китте, артыннан карлы су җәелеп калды. Без аның буага бәрелеп сынуын көтеп тора башладык. Авылда бер көймә дә юк, булганы Агыйдел буенда. Хәзер чыгып калмасак — эш яман.

Авыл ягында ташуга ияреп чапкан бала-чага җыела башлады. Кайсыдыр безгә йөгерде булса кирәк: тиздән, арканнар күтәреп, әни белән Әдрән килеп җитте. Якынтирә апалар да җыелды, кулларында дилбегә йә колга иде.

Ташу безнең буага төртелү белән, агым әкренәйде, мәгәр суы күренеп арта башлады. Минут та көтәргә ярамый иде, капчыкларны баш өстенә куйдык та тәвәккәлләдек. Аяк хәзер тигән җиргә тия, тимәгән җиргә юк. Агым безне тегермәнгә таба агызып бара, безгә

аркан ыргытырга җай көткән апалар белән әни дә яр буйлап ияреп баралар. Сизәм: без суда булсак, әни утта иде. Ярдан безгә:

— Ташлагыз капчыкларыгызны! Мал кыйбатмы сезгә, җанмы? — дип кычкыра башладылар.

Тик безнең колак ишетсә дә, кул тыңламый: бердән, капчыкта безне юасына, какысына илтеп җиткерәсе ризык булса, икенчедән, су тагы тирәнәя калса, әз-мәзябышып йөзәрлек калкавыч та иде. Ярый әле су муеннан артмады. Инде өч аркан буе җитәрлек иде — яныбызга шап итеп дилбегә башы килеп төште.

Без исән-аман ярга чыктык...

Көчкә кузгалып, лач та лоч өйгә чаптык. Әни безгә сандыктан абыйларның күлмәк-ыштанын алып бирде. Йөзеннән курку яңа киткән. Әдрән салам бәйләп тимер мич ягарга кереште. Тимер мич тиз кыза — өй эче май булды. Әни, җаны кебек күргән бөртек чәен сандык төбеннән алып, чәйнектә сары мәтрүшкә белән томалап тотты да тәмли-тәмли безгә эчерде.

Шулай үтте. Авырып-нитеп ятмадык.

Ә көзгә Хәвадис абый йомшак кына итеп йөткерә башлады. Бер дә басылмагач, табибка күренергә киңәш иттеләр. Больница ерак түгел — биш кенә чакрым. Абый шунда барып, ярты литрлы шешә белән ютәл даруы алып кайтты. Тәмле икән бу дип, кашыклап кына эчеп бетерде бу моны. Ләкин ютәле бетмәде. Председатель Тимершәех абый безгә әни ягыннан җизни тиешле кеше иде, шул:

— Болай ярамый, апай[1]. Ютәл белән уйнарга ярамый, дип, абыйны, атына утыртып, район больницасына алып китте.

Тик юллары уңмаган. «Рингин аппаратлары ватылган» дип кайттылар. Шуннан калды. Утыз чакрымны көн саен йөреп булмый.

Кырык дүртенче ел башында Хәвадис абый яшендәгеләргә дә чират җитте. Ләкин абыйны сугышка алмадылар. «Открытый форма туберкулеза» дип җибәргәннәр.

---

[1]Апай — Татарстанның Минзәлә, Башкортстанның көньяк-көнбатыш татарлары «апай» дип үзеннән кече яшьтәге кызларга да, малайларга да әйтәләр.

Кыш өстендә ярты юлны җәяү, ярты юлны ат туры килеп, ачлы-туклы килеш, ике йөз чакрымны кайтып егылды абый. Ябыгып борыны сөягенә төшкән, башлары бәләкәйләнгән иде...

Шулай ике елга якын, эшкә чыга алмыйча, өйдә генә ятты да, кинәт тазарып китеп, бит очларына алсу нур йөгерде. Әйтерсең лә сугыш елларында килгән чире сугыш елларыдай артта калган иде. Ә кырык бишнең җиңүле язында икәү бергә сабанга төштек.

Энебез Әдрән дә ул елны җиденчесен бетерде. Имтихан биреп йөргән булдылар.

Шимбә саен клубта «бичер»[1]. Сугыш чорында да рухы сынмаган халыкның күңеле көр, күтәренке. Клубта да, мәҗлестә дә: «Күтәренке күңел белән үтсен безнең гомерләр»,— дип җырлыйлар. Гармун Хәвадис абый кулында. Без килгәнче берәрсе уйнап утырса, без ишектән күренү белән:

— Җитте, апай, такта ярма,— дип, кулыннан шундук гармунын алалар да абыйга китереп тоттыралар. Ул уйный башлады исә, клубның идәннәрен сыгып, сындыра язып бииләр иде!..

2

Хәвадис абыйның чире онытылып тору өстенә, кырык алтынчы елның алмалар чәчәк аткан бервакытны хәрби хезмәтләрен дәвам иттергән ике зур абый, берберсенә алдан хат язышып, бер-бер артлы гына отпускыга кайтып төштеләр.

Сугышта кайсының ире, кайсының улы, кайсының улы да, ире дә үлеп, ачы ялгызлыкта шомланып яшәгән апалар, безнең абыйлар белән елый-елый күрешкәндә, шатлык яшен яулык очы белән генә сөртеп торган әнигә сүз каталар:

— И Мәһисәрвәр җиңгәчәйкәйләр! Берсе-берсе кешенең ике баласына тиң биш балаң да исән бит! Нинди догалар укыдың без белмәгән?!

Күкрәгенә, сөлектәй, шатлык ябышкан әни генә:

— Улларымның кулыннан туфрак насыйп иткәндер инде, Аллага шөкер! — дип, ак яулык очын тагы күзенә китерде.

[1] «Бичер» — кичә — русча «вечер» сүзеннән үзгәртелгән.

Май ахыры иде инде. Сабан беткәннең икенче көнендә абыйларга дип атап куйган бүлтерек тәкәне суеп, туган-тулпы, күрше-күләнне җыйдык.

Хәвадис абый сандугач тавышлары белән тальянын уйнатып җибәрде. Аңа ике яткан ике абый җыр әйтеп кушылды:

Тальян гармун — моңсу гармун,
Басмый теле ачылмый.
Безнең йөрәк — ярсу йөрәк,
Бер җырламый басылмый...

Шулай бәйрәм иттек без абыйларның сугыштан исән кайту шатлыгын. (...)

3

Өч-дүрт көн ара белән кайткан абыйлар киткәндә бергә киттеләр. Алар киткәч, бишебез бергә өй тулып яшәгәннән соң, өй эче көзге басудай бушап, идән сайгакларына кадәр боегып-тынып калды.

Ямансу булса да күңелсезләнмәдек: күрәләтә үлемгә түгел, ә тыныч вакытның солдат хезмәтенә киттеләр.

Әни, аларны озатканда, икесенең дә аркасыннан сөеп-сыйпап:

— Улларымның киткәннәренә дә, калганнарына да Локман хәким[1] гомерләре бирсен, минем карт сөякләремне, җыеп-тәрбияләп, сез күмәргә язсын, йа Рабби Ходаем!..— дип, теләкләр теләп калды.

Абыйлар да безгә теләк-киңәшнең катысын әйтеп киттеләр: егыла-тора булса да, өчебезгә дә укырга куштылар. Зур абый җөпләп тора, Мирза абый иплән кенә сөйләп тора:

— Үзегез беләсез инде, апайлар: эткәй үлеп, без укый алмый калдык. Раббани абыйның — дүрт, минем — җиде класс. Безнең уку ак өстендә караны аерырлык кына. Сез дә шулай калырсызмыни? (...)

Абыйлар сүзендә дөреслек бар: укырга кирәк. Зур укыган кеше ул чакны берничә авылга бер генә иде. Сугыш вакытында уку кайгысы булмады,— кая инде ул каядыр китеп уку! — хәтта көрәк тотарлык балаларын күршедәге мәктәпкә йөртү дә аналары өчен авыр

[1] Локман хәким — борынгы галим. Мең ел яшәгән, имеш.

йөккә әйләнде. Алтынчы, җиденче класслар болай да сентябрь-октябрьдә укымадылар, майда инде тазарак малайлар сабанга чыга иде. Шулай укылды.

— Менә шул, апайлар,— диде Мирза абый ахырда.— Сүз боткасы — кәҗәгә азык. Кыскасы, укырга сөйләштек...

— Ишеттегезме? — диде Раббани абый да. Без өчебез бергә тиз генә баш кактык. Ләкин Мирза абый аның белән генә чикләнмәде:

— Бәлки, апай, быел ук син дәрт итәрсең[1], ә? — дип, күзен батырып Хәвадискә карады.— Син — иң олысы. Анда бит яшьне дә карыйлар. Соңлап куймагаең.

— Белмим шул. Бер дә уйлаган эш түгел бит әле ул...— дип, Хәвадис абый уйга калды.

— Сиңа аны уйлап торасы да юк. Тот та музыкаңа кит. Анда сине дә алмагач, кемне алсыннар? Музыкантлар сугышта да бик рәхәт йөрделәр...

Чынлап та, абыйлар китеп күңел утырыр-утырмастан, Хәвадис абый уку белән җенләнә башлады. Дәрт итеп, август аенда Уфа музыка училищесына кереп кайтты.

Без аның юлына, ипи карточкалары алганчы-ниткәнче дип, торырына ризык юнәтә башладык. (...)

Августның егерме бишләрендә Хәвадис абыйны, капчыгына ике мич сохари, ике шешә сары май, бер түгәрәк ипи салып, пристаньга илттек. Үзе дә, тавышы да бик матур бер пароход бар иде, шуңа утырып китте. Түбәбез күкләргә тиеп озатып җибәрдек шулай. Әни, гадәтенчә, безгә дә ишеттереп, теләген теләп калды:

— Раббәнәә атинә фид-дөнья хәсәнәти, биргән көнеңә, иткән рәхимеңә шөкер, Ходаем-Тәңрем! Инде үзең биргән чирне үзең алып, исән-сау гына укып кайткан сәгатьләрен күрергә язсын ие. Амин!..

Тик әнинең теләге кабул булмады. Хәвадис абыйның октябрь азагына таба бик көттереп бер хаты килде. «Хәлем бик шәптән түгел. Пароход туктаганчы берәрегез килеп китә алмассызмы?..»

Ул кышны Хәвадис абый Уфа тубдиспансерында үткәрде. Шулай итеп, укуга дип аткан беренче угыбыз ташка тиде. Хәвадис абыйга больницада бездәгечә салкын кышы, начар көзе булмаган җылы якта яшәп

[1] Дәрт итәрсең — укырга китәрсең мәгънәсендә.

карарга киңәш иткәннәр. Уфадан шул өмет белән дәртләнеп кайтты. Үзен бик тә савыктырасы килгәнгә, без аның өметен сүндермәдек; киресенчә, өчебез өч яктан куәтләп, билгесез авыр юлга җибәрергә булдык. Терелсен генә!

Өч атна дигәндә генә хаты килде. Ут йотып йөргән йөрәкләргә сары май булып ягылды абыйның сүзләре. «Тирә-якта кайнар сулыш өреп торган ком чүле. Урамда да аяк йөзеннән ком ярып йөриләр. Өстенә йомырка куйсаң, момент пешеп чыга... Их, үзебезнең юеш Агыйдел комнары өстеннән су буйлап кына йөгереп бер үтәсе иде!.. Йөгереп кенә кайтыр җирләр түгел шул...» — дип язган абый. Ахырда җыры да бар:

Күгәрчен оя кормасын,
Бала да чыгармасын.
Ризык читтә булса булсын,
Туфрак читтә язмасын.

Моннан соңгы хатларында да Хәвадис абый гел сагынуны гына язды. Ниләр генә сагынмый иде ул! Үз илебезнең карлыгач канатыдай кара җирләрен, Агыйделнең сөт өстедәй куе томаннарын, игеннәрнең буынга сикергән, баш кыскан, сөт тутырган, серкә очырган чакларын, үзебезнең буа буйларын; тагын әллә ниләрен сагынып, җирсеп ятуларын яза иде...

— Болай булгач терелә алмый инде ул анда, балакаем,— дип куйды әни.— Әйтәм җирле, авыруын бер дә язмый...

Хат алгач, берсендә түзмәде:

— Канаты юк, койрыгы юк бер кош төсле, чит җирләрдә ятмасын анда. Үз кояшым үземә — куып җибәрмәдек, кайтсын. Юлына дисә, актык сарыкны булса да сатып җибәрербез,— диде.

Сарыкны сатарга туры килмәде. Йөземдер, курәгәдер ише кучтәнәчләр алып, хәбәрсез генә кайтып төште абый. Тазарасы урынга ямьсез кара төс кунып ябыккан иде.

— Эссе. Һич бер тәгам йиә алмадым,— дип, төркмәнчәләп әйткән булды.

Салкын. Юеш. Ноябрьнең соңгы сибәләк яңгырлары өзлексез мал йөреп карайткан ужым өсләрен юа иде.

— Бу яңгыр җиргә түгел, минем үпкәмә генә явадыр инде!..— дип, сөзәк тау битендәге шул ужымнарга тәрәзәдән карап ятар иде.

Больницага бер дә барасы килмичә, бер атна чамасы ятты да беркөн әйтте:

— Булмаса илтеп куегыз инде мине...— диде. Ат алып, Әдрән үзебезнең больницага илтеп куйды. Аннан инде, самолет йөри башлау белән, Уфага җибәрделәр.

Кышның туксан, язның алтмыш көнен ул тагы шулай тубдиспансерда үткәрәчәк иде.

Сораулар һәм биремнәр

1. Бу гаилә кешеләренә уртак булган сыйфатларны әйтегез.

2. Ата белән ана балаларны ничек тәрбияләгәннәр?

3. Малайларның бер-берсеннән аермалы якларын табыгыз.

4. Хәвадис — нәфис табигатьле, нечкә күңелле малай. Сез моны нәрсәләрдә күрәсез?

5. Авыл кешеләре әтисез калган бу малайларга мөмкин булганча шәфкатьлелек күрсәтә. Сез моны кайсы күренешләрдә сизә алдыгыз?

6. «Укуга дип аткан беренче угыбыз ташка тиде» дигән җөмләнең мәгънәсен киңрәк итеп аңлатып бирегез. «Ук ату»— әлеге очракта образлы әйтү. Әсәрдән тагын шундый образлы сөйләм мисалларын табарга тырышыгыз.

7. Хәвадис туган якны сагынуын ничек итеп яза? Шул урынны дәрестә сәнгатьле итеп укыгыз.

5

Кырык сигезенче елның март аенда миңа унсигез яшь тулды.

Кырык сигезнең март аенда солдаттан Раббани абый кайтты.

— Мирзадан хат бармы? Ниләр яза? — диде абый.

— Синнән хат алмавына бик аптырап язган бер хаты килгән иде, шуннан юк әле,— дидем мин.

— Госпитальдән госпитальгә күчеп өзелдек шул...

— Аның хезмәте кайчанрак бетәр икән соң, улым? — дип сорады әни дә.

— Озакламас инде. Безнең действительный срогы[1] икебезнеке бер булырга тиеш.

— Кайтып та бер дә авылда торыр шикелле язмый әле ул,— дидем мин.

---

[1] Действительный срогы — тыныч вакытта армиядә хезмәт итү вакыты.

— Ә кайтып ни бар? Офицер башы белән малай-шалайлар янында сабан сөреп йөрерме? Мин инде мәҗбүри кайттым. Менә аягым төзәлсен әле...

— Шулай берәм-берәм таралып бетәрсез микәнни инде? — дип көрсенеп куйды әни.

— Соң, инәй, бер ояда биш ир бала өелеп ятып булмас бит инде.

— Төпчек тә бик үскән!..

— Инде ике ел Сабан туе булды, үз ишеннән беркемгә бил бирмәде,— дидем мин.

Абый, таягына асылынып, бер урында әйләнә-әйләнә, дөньябызны күздән кичерде. Әтидән калган өй дә, абыйлар үзләре тергезеп киткән каралты-кура да сипләп торуга карамастан, искереп килә; кар да күмгәч, әле бөтенләй җиргә иңгән сыман иде. Раббани абый, сузып кына: «Да-а...» — дип, кара төк баскан яңагын сыйпап торды. Бу аның сагынуы идеме, әллә бизеп, ятсыну авазы идеме,— белмәдем.

Көннәрнең берендә Мирза абыйдан хат килгәч, уку турында тагын сүз кузгалды. Беребез укый алмагач, мин инде бу сүзне беткәнгә саный идем — Мирза абый бетермәгән икән.

Бу юлы чират минеке иде. Мирза абый шулай язган.

Тик мин көн дә суза киләм. Керә аламмы-юкмы дип уйламыйм, Раббани абыйның аягы төзәлсен әле, шуннан күз күрер дип уйлыйм. Берсе авыру, берсе аяксыз ике олы кешене бер Әдрән белән әнигә калдырып китеп булмый бит инде!

Тимершәех абый да:

— Әкрен барган — куян артыннан җиткән, шәп барган — сыер артыннан да җитмәгән, диләр. Ашыкма, вакыт бар,— диде.

Шулай суза торгач, сабаннан соң тәки ремонтына кереп киткәнмен. Ахырда Раббани абый түзмәгән, тәмам ныгып таягын ташлагач, минем өчен Тимершәех абый янына кергән.

— Эти дә, үзем дә эшләгән алачык — иртәгәдән урнысына[1] үзем басам, җибәреп карыйк әле шул Сиринне берәр укуга. Мирза да бик нык кушып яза,— дип үтенгән.

---

[1] Урнысына — урынына.

Шуннан соң гына мин документлар әзерли башладым.

Документларны салып җибәрү белән, Хәвадис абый шикелле, китап җыеп әзерләнә башладым.

Тагын бер атнадан ипиен, китабын бер бәләкәй капчыкка салып, каеш белән битәрләп, пристаньга төштем. Агыйделдә йөргән ике катлы «Тукай» пароходы килеп, мине Уфага алып китте.

Техникумын тиз таптым. Ап-ак йөзле бер чибәр апага белер-белмәс русчам белән үземнең кем икәнлегемне әйттем. Ул минем аттай гәүдәмне баштанаяк күздән үткәрде дә бик ягымлы итеп аңлатып бирде. Минем монда килеп йөрүемнең кирәге дә булмаган: мине имтихансыз гына кабул итәчәкләр икән. Бер кәгазь язып бирде.

— Шушы язу белән августның егерме бишеннән дә калмый килеп җит.

Мин Уфада Хәвадис абый торган квартирда яши башладым. Карточка системасының беткән елы. Шулай да ипине бик мулкытмыйлар[1]: кулга биш йөз грамм. Дәрестән соң без, үзебезнең буфет алдына өелеп, ипи сата башлаганнарын көтәбез.

Ипи юк елларны да бер кимсенү күрми үскән очар кош булганмын икән авылымда!

Ләкин минем өчен иң авыры, үзәкләргә ярып үткәне бу түгел — уку иде. Группадагы малайларның күбесе (кызларыбыз биш кенә бөртек) җиденчене быел гына бетергән. Буйга миннән бик бәләкәйләре дә русчаны чатнатып сөйли иде. Ә минем ык-мыктан узмый. Дөрес, үзләрен генә аерым әйткәндә, белгән сүзләрем дә байтак шикелле, ләкин мин аларны бер-берсенә ялгый алмыйм. Ә инде укытучы сөйләгәндә, зиһенем бөтенләй куе томанга төрелеп, бик аңлаган берәр сүз чыкса гына, бер як чите ачылып киткәндәй була иде. Тәүлегенә туксан тапкыр: «Әллә ташлап кына китим микән техникумнарын — мин укымаудан гына әллә укыган кеше уннан тугызга калмас иде әле!» — дип уйлыйм. Әмма акылның икенче чаты йодрык төеп тора: «Дәрес белмәвең бер оят булса, ташлап китүең — ун оят. Хәвадис абыең чире сәбәпле укый алмады. Ә син?.. Тап-таза башың белән укуыңны ташлап кайтып, әниеңә син дә

---

[1] Мулкытмыйлар — күп бирмиләр.

борчу салыр иденме? Ул да бит синең укуыңны тели. Укыган угыл — атадан олы дип, әниең әйтә түгелме?..»

Шулай итеп, кимсенгән күңел тәүлегенә туксан тапкыр ташлап китәргә талпынса, кимсенмәячәк күңелем туксан тапкыр: «Юк!» — дип җавап бирә иде. Ноябрь башы белән военкоматка чакырып, кулга повестка тоттырдылар. Мин инде районда да, монда да комиссия үткән — ни тышымда, ни эчемдә солдатка ярамаслык бернәрсә дә юк иде. Армиягә китәчәгем турында өйгә хат салдым. Шулай итеп, укырга дип аткан икенче угыбыз да ташка тиде.

* * *

Авылдан телеграмма килгәндә, шәһәр алмагачлары, өсләренә куе сөт түккән төсле, шау чәчәктә утыралар иде. Ә мин кара кайгы белән автобуска утырдым.

Ләкин хәсрәт минем зиһенемне дә томалаган: мин телеграмманың бирелгән көнен карамаган йә карап та күрмәгән — Хәвадис абый мин телеграмма алган көнне түгел, алдагы көн үлгән икән. Безнең халык мәетне, бүген үлсә, иртәгесен күмә дә. Ә Хәвадис абыйны, мин кайтасын көтә-көтә, ике көн тотканнар. Ә мин күмгән көннең кичендә генә кайтып төштем.

Шулай итеп, пәрәвездәй нәзек күңелле Хәвадисебез үлгәндә, без аның дүрт туганы дүртебез дүрт якта сибелеп калдык. Раббани абый урманда, Әдрән армиядә, Тимершәех абый аларга хәбәр дә иттермәгән: дүрт-биш көнсез кайта алмагач ни файда? Икесенә дә хат кына яздык. Ярый әле көннәр аяз килеп, самолет оча иде. Мирза абый, туры Актанышка очып, Хәвадис абыйны үле килеш булса да күреп калырга җитешкән.

Мин юкта килен булып төшкән Тәрҗимә безнең өйдә бөтенләй үз булып беткән. Ләкин миңа аның, өлкән апаларча, күлмәк итәкләрен ике яклап күтәреп куеп, олы гәүдәсе белән карчыкларга аш ташып йөрүе әллә ничек мәзәк тоела иде.

Әни, күзен сөртә-сөртә, Хәвадис абыйның үлемен сөйли башлады:

— Уфадан кайткач, көнләп түгел, сәгатьләп сызды балам. Терелеп түгел, йөрәкләнеп кенә кайткан икән бүлнисеннән дә. «Бүлнис куйкыларында үлгәнче...» — диде. Вафатына ике генә көн кала: «Тукай яшенә дә

җитми үләм инде, әни,— дип елады.— Дөньяда исемем калырлык эш тә кыла алмадым ичмаса, үлемнән дә үкенечлесе шул»,— дип, башларын салындырып утырды.

Үләр көнендә иртә торып, битен кат-кат сабынлап юды. «Чиста ак күлмәгемне бир әле, әни»,—диде. Сандыктан күлмәген алып бирдем. Галстугын бәйләде. Әртисендә йөргәндә генә кия торган кара кәчтүнен алып киде. «Кая барасың болай бик иртә, балам?»— дип сорадым. «Китәм инде, әни...»— ди. «Әзрәк савык әле, әртислегеңә өлгерерсең»,— дим. Тик монысына бер сүз дә катмады. Шулай караватына килеп утырды. Мин урын-җирен одеял белән генә каплап куйган идем инде. «Кая, әни, баш астына бер мендәр бир әле»,— ди. Мендәр китереп салдым. Иртән ашаган да түгел. «Пешәр-пешмәс кенә итеп күкәй пеширимме, улым?»— дип сорадым. «Хәлем бетте, әни. Ятып торыйм әле»,— дип ятарга иткән иде дә, кинәт ютәле кубып, берьюлы кан коса башлады. Мин тиз генә кар базына чыгып, боз алып кердем, шуны вак-вак кисәкләп йотса туктый торгание. Тик балакаем башын гына чайкады. Бераз тын алгач, ап-ачык итеп: «Мин киттем, әни, бәхил бул...»—диде дә әкрен генә артына авып төште. «Ай Алла!»—дип, тиз генә башын мендәргә куеп, аякларын караватка күтәреп салдым. Баш очындагы тастымалы белән авызын-борынын сөрткәләгәнче үлеп тә китте... Үләсен белеп, юынып, яхшы киемнәрен кигән икән, балакаем...—дип, әни нык кына елап алды. Әбиләр дә берәм-берәм яулык очларын күз төпләренә тигереп чыктылар. Әни дәвам иттерде:

— Җеназа укыганда, Хәвадисемнең башына бер күбәләк килеп кунган. Китми дә китми, ди, канатын селкеп тик тора, ди. Моны Мәүләй карт сөйләде. Барыбыз да аптырадык, ди... Зиратка да кергән бу күбәләк. Ләхеткә төшергәндә генә юкка чыккан. Ә бүген иртән торып утыргач, бит очыма гына бер күбәләк килеп кунды. Селкенергә дә куркам. Шуннан Хәвадисем яткан карават башына күчте. Мин карап тик торам. «И улым, улым, мин әйтәм, инде синең сөйләргә сүзең юк, рухың шулай күбәләк булып кайттымы?..»— дип елыйм. Шулай тик кенә торды-торды да әнә теге тәрәзәдән кыйблага карый очып китте. Күздән югалганчы карап тордым — бер җиргә дә кунмады...

— Улың изге җан булыр,— диде бер әби.

— Кызлардан да болайрак әдәпле ие шул... Җир куеннары өчен генә үскән икән озын буйлары!..— дип, әни тагы күз яшен сөртеп алды.— Төсе итеп карарга бәбәе дә калмады ичмасам. Өйләнмәде бит! Ничә мәртәбәләр әйтеп карадым: «Йөрмә буйдак булып, өйлән, улым»,— дидем. Бүгеннән килергә торган алма төсле кызлары бар ие. Бигрәк тә әртислегендә бергә йөргән бер кызын ошаткан ием. Үлепләр тора иде инде менә! «Әллә шулмы соң, улым?» — дип тә сораган булдым. «Үзебез ятим үстек, ятим бала калдырасым килми, әни»,— диде балакаем...

* * *

Бүген безнең туй көне... Бүген сәгать икедә туйга әниләр дә килеп төшәчәк. Әни белән тагы кем килер икән дип уйлыйм. Әдрәнме? Раббани абыймы? Телеграммага исемләп язмаганнар. «Безне каршыла» дип кенә куйганнар... Юк, Әдрән килә алмас. Районда бер тракторчыны чәчү өстендә Казан тикле Казанга кем туйга җибәрсен?.. Сорамаячак та. Килсә Раббани абый килер. Иң зурыбыз — ул. Минем яктан ул утырыр инде башкода булып...

Шулвакыт кухняга кемдер кергәне ишетелде. Гөлсем ападыр. Чөнки ул гына шулай каты басып, ашыгып килеп керә.

Ләкин:

— Кодагый җаным! Сириннәр тордымы әле?..— дип соравын ишетү белән, тәнем буйлап салкын йөгереп үтте.

— Ходаем, ни булды?..— Монысы әбинең куркынган тавышы иде.

— Ай, әйтерлек кенәме? Ай, әйтерлек кенәме?..— дип кабатлый-кабатлый, бүлмәгә тәмам төсе качкан Анифә апа килеп керде.

Анифә апа, ачыргаланып:

— Сирин!.. Киленчәгем!.. Кодагый җаным!.. Башкаебызга тегермән ташы микъдар кайгы төште бит — Мирзабызга хулиганнар чәнечкән!..— диде.

Мин, сулышым өзелеп, караватның салкын никеленә тотындым.

— Нинди хулиганнар?..

— Исерек хулиганнар инде... Яшьләр... Эчен айкап өлгергәннәр.

Диләрә дә сикереп торып утырган иде инде, ни әйтергә белмәгәннән:

— Сирин, өстеңә ки ичмасам,— диде.

Шунда гына мин, әби белән Анифә апа алдында трусиктан гына килеш торуымны сизеп, аңсыз бер хәрәкәт белән пижамамны алып кидем. Әби Анифә апага урындык китереп бирде.

— Хараплар гына иттеләр дөлдөл сыман ир-егетне!..— дип, Анифә апа урындыкка утырып елый башлады.— Бер сөйләп ун көлә торган гүзәл кеше иде бит! Ничек күтәрербез бу хәсрәтне — ничекләр күтәрербез!.. Нилүфәркәем нишләр анысыз? Үлепләр тора иде бит аның өчен... Анагыз нишләр? Туйга килгән җирдән?.. Аһ-аһ!..

— Туктагыз әле, Анифә апа, ул хәтле тойгыга бирелмәгез әле. Мирза абыйның хәле ничек, шуны әйтегез?

— Ничек булсын инде эчен айкап ташлагач...

— Әле кайда соң абый?

— «Шамский»да... Нилүфәр дә шунда. Мине машина белән сине алмакка җибәрделәр. Әйдә тиз генә, абыең хәл эчендә...

Безне бер тоткарлыксыз абый янына керттеләр. Елап ярсыган, шашынган Нилүфәр җиңгине ике сестра, култыклап, палатага алып кереп баралар иде. Без кергәч, милиция майоры, безгә баш кагып, тын гына ишек төбенә барып басты. Мирза абыйның кичке кояштай нуры сүнеп барган саргылт ак йөзен күрү белән, йөрәгем өзелде дә төште. Мин барын да аңладым. Безне генә көтеп ята иде ул...

— Абый! Нишләттеләр сине болай? Нишләттеләр?..— дип тезләнеп, баш очына сыгылып төштем. Абый һушында иде әле.

— Менә... нимес пулясы да тимәгән иде...

Күзләремне тыелгысыз яшь каплап алды.

— Елама, туганым...— диде абый.— Туеңны гына күрә алмадым... Инәйне ничек тә юатырга тырышыгыз инде... Елап йөрәген бетермәсен...— Ул кинәт «ай!» дип тартыша башлады. Маңгаена тир бәреп чыкты. Сикереп торырдай талпынып: — Кая, кая каршыма, Нилүфәр... Бүлбүлем!..— диде.

— Мирзам!..— дип, җиңги, атылган кош кебек, абый өстенә егылганда, сестралар гына тотып калды.

— Башымны күтәр...— диде Мирза абый. Мин аның инде авырайган башын мендәрдән калкыттым. Абый дөньяда мин барын да, бүтәннәр барын да онытып, Нилүфәр җиңгинең күзләренә текәлде. Шул килеш, карап торган килеш, җан бирде. Җан биргәч тә, күзе йомылмады, тутырып ачкан күзләре белән туп-туры җиңгигә карап ята иде. (...)

* * *

Пароход ике сәгатькә соңлап килде. Шушы ике сәгать вакыт эчендә мин абый үлеменең — үз күз алдымда үлсә дә — күңелем ышанып җитмәгән чынлыгына ышандым. Чынлап үлдеме соң әле ул минем Мирза абый?.. Чынлап үлде түгелме соң минем Мирза абый?.. Чынлап үлде шул — чынлап!.. Күзләрен йомасы килми үлде...

Мирза абыкай-йым!

Диләрә:

— Елама инде шулкадәр...— ди.

Икенче абыең да үлгәч елыйсың икән шул! Кайгы тулы ике сәгать үткәч кенә, Маркиз атавының бу ягыннан кечкенә бер пароход күренде.

Пароход тавышы үзәгемне телеп алды.

Менә килеп җитте. Кырылышып халык төшә башлады. Әллә безнекеләр юкмы тагын?.. Бар икән. Әнә кешеләрдән бер баш калку булып Раббани абый чыгып килә. Янында Тәрҗимә җиңгинең таза гәүдәсе... Әни кайда соң... Әни дә күренде. Тик нигәдер бик ачык түгел. Абый белән җиңгинең дә гәүдәләре эреп ага башлады... Күземне сөртеп, яшемне селтәп аткач кына, дөнья элекке хәленә кайтты. Абый да мине күргән:

— Апай Сирин!..— дип кул болгап, миңа карап килә башлады.

Әни дә мине күреп елмайды.

Менә инде алар пристань капкасыннан чыктылар. Без үзебезчә ике куллап, ә Диләрә шәһәрчә итеп, әнине кочаклап күреште. Әни:

— Бу киленем дә бик сылу икән, күз тимәсен. Тигезлек белән, тазалык-байлык белән гомер итәргә язсын, амин,— дип, теләк теләде. Аннары минем чалбаргаябышып, минем артка качкан Сөмбелне күреп алды.— Бәй, Сөмбелем түгелме соң анда? Кил әле, лачыным, кил

әле, гөлем, кил әле, күз нурым!..— дия-дия шапылдатып сөя башлады.— Зуп-зур булган бит! Зуп-зур булган!.. Баланың баласы бигрәкләр дә татлы шул... Әтиең эштәдер инде. Эштәме, ә?.. Яратмады әле — җавап бирми. Бу нинди тешсез кортка дип торамы?.. Эштәдер шул әтиең, эштә булмаса төшәрие...

Мин инде тыела алмадым, Раббани абыйның күкрәгенә капландым.

— Их, абый!.. Раббани абый!..

— Чү, балам! Сиңа ни булды кинәт! Кеше болай шатлыктан кеше алдында еламас,— дип, әни иплэп кенә иңбашыма кагылды.

— Их, инәй! Инәкәччәем!.. Ходайдан сабырлыклар сора. Мирза абыйны үтерделәр бит!..

— Булмас! — дип, Раббани абый мине күкрәгеннән этеп җибәрде.

— Тәңрем, тәүбә! Ул ни дигән сүз? Өнемме бу, төшемме? — диде әни дә.

— Их, төш кенә булса иде!

Хәбәрнең чын икәнлеге Раббани абыйга да барып житте. Тик ул минем шикелле җебеп елый алмый иде. Беренче булып әни телгә килде.

— Ягез, балалар, кеше каршында җылашып тормагыз. Килешмәгәнне! Җылаудан гына үлгәннәр терелә калса, җир йөзендә мәңге-бакый җылашу гына булырие,— диде. Ләкин үзенең сыны каткан — ни үле, ни тере түгел, иреннәре генә дерелдәп елый иде.— Әйдәгез кузгалыйк. Инде күмеп үк куймаган булсагыз. Мирзамның йөзен күрим,— диде әни.

Без, такси тотып, Соцгородка киттек.

Мирза абыйны инде алып кайтканнар, өстәл өстенә куелган зур озын табутка сыя алмыйча, гел тере кебек ята иде. Әни шунда гына абыйның битен сыйпый-сыйпый елый башлады. Ләкин аның тавышы юк, тыны юк — күзеннән генә моңарчы бөялеп[1] торган яше ага иде. Елаудан туктагач та әле, бик озак итеп абыйның битен сыйпап торды.

Сәгать алты җитеп килә иде инде. Диләрә дә тынгысызлана башлады. Ләкин сүз әйтергә базмый, миңа гына төртә. Мин әни янына бардым.

---

[1] Бөялеп — күзенә тулып торган.

— Әни, туйны нишләтәбез соң инде? Җидегә кунаклар чакырылган. «Килмәгез» дип, һәркайсына әйтеп чыгып булмады. Бу бит авыл җире түгел...

— Ай балакайларым! — диде әни.— Башкаемнан бөтенләй чыккан бит!.. Туйга килгән кешене кире куалар димени? Ходай Тәгалә безгә биргән кайгылы үлемнең ахыры хәер-догалы булсын, ясагыз туегызны, балам. Гомер гомергә ялганмый, юньле туй да бер генә килә.

— Ә үзең бармыйсыңмыни?

— Юк, балалар, бара алмам. Син үпкәли күрмә, килен. Әле сезнең туйны без авылда да итәрбез, боерган булса... Раббани улым, Тәрҗимә килен, сез барыгыз. Мәет янында төн үткәрү сезнең эш түгел. Ә мин Мирзам янында соңгы кабат утырып калыйм инде. Хәвадисемә дә кырык бер ясин чыкканием... Барыгыз, балалар, бар. Тик җылап-мазар итеп кунакларыгызга сиздерә күрмәгез тагы. Бу хәлне белсәләр, үзләре дә килмәс иде дә бит... Килгәч инде — белмәсеннәр. Барыгыз...

— Каенанам! Мин бара алмыйым. Насыл мән бүген утырайым?[1] — диде Нилүфәр җиңги.

— Кызым, мин бит сиңа «бар» димәдем. Син кал, балам, кал,— диде аңа әни.

Раббани абый белән Тәрҗимә генә безнең белән китте. ...Ләкин безнең туй туй булмады. (...)

Сораулар һәм биремнәр

1. Сирин, нәрсә генә эшләсә дә, әнисен, туганнарын кайгырта. Бу нилектән шулай?

2. Башлангыч мәктәптән алып югары уку йортын тәмамлаганчы татар телендә эзлекле уку мөмкинлеге булмау күп еллар буена яшьләргә өстәмә кыенлыклар тудыра килде. Әсәрне укыганда, сез моңа игътибар иттегезме?

3. «Укыган угыл — атадан олы» дигән әйтем белән халык нәрсә әйтергә теләгән?

4. Язучы, Хәвадис үлемен тәэсирле итеп сурәтләү өчен, нинди алымнар куллана?

5. Бер үк көнне бу гаиләдә капма-каршы ике вакыйга була: бер туганнары үлә, икенчесенең туе уза. Шушы көнне ананың үз-үзен тотышындагы кайсы яклар сезнең игътибарны аеруча җәлеп итте?

6. Хәвадис тә, Мирза да вакытсыз вафат булалар. Бу ике үлем арасында охшашлык шунда гына. Әлеге ике үлемнең

---

[1] Мин бара алмыйм. Мин бүген ничек утырыйм?

аермалы яклары һәм аларның сәбәпләре турында аңлатыгыз. Ул сәбәпләргә сезнең мөнәсәбәтегез нинди?

7. Кайгыны җиңеләйтү өчен, әсәрдә төрле кеше үзен төрлечә тота. Ана, Сирин, Раббаниларның кайгыны ничек кичерүләрен сөйләгез.

Февраль ае иде инде. Шунда гына, көчкә, авылдан бер хат килеп төште. Энем Әдрән язган иде.

«...Раббани абыйны мәҗбүри дәваларга җибәрделәр, аракыдан ми шашкынлыгы башланган дип, Уфага озаттылар. Хәзер шунда. «Лечхоз» дигән җирдә. Эшләтеп дәвалыйлар икән...»

Шул көнне иртә белән мин Уфага очтым.

Уфада минем эшем юк иде. Гостиницага урнашу белән (әле көн бар), мин абыйны эзләп киттем.

«Лечхоз» дигәннәре бөтенләй шәһәрдән читтә — бүген генә үзем очып төшкән аэродром ягында булып чыкты. (...)

Як-ягыма карана торгач, абыйны күреп алдым.

— Раббани абый!..

Абый миңа каршы килеп кочаклап алды.

— Капкадан кергәч үк шәйләп алдым алуын. Тик бер дә көтмәгәнгә, синә охшатып кына утыра идем,— диде.

Без шундагы эскәмиягә утырдык.

— Нинди эшләр белән килеп чыгасы иттең Уфага? Кайчан килдең?

— Бүген генә килеп төштем әле,— дидем мин.

— Ни йомыш белән соң?

— Йомыш белән түгел, синең яныңа килдем, хәлеңне белергә. Язган идем бит.

— Бик рәхмәт инде, апай. Бик рәхмәт!..

— Кайтышлый, бер уңайдан авылга да кереп чыгармын, дидем.

— Килен белән түгелдер бит?

— Юк. Үзем генә.

— Гаиләдә татулыкмы соң?

— Татулык дип...— Мин җавап бирергә кыенсынып калдым. Бу көнгә җитеп беркемгә дә Диләрәне сөйләгәнем юк. Шуңа күрә, үз абыем булса да, Диләрә белән киткәндә талашып китүемне әйтәсем килмәде.

— Тату яшибез алай...— дип йомдым.

— Шулай, апай, татулык кирәк,— диде Раббани абый.— Уфада күпме булырга итәсең соң әле?

— Менә сине күрдем, хәлеңне белдем — Уфада эшем дә бетте. Иртәгә китәрмен дә.

— Соң, алайса, бергә кайтырбыз! — диде абый, шатланып.

— Ничек?

— Курс лечения тәмам! — диде ул, мактангандай.— Өченче көн Терегулов, безнең баш врач инде, мине үзенә чакырып алды да шуннан сөйләшеп киттек. Без яшьтәшләр дә булып чыктык... Безне бик яхшы бер дару белән дәваладылар. (...)

Без, шулай сөйләшә-сөйләшә, Каридел буеннан урап мендек. Аннары абый, расчет алырга дип, бухгалтериягә кереп китте. Аннан ул бетмәс сөенеч алган бер малай сыман килеп чыкты. Эшләгәне өчен (ашавыннан-эчүеннән калганы) кулына мең ярымга якын акча тигән икән.

Ул бүген үк минем белән китәргә талпына башлады.

— Бүген чыксаң, кайда кунарсың, кунакханәләр тулы,— дигәч кенә туктады.

Без иртәгә, сәгать тугыздан да калмый (чөнки пароход унбердә үк китә), мин туктаган «Астория» кунакханәсендә очрашырга булдык. Бүләк, күчтәнәч кебек нәрсәләрне мин бүген үк алып, иртәгә пароходка төшәргә сөйләштек. Раббани абый, дүрт баласына дүрт төрле әйбер алырга кушып, миңа дүрт йөз сум акча бирде.

— Үзең беләсең инде: ике малай, ике кыз. Барысына да кием-салым булсын. Икеләнеп торма — кара корсак авыл балаларына теләсә ни ярый — тот та ал. Нык кына булсын,— дип калды.

Пароходы да безне көтеп кенә торган төсле иде. Без төшү белән утырта да башладылар. Исең китәрдәй иркенлек — бернинди чиратсыз-нисез икебезгә бер каюта алдык.

Ә икенче көнне без кичке сәгать тугызда өйдә идек инде.

— Инәй! Менә апайны да алып кайттым әле. Мине күрер өчен Уфага килгән бит! — диде Раббани абый.

Әни, минем аркамнан сөеп:

— Үзең генә кайттыңмыни, балакаем? Киленем белән оланым кайтмадымыни? — диде.

— Алар Казанда калды, инәй. Мин Уфага Раббани абыйның хәлен белер өчен генә барган идем. Менә бер уңайдан сезне дә күреп чыгыйм, дидем. Әдрәннәрне

дә котлыйсым бар... Быел башкача кайтып булмас, инәй.

— И Ходаем! Киленем белән оланымны быел күрә алмам микәнни инде болай булгач?..

— Кайгырма, инәй, берсе-берсе, ярсаң, ике чыгарлык ике киленең янында! — дип, Раббани абый көлеп куйды.

Әни абыйга карады:

— Синең соң, балакаем, дәваланып кайтуыңмы инде бу?

— Дәваланып кайтуым, инәй, дәваланып! — диде абый.— Моннан ары иске авыруым тотмаячак. Менә ипи!..— дип, өстәлгә таратып ташлаган клиндерләрнең иң зурысын алып, баш өстенә куеп торды.

— Ай Алла! Антың башыңа төшмәсен берүк! Тәүбә-тәүбә!..— дип, әни коелып төште. (...)

Шулвакыт өйгә, ике баласын ияртеп, без кайтканны ишеткән Тәрҗимә килеп керде. Балалары: «Әти!» — дип йөгереп килеп, икесе ике ботын кочаклап алды. Абый аларны, икесен ике кулына күтәреп, күкрәгенә кысты.

— Нишләп үз өеңә кайтмый торасың? Бик сагынгансың икән балаларыңны!..— диде Тәрҗимә, ачуланмыйча гына.

— Бәй, мин — үзем үскән өйдә, үз анам янында лабаса!— дип көлде Раббани абый.

Тиздән алар бүләкләрен, күчтәнәчләрен күтәреп, сөенеп-шаулашып чыгып киттеләр.

Караңгы төшкәч кенә, «матай»ын тырылдатып, Әдрән кайтып керде. Мин, көтеп утыра торгач, йокыга китеп бара идем инде. Әдрән, авызын җәеп, минем белән килеп күреште. (...)

— Бик вакытлы кайттың әле, Сирин абый. Берсекөнгә Сабан туе бит!..

* * *

Чын Сабан туен мин гомеремдә өч тапкыр күргән кеше: кырык алты, кырык җиде, кырык сигезенче елларда күрдем. Шулардан беренчесе — Җиңүдән соң беренче Сабантуй! — яшьлек хыялымда гомер күрелмәгән бер ямь, бер моң булып уелып калган. Исемә төшерсәм, әле һаман да бөтен бизәге-чәчәге белән, колгадагы сөлгеләре белән күз алдыма килә дә баса. Йөз җирдә йөз гармун уйнаулары, тыныч тормыш, бәхет,

мәхәббәткә сусап җырлаулары (бүген ишетәм диярсең) колагымнан һаман китми тора. Күңелемдә ул Сабантуй әле булса таралмаган, таралырга тиеш тә түгел сыман; теләсәм, менә бүген үк шунда барыр идем сыман торып калган иде...

Казанда мин бер генә тапкыр Сабан туена бардым. Каенлыкта иде. Ләкин мин анда күңелемә сеңгән яшьлек Сабан туен күрмәдем. Урам булып тезелгән буфетларга, каен төбе саен утырган компаниягә очрап, көрәшкән-йөгерешкән җиренә барып җитә алмадым. Дөресрәге, анда борын төртерлек тә түгел, мәхшәр иде. Мин кул селтәп кайтып киттем.

Хәзер минем яшьлегем Сабан туен күрәсем килә иде.

Әни иртәдән пешеренә башлаган. Киленебез мунчалар яккан. Беренче булып мин кереп чыктым. Сабан туеннан соң туры безгә кунаклар киләсе булганлыктан, әни Тәрҗимә белән аш әзерли калды. Зөлфия безнең белән китте.

Сабан туеның урыны үзгәрмәгән, шул ук Иске Агыйдел яланында иде. Ләкин, бару белән күрдем, бүген дә яшьлегем Сабан туе булмаячак. Берничә җирдә берничә машинадан шәрабтыр-аракыдыр саталар, кешеләр дә Сабан туе караудан бигрәк, дус — дусты, туган туганы белән җыелышып эчәргә килгән сыман иде.

Әдрән килү белән көрәшкә әзерләнә башлады. Ул инде ике ел рәттән батыр калган, быел да мәйданга бик дәртләнеп чыкты. Ләкин... бөтенесен рәттән кырып килгән Актаныш батыры аны да җиргә салды. Искәрми дә калдык. Бу яшь, яңа батырның гайрәтенә халык аһ итте. Әдрән бик кызу да, гарьчел дә иде — сикереп тә торды, үзенә дусларча кул биргән Актаныш егетен сугып та екты.

Инде батырга чыгарга кеше дә калмаган иде. Шунда түгәрәкне ерып, Раббани абый килеп керде. Пинжәген салып атты, күлмәген салып атты, сул кулына сөлгене урап тотты.

— Кил, акыллым!..— диде ул әлеге батырга.

Батырның да гаре кузгалган иде — җан ачысы белән алыша башладылар. Минем яндагылар:

— Нишләп керәсе итте соң әле бу Раббани? Гомер көрәшкән кеше түгел бит! Көрәштә ул, көчтән дә бигрәк, саллы булу кирәк,— дип, абый өчен борчылып алдылар.

Лəкин, спортны белгəн кеше, мин күрəм: бу егет абыйның уникe яшьтəн тимер сугып каткан билен ала алмаячак иде. Ул да булмады, абый аны «у-ух!» итеп җирдəн суырып та алды.

— Ат үзен Актаныш ягына!..— дип, безнекелəр дəррəү кычкырып җибəрделəр.

Лəкин абый тегене, үз гəүдəсеннəн аерып, атып бəрə алмый: атарга итсə, бергə егылачаклар иде. Ахырда абый, бер мəзəк итеп, батырны күтəргəн килеш, түгəрəк əйлəнəсеннəн алып китте. Шулай бер əйлəнеп чыкты да, «тик кенə тор, кыймылдама» дигəндəй, мəйдан уртасына бастырып куйды. Батырның кулын кысып, безнең янга килде.

Шунда мин абыйның һаман бетмəгəн көченə хəйран калдым.

Сабан туеннан Əдрəн кунаклар җыеп алып кайтты. Мин белгəннəре дə, белмəгəннəре дə бар — биш пар кунак иде. Бəйрəм өстенə, минем Казаннан, абыйның больницадан кайтуын бизəккə санап, күңелле иттереп табын башлап җибəрделəр. (...)

* * *

Икенче көнне Раббани абый кичкə таба кинəт юкка чыкты. Əни əйтмешли, ут булды да су булды. Бер «матай» тавышы ишетелеп калган иде, шуңа утырып киткəн, ахры.

Тəрҗимə каядыр киткəн. Əдрəн эштə. Мин кая баруымны əнигə генə əйттем дə пристаньга киттем. Хəерчегə җил каршы дигəндəй, юлда ни аты, ни «матай»ы туры килмəде. Шулай җəяүлəп кенə өч чакрымны барып җиттем.

Пароход, көндəгечə, сигез тулгач килергə тиеш иде. Ул килер алдыннан яр өстендəге ларекны ачып җибəргəннəр. Раббани абый шунда, ларек авызына янын куеп, мин белмəгəн кешелəр белəн басып тора иде. Алларында аракы.

— Раббани абый, эчмисең! — дидем мин.

— Мин эчмим дə,— диде ул.— Менə дусларны гына сыйлыйм.

Лəкин авызына инде аракы кергəн: күзеннəн үк күренеп тора иде.

— Алайса, буталып йөрмә, әйдә кайтыйк,— дидем мин.

— Менә пароход килсен дә, кайтырбыз.

Пароход бераз соңлап килде. Җыелган ирләр, буфетыннан сыра алып калырга өлгерер өчен, басма салганны да көтмичә, борт аша сикереп, пароходка ташландылар. Беренче булып диярлек сикергән абый, аягы аксап китепме, артта калды. Пароход соңлап та килгәч, һәммәсе ашыга, чөнки еш кына, кире чыгарга өлгермичә утырып китеп, икенче пристаньнан егерме-утыз чакрым җәяү кайтучылар да була икән.

Соңлап килгәч, ун минут та үтмәгәндер, пароход китәргә дә яскана[1] башлады. Ике матрос, дөбер-шатыр китереп, басманы тартып алды. Сырачылар, йөгерешеп чыккан уңайдан, без торган дебаркадерга сикерәләр. Ләкин әле барысы да чыгып бетмәгән, шул исәптән Раббани абый да юк иде. Ул арада борын якны чишеп җибәрделәр. Агымга каршы туктаган пароход борыны көчле агым белән бик кызу аерыла башлады. Раббани абый белән тагын ике кеше чабып килеп җиткәндә, пароходның борыны гына түгел, биле дә дебаркадердан кеше буе аерылган иде инде.

— Койрыкка барың!.. Койрыкка барың!..— дип кычкырышып, без дә койрык ягына йөгерештек.

Ләкин безнең абыйлар, чыгар юл табып, койрыкка барып җиткәнче, койрык бавын да чиштеләр. Алда, заготзернодан икмәк төяп, бик зур «Волготанкер» торганлыктан, пароход борылып китәр өчен, артка чигәргә тиеш иде — гөжләтеп куласасын әйләндереп җибәрде. Нәкъ шулвакыт, беренче булып, пароход читенә безнең абый килеп чыкты. Чалбар кесәләре, пинжәк кесәләре тулы шешә иде. Кулына да икешәрне тоткан. Ләкин күзе тонган — мине күрмәде дә. Мин:

— Раббани абый, сикермә! Утырып кына кит! — дип кычкыруым булды, абый, шешә тоткан ике кулын алга сузып, дебаркадерга сикерде. Ләкин, култыксасына ябыша алмыйча, ике арага шатырдап төшеп китте. Халык аһ итте. Ул арада Раббани абый артка чажлап чигенгән пароход астына суырылып кереп юкка чыкты. Капитан өстән:

— Стоп!.. Полный ход вперед!..— дип кычкырды.

---

[1] Яскана — омтыла, дәртләнә.

Ләкин соң иде инде — пароход абыйны таптап үткән иде. «Полный ход» белән алга киткәч кенә, куласа дулкыны абыйның җансыз гәүдәсен, кисә тулы шешәләре белән, үзебезнең кечкенә елга тамагына илтеп какты...

Ә икенче көнне әнинең чәче ап-ак булып агарып чыкты.

Менә биш туган идек. Раббани абый белән Мирза абый сугыштан, тәннәренә пуля түгел, шырпы да тими кайтканнар иде. Базарларда бер без генә, бөтен базар өстеннән калкып, бер-беребезне күреп йөри идек... Булмаган да сыман беттеләр... Биш туганнан икәү калдык. Каян табыйм мин хәзер андый туганнарны?! Нигә тотып калмадым мин Раббани абыйны?! Аһ!..

— Ал мине, газиз җир, җылы куеныңа!.. Ал!.. Салкын туфракларың белән суыт кайгыларымны!..

Минем туйда Раббани абый да нәкъ шулай елаган иде.

— Чү, балам, ипле сөйләш...— дип, әни телгә килде.

Мин күтәрелеп әнигә карадым.

— Их, инәй! Балаларыңның үлемен күреп үләр өчен генә тудыңмы әллә син дөньяга?!

— Сабыр бул, улым. Без күрәсене, без күрмичә, кем күрсен?..— диде әни.

— Бу кайгыларга ничек түзеп торасың икән акылдан язмыйча!..

— Тәүбә диген, улым!.. Мин дә акылдан язсам, Раббани улымның бәбәйләрен кем карар?..— диде әни.

1976 ел

Сораулар һәм биремнәр

1. Җаваплылык (ил, гаилә, балалар алдындагы җаваплылык) нәрсә ул? Дүрт балалы Раббанида ул хис бармы?

2. Раббаниның эчкечелеккә сабышуын сез нәрсә белән аңлатыр идегез?

3. Сүз бирү, ант итү — кешенең үз өстенә җаваплылык алуы. Сүз биргәндә, кеше күңеленнән нинди уйлар кичерергә тиеш? Раббани ант итүгә җитди карыймы?

4. Сирин элекке Сабантуйлары белән хәзергеләре арасында нинди аерма күрә?

5. Язучы сурәтләгәнчә, мәҗлестәгеләр, күңел ачудан бигрәк, төп максат итеп нәрсәне куялар? Сезнең моңа мөнәсәбәтегез ничек? Сезнеңчә, бәйрәм табыннары нинди булырга тиеш?

6. Хәвадис, Мирзаларның үлеме белән чагыштырганда Раббаниның үлеме сездә нинди тәэсир калдырды?

7. Ананың: «Мин акылдан язсам, Раббани улымның бәбәйләрен кем карар?» — дигән сүзләреннән сез нәрсәне аңлап калдыгыз?

8. Кече туган Әдрән турында сездә нинди фикер туды? Аның язмышы алга таба ничек булыр дип уйлыйсыз?

9. Язучының шушы әсәрен табып, тулаем укып чыгарга тырышыгыз.

«БЕР АНАНЫҢ БИШ УЛЫ» ПОВЕСТЕ ТУРЫНДА

Беренче карашка әсәрнең эчтәлеге бик гади кебек. Солтан белән Маһисәрвәрнең биш улы бар. Тимерче булып эшләгән этиләре бик иртә үлеп китә. Малайларның барысына да тазалык, эш сөючәнлек, кешелеклелек сыйфатлары этиләреннән күчкән дип уйларга мөмкин. Әлбәттә, аларның таза-сау, акыллы, инсафлы булып үсүләрендә әниләренең дә өлеше аз түгел. Раббани, Мирза, Хәвадис, Сирин һәм Әдрән исемле бу малайларны үз авылларында гына түгел, тирә-якта да яхшы беләләр. Безне бигрәк тә аларның әниләренә һәм бер-берсенә булган җылы мөнәсәбәтләре сокландыра. Туганнарына абыем, апаем дип кенә эндәшәләр алар.

Аерым кеше кебек үк, гаилә дә башка кешеләр белән аралашмыйча яши алмый. Язучы менә шушы мөнәсәбәтләрнең бик үк гади булмавын, гомумән, яшәүнең рәхәт тә, бер үк вакытта шактый ук катлаулы да булуын күрсәтеп бирә. Шуңа күрә әсәрне бары тик Маһисәрвәр апа һәм аның биш улы турында гына дип әйтү бигүк дөрес булмас иде. Әсәрдә, тулаем алганда, сугыш алды, сугыш чоры һәм аннан соңгы еллардагы җәмгыятебез, шул вакыттагы кеше язмышлары сурәтләнә. Бер гаиләнең язмышы аша язучы, гомумән, тулаем бер чор кешеләренең яшәү рәвешләрен сурәтли.

Әсәрдә әхлаклылык турында сүз бара. Повестьның мавыктыргыч көче, барыннан да элек, шушы мәсьәлә тирәсендә тупланган. Әхлак — кешенең үз-үзен тотышын, башкалар белән мөнәсәбәтен билгеләүче нигез. Ягъни кеше нәрсәне яхшы, нәрсәне начар дип исәпли, теге яки бу гамәлне ул үзе өчен ярый дип саныймы-юкмы, шушылардан чыгып, ул башка кешеләр белән эш итә, яхшы яки начар эшләр кыла. Х. Сарьян да үзе сурәтләгән образларны шушы әхлак кануннары аша сыный.

Игътибар иткәнегез бардыр: һәр кеше башкалардан үзенең тышкы кыяфәте белән генә түгел, үз-үзен тотышы, сөйләшүе, эш-гамәлләре белән дә аерылып тора. Без үзебез күпмедер

дәрәҗәдә белгән берәр кешенең нинди сүзләр сөйләвен яки нинди эшләр башкаруын алдан ук чамалыйбыз. Ә инде ул кеше без бөтенләй көтмәгән ниндидер эш эшләсә аптырап калабыз: «Алай итәр дип кем уйлаган?» — дибез. «Бер ананың биш улы» әсәрендә дә биш туган, бер үк ата-ана балалары булуларына, бер үк шартларда тәрбияләнүләренә карамастан, бишесе биш төрле. Ни өчен шулай? Моның төп сәбәпләреннән берсе — аларның һәрберсенең төрле-төрле әхлак кануннарын үз гамәлләренә нигез итеп алуларында.

Яшьрәк чакта малайлар әхлаклылык ягыннан бер-берсеннән әллә ни аерылмыйлар кебек. Барысы да сөйкемлеләр, бер-беренә ихтирамлылар, өлкәннәргә, ата-анага хөрмәтлеләр. Раббани белән Мирза сугыштан тагы да ныгып, башка туганнарына терәк булырдай булып, ирләрчә җитлегеп кайталар. Бу яктан Мирза аерылыбрак та тора. Башта ул Хәвадисне, соңыннан Сиринне укырга өнди, олы тормыш юлларын күрсәтә. Үзенә исә әхлаклылыкның иң югары таләпләрен канун итеп алган. Гаиләсендәге мөгамәләсен карагыз. Хатыны, балалары белән дус, тату яши. Эшен дә бик теләп башкара. Милиция хезмәткәре булганы өчен генә түгел, күңеле белән яхшы кеше буларак, бүтәннәр бәхетен, иминлеген кайгыртып яши. Аның үлеме дә олы мәгънәгә ия — кеше гомере хакына фаҗигале төстә һәлак була. Гаиләсе, туганнары, тулаем җәмгыять алдында Мирзаның йөзе ак. Хәвадиснең үлеме дә укучыны тетрәндерә. Бу чибәр, оста гармунчы, күңеле матурлык белән тулы, акыллы егетнең күзгә күренеп сула баруы укучыны да хәсрәткә сала. Сугыш афәтенең балаларга да никадәр газаплар алып килүен Хәвадис язмышы аркылы тагы да көчлерәк сизәсең.

Шушы ике туганның үлеме янында Раббаниның һәлакәте бөтенләй капма-каршы хисләр тудыра. Без башта аның образында, әтисе һөнәрен дәвам итеп, тимерче булып киткән таза гәүдәле, бөтен туганнарына ата кебек булырдай кешене күрәбез. Үзе кебек уңган, җир җимертеп эшләүче Тәрҗимәгә өйләнеп, берсеннән-берсе тере дүрт бала атасы булган ул. Менә дигән өй дә салып керәләр. Нәсел-нәсәбенең тамырын авылда ныгытыр бу, дип көтәсең. Ләкин тора-бара аның мондый ышанычны акларга сәләтсез икәне күренә. Ул эчүгә сабыша. Хәмер хирыслыгына бирелгән кеше — беткән кеше. Аңарда дөнья гаме, гаилә, үзе турында кайгырту кебек хисләр тупасланганнан-тупаслана бара, һәм ул көннәрдән бер көнне фаҗига белән

гомерен дә чикли. Балаларын ятим итә, хатынына, әнисенә, туганнарына әйтеп бетергесез хәсрәт китерә. Язучы эчкечелекнең бу чиргә тарыган кешегә генә түгел, тирә-яктагыларга да, җәмгыятькә дә зур зарар китерүен тормышчан итеп сурәтләгән. Әдәби әсәр белән шушы ямьсез күренешкә каршы көрәшкә чыккан.

Кече туганнары Әдрән дә, әсәрдә шактый аз гына күренеп китүенә карамастан, үзенә бер холык иясе булып күзаллана. Бу егет Сабан туенда ике ел рәттән батыр калган. Өченче елда үзен батыр асты калдырган егетне көтмәгәндә сугып егуы да аның холкының бер ягын — гарьләнүчән, кызып китүчән булуын күрсәтә. Сөйләгәндә сүзен дә башкаларга ничек тәэсир итәр дип чамалап тормый, турысын ярып сала. Әдрән олы абыйсы Раббани белән авылда калган. Аның исерек абыйсын дөрес юлга бастырасы килә, кеше арасында ким-хур булмасын, ди. Әмма, бөкрене кабер генә төзәтә дигәндәй, күпме тырышса да, теләгенә ирешә алмый. Боларның һәммәсе Әдрәннең холкына тәэсир иткәндер дип уйларга кирәк. Шулай да укучы бу кече малайны үз итә, яратып кала.

Ни генә димә, повесть белән танышканда төп игътибар Сирингә юнәлә. Сирин — әсәрдә хикәяләүче. Укучы һәрвакыт аның белән: Сирингә ияреп Уфага да, Казанга да бара, авылга да кайта, гаилә мөнәсәбәтләренә дә килеп керә. Бу егет әти-әнисенә, туганнарына, якыннарына, тормыш юлында очраган башка кешеләргә һәм шул еллардагы җәмгыятебез тормышына бәя бирә. Бик сөйкемле, тирәнтен уйлый һәм кичерә белүче, кешеләрне яратырга сәләтле егет. Кичерешләренең самимилеге белән ул үзенең эчке дөньясын да бик тулы итеп ачып сала. Аның мәхәббәт хисләре дә дулкынландыргыч итеп сурәтләнгән. Хикәяләүче буларак, Сирин кешеләргә һәм вакыйгаларга бәя биреп бара, ләкин күп очракта хөкем чыгаруны ул укучының үзенә калдыра. Бу исә әсәрне кабул итүчене уйларга, бәя бирергә этәрә.

Кеше үз язмышын үзе сайлый, диләр. Холык-гадәт кешенең бүгенгесен һәм киләчәген билгели. Ләкин холык-гадәт үзгәрми тормый. Кеше — акыллы җан иясе. Аң исә — характерны кирәкле юнәлештә үзгәртергә ярдәм итүче нигез. Бу яктан Сирин образы безгә үрнәк булып тора. Ул ара-тирә кызып та киткәли, дуамаллык та бар аңарда. Ләкин Сириндә шул ук вакытта салкын акыллылык та бар, менә шул аны туктатып кала, дөрес юлга борып җибәрә. Үз-үзенә хуҗа булган кеше генә

көчле ихтырлы шәхес дип саналырга хаклы. Димәк, бөтен уңышларның ышанычлы нигезе — шәхесеңне хөрмәт итү, үзеңне яхшы гамәлләр белән мавыктыру. Без Сиринне әнә шундый шәхес булыр дип ышанабыз.

Ана образы — Хәсән Сарьянның зур уңышы. Татар хатынының акылын, саф әхлаклылыгын, рух көчен күрсәткән образ бу. Маһисәрвәр апа бер-бер артлы өч баласын югалта. Табигатьнең кануны шундый: ата-ана, балаларын калдырып, дөньядан алдан китеп бара. Иң кадерле кешеләрнең үлеме зур кайгы булса да, шулай булырга тиешле дигән уй күңелгә бераз юаныч бирә. Ә ата-ананың йөрәк бәгыре булган балаларын соңгы юлга озатуы табигый хәл түгел. Моннан да олы хәсрәтнең булуы мөмкин түгел. Ана арысландай өч баласын җирли, мөмкин булган кадәр сабырлык күрсәтергә тырыша. Хәтта Мирзасы үлгән көнне үзендә Сирингә туй итәргә рөхсәт бирерлек көч таба. Хәсрәтен тышка чыгармаска тырышса да, бер-бер артлы килгән бу олы кайгылар аны иртә картайталар. Раббание да үлгәч, ананың чәче ап-ак була. Әмма монда да ул көчле рухлы булып кала. Бу яктан әсәр ахырында Сирин белән ананың сөйләшүе гыйбрәтле:

«Мин күтәрелеп әнигә карадым:

— Их, инәй! Балаларыңның үлемен күреп үләр өчен генә тудыңмы әллә син дөньяга?!

— Сабыр бул, улым. Без күрәсене, без күрмичә, кем күрсен?..— диде әни.

— Бу кайгыларга ничек түзеп торасың икән акылдан язмыйча!..

— Тәүбә диген, улым!.. Мин дә акылдан язсам, Раббани улымның бәбәйләрен кем карар?..—диде әни».

Әйе, ана хаклы. Тормыш дәвам итә. Раббани үлеме балаларның үсүен, яшәүнең дәвам итүен туктата алмый. Ана бу сүзләре белән гап-гади бер фәлсәфи хакыйкатьне — тормышның мәңгелеген раслый.

Шул рәвешле, татар әдәбиятында сурәтләнгән аналар янында тагын берәү — үтә тыйнак, тавыш-тынсыз гына үзенең тормышын җайлап алып баручы, сабыр холыклы, үзендә милләтебезнең матур сыйфатларын туплаган Маһисәрвәр апа да бар.

Тема — грек сүзе, «нигез» дигән мәгънә аңлата, әдәби әсәрнең нигезенә салынган мәсьәләләрнең иң әһәмиятлесе, аларның барысын бергә берләштерүче. «Бер ананың биш улы»

әсәрендә берничә мәсьәлә күтәрелә: туганнарның бер-берсенә мөнәсәбәте; балаларның шатлыклары, кайгы-хәсрәтләре һәм ана күңеле; малайларның мәхәббәткә һәм гаилә коруга булган карашлары; хәмер (исерткеч) һәм кеше язмышы; кешенең гаиләдәге җаваплылыгы һәм башкалар. Шушыларны бербөтенгә туплаучы үзәк булырга тиеш. Алай булмаганда, әсәр бөтенлекле булып оеша алмас иде.

Бер ана һәм биш бала. Малайлар һәммәсе дә бер үк шартларда үскән, бер үк ананың балалары. Димәк, холык ягыннан уртаклык зуррак булырга тиеш иде кебек. Әмма алар бик төрле-төрле, шул сәбәпле яшәешләре дә һәрберсенең үзенчә. Холык — кеше язмышы, дибез икән, әсәрнең тулаем темасын малайларның холыклары һәм язмышлары дип билгели алабыз. Дөрес, аерым кешенең язмышы тагын бик күп нәрсәләргә бәйле. Тормышта, гомумән, яшәештә холкыңның ниндилеге дә бик мөһим. Димәк, холкыңның игелекле, итагатьле, нык булуы турында кайгырту — киләчәгең турында уйлау дигән сүз. Автор укучыларга менә шул хакыйкатьне җиткерергә тели.

Сораулар һәм биремнәр

1. Түбәндәге темаларга (арадан сайлап алып) инша язарга тәкъдим итәбез:

1) Ананың күркәм сыйфатлары: йомшак күңеллелек һәм рух ныклыгы.

2) Мәһисәрвәр апа — киң күңелле ана!

3) Мин әсәрдәге ананың нинди сыйфатларын үземдә булдырыр идем?

4) Сирин образындагы һәм минем холкымдагы аермалы яки уртак яклар.

5) Мирзаның үлеме — иң югары дәрәҗәдәге мәгънәле үлем.

6) Исән булса, Хәвадискә яшәү җиңел булыр идеме?

7) Әдрән холкының миңа ошаган һәм ошамаган яклары.

8) Эчкән кеше — беткән кеше.

2. Сыйныфтан тыш түбәндәгеләрне эшләргә мөмкин:

1) «Кешенең бәхете — үз кулында» дигән темага бәхәс.

2) Шамил Усмановның «Канлы көннәрдә» пьесасын табып укырга тырышыгыз. Анда сурәтләнгән гаиләдә дә биш бала. Алар да бишесе биш төрле холык-фигыльгә ия, омтылышлары да һәрберсенең үзенә бертөрле. Ни өчен? Ике әсәрне чагыштырып, шул сорауларга җавап табарга тырышыгыз.

ХӨРМӘТЛЕ УКУЧЫЛАР!

Менә дәреслекнең соңгы битен дә ябып куйдык. Без аңа ел буе нык ияләнгәнбез икән, күңелне моңсулык басты. Ләкин бу беренче карашка гына...

Сез бу уку елында татар әдәбиятыннан бик күп мәгълүмат алдыгыз. Халык авыз иҗаты хәзинәләре булган мәкальләр, бәетләр, риваятьләрдән алып язма әдәбиятның төрле жанрларында иҗат ителгән әсәрләр белән ныклап таныштыгыз. Аларда халкыбызның олы язмышы чагылуын күрдегез. Әлеге әсәрләрдә күпме кеше язмышлары! Ул язмышлар бәхетле һәм фаҗигале, өметле һәм хәсрәтле, якты һәм караңгы... Әйе, яктылык һәм караңгылык — мәңгелек юлдашлар. Тик шунысы бар: яктылык күбрәк булган җирдә караңгылыкка урын азрак кала, дөньяны караңгылык басса, яктылыкка көн калмый. Сөембикәләр буыны фаҗигасенең күләгәсе берничә йөз еллар буе милләтебез өстенә караңгылык сирпеп торды.

Әмма К. Насыйри шикелле мәгърифәтчеләребез, Г. Тукай, Дәрдемәнд, Һ. Такташ, С. Хәким, Н. Арсланов кебек шагыйрьләребез, Г. Исхакый, М. Әмир, Ф. Хөсни, Г. Ахунов, Х. Сарьян сыман язучыларыбыз, К. Тинчуриндай драматургларыбыз халкыбызның көчле рухлылыгын, сафлыгын, пакьлеген, хөрлеккә омтылышын, хезмәт сөючәнлеген, җырга-моңга һәвәслеген һәм тагын бик күп башка сыйфатларын үзләренең әсәрләрендә чагылдырдылар. Аларның әсәрләрендә сурәтләнгән образлар сезгә әйләнә-тирәдәгеләрне аңларга ярдәм итәрдәй олы мәктәп хезмәтен үтәделәр. Әйе, балалыктан чыгып үсмер булып килгән вакытта кешеләрнең асылын аңларга, аларны сүзләре, кылган гамәлләре ярдәмендә танырга өйрәнү — гаять кирәкле эш. Монда бары тик әдәбият кына шулай үтемле итеп ярдәм күрсәтә ала.

Шул ук вакытта сез халык авыз иҗаты һәм язма әдәбият әсәрләренең жанрларын һәм аларның үзенчәлекләрен аерырга да өйрәндегез. Әсәрләргә анализ ясауның серләренә төшендегез. Боларның һәммәсе сезгә сәнгать әсәрләрен һәм алар ярдәмендә тормышны, яшәешне тагын да нечкәләп танып белергә ярдәм итәләр.

Шулай һәр сыйныф сезгә белем өсти, олы тормышка әзерләнүдә әһәмиятле баскыч булып тора. Алга таба да сезгә уңышлар телибез.

ЭЧТӘЛЕК

Халык зирәклеге, поэтик иҗаты
Татар халык мәкальләре 5
Бәетләр 9
Сөембикә бәете 9
«Сөембикә бәете» турында 16
Язма әдәбият
Каюм Насыйри
Әбүгалисина 18
«Әбүгалисина» повесте турында 37
Габдулла Тукай
Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш 39
«Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш» поэмасы турында 55
Гаяз Исхакый
Кәҗүл читек 64
«Кәҗүл читек» хикәясе турында 75
Дәрдемәнд
Кораб 77
Рәсем 77
«Урысча күп сүзең, азы татарча...» 77
«Куанды ил, канат какты мәләкләр...» 78
«Җәй үтте...» 78
Видагъ 78
Дәрдемәнд шигырьләре турында 79
Кәрим Тинчурин
Мәдрәсәдә беренче көн . . 83
Бүре зәхмәте 89
Кәрим Тинчурин хикәяләре турында 93
Һади Такташ
Шагыйрь иҗатының үзенчәлеге 98
«Мокамай» әсәре турында 98
Мокамай 102
Мирсәй Әмир
Агыйдел 108
«Агыйдел» повесте турында 124
Сибгат Хәким
Юксыну 128
Әнкәй 131
Клиндерләр эзлим . . . 131
Тегермән стенасындагы язулар 133
Һәйкәл урынында уйланулар 135
Фатих Хөсни
Йөзек кашы 139
«Йөзек кашы» повесте турында 164
Фатих Кәрим
Ант 172
«Сөйләр сүзләр бик күп алар...» 175
Ватаным өчен 175
Кыңгыраулы яшел гармун 178
Әмирхан Еники
Әйтелмәгән васыять . . . 185
Әмирхан Еники иҗатының үзенчәлеге 225
«Әйтелмәгән васыять» хикәясе турында 225
Нури Арсланов
Атлантида 230
Яз 233
Тәлгәш-тәлгәш миләш 234
Халкыма 235
Гариф Ахунов
Артышлы тау буенда . . 241
«Артышлы тау буенда» повесте турында 252
Хәсән Сарьян
Бер ананың биш улы . . . 256
«Бер ананың биш улы» повесте турында 281

Учебное издание

Хатипов Фарит Миргалимович
Галимуллин Фоат Галимуллович

ЛИТЕРАТУРА

Учебник-хрестоматия по татарской литературе для 7 класса
татарской средней общеобразовательной школы

Издание четвертое, переработанное

Казань. Издательство «Магариф». 2006

На татарском языке

Уку-укыту басмасы

Хатипов Фәрит Миргалимович
Галимуллин Фоат Галимуллович

ӘДӘБИЯТ

Татар урта гомуми белем бирү мәктәбенең
7 нче сыйныфы өчен дәреслек-хрестоматия

Үзгәртелгән дүртенче басма

Редакторы *З. М. Гыйниятова*
Тышлык рәссамы һәм бизәлеш редакторы *Р. А. Сәйфуллина*
Рәссамы *И. М. Воробьев*
Техник редакторы һәм компьютерда биткә салучы *Л. И. Матвеева*
Рәсемнәрне компьютерда эшкәртүче *Э. Ф. Нурмөхәммәтова*
Корректоры *Г. Г. Мөхәммәтҗанова*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 20.07.2006. Форматы $60\times90^{1}/_{16}$.
Офсет кәгазе. «Школьная» гарнитурасы. Офсет басма.
Басма табагы 18,0 + форз. 0,25. Нәшер-хисап табагы 15,58 + форз. 0,39.
Тиражы 14 000 д. Заказ З-502.

«Мәгариф» нәшрияты. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
Тел./факс (843) 292-57-48.
http://magarif.kazan.ru
E-mail: magarif@mail.ru

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы» ААҖ.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.

Татар бәхте өчен мин җан атармын:
Татар бит мин, үзем дә чын татармын.

Габдулла Тукай